ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# Казан утлары

7.2008



## Хикәяләр ярышына йомгак

Укучыларыбызга мәгълүм булганча, "Казан утлары" моннан ике ел элек иң яхшы хикәяләргә ярыш-конкурс игълан иткән иде. Шартлы рәвештә "Яна дәвер кешесе" дип исемләнгән бу конкурсның максаты— хикәянең дәрәҗәсен һәм әдәби-эстетик куәтен арттыру, прозаның бу жанрына каләмдәшләребезнең игътибарын арттыру, туган телебездәге әдәбиятка укучыларны күбрәк җәлеп итү... Конкурска йөзгә якын хикәя килде. Аларның утызлабы—иң яхшы дигәннәре журналда бастыру өчен сайлап алынды.

Конкурска дип җибәрелгән хикәяләрне җентекләп өйрәнгәннән соң, редакция хезмәткәрләре һәм абруйлы язучы-авторлардан торган жиде кешелек жюри түбәндәге нәтиҗәгә килде:

**Беренче бүләк (25 мең сум)—Рифә Рахманның "Сөннәтче әби" хикәясенә;**

**Икенче ике бүләк (15әр мең сум)—Рәмзия Габделхакованың "Китмә!!!" һәм Радик Фәизовның "Ат карагы" хикәяләренә;**

**Өченче өч бүләк (10ар мең сум)—Марат Әмирханның "Убыр уты", Халисә Ширмәннең "Мәхәббәтнең соңгы көне", Роза Мулланурованың "Өрәңге өрәге" хикәяләренә.**

Жюри шулай ук **Ркаил Зәйдулланың** "Кыз-хатын", **Мәгъсүм Хуҗинның** "Ипи. Колын. Без.", **Әхәт Гаффарның** "Коелы өй", **Илсөяр Иксанованың** "Житкән кыз", **Фәрит Яхинның** "Чишелмәс төен" хикәяләрен кызыксындыру бүләкләренә лаек дип тапты.

"Казан утлары" редакциясе җиңүчеләрне котлый һәм хикәяләр ярышында катнашкан барлык авторларга рәхмәт белдерә, каләмдәшләребезнең киләчәктә дә (алга таба да ярышлар булыр!) әдәбиятыбызның һәр жанрына да игътибарлы булып, талантлы әсәрләр язуларын, журнал һәм укучылар белән ныклы элемтәдә торуларын теләп кала.

**Казан утлары**
**Qazan utları**

2008

# 7
**(1029)**

*Гамәлгә куючы:*
*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир—292-38-60.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—541-38-77.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.*
*Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.*
**Факс**—*(843) 541-38-77.*
**E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Рим ИДИЯТУЛЛИН. Бәгырьләрне өзә бүз тургай... *Шигырьләр.* 5
Марат ӘМИРХАНОВ. Үрбәт Ханәкә гыйшкы. *Роман.* 10
Рәсимә ГАРИФУЛЛИНА. Кем көчлерәк? *Поэма-баллада.* 36
Айдар ХӘЛИМ. Хунвейбин. *Роман-эпопея.* 39
Ирек КИНЬЯБУЛАТОВ. Гомер. *Шигырьләр.* 87
Зәки ЗӘЙНУЛЛИН. Кави Нәҗми дигән язучы... *Роман.* 91

ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҮРНӘКЛӘРЕ

Лена ШАГЫЙРЬҖАН. Шигърият галәмендәге дәрвиш. 115
Райнер МАРИЯ РИЛЬКЕ. Шигырьләр. 118

ПУБЛИЦИСТИКА

Һәр нәрсәнең иясе бар... *(Шагыйрь Разил ВӘЛИЕВНЕҢ рәссам Әхсән ФӘТХЕТДИНОВ белән әңгәмәсе).* 121

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Ил йөрәгенә яза ул. 127
Рашат НИЗАМИ. Аучы. Шагыйрь. Гуманист. 139

ТАРИХ

Фәридә ГАФФАРОВА. Садри Максуди Арсал. 143

ФӘН

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. 148
"Татар энциклопедиясе" битләреннән. 153

СӘНГАТЬ

Кадим ҖӘМИТЕВ. Кайттым герман жиреннән. *Скульптор язмалары.* 158

КЫЗЫКЛЫ ДӨНЬЯ

Ким ШАКИРОВ. Курку. 169

МАРС ШАБАЕВНЫҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ

Камил КӘРИМОВ. Үҗәт мөхәррир. 182

Берлекнең яңа әгъзалары 181
"Казан утлары" архивыннан 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан 188

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": роман М. АМИРХАНОВА "Любовь Урбат-ханака"; роман-эпопея А. ХАЛИМА "Хунвейбин" (продолжение); роман З. ЗАЙНУЛЛИНА "Писатель Кави Наджми...", стихи Р. ИДИЯТУЛЛИНА, поэма-баллада Р. ГАРИФУЛЛИНОЙ "Кто сильнее?"; стихи И. КИНЬЯБУЛАТОВА.
"Образцы мировой литературы": стихи Райнер МАРИЯ РИЛЬКЕ (с предисл. Л. ШАГИРЬЗЯН).
"Публицистика": беседа поэта Р. ВАЛЕЕВА с художником А. ФАТХУТДИНОВЫМ.
"Литературная критика": статья Д. ЗАГИДУЛЛИНОЙ о творчестве писателя-критика Т. Галиуллина; Р. НИЗАМИ о творчестве поэта Ш. Гаделши.
"История": Ф. ГАФФАРОВА. "Садри Максуди Арсал".
"Наука": Ф. ГАРИПОВА. "История наших деревень" (продолжение).
Страницы из "Татарской энциклопедии".
"Искусство": автобиографический рассказ К. ЗАМИТОВА.
"В мире интересного" К. ШАКИРОВ. "Страх".
"К 75-летию М. Шабаева": статья К. КАРИМОВА.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: "Вечный Кабан, тысячелетняя Казань...";
писатель Амир КАМАЛИЕВ.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

"Prose and poetry": novel by M. AMIRHANOV "Urbat Han's love";
novel-epopee by A. HALIM "Hunveybin" (continuation); novel by Z. ZAYNULLIN "Writer Kavi Najmi...", verses by R. IDIYATULLIN, poem-ballad by R. GARUFULLINA "Who is stronger?"; verses by I. KINYABULATOVA.
"World literature samples": verses by Rayner MARIA RILKE (with foreword by L. SHAGIRZYAN).
"Publicism": conversation of poet R. VALEEV with artist A. FATHUTDINOV.
"Literary criticism": article by D. ZAGIDULLINA about creativity of writer-critic T.Galiullin; R. NIZAMI about creativity of poet S.Gadelshi.
"History": F.GAFAROVA. "Sadri Maksudi Arsal".
"Science": F. GARIPOVA "History of our villages" (continuation).
Pages from "Tatar encyclopedia".
"Art": autobiographical story by K. ZAMITOV.
"In world of wonders" K. SHAKIROV. "Fear".
"To 75th anniversary of M. Shabaev": article by K. KARIMOV.
From photoarchive of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: "Eternal Kaban, thousand-year Kazan...";
writer Amir KAMALIEV.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 25.06.2008 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Т–755 Тираж 5182.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2008 ел.



Рим
Идиятуллин

## БӘГЫРЬЛӘРНЕ ӨЗӘ БҮЗ ТУРГАЙ...

### Карабодай

*«Авырыйм, Ватан ризыкларын ашыйсым килә».*
*Гаяз Исхакыйның, вафаты елында, Финляндиядә яшәүче*
*Халидә ханым Вафага язган хатыннан.*

**Кояш кысыр кышын... Кай төннәрдә**
**Тәрәзәм каршындагы ярымай**
**Гаҗизләнеп карап торган була,—**
**Белмим танып, белмим танымай.**

**Саташулы төнем... Чулпан йолдыз**
**Уянганчы төрек күгендә**
**Кунмый йокы; сыңар яшь бөртеге**
**Ачыта да тора күземне...**

**И ашыйсым килә карабодай!—**
**Әллә тамак, әллә җан даулай;**
**Ни гаҗәп: капкасы ачык зират**
**Төшләремә керә, шау бер ай.**

**Дәвамы да хәтер очында ук:**
**Бал кортлары безләр тын тугай,**
**Бер карышта урман... Баш түбәмдә**
**Бәгырьләрне өзә бүз тургай...**

**Халәтемә карап хәятыма**
**Разый булдым ошбу килештән;**
**Тәкъдиремдер: туган тупрак илә**
**Дөньялыкта соң кат күрешмәм...**

**Галәмәти картлык: илемезнең**
**Исләренә мин дә бик тансык;**
**Төшләремнән коткар,—карабодай**
**Күңдерсәнә, туташ, бер янчык!..**

Рим ИДИЯТУЛЛИН (1940) *– шагыйрь; "Хәерле иртә", "Хәерле көн", "Хәерле кич" исемле китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Уфада яши.*

## Кыргыйлык хакында

1

Кыргый дала... Кыргый кабилә...
Кыргый кошлар... Кыргый җанварлар...—
Бу тәгъбирне кайдан тапканнар,
Нигә аны сезгә такканнар?!—
Җандашларга яла якканнар.

И җәбер сүз, ертык йөрәкне
Утлы энә белән тегәсең;
Сандугачым!—ник син бәндәгә
Кыргый моңнарыңны түгәсең?!—
Күч тә кит син аулак урманга!

2

...Кылган баскан кыргый далада
Җиргә чүккән ятим курганнар;
Кай дәвердә кайсы бабалар
Җил күзендә кирмән корганнар?—
Шәҗәрәләр аусын хәтергә!

Алдалыйсыз, ахры, дастаннар!—
Шушы кипшек сөяк-санакмы
Безнең кебек шашып сөйгәннәр?
«Гариб[1], булды гыйшкым гөл кеби,
Кой яшь, сулаганлар[2]!» дигәннәр,—
Чәрдәкләнгән кабер ташында.

Алдаламый, ахры, дастаннар!—
Үлеп сөйгәннәр ич Зөһрәләр,—
Энҗе хисен, саклап ят күздән,
Яулык очларына төргәннәр,—
Бүгеннәргә[3] гыйбрәт икәннәр!

(Кара урмандамы, әлерәк[4],
Очратканнар кыргый кабилә,
Шул «вәхшиләр» шәрә килеш тә
Фәхешлекне белми, имеш тә...
Без аларны уздык бу «эштә»).

Кеше—залим, җанлы-җансызны
Кол итәргә әзер, гамәлдә
Кыргый дияр җәйге кырауны,
Зыян-зәүрәт салса түтәлгә...

Разыйсыңмы, Ходай, Адәмгә?!.

3

P.S. Тукта! Көтү таптамаган җирдән
Баллы җиләк өзеп кабыйм, бул
Сабыр!.
...Җырламадым хорда, кайтавазсыз

---

1 Гариб—юлчы, мосафир
2 Сулаганлар—хәзерге язылышта: сулаганнар
3 Бүгеннәргә—бүгенгеләргә
4 Әлерәк—яңарак

Кырда моңым чәчтем,—кыргый бер
Шагыйрь.

## Кайту

1

Елга иде монда кайчандыр...
Картлар яше кебек саркыган;
Ә җәйләрен—буа... Истә әле:
«Батам!..» диеп ярдәм чакырган
Чакларым.

Без—малайлар—атлар йөздердек,
Төн җиткәчтен, кайтып басудан...
Инеш—ташмас!—елак җанымны
Сөзәк ярга басып ник сыгам?!.

...Анда тау бар иде шикелле...

Калды бары ачы юаныч:
«Син генәме?—дөнья үзгәрде!»
Бәхеткәдер, Ходай карт көндә
Күрер-күрмәс итә күзләрне,—
Якты сурәт җанда калсынга...

2

Как агачны күреп, дертләп киттем,
Өтте карашны:
Үр өстендә котны очырырлык
Шәрә карачкы;
Әйтте улчак Әнкәй: «Яшен суккан
Ялгыз агачны...»

Хәлсез Әнкәм тарта мине тауга,
Кулдан өстерәп,
И шурлим мин—бала, и карышам,
Аяклар терәп.—
Күпме еллар узган, күз алдымда
Һаман шул сурәт.

Кайттым. Таулар сөзәк, дөньялар вак,
Котәм ахырны;
...Әнкәм!—боексың, җил кискәнгәме
Кабер ташыңны?
Мин дә моңсумын: яшен сугар күк
Ялгыз башымны...

3

Тимерлектән дивар гына калган;
Башка сыйдырмаслык замана:
Без көлешеп җиләк җыйган төштә
Тимер эзли моңсу бер бала.

Туң тимердәй каткан күңелләрне
Чүкисе иде, салып сандалга!
...Кеше иканебез искә төшәр,—
Улап йөрсен бүре далада!

4

Ташландык йорт тиз танылa:
Тимгелле тәрәзләре,—
Тилмерепләр карап торган
Үксез сабый күзләре.

Ак әбинең алма белән
Сыйлаганы исемдә...
Бурга әйбер калмагандыр,—
Йозак юк ишегендә.

Малай чак исе килә күк
Күгәреп беткән мүктән;
Чыршы сагызы кап-кара
Кайгы төседәй кипкән.

Ярык бүрәнә эченнән
Күзәтә кебек кемдер;
Әрвахлар җаны булсаң, әй,
Саулардан сәлам күндер!

Кирәкмәс булды микәнни
Рамдагы соры фото?!.
Кем? Танымыйм! Карашлары
Бәгырь төбенә бата.

Картайган кадак матчада.—
И тирбәлгәндер бишек!
Шыңшыр да кем, фотосурәт
Бәү итәр кебек, төшеп...

Ишек үрендә үрмәкүч,
Ризыгы юк, кымшанмый;
...Оран сала тышта бала,
Уят дөньяны, сабый!..

5

Тамчы йолдыз, бөрчек болыты да
Карендәшем иде кайчандыр;
Ул чактагы күкләр каралгандыр,
Ул чактагы йолдыз—тузандыр.

Танийсызмы мине, таз малайга
Чәч үстереп яуган болытлар?!
Авыл үлсә, шагыйрьләр дә бетсә,
Кемнәр сезгә җыру багышлар!

...Ява яңгыр. Телләремә тигән
Тамчысында тимер тәме бар.
И-и-их!
Эт кимергән сөяк булачак ул
Шагыйрьләре тумас дәверләр...

6

...Зәйнәп апа, урак урган кебек,
Тирләп-пешеп изә камырны:
—Без дә китеп барсак, ипи тәмен
Тояр буын, энем, калырмы?!

Авылда газ. Аның исән миче
Кызлар бите кебек акшарлы:
—Ялгызым бит. Ничек сарыф итим
Үлемтеккә куйган акчамны!

Хәләл җефтен явыз сугыш йоткан,
Ике сабый киткән ачлыктан.
—Яшь ипине өлгертәлмәм сиңа,
Көлчә коеп бирим, ашыксаң.

...Антей[5] булган. Ул җиңелмәс булган,
Җиргә тигән булса тәпие.
—Җирләргә кайт! Кыстыр уң учыма
Бер кыерчык арыш ипие!..

[5] Антей—грек мифларындагы пәһлеван. Аягы җирдә булса,аны беркем җиңә алмаган.

7

Таң туа.
Йолдызлар да берәм-берәм үлә;
Ай авышкан:
Зөһрә сылуның
Мөлдерәмә суы чайпала да
Үләнгә чык булып түгелә...

...Без искердек, күкләр искермәгән;
Иртәләрнең илаһ сурәтен
Җанда калган тере сүзгә манып
Яңартырга сондыр, күрәсең.

Күңел—сукыр, хисләр чукрак хәзер,
Вакытлар да безгә битараф;
Кем мин?!—
Җир-Күк матурлыгын урлап,
Таш калага качкан бер карак...
Кичер, туган туфрак!

8

Туң мәктәптә серле әлепбине
Төшендергән иде ул безгә;
Кучтәнәчем—кәнфит. Озаклап күз
Тегеп торды ялтыр кәгазьгә.

Уралса да абзар тирәсендә,
Абыз кеше!—корды фәлсәфә:
—Зарлы шагыйрь ярлы була. Рәхмәт!
Эчен белмим, тышы ничава.

Зарлы гавам да бит ярлы була;
Ә син беләсеңме нилектән?—
Чүп эзли ул алтын арасыннан,
Алтын эзләр җирдә чүплектән.

Хәзер бәндә хәтта ут күршегә
Сәлам бирми, ягъни мәсәлән;
Йөзе—күркәм, эче—мәрхүмәмнең
Бирнә мендәре кук сусәргән.

Ишеттеңме, арьяк Хәдичәнең
Тавыгы бар, ике кикрикле;
Канатлы эт, башсыз адәмнәр дә
Тумас диеп әйтү икеле.

Аерылды адәм җирдән, ахры
Җирнең тарту көче кимеде;
Сөю-гыйшык шыр ялангач калды,
Элек заман хәйран сер иде.

Син әйт менә, базар дөньясының
Булырмы бер рәте-чираты?
Юксылларны якла, зарлы шагыйрь! —
Дип хушлашты авыл Сократы[8]...

[8] Сократ – борынгы грек философы.

Марат
Әмирханов

# ҮРБӘТ ХАНӘКӘ ГЫЙШКЫ[1]

РОМАН

***

Василий быел иртә җәйдән үк гаиләсе, даирәсе белән Чыпчык тавы атамасы белән даны чыккан утарына күченеп килде. Авыл тормышының тынычлыгы, иркенлеге ошый аңа. Әмма олуг кенәзне җәйге манзара гына җәлеп итми иде. Күптән түгел, аның аюлар белән мавыгуына яңасы өстәлде. Ул хәзер ау этләре асрый башлады. Монда иң яраткан маэмайлары яши. Әлегә кадәр Рәсәйдә ауга эт белән чыкмыйлар иде. Бу яңалыкны ауропалыларга ияреп, Василий кертеп җибәрде. Аннан күрмәкче, башка боярлар тартылды. Аюларга бераз кысылырга туры килде.

Василий бүген дә кичкә кадәр этләре янында булашты. Бурзайлары янында кайнашу аңа зур канәгатьлек китерә иде. Шуңа күрә табын вакыты җиткәнен сизми дә калды. Хатыны бөек княгиня Соломония аш-су мәсьәләсендә үтә дә нәзберек зат. Һәркемнән этикет кагыйдәләрен төгәл үтәүне таләп итә. Нигъмәтләр һәрвакыт мулдан. Шуның белән бергә, көннеке көнгә туры килми, төрләндереп кенә торалар. Олуг кенәз өчен бер генә даими ризык бар. Ул да булса—кыздырылган аккош. Аны махсус ашчы оста хәзерли. Аккош ите матурлык, гайрәт вә дәрт чыганагы, имеш.

Соломония ымсындыргыч буй-сынлы, мамык иренле чибәр хатын. Кара чәчле, кара күзле. Толымнары озын. Ул аларны әле калку күкрәге буйлап төшерә, әле арка ягыннан биленнән түбәнгә шудыра. Кәс-кәс атлап киткән чакларында ирексездән күзләр шунда юнәлә.

Җир янгырдан туймас, бәгъзе хатын ирдән туймас, дигән әйтемне, гүя Соломониягә багышлап чыгарганнар. Нәфесенең башы һич ябылып тормый. Василий хатынын шаяртып, “Ак пәри”, дип йөртә.

Балага тиешле бөтен иркәләү-сөешүләрен алар бер-берсенә сарыф итәләр. Чөнки никахлашуларына унөч ел үтеп китте инде, ә гүзәлкәй һаман көмәнгә узмый да узмый. Им-томнарның да, гыйбадәт-догаларның да, дару-төнәтмәләрнең дә файдасы тими. Василий (ул гынамы, бөтен Рәсәй!) эченнән генә варисы булмаганга бик көя. Туганнары Симеон белән Димитрийны, сакаллары билләренә җитсә дә, башлы-күзле итәргә ашыкмый. Уллары туып, тәхетне бүлешергә туры килмәгәе дип шикләнә.

Василийның үз никахы да алдан тәгаенләгәнчә булмады. Атасы Иван өченче егерме биш яше суккан өлкән улына чит илдән патша кызы алырга ниятләгән иде. Бу хакта Дания короле белән сөйләшүләр дә алып барылды.

---

[1] *Ахыры. Башы журналыбызның 4 санында.*

1503 ел буе ике арада илчеләр йөреп торды. Тик король, һич көтмәгәндә, кызы Елизаветаны Швед курфюрсты Бранденбурскийга биреп куйды.

Иванның хәле авырайган чак иде. Шуңа күрә бу изге эшне ашыктыруны мәгъкуль санады. Юрий Малый дигән якын боярының кызын ярәшмәкче итте. Инде Василий тәртәгә типте, грек кызына күнеле ятмавын белдерде. Иван улының теләгенә каршы килмәде. Алай гынамы, мең биш йөз дәрәҗәле Рәсәй кәләшләре арасыннан үзенә охшаганын сайлап алырга рөхсәтен бирде.

Василий нәсел-ыруы татар морзасы Чита токымына барып тоташкан Юрий Сабуров атлы гади түрәнең гүзәл кызы Соломонияне сайлады (үзе патшалык итә башлагач кына ул бабасын бояр дәрәҗәсенә күтәрде).

—Василий Иванович, бурзайларыңны миннән өстенрәк күрәсең син,—диде патшабикә,—хәтерлисеңме, өстеңнән кош та очырмам дигән идең...

—Дәгъваләрең урынсыз, күгәрченкәем, син һәрвакыт йөрәк түрендә,—дип, Василий бичәсенең бит очыннан үбеп алды.

Олуг кенәзне трапеза вакытында борчу тыела. Тик шулай да, аеруча кичектергесез эшләр килеп чыкканда, әлеге кагыйдәне урап узарга да ярый. Бу нәкъ шундый очрак иде, күрәсең. Эшләр башкаручы дьяк Василий янына килеп басты.

—Ни бар?—дип сорады олуг кенәз канәгатьсез генә.

—Казан-йорттан илчеләр килгән, бик мөһим хәбәр алып килгәннәр. Кайда һәм кайчан кабул итәсең?—дип сорады дьяк.

—Монда! Бүген үк!—диде Василий.

Казанлыларны олуг кенәз эш бүлмәсендә каршы алды. Гадәти сәламләүләр, бүләкләрдән соң Шаһ-Хөсәен ана Мөхәммәдәмин ханның сырхавы һәм шул сәбәпле тәхеттән ваз кичәргә карар итүен җиткерде.

—Хан үз урынында Габделләтыйф ханны күрергә тели һәм бу аның бердәнбер шарты,—диде илче.

Василий өнен югалтты. Беренчедән, бу адәм ышанмастай хәбәр иде. Мондый хәбәрне дөрес булса да сөйләргә ярамый. Икенчедән, әлегә Мөхәммәдәминнең тәхеттән китүе мөнәсәбәтләрендә килеп чыгачак үзгәрешләрне колачларлык хәлдә түгел иде аның акылы.

—Сәед, бик кайгылы хәбәр алып килгәнсең. Туганым Мөхәммәдәминнең сырхавы минем өчен дә зур бәхетсезлек. Тик, кем әйтмешли, солы үз урынында, печән үз урынында калсын әле, аларны буташтырмыйк, бахбаебыз тубырлап китмәсен,—диде, ниһаять, киная беләнрәк.

—Мин сөйләшүләрне тизләтү мәнфәгатьләрен генә күздә тотам,—диде Шаһ-Хөсәен.

—Ашыгу борча тотканда гына ярый, сәед, кабаланмыйча гына асылына төшик,—дип, Василий кулына бокалын алды.

Шаһ-Хөсәен олуг кенәзгә карап торды. Василий шактый үзгәргән иде. Гәүдәсе тулыланыбрак та киткән, ахры. Чын ир-ат булып җитешкән. Сакал-мыегы да килешле. Ул хәзер нәкъ атасы рәвешен алган иде. Тавышына кадәр Иван патшаны хәтерләтә.

Мондый чакта кулга бокал алу, гадәттә, сөйләшүләрнең тәмамлануына ишарә итә. Ләкин әле сөйләшү башланмады да ич. Шуңа күрә Шаһ-Хөсәен сүзен Василийның үзе шикелле киная кабыгына төрде.

—Олуг кенәз, чаптарыбыз йончыган, нәрсә ашатабыз соң, солы бирәбезме, печәнме?—дип сорады.

—Син безнең кадерле кунак, сәед,—диде Василий дусларча елмаеп,—бер өч-дүрт көн рәхәтләнеп ял итегез, җаныгыз ни тели, шул булыр. Ул арада без монда киңәшеп, уртак бер фикергә килербез. Саламмы, печәнме,

солымы—барысын да түкми-чәчми сезгә житкерербез. Мәсьәлә бик мөһим.

Нәкъ атасы, дип уйлап куйды сәед. Күр, ничек сак кылана, ник бер тәгаен сүз әйтсен.

Шул рәвешле, йомшак кына җәеп, олуг кенәз казанлыларны урманга “сөрде”. Анда ял итү өчен барысы да бар иде. Телисеңме-теләмисеңме, рәхим итеп күңел ач, кәеф-сафа кор. Күңел дә ачтылар, кәеф-сафа да кордылар. Василий да сүзендә торды. Нәкъ өч көннән соң Кремльгә чакыртып алды.

Казан-йорт мәскәүлеләр өчен кыргый ат кебек иде. Һич йөгәннәтми, болын тутырып тик чабып йөрүен белә. Солыга да, печәнгә дә, хәтта башакка да алданырга теләми.

Әйе, күп урыс патшаларының төн йокыларын качырган кала ул шәһри Казан. Һәр патша үзенең алмашына, бу күндәмсез татар оясын буйсындыр, дип васыять әйтеп калдырган. Иван өченче дә Василийдан ант эчерткән иде. Ләкин тәүге һөҗүмендә үк хурлыклы рәвештә качып китәргә мәҗбүр ителде. Аның күкрәгенә кадалган татар хәнҗәреннән әле булса кан саркып тора.

Кыргый атны нукталарга тагын бер форсат чыкты менә.

—Без сиңа бик рәхмәтле, олуг кенәз, ял искиткеч күңелле булды,—дип билен бөкте Шаһ-Хөсәен,—инде атларны ашатыр вакыт та житкәндер, шәт.

—Җариләр зарлана ди анда, безгә күз дә төшермәделәр, дип әйтәләр, ди.

Василий әйләнә-тирәдәгеләргә күз кысты.

—Без намаз картлары, олуг кенәз,—диде сәед,—гөнаһ җыюдан бик куркабыз.

—Алайса шул,—диде Василий житди төс алып,—безнең шартлар эшләнде, сөйләшү алып баручы илчеләр билгеләнде. Алар барысын да бәйнә-бәйнә төшендерерләр. Ике-өч көннән янә очрашырбыз. Аллаһы тәгалә мәрхәмәтеннән ташламас, боерган булса.

Олуг кенәз вәкаләтле илче итеп мәртәбәле өч дәүләт эшлеклесен билгеләгән иде. Тучков, Карпов дигәннәре белән Шаһ-Хөсәеннең беренче очрашуы. Чөнки яшьләр әле. Ә менә Иван Телешев күптәнге танышы. Мөхәммәдәминне тәхеткә утыртырга килүчеләр арасында да бар иде. Бик астыртын кеше. Шома. Егерме дүртенче июнь зилзиләсендә дә җил-яңгыр тигертмәде үзенә. Кляпикны таш капчыкка яшерделәр, ә Телешев исән-имин Мәскәүгә элдертте.

Сөйләшү дигәннәре исә эт кура төбен чылатканчы төгәлләнде. Юка иреннәрен бөрештереп, Телешев авызыннан бер-ике генә җөмлә сытып чыгарды. Чынлыкта бу ультиматум иде.

—Казан тәхетенә Мәскәү белән килештермичә хан утыртмау турында ант ярлыгы языгыз,—диде,—олуг кенәз фатихасын бирүгә, барыбыз бергә Казанга юл тотачакбыз. Мөхәммәдәмин хан ярлыкка мөһерен сугып, ант эчәргә тиеш. Корылтайның да ризалыгын алу зарур.

—Тәхеткә Габделлатыйф ханны утырту шартын исегездән чыгармагыз,—дип кисәтте сәед.

—Анысына да чират житәр, әүвәл төп мәсьәләне хәл итү зарур,—диде Телешев. Ул күз очы белән генә елмайгандай итеп, башын иде.

Солых вакытында да күпме изаландылар. Бер ел буе Казан белән Мәскәү арасына тузан кундырмадылар. Әле монысы ярамый, әле тегесен килештерми.

Олуг кенәз янә шул юлны сайлады. Шаһ-Хөсәен бәхәскә кереп тормады.

Мәскәү әлеге мәсьәләне иң мөһиме дип санаса да, Казан өчен тәхет иясе беренче урында тора иде. Монда инде икеле-микеле була алмый. Җә Габделләтыйф дилбегәне үз кулына тота, җә Мөхәммәдәмин сүзен кире ала.

Мөхәммәдәмин сәедкә дусты Челядинны күреп сөйләшергә кушкан иде. "Сүзе үтә, абруе зур, ярдәм итми калмас",—дигән иде. Чөнки икесе дә белә, Габделләтыйфны тәхеткә утырту өчен аны иң элек тоткынлыктан азат итәргә кирәк әле.

Челядин сәедне үзе эзләп тапты. Мөхәммәдәминнең сырхавы турындагы хәбәр бөтен Мәскәүгә таралып өлгергән икән инде.

—Что, Аминка, серьезно болен что-ли?—дип, бусагадан атлап кerәкерешкә сорауларын яудыра башлады.

Шаһ-Хөсәен хәлне бик вәземләп аңлатты. Иван башын иеп озак кына сүзсез утырды да:

—Мина бер касә шәраб бирегез,—диде.

—Без аны үгез дип йөртә идек...

—Бәлки әле йөреп тә китәр,—диде сәед,—тәхеттән ваз кичүгә килгәндә исә моңа ил каршында, халкы каршында зур җаваплылык хисе тою этәргәндер дип беләм.

—Ашыкмыймы, кабаланмыймы—менә нәрсә борчый мине,—диде Иван,—үкенергә туры килмәгәе...

—Ханның карары катгый.

Габделләтыйф исемен ишетүгә, Челядинның тар, очлы маңгаена сырлар ятты.

—Турысын әйтим, бу хан белән һич тә исememне буясым килми, сәед, диде.—Габделләтыйф Мәскәү өчен улай шәхес түгел.

—Бу Мөхәммәдәмин хан үтенече кенәз...

—Беләм. Казанда булганда сөйләшкән идек инде бу хакта. Хәтта ризалыгымны да биргән идем. Ләкин моңа минем теш кенә үтми. Тырышып карармын, билгеле,—диде Челядин теләр-теләмәс кенә. Шаһ-Хөсәен аның бармакка бармак та сукмаячагын шундук аңлап алды.

—Мин Аминкага елан агуыннан ясалган төнәтмә җибәрәм, мең авырудан дәва,—дип, сүзне икенчегә борып җибәрде кенәз,—күрерсең дә торырсың, яна ханның хаҗәте дә чыкмас.

***

Габделләтыйф көтүдән аерылып калган ялгыз куй хәлендә иде. Ә көтү ташлаган малны бүре алыр, ил ташлаган ирне гүр алыр, ди. Дөрес, көтүен дә, илен дә үз ирeге белән ташламады. Гомумән, җырсыз сандугач инде ул, ватансыз бәндә. Казанда туса да, аны ватаным дип авыз тутырып әйтә алмый. Чөнки атасы вафатыннан соң, анасы Нурсолтан, Кырым ханына кияүгә чыгу сәбәпле, улын үзе белән алып китте. Кырымны да ватаным диярга теле әйләнми. Кырым ата-бабасы җире түгел. Аның иң күп гомере Мәскәүдә үтте. Тик монда ул—тоткын. Ватан исә ирекле була.

Габделләтыйф үзенең ясины укылган дип саный иде. Башкалар да барлыгын оныттылар шикелле. Килүче-китүче дә, хәл белүче дә юк. Шуңа күрә туганы Ходайколның зинданга килүе аяз көндәге яшен шикеллерәк тәэсир итте. Беренчедән, аларның күрешмәгәненә дә дистә елдан артык иде. Икенчедән...

Икенчедән, Ходайкол үзе дә Ходайкол түгел бит инде. 1505 елдан Петр атамышлы. Христиан. Бу адымы белән ул ханлыктан баш тартты. Шул бәрабәргә олуг кенәз ана сеңлесе Евдокияне никахлады, үз гаиләсенә кертте. Хәләле Петр Ибрагимовичка ике кыз бала алып кайтты. Аларны

бик дәрәҗәле кенәз улларына ярәшеп тә куйдылар. Кыскасы, Ходайкол үзен бәхетле кешеләрдән саный иде. Габделләтыйфның Василийга сырт йонын кабартуын аңламый, аңларга да теләми иде.

Габделләтыйф агасын башта танымады. Ул затлы киемнән иде. Кафтанының билбавына кадәр асыл ташлар белән бизәлгән. Аягында чигүле сафьян итек.

—Слава богу, ты в добром здравии,—дип сөйләнә-сөйләнә кунак чукыну хәрәкәтләре ясап алды.—Вот и свидились брат. Я очень рад, дайте-ка я тебя поцелую...

Габделләтыйф читкә тайпылды.

—Не узнаешь что-ли, я же твой кровный брат, Ходайкол, то-есть Петр Ибрагимович...

—Син ата-анаңнан, динеңнән, телеңнән ваз кичкән сатлык җан, якын килмә,—диде Габделләтыйф ачу белән.

—Осторожно, я из царьской семьи...

Аларның сүзләре ялганмады. Ходайкол буш кул белән кайтып китте. Хәер, буш кул белән түгел. Шул ук көнне бүлмәдә православиегә кагылышлы образлар пәйда булды. Габделләтыйф юк чакта кертеп куйганнар. Ул аларны үз куллары белән ботарлап ташлады. Агасы аңа башка бүләк тә калдырган икән. Сакчы ниндидер язу кертеп бирде. Бу—Ходайколның чукынган вакытта олуг кенәз Василий Ивановичка биргән ярлыгының күчермәсе. Габделләтыйф аны кызыксынып укып чыкты. Менә ул.

"Мин, шаһзадә Петр, Ибраһим хан улгы, үземнең туганым Илһам илә, бөтен Русиянең олуг кенәзе булган Иван Васильевич кулына төшкән идек. Хәзергесендә исә минем падишаһым олуг кенәз Василий Иванович мине тоткынлыктан җибәрделәр. Мин үземнең падишаһым, атам, бөтен Русиянең митрополиты булган Семенга багынып, аның багышлавын үтендем. Һәм дә мин үземнең падишаһым олуг кенәз Василий Ивановичка багынып, аның мине чукындырырга кушуын үтенгән идем. Минем падишаһым, бөтен Русиянең олуг кенәзе Василий Иванович митрополит Семенга мине чукындырырга кушты. Семен һәм мәрхәмәт итеп, мине чукындырды. Мин, шаһзадә Петр, шушы хак булган православный диндә бик нык булып, ахыр гомеремәчә аңардан күчмәскә, үземнең падишаһым, бөтен Русиянең олуг кенәзе булган Василий Ивановичка һәм дә аның балаларына хезмәт итеп, аларга яхшылык теләргә, шулай ук аларның җирләренә һәр эштә тугры булып, һичбер начарлык теләмәскә, кылмаска, уйламаска, һичкем белән ул хакта хәбәрләшмәскә, падишаһлык зарарына тырышучыларның һичбере белән дуслашмаска, падишаһлыкка яманлык теләүчеләрнең һичберсенә, Казанга, Литвага һичбер вакыт үземнең падишаһым олуг кенәз Василийны ташлап, ахыр гомеремәчә, китмәскә, үземнең падишаһым хакында христианнан, татардан һәм Литва кешесеннән яхшы вә яхуд яман бер хәбәр ишетсәм, шуны турылык белән үземнең падишаһым олуг кенәз Василийга һәм дә аның балаларына һичбер хәйләсез ирештерергә, аны һичбер вакыт яшермәскә, Казан падишаһы булган минем туганым вә яхуд андагы икенче падишаһ, шулай ук Казан кешеләреннән кем дә булса берәү яисә литвалылардан берәү миңа бер кешене ни дә булса бер нәрсә белән вә яхуд берәүне ярлык белән җибәрсәләр, миңа шул кешене тотып, үзенең ярлыгы белән сез падишаһым олуг кенәзгә һәм дә аның балаларына тапшырырга, кем дә булса миңа бер сүз әйтсә, шуны үземнең падишаһым олуг кенәз Василийга һәм дә аның балаларына тугрылык белән сөйләргә, һичбер эшне алардан яшермәскә, миңа үземнең падишаһым олуг кенәз Василий һәм дә аның балалары янында һәр эштә олуг кенәз кушканча

булырга, олуг кенәз Василий, шулай ук аның балаларына хезмәт итеп, аларга яхшылык теләргә, җирләренә дә һәр эштә тугры булырга, үземнең падишаһымнан һәм дә аның балаларыннан, шушы ярлыкта язылган нәрсәләрнең барчасыннан ахыр гомеремә чаклы аерылмаска, мина, үлгәнчегә чаклы, хак булган православный диндә бик нык булырга, үземнең падишаһым, бөтен Русиянең олуг кенәзе булган Василий Ивановичка һәм дә аның балаларына хезмәт итеп, һәр эштә шул ярлыкта язылганча эш итәргә сүземне бирәмен. Әгәр дә мин шушы ярлыкта язылганча эш итмәсәм, ул чагында Тәңренең, аның саф булган анасының, шулай ук олуг кәрамәтләр иясе Петр, Алексей митрополитларның, Леонтий, Сергей, Кирилл, Варлаамнарның вә хәзерге митрополит Семеннең миңа үземнең булган чагымда һәм киләчәктә мәрхәмәтләре булмасын! Бу ярлыкка минем атам Семен митрополит үзенең кулын һәм дә белгермәсен (печать) басты. Минем атам Нифонт Суздальский үзенең кулын куйды. 7014 ел, декабрьнең 28 нче көне (дөнья яратылудан) ".

—Һи, адәм актыгы, ләгыйнь,—дип Габделләтыйф ярлыкны ачу беләнерткалап ташлады.—Бу соң мине дә үз артыннан ияртмәкче ич. Кабәхәт.

***

Илчеләр Казанда озак юанмадылар. Чөнки Мөхәммәдәмин хан олуг кенәзнең тәхеткә мөнәсәбәтле шартларын кабул итте, антлы ярлык язды. Василий, үз чиратында, йөкләмәсенә тугры калып, Габделләтыйф ханны тоткынлыктан чыгарырга тиеш иде. Билгеле, ул вәгъдәсендә торачак. Шуның белән бергә, аны Казан тәхетенә утыртмас өчен көчен дә кызганмаячак. Петр Ибраһимовичны да Габделләтыйф янына шул максатны күздә тотып җибәрде. "Бәлки православиегә аударып булыр",—дигән иде. Ул вакытта мәсьәлә бик җиңел хәл ителер иде.

Хуҗасының хәлен күреп торган шамакай аның алдына килеп утырды да, сөеп-яратып, сакалын сыйпаштырырга кереште.

—Мин булсам, мичкәндәге суны аударып ташларга ашыкмас идем,—диде ул күзләрен уйнатып.

—Нинди мичкә ул?—диде Василий аптырабрак.

—Башыңа кибәк тутырганга мин гаепле түгел лә,—диде шамакай.

—Авызыңны үлчәп ач.

—Үлчәсәң дә, үлчәмәсәң дә кибәк кибәк инде ул,—дип шаркылдады шамакай.—Мин сиңа хәзер бер мәзәк сөйлим, шуннан татарлар белән нишләргә кирәген үзең чамаларсың. Урман аланында йөргән үгез янына ач бүре килеп чыккан. Шул бүре әйтте, ди:

—Үгез, мин сине ашыйм!

Үгез моңарга каршы әйтте, ди:

—Бик ашар идең дә, көчең җитмәс шул.

—Алайса нишләргә соң миңа, бик ачыктым бит,—дигән бүре.

—Менә нәрсә,—дигән үгез,—күзең кызарганчы көчәнеп кара. Шул вакытта сиңа мине җиңәрлек көч керер.

Әй, көчәнә, ди, бүре, әй, тырыша, ди. Менә күзем кызара, менә көчем арта дигәндә генә күзләре атылды да чыкты, ди.

—Димәк, мин Мөхәммәдәмингә шундый шартлар куярга тиешмен ки, көчәнә-көчәнә күзләре шартлап чыксын. Шулаймы?

***

Олуг кенәзнең фәрманы белән 1516 елның 12 нче ноябрь көнне Габделләтыйф зинданнан азат ителде. Василий аңа янә ханнар биләмәсе

саналган Каширавы багышлады. Казан тәхетенә утыру өчен юл ачылды. Һәр ике як та үз сүзләрен үтәде. Тик Шаһ-Хөсәенгә Габделләтыйфны күреп сөйләшергә генә мөмкинлек бирмәделәр. Янәсе, рәсми тәкъдим ясау олуг кенәз вазифасы.

Нишләргә? Төрлечә гөманлап карадылар. Ахырда иң дуамал, иң хәвефле дип саналган ысулга тукталу мәгъкуль күрелде.

Кышкы матур көн иде. Дымык. Күк гөмбәзенә челтәрдәй юка өрфия болытлар эленгән. Шул болытлардан иренеп кенә вак-вак кар бөртекләре төшкәли. Карап туймаслык.

Олуг кенәзнең дә йөзе якты иде. Бик дустанә сөйләште.

—Мәскәүдән чыкканчы озатып куярлар, юлыгыз тәгаенләнгән, барысы да унышлы булыр, Мөхәммәдәмин ханга ихлас сәламемне житкерегез,— дип хәерле сәфәр теләп калды.

Илчеләр исә озатучылар китеп, кала төтеннәре күздән югалуга, олы юлдан читкә каерылдылар. Аулак урын. Үтүче-сүтүчеләр дә юк. Атлар шәпле, камчы тигертмиләр. Бара-бара бүрәнә коймалы бер зур гына утарга килеп життеләр. Монда аларны көтәләр иде, кыр сыман зур ишек алдына кереп тә тулдылар.

Эзләрне кар күмеп китте.

Иртәгәсен биек капка янә шыгырдап ачылды. Аннан пар ат жигелгән бизәкле купшы чана һәм өч жайдак чыкты. Алдагысы кырмалы тун кигән, башында очлы бүрек. Биләндә—кылыч. Бик фырт күренә.

Төп кебек калын гәүдәле бу хәрбинең Бозак бахшы икәнен хәтта якыннары да танымас иде. Кием-салымы бер хәл, килеш-килбәте үзгәргән. Ул болай да саргылтлыгы белән урыс кавеменә тартым. Сакал-мыекларын да православичә килештереп төзәткәч, бөтенләй москалга әйләнгән. Ә тел мәсьәләсенә килгәндә, аңа тылмач кирәкми, урысның үзен сатып жибәрер дәрәжәдә белә ул аларның телен.

Шулай да, читтән күзәтеп торучы иң әүвәл чанага игътибар итәр иде, мөгаен. Купшылыгы өчен генә түгел. Купшылыгы да бар, әлбәттә. Бизәкле, чәчәкле-чуклы.

Һәм шул чибәр чананың түрендә ике сәер зат утыра. Икесе дә ап-ак бөркәнгеч ябынган. Күзләр иң әүвәл шуларга ябыша.

—Аллага тапшырдык!—диде бахшы-хәрби.

Атлар жилдәй элдертә, тояк асларыннан кар йомарламнары гына чәчрәп кала. Әнә, олы юлга да чыктылар. Анда исә сыргавыл арты сыргавыл. Алар патшаныкыннан кала, бар экипажларны да жиң эченнән уздыралар. Кырымнарның урыс хәрбиләре киеменнән чик буе шәһәрләрен талап йөрүләре акылга утыртты аларны. Бозак моны бик яхшы белә, шуңа күрә сакчылардан алдан телен тибрәтә башлады. Илче сыйфатында ул болай вакланып та тормас иде дә, аларның юл картасында әлеге юнәлеш каралмаган шул, алар бу юлда качкын.

—И, служивые, трудно в такой мороз торчить на дороге, сам испытал, знаю почем пуд лиха. Могу помочь, специально для вас прихватил,—дип лыгырдарга тотынды. Шешәләр дә китертте, кабымлыклар да. Башта сакчылар бер-берсенә каранып кыяр-кыймас кына тотынганнар иде дә, түземлекләре бик тиз төкәнде. Хәер, эттән сөяк арта ди мени?!

Ә бахшының авызы йомылып тормый, бытырдапмы-бытырдый.

—Каширага озатып барыш менә бу жарияләрне. Күрәсезме, бакча карачкысы шикелле бөркәнеп утырганнар, йөзләрен ачырга ярамый икән мөселманнарның. Берсе—Каширадан хан кәләше, ди. Бик нык сакларга боердылар. Ашыгабыз. Барыбер бер мәзәк сөйләмичә сезнең яннан китәсе килми. Бик ошадыгыз.

—Айда, валяй,—диеште сакчылар,—вакыт тизрәк үтәр ичмасам.

Бозак башта шук кына елмайгандай итте дә, күзләрен ялтыратып, сорау бирде:

—Служивые, менә әйтегез әле, тере мәет буламы?

Тегеләрнең җилкәләре җыерылды.

—Годок, син нидер буташтырасың,—диде арадан берсе.

—Юк, служивые, үз акылымда мин, мәет үле дә, тере дә була.

—Ничек?

—Фаразан, кемсә итәгатьле балалар үстерсә, бакча утыртса, йорт-җир караса, андый адәм халык күнелендә үлгәннән соң да озак яшәр, ди. Ә инде...

—Аңлашылды, годок, бу мәзәгең безнең ишеләргә түгел,—дип бүлде баганадай озын хәрби,—син лутчы җарияләреңнән авыз иттерер идең...

Дәррәү кубып көлделәр: ха-ха-ха...

—Бигайбә, служивые, вакыт тар, другой раз...

Алдагы сыргавылда да аралашу майлаган кебек башланып китте. Карышып тормадылар, хәмерне дә алдылар, мәзәкне дә бүлдермичә тыңладылар. Ул анда башка мәзәк сөйләде.

Имеш, бер адәм итекчедән итекләрен төзәттергән. Алып кайтып кигән икән, аягына су үткән. Итекчегә барган да:

—Төзәтә алмагансың!—дип, тавыш күтәргән.

Итекче әйткән:

—Ашыкма, җирне катырсын әле, аннан соң су да үтмәс,—дигән.

Рәхәтләнеп, эчләрен тота-тота көлделәр. Булды бу, эш пеште, дип уйлады бахшы, инде тайсаң да ярыйдыр. Тик инде кузгалып китәбез генә дигәндә, сак башлыгы юлга киртә салды.

—Телеңне шәп болгатасың анысы,—диде күзләрен чекерәйтеп,—әмма дә ләкин мин синең ул балахон ябынган чәчбиләреңне тикшерергә бурычлымын, йөзләрен ачсыннар, тәртип шуны таләп итә. Имею право!

Бозакның теле аңкавына ябышты. Ләкин моны һич тә сакчыга белгертергә ярамый.

—Таләп шулай икән, рәхим ит служивый, кара. Тик кисәтеп куям: күреп торасың, аларны ике мөселман ялмавызы саклый, чын башкисәрләр. Алар хан кәләше өчен җаннарын бирергә дә әзер. Суеш булачак. Олуг кенәз дә бу гамәлләрегезне хупламас. Чөнки Габделләтыйф аның вассал ханы.

Сак башлыгы бу сүзләрдән аптырап калды. Шуннан файдаланып, бахшы башкаларга сиздерми генә моның учына алтын тәңкә дә салды.

Алтын тәңкә тегенең кесәсенә кереп оялагач кына җиңел сулап куйды.

Ниһаять, Кашира биләмәләренә килеп керделәр. Бер җайлырак җирдә тукталып хәл алырга, үзләрен тәртипкә китерергә кирәк иде. Чанадагы кәләшләргә дә япмаларыннан арынырга вакыт. Аның берсе илчелек башлыгы Шаһ-Хөсәен, икенчесе Шаһ-Йосыф иде.

—Алла саклады, сират күперен исән-имин үттек бит, ходайның рәхмәте,—дип дога кылды сәед.

—Бозак бахшыга мәдхия, аның тапкырлыгына, тәвәккәллегенә исем-акылым китте, сөбханалла,—дип өстәде кече илче.—Япмаларны ачсалар, бөтен кылган гамәлләребез җилгә оча иде...

—Әйе, зур тавыш чыгачак иде,—дип җөпләде сәед туганын.

—Кузгалыйк, җәмәгать, төнен янә сәфәр чыгасы,—диде бахшы.

Габделләтыйф исә илчеләрнең бу мажаралы сәяхәтенә лаеклы бәһасен бирергә ашыкмады. Ул аның максатын да, хәвефен дә аңлап житкермәде, ахры. Үзе ирекә чыкса да, күңеле тоткынлыкта иде бугай әле. Күз

карашы ваемсыз, чырае төмсә. Әйтерсең лә, бер-бер хастасы бар. Дөнья мәшәкатьләреннән ваз кичкән бәндәгәрәк охшап тора.

Шаһ-Хөсәен аның йокымсыраган җанын уятырга теләп булса кирәк, тавышына тантана төсмерләре чыгарып, Каширага килүләренең максатын җиткерде.

—Барча Казан җиренең бөек ханы Мөхәммәдәмин галиҗәнапләре авыру сәбәпле, тәхетен, Габделләтыйф хан, сиңа мирас итә,—диде.—Җавап сүзеңне әйт. Без аны бөртекләп Мөхәммәдәмин ханга җиткерербез.

Габделләтыйф бу хәбәрдән дә кабынып китмәде. Очлы ияген алга сузып, озак кына шул битараф кыяфәттә сүзсез утырды. Мичтә шарт-шорт килеп каен утын яна. Ул әлеге тынлыкка ниндидер төшенкелек өсти иде кебек.

—Агаемның хәле шулай ук өметсез мени?—дип сорады Габделләтыйф, ниһаять, сүрән генә.

—Фалиҗ, аяксыз калды,—диде Шаһ-Хөсәен,—ул тәхеткә синең утыруыңны тели. Олуг Мөхәммәд ыруыннан син бердән-бер варис. Ярлык та җибәрде.

—Корылтай шулай ук ризалыгын бирде,—дип белдерде Шаһ-Йосыф.

—Халык хуплап каршы алачак,—дип өстәде Бозак бахшы.

—Олуг кенәз Василий ни әйтер бит әле?—диде Габделләтыйф бу тәкъдимгә ышанасы килмичәрәк.—Мин бит аның кулында.

—Олуг кенәзнең фатихасын алдык,—дип шатлыгын бүлеште сәед,—Мөхәммәдәмин ханга рәсми ярлыгын алып кайтабыз.

***

Көннәрдән бер көнне сарай әһеле кенәз Петр Ибрагимовичтан хәбәр килеп төште. Патша йомышы белән каядыр бара, имеш, юл уңаенда Каширага да сугылып чыкмакчы икән.

Агасын өнәмәсә дә, кабул итми хәле юк иде Габделләтыйфның. Зур түрәләрне каршы алу, кабул итү, зурлап озатып җибәрү аның ин мөһим бурычларыннан санала.

Каз сугымы вакыты иде. Габделләтыйф каз ите ярата. Шуңа күрә монда аны күпләп асрыйлар. Мәҗлес өчен дә мул итеп каз ризыклары хәзерләргә кушты. Каз—татар ризыгы. Чукынган туганының ярасына тоз сибеп алу да зыян итмәс. Ләббәйкә генә итеп торалар дип уйламасын. Чучка итен өендә ашар.

Петрның энесе Минлетаһир белән бик дустанә яшәделәр алар. Агасыннан аермалы буларак, анысы диненнән китмәде, ләкин балалары өчен бик борчыла иде, минем үлгәнне генә көтәләр, икенче көнне үк чиркәүгә чабачаклар, дип хурлана иде. Агамның кызларыннан үрнәк алалар, дия иде. Чөнки Петрның олы кызы данлыклы кенәз Федор Михайлович Мстиславский белән, икенчесе шундый ук абруйлы кенәзләрдән саналган Василий Васильевич Шуйский белән никахлаштылар. Пычаклары майда йөзә. Дан, дәрәҗә, ихтирам—барысы да бар.

Мәшһүр Ибраһим ханның токымын Мәскәү тәки таркатты бит, туганнар арасына чөй какты. Петрның кызлары туганда ук христиан булып тудылар.

—Бу йортка ходай иминлек, үзегезгә тән тазалыгы, исәнлек-саулык, муллык бирсен,—дип сәламләде кенәз көр тавыш белән.

Мөселман йортында чукынмаса да була иде, билгеле, ләкин зур түрәгә каршы килеп була ди мени? Күңеле рәнҗесә дә, Габделләтыйф түзде. Ә сөйләшүен татарча сөйләште. Ни гаҗәп, Петр үзе дә рәхәтләнеп ана телендә гәпләште, әйтерсең лә, алдан килешеп куйганнар иде. Ходайколлыгы

җинде, күрәсең, ата-ана каны әле дә үзен сиздереп тора булса кирәк.

—Без Ибраһим хан уллары, аслыһи нәслеһи,—дип мактанып та алды.

Аш мәҗлесе бик күңелле үтте. Петр—Ходайкол үзен бик иркен тотты, көлде, шаяртты, мәзәк сүзләр сөйләде. Каз ризыкларын да охшатты, мактый-мактый ашады.

—Каз дигәннән, безнең нәсел-ыруга бәйләнешле бер хикәят тә бар бит,—диде Габделләтыйф,—бик мәгънәле хикәят.

—Ә нишләп мин белмим соң аны?—дип күзләрен шакмакландырды кенәз,—җәле, сөйлә әле.

Габделләтыйф алдындагы кымызын йотып куйды да тасвирларга тотынды.

—Бабабыз Олуг Мөхәммәд патшаның мактанчыграк бер вәзире булган. Җае чыккан саен үзен бик акыллы зат итеп күрсәтергә тырыша икән. Көннәрдән бер көнне йөрергә чыкканнар. Буа янынннан үткәндә тегермәнче карт очраган.

—Әллә мәллә?—дип мөрәҗәгать иткән Олуг Мөхәммәд.

—Кәллә мәллә,—дип җавап кайтарган тегермәнче.

—Әгәр мәгәр?—дип сорый Олуг Мөхәммәд.

—Мәгәр тәгәр,—ди тегермәнче.

—Алты уникегә җитәме?

—Утыз икедән артмый,—ди тегермәнче.

—Каз җибәрәм, йонын йолкырсыңмы?—дип сорый Олуг Мөхәммәд.

—Мамыгын да калдырмам,—ди тегермәнче.

Саубуллашканда Олуг Мөхәммәд әйткән:

—Әлтер-мелтер,—дигән.

—Шалтыр-шолтыр,—дип җаваплаган тегермәнче.

Олуг Мөхәммәд вәзиреннән әлеге әңгәмә турында фикерен сораган. Ләкин тегесе ык-мык килгән, әңгәмәне ни дип шәрехләргә дә белмәгән. Олуг Мөхәммәднең кәефе кырылган.

—Иртәгә иртәнгә чаклы белеп килмәсәң, астырам,—дигән.

Вәзир бик кайгырган. Бер янчык алтын алып, төнлә тегермәнче карт янына килгән, сүзләренең мәгънәсен әйтеп бирүне үтенгән. Тегермәнче йөз алтын сораган.

—Патша миңа: "Әллә мәллә?"—диде. Бу аның сәлам бирүе иде, "Кәллә мәллә",—дип сәлам кайтардым,—дигән.

—Ә "Әгәр мәгәр?"

Тегермәнче яңадан йөз алтын сораган. Вәзир шыгырдый-шыгырдый анысын да түләгәч кенә карт аңлатып биргән:

"Әгәр мәгәр" дигән "Тегермәнең тартамы?"—дип соравы иде. Мин: "Мәгәр тәгәр",—дидем, ягъни суы булса тарта.

Өченче сүзне сораганда да тегермәнче вәзирдән тагын йөз алтын алгач, әйткән: "Өченче сүзнең мәгънәсе шул иде: ул миннән, алты уникегә җитәме—ягъни алты ай эшләгәнең унике ай яшәргә җитәме, дип сорады, мин—утыз икедән артмый, ягъни утыз ике тештән—ашаудан артмый, дидем.

—Ә каз җибәрәм, йолкырсызмы, дигәне? Син: "Мамыгын да калдырмам", дип әйттең.

—Әйе, каз турында да сүз булды. Каз канаты канун язар, ди, бик дәрәҗәле кош ул каз.

—Балта сораганда, шөшле тоттырма әле син, карт,—дип йөзен чыта вәзир,—соравыма җавап бир.

—Хакы йөз алтын.

Вәзир, нихәл итсен, актык акчасын чыгарып бирә.

—Әле дә анламадынмы?—дип сорый тегермәнче.

—Юк,—дип җилкәсен җыерган вәзир.

Тегермәнче көлгән дә әйткән:

—Каз дигәне син үзең буласың инде, алтынын—мамыгың иде. Күреп торасың, мин аны берәм-берәм йолкам...

Петр Ибрагимович тәгамен тәмам иткән иде инде. Майлы иреннәрен тастымал белән корытып алды да, Габделләтыйфка текәлеп бакты. Озак кына сынап карап торганнан соң әйтте:

—Бабабыз Олуг Мөхәммәднең бу хикмәтле казы сиңа да шатлыклы хәбәр алып килде,—диде,—сине Казан тәхете көтә, сәгатен сукты.

Габделләтыйф бу күңелле хәбәрне Петр авызыннан ишетермен дип көтмәгән иде. Бик рәхәт булып китте. Туганнар ич. Кан кардәшләр.

Дөресен генә әйткәндә, өметен өзгән иде инде ул. Шулай булмыйча, Мөхәммәдәминнең тәкъдименә дә бер ел вакыт үтте лабаса. Моңарчы бернинди җан-тын ишетелмәде. Аның урамында да кояш чыгар көн булган икән. Рәхмәт, Ходайколга.

Алар туганнарча кочаклашып аерылыштылар.

Габделләтыйф әлеге көтеп алган куанычлы хәбәр уңаеннан үз кешеләренә дә бәйрәм мәҗлесе оештырды. Үзе ике тән сакчысын алып, тәпи-тәпи генә урман йөрергә чыкты.

Кояш шактый түбәнәйгән иде. Күккә ашкан чыршыларның күләгәләре үзләреннән дә озынрак булып сузылган, тирә-якта шушы вакытта гына була торган ниндидер моңсу хозурлык.

Габделләтыйф шушы күркәм манзарага мөкиббән китеп атлый. Ул табигатьнең һәр фасылын ярата, аннан тәм таба белә иде. Күзачкысыз буранда җил пыран-заран китереп йөрткән кар бөртекләрен көннәр буе күзәтеп торганы бар аның. Ә җәен кичке дымык һавада суга карап утыру үзе бер ләззәт дөньясы лабаса. Язгы җылы көннәрдә бала-чага белән бергә ярыша-ярыша гөрләвекләр ярып йөрүне дә бик ошата ул. Бүген әлеге тәэссоратка үз куанычы да килеп кушылгач, җиһан тоташ балкышка әйләнгәндәй булды.

—Елдырым күренми, кая олакты икән?—дип, як-ягына каранды Габделләтыйф.

—Хәзер сикергәләп килеп җитәр, хан, аның гадәтен беләсең ич инде,—диде сакчыларның берсе. Шушы сүзне генә көтеп торган диярсең, Габделләтыйфның җилкәсенә кош шикелле очып кына күпермә койрыклы тиен килеп тә кунды. Тиенкәй шундый җитез, шундый өлгер, күз сирпеп алганчы әллә нинди хәрәкәтләр ясап ала. Җитезлеге өчен Габделләтыйф аңа "Елдырым" дигән исем кушты да инде. Ул аны иң элек кулына ияләштерде. Ак күл токтынлыгы урманында да тиеннәр күп иде. Алар да аны үз итә иде. Чөнки карый, ашата, уйната иде.

Елдырым хуҗасының учындагы чикләвекне сыптырып алды да, агач ботагына сикерде. Кеше кулыннан ризык алса да, ул аны үз табынында ашый. Кулга ияләшүе дә шул азык өчен ич инде. Җан иясен тамак йөртә.

Елдырым тагын берничә чикләвек эләктерде дә, аннан соң бөтенләйгә юкка чыкты.

—Йокы вакыты җитте, эңгер-меңгер дә төшеп килә икән,—дип, сөйләнеп алды Габделләтыйф.

Сакчылар аннан дүрт-биш адым арттарак атлыйлар иде. Ул аларны кул изәп, үзе янына чакырып алды. Бу ике игезәк сакчысын аеруча якын күрә иде. Яшьләр, чибәрләр, көчлеләр. Алып батыр токымы. Исемнәре дә

ятышлы: берсе Авызбакый, икенчесе—Авызгәрәй. Бер-берсенә ике тамчы су шикелле охшаганнар.

—Мин сезне үзем белән Казанга алырга ниятлим, каршы түгелсездер бит?—дип, Габделләтыйф егетләрне күзеннән үткәрде.

Сакчылар ханның аяк астына аудылар.

—И, мәрхәмәтле бөек хан...

—Алдагы мәлдә унбашы итеп билгеләрмен, аннан йөзбашы,—дип дәвам итте сүзен, Габделләтыйф,—абруйлы гаиләдән кыз ярәшербез, никахыгызга фатиха бирермен, анда да игезәк кызлар бардыр, иншаллаһ.

Ниһаять, Габделләтыйфка да җиһан ак йөзен ачты. Ахыры гына хәерле булсын, ходаем.

Мунча кереп, юынып-пакъләнеп, догаларын укып, бик бәхетле халәттә Габделләтыйф ятагына ауды.

Җиһанга төн хуҗа иде инде. Һәммә кеше татлы йокыга талган. Шылт иткән тавыш та ишетелми. Хәтта чикерткәләр дә бүген ни сәбәпледер ярыкларыннан чыкмыйча посып яталар.

Бераздан төн пәрдәсенә төренеп, хан бүлмәсенә шыпан-шыпан гына дию гәүдәле ике адәм килеп керде. Туктатучы булмады. Никтер ясавыллар да күренмәде.

Адәмнәрнең берсе килә-килешкә Габделләтыйфның йөзенә мендәр каплап, үгез авырлыгы белән өстенә ятты. Икенчесе ханның аякларын келәшчәдәй кысып, тотып торды. Ханның гөнаһсыз зәгыйфь гәүдәсе бу иләмсез кара көчкә каршылык күрсәтә алмады. Бары чарасызлыктан сенерләре генә тартышып-тартышып азапланды. Тиздән алар да тынды...

Адәмнәр ханның урын-җирен рәтләп куйдылар да, яшерен ишектән урамга чыктылар. Аларны көтеп торалар иде. Тавышсыз-тынсыз гына урман караңгылыгына кереп югалдылар. Төн барысын да йотты.

Петр Ибрагимовичның әйткәне раска килде. Чыннан да, Габделләтыйф ханның сәгате суккан булган икән.

Бу—1517 елның 19 ноябре иде.

***

Үрбәт соңгы вакытта хан көтепханәсенә йөрүен ешайтты. Аның анда электән үк махсус бүлмәсе бар. Ул көнчыгыш шагыйрьләренә мөкиббән. Мөхәммәдәминнең үз китабын булдыру фикере дә шушы мавыгулар нәтиҗәсендә туды. Ниһаять, ризалыгын алды. Әмма әүвәл Габделләтыйфны тәхеткә утыртыйк әле, аннан соң китап белән шөгыльләнербез, диде. Үрбәт килеште. Чөнки китап эше—ханлык эшенә бәрабәр искиткеч җаваплы гамәл бит ул.

Көтепханәгә әлеге йөрүләре исә иренең хастасына мөнәсәбәтле иде. Әгәр Тәңре үзенең иң якын, иң турылыклы адәми затын иң авыр сынауларга дучар итә икән, бу бер дә сәбәпсез түгелдер, мөгаен. Моның төбендә нindидер сер, тылсым, могҗиза ятарга тиеш, дип уйлый иде.

Шушы тылсымны ачыклау теләге белән янып йөрүе иде Үрбәтнең. Көтепханәче Габбас атлы бик гыйлем хәзрәт. Дин тәгълиматыннан да, хисап, галәм, җир-су, табигать, күк белеме кебек дөньяви фәннәрдән дә хәбәрдар.

—Ханәкә-солтан, узганында Фирдәүсинең "Шаһнамә"сен соратып алган идең, аның әле "Зәл һәм Рудәбә"се дә бар, китерсеннәрме?—диде.

—Сабыр итсеннәр әле,—диде бикә уйланыбрак,—мине бүген бөтенләй башка нәрсә кызыксындыра, әйтик, дин тарихы буенча ни-нәрсә тәкъдим итәр идең?

Габбас сирәк төкле кыска сакалын бөтергәләп торды да:

—Дин тарихы дәрья кебек бит ул, ханәкә-солтан, иксез-чиксез, сине тәгаен генә кайсы тармак кызыксындыра соң?—дип белеште.

—Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең хәләл җефете хәзрәти Хәдичәнең, Әйүп пәйгамбәрнең тормыш юллары турында тулырак беләсем килә,—диде Үрбәт.

—Бик хуш, бүлмәңә рәхим ит, ханәкә-солтан, хәзер барысы да булыр.

Үрбәт искиткеч мавыктыргыч, чик дәрәҗәдә гыйбрәтле вакыйгаларның шаһитына әверелде. Бер караганда, барысы да гадәти кебек, шул ук инсаннар, шул ук көнкүреш мәшәкатьләре, сәяхәт, сәүдә... Һәркемнең башына төшә торган хәлләр. Тик шушы гадәтилекнең асылында гади бәндәнең акылы, зиһене генә түгел, буе да җитмәс бөек гамәлләр ятканын тоясың. Син үзең дә сизмәстән мәрхәмәтле нурга коенасың. Алай гынамы, узгандагы ялгышларыңның, хаталарыңның чын бәһасенә төшенәсең, аларны төзәтәсең килә башлый, мохтаҗларга карата ихтирамлылык, яхшылык, миһербанлык кылу теләге уяна, тәүбәгә киләсең.

Бу тылсымлы дөньядан һич аерыласы килми. Үрбәт төш вакыты җиткәнен сизми дә калды. Икенче көнне дә килде, өченче көнне дә, дүртенче-бишенчесендә дә. Укый-укый, алиһә затларның гамәлләрен өйрәнә-өйрәнә Үрбәтнең үзенә дә күктән ачыш инде. Мәгълүм, хан Аллаһы тәгаләнең җирдәге вәкаләтле вәкиле. Бу—хак. Тик вәкил генәме икән Мөхәммәдәмин? Бәлки, илчедер? Пәйгамбәрдер? Шулай булмаса, Аллаһы тәгалә аңа берсеннән-берсе авыррак сынаулар җибәрер иде мени?

Кире какмаслык дәлилләр дә уйлап тапты.

Яшьли ятим калган Мөхәммәд атасы Габдулланың бертуганы Әбү-Талип тәрбиясендә яши. Көннәрдән беркөнне агасы аны Шам шәһәренә алып китә. Алар Басра дигән җиргә җитеп, бер дәрвишкә тукталалар. Бу кемсә Мөхәммәдне һәрдаим баш очында күләгәләп, аны эсселектән саклап йөргән болыт кисәгенә игътибар итә. Монда бер-бер хикмәт бар, дип уйлый Бәхирә дәрвиш. Әбү-Талипка әйтә:

—Бу баланы Шамга алып барма, юкса, яһүдиләр аңарга зыян китерерләр, бу бала заман ахыры пәйгамбәре булса кирәк,—ди.

Фәрештәләр Мөхәммәдәминне дә нәкъ шушы рәвештә үз канатлары астына алалар лабаса! Мәсәлән, 1505 елның сентябрендә Түбән Новгородка яу йөргәндә сәргаскәр чатырына урысларның утлы коралы төкереген чәчә. Чатырдагы барча хәрбигә үлем китерә әлеге иблис төкреге. Бер Мөхәммәдәмин исән кала.

Берсенә үзе дә шаһит Үрбәт бикә. Бервакыт Идел буена чыкканнар иде. Җәйнең чәчәкле-чуклы чагы. Тирә-як гөлт иткән. Шушы матурлыкка хозурланып бара-бара шактый җир кителгән. Йөзләренә салкынча җил килеп бәрелгәч кенә исләренә килделәр. Күтәрелеп карасалар, җә, Ходай, күкне ямьсез кара болыт каплап килә. Көн кояш тотылгандай караңгыланып, сүрәнләнеп китте. Үрбәт иренә елышты.

—Мин куркам,—диде.

—Курыкма,—дип хатынын тынычландырырга ашыкты Мөхәммәдәмин,—яңгыр мине урап уза ул, күрерсең, күп тапкырлар сынаганым бар.

Дөрестән дә, баш өстенә килеп җиттем дигәндә генә әлеге кара болыт икегә ярылды да, читләтеп узды.

Аллаһының сагы ич инде бу.

...Егерме биш яшендә Мөхәммәд Хәдичә исемле кырык яшьлек бер күркәм тол хатын белән никахлаша. Бик тату гомер итәләр. Хәдичә Мөхәммәднең иң ышанычлы таянычы, киңәшчесе була.

Кырык яше тулгач, көннәрдән бер көнне, Мөхәммәд янына Җәбраил галәйһиссәлам килә.

—Икъра-а! Укы!—дип мөрәҗәгать итә ул аңа.

Мөхәммәд куркып кала. Хатыны Хәдичә янына килеп хәлне сөйләп бирә. Шайтан ләгыйнь булмасын, ди.

Икенче көнне дә кабатлана бу. Хәдичә әйтә:

—Әгәр иртәгә дә килә калса, мине чакыр, кемлеген ачыкларбыз,—ди.

Өченче көнне Җәбраил фәрештә килгәч, Мөхәммәд хәләл җефетенә хәбәр сала. Хәдичә башындагы яулыгын сала да сорый:

—Инде югалдымы?—ди.

—Югалды,—дип җаваплый Мөхәммәд. Һәм сорый: "Син ни өчен бу рәвешле эшлисең?"—ди.

—Әгәр шайтан булса, гаурәтне күрү белән качмас иде, карап торыр иде,—ди Хәдичә,—димәк ки, сиңа килгән зат Җәбраил фәрештә булса кирәк.

Шушы рәвешле берничә кат тикшергәч, Хәдичә банат әйтә: "Җәбраил фәрештә Аллаһы тәгаләдән бер-бер мөһим хәбәр алып килгәндер",—ди.

Чынында да, Җәбраил фәрештә хәзрәте Мөхәммәдкә пәйгамбәрлек индерә һәм аңа әүвәл башлап "Ик—ра-а би-ис-ми Раббикыл—ләзи халәкә" сүрәсен укып бирә. Беренче булып Мөхәммәд пәйгамбәребезгә ингән дога да менә шушы сүрә инде.

Үрбәт хәзрәте Хәдичәне чын ярату белән ихластан яратты. Үзе гади, үзе изге. Ислам диненең чишмә башында торган илаһи зат.

Мөхәммәд белән Хәдичәне бер-берсеннән аерып булмый, алар бербөтен. Ходай Мөхәммәдәмин белән Үрбәтне дә бербөтен итеп яраткан. Хәдичә банатка да, Үрбәт бикәгә дә насыйп тормыш юлдашлары ак тулпар атка менгән хәлдә төшләренә керде. Охшаш алар, охшаш!

Үрбәтнең күнеле чайпалам-чайпалам дип кенә тора. Көтепханәче дә моны тоеп-сизеп алды.

—Күрәм, ханәкә-солтан, әһле китап сүзе күнеленә җылы шытым бирә, бик дулкынлангансың,—диде.

Үрбәт кулындагы китабын, баласын назлаган яшь анадай, күкрәгенә кысты.

—Хак, Габбас хәзрәт, эчем-тышым балкыш минем,—диде.—Мөхәммәд пәйгамбәр белән хәзрәте Хәдичә банат арасындагы мөнәсәбәтләрнең самимилегенә сокланып туя алмыйм. Чын мөселман гаиләсе.

—Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһ галәйһиссәламнең һәр гамәле үрнәк аның,—диде көтепханәче.—Үзеннең дә үпкәләрлегең юк, ханәкә-солтан, Мөхәммәдәмин ханның сиңа зур ихтирамы турында бөтен кала белә.

—Аллага шөкер, хәзрәт, Мөхәммәдәмин бик изге зат. Аллаһы тәгалә аны җиргә пәйгамбәр вазифасы белән иңдергән. Китапларың миңа шушы хакыйкатьне ачты.

—Берүк хаталана күрмә, ханәкә-солтан,—диде Габбас хәзрәт,—Мөхәммәд пәйгамбәр җиргә җибәрелгән утыз пәйгамбәрнең иң соңгысы. Ул—ахырзаман пәйгамбәре.

Үрбәткә болар мәгълүм иде. Тик Мөхәммәдәминнең пәйгамбәрлегенә дә ышанасы килә иде, һаман үзенекен куәтли.

—Аллаһы тәгалә Мөхәммәдәмингә Әйүп пәйгамбәр язмышын насыйп иткән,—дип, үзенекен исбат итте Үрбәт,—беләсеңме, хәзрәт, соңгы вакытта ул табиблардан, дарулардан баш тартты бит. Әйүп пәйгамбәрчә: "Сәламәтлекне Аллаһы тәгалә үзе бирде, үзе алды",—ди. Килер бер көн,

ходайның рәхмәте белән аягына да басар. Әйүп пәйгамбәргә дә сырхаулый башлаганына җиде ел, җиде ай, җиде көн үткәч кенә саулыгы кайта. Мөхәммәдәминнең әле вакыты бар...

—Йә, ходаем, безне сыный калсаң, сабырлыклар бир. Юкса күңелебез тар, акылыбыз зәгыйфь, үзебез көчсез. Ярдәменнән ташлама, йә Раббым,— дип дога кылды хәзрәт.—Сиңа, ханәкә-солтан, Әйүп пәйгамбәрнең җәмәгате Рәхимә банат турылыклары вә түземлекләре юлдаш булсын. Адәмнәр пәйгамбәрдән йөз чөергән вакытта да хәзрәте Рәхимә ирен ихластан хөрмәт итә, җирәнмичә карый, тәрбияли.

—Әйүп пәйгамбәргә ару хәле кайтканнан соңгы халәте исемә төшә дә, ирексездән күзләремә яшь килә,—дип ялгап китте Үрбәт,—монда минем бер авыруым бар иде, әллә бүре ашаганмы, дип өзгәләнә бичара Рәхимә бикә. Ник кенә янында булмадым, ник кенә киттем икән, бүре мине дә аның белән бергә ашаган булсачы, дип елый. Әйүп пәйгамбәр янына килеп җиткәч кенә, ирен таный.

—Бик гыйбрәтле язмыш, ханәкә-солтан.

—Мин үзем дә Мөхәммәдәмин өчен җанымны фида кылырга әзер,— диде Үрбәт.

Габбас хәзрәт салынып төшкән калын кашлары астыннан ханбикәгә күз сирпеп алды. Ул инде аның гадәти кануннарга ярашып бетми торган йөгәнсезрәк фикер сөрешенә күнеп килә иде. Башта Үрбәт Мөхәммәдәмин ханны пәйгамбәр дип тәкърарлады, шуны ярсып-ярсып исбатларга тырышты. Хәзер менә Әйүп пәйгамбәрнең хәләл җефете Рәхимә бикәнең гамәлен үзенчә шәрехләргә керешә.

Ханбикәне аңларга да була, билгеле. Ул сырхау ире—Мөхәммәдәмин ханны аякка бастыру максатыннан шулай өзгәләнә, чәбәләнә, тәрәккъыят кылмак итә. Ләкин бу аны һич тә акламый. Хата төзәтелергә тиеш. Чөнки хата фикер хата гамәлләргә этәрә. Ә моны күрмәмешкә салышу Ходай алдында зур гөнаһ.

—Мөхтәрәм ханәкә-солтан, ялгыша күрмә берүк,—диде хәзрәт чын кайгырту белән,—Рәхимә бикә җәмәгате Әйүп пәйгамбәр өчен үз ирегеннән үз гомерен өзәргә җыенмый. Ул фәкать: "Бүре мине дә аның белән бергә ашаган булсачы",—дип кенә сызлана. Җанны фида кылу белән бүре ашау арасында аерма бик зур.

Үрбәтнең чырае караңгыланып китте. Сәер кеше бу көтепханәче.

Мәхәббәт—беренче чиратта, яраткан затың өчен теләсә-нинди корбанга барырга әзер булу дигән сүз ул. Ире каберенә кереп яткан мангыт кызы Айбиби кебек Рәхимә бикә дә шул гыйшкы, яратуы хакын хаклап бүре авызына керергә тели ләбаса. Хатын-кызның мәхәббәте пар мәхәббәт икән, ул чикләрне белми, тотып та тыя алмыйсың.

Үрбәткә мәхәббәт утыздан соң килде. Мәхәббәтне берни белән дә чагыштырып булмый. Ул кырык рәвешкә керә: бер карыйсың, язгы ташкындай шаулый, яшендәй яшьни, икенче карыйсың, йөрәккә моң булып сарыла, шунда ук сыкрый башлый. Күп тә үтми, толпар шикелле канатланып, күккә иңә...

Үрбәтнең күңелендәге янартау куәтенә тиң бу хисләр өермәсен Мөхәммәдәмин тузгытты. Шуңа күрә Мөхәммәдәмин аның пәйгамбәре дә, алласы да.

Габбас хәзрәт шуны аңламый, һаман акыл өйрәтә, һаман үзенекен тукый. Ә Үрбәтне үз кыйбласыннан кайтарырдай көч юк бу дөньяда. Хак, мәхәббәте сукыр мәхәббәт аның.

—Киңәшләрең өчен рәхмәт, Габбас хәзрәт, мин әле килгәләрмен,—дип, ханбикә көтепханәче белән саубуллашты.

***

Ханның телмәр тавышкылары гадәттәгедән иртәрәк аваз салдылар. Башка көннәрдә өйлә намазыннан соң гына шәһәр буйлап чәчеләләр иде. Бүген сарай капкалары да ничектер кисәк кенә ачылып китте кебек. Атлар да кигәвен тешләгәндәй койрык чәнчеп чабалар. Шуңа күрә үткән-сүткән кеше шомга төште: ул-бу булмагандыр бит, нигә шул кадәр кабаланып чабыша хан телмәрләре?

—Тыңлагыз, тыңлагыз, ханның әле генә табадан төшкән яңа әмере!

Тиз генә халыкны түгәрәккә җыйдылар. Баш телмәр кәгазен сүтеп, ханның ярлыгын җиткерде.

—Мин, Барча Казан җиренең бөек ханы Мөхәммәдәмин, Габделләтыйф ханның вафаты сәбәпле, бүгенге көннән тәхет хуҗасы турында Мәскәү белән төзелгән килешүне гамәлдән чыгарам. Ходай насыйп иткән ханлык вазифамны соңгы сулышыма кадәр үзем башкарачакмын! Амин!

—Бирсен ходай!

—Гәләс-саләһ!

Кешеләр ак карга тезләнеп, догага оедылар.

Габделләтыйфның үлеме турындагы хәбәрне башта Каширадан килгән атчабар җиткерде. Мөхәммәдәмин ышанмады. Чапкынны зинданга ябарга боерды. Моңа ышану авыр иде. Хан өч көн башын күтәрмичә ятты, янына берәүне дә кертмәде. Тиздән Василийдан илче килде, Мөхәммәдәмингә олуг кенәзнең ярлыгын тапшырды. Олуг кенәз кайгысын уртаклашкан, киләчәктә дә Мәскәүнең моңа кадәр гамәлдә йөргән килешүләргә турылыклы булуын белдергән, Казанны да шуңа өндәгән.

—Хан ни сәбәпле үлгән, үз үлеме беләнме, үтергәннәрме?—дип белеште Мөхәммәдәмин илчедән.

—Мунчадан соң ятагында вафат булган. Ис тигән, диләр. Мунчачы, башка якын хезмәтчеләре кулга алынды, һәммәсе тиешле җәзасын алыр.

—Шаһитлар бармы?

—Төнге ясавыллары качып киткән. Эзлиләр. Ерак китә алмаслар, тотылырлар.

Олуг кенәз ярлыгында Мөхәммәдәминнең варисы турында ләм-мим әйтмәгән. Әйтсә-әйтмәсә дә, ул тәхетен беркемгә дә бирмәячәк. Чир сылтау булудан туктый. Моны халык та белеп торырга тиеш. Шул сәбәпле, бүген хан капкасы вакытыннан элек ачылды да инде.

Туганы файдасына үз теләге белән ханлыктан китәргә хәл кылуы аның абруен тагын да үстереп җибәрде. Димәк, үз мәнфәгатьләрен өстен куймый, беренче урында—ханлык язмышы. Хәтта төрле төркемнәргә бүлгәләнгән аксөякләр дә итәк астыннан эш йөртүдән туктадылар. Соңгы елларда чын мәгънәсендә халык хакименә әверелгән иде ул.

Тәхеттән дә шушы абруй балкышында китәргә теләгән иде. Барып кына чыкмады, янәдән җин сызганырга туры килде. Ләкин сырхау адәм бик җәелеп тә китә алмый шул. Мөхәммәдәмин дә кайбер гамәли вәкаләтләрен вакытлыча Уйгын бәккә бирергә булды.

Булат Ширинның мин-минлегенә тиде бу. Чын-чынлап үпкәләде. Хан беренче чиратта баш карачы белән киңәш-табыш итешергә тиеш иде ләбаса. Ә ул аны бөтенләй күрмәмешкә салышты. Димәк, читләштерәләр.

Шул кызулык белән ул хөкүмәт әгъзаларын җыйды.

—Нишлибез, куып таратканчы вәкаләтләребездән үзебез ваз кичәбезме, әллә ханның рәсми әмерен көтәбезме?—дип, карачыларга бакты.

Башлар иелде. Чөнки берсенең дә бу дәрәҗәле дә, төшемле дә урынын

югалтасы килми иде. Бер-берсенә күтәрелеп карарга да кыймыйча озак кына тып-тын утырдылар.

Тышта буран котырына иде. Тишеп керердәй булып тәрәзәләргә энә очлы каты кар бәрә. Түбә астында шомлы җил улый. Ирексездән колакларны мендәр белән каплыйсы килә башлый.

Җилдән, ихтимал, шул рәвешле котылырга да мөмкин булыр. Чынбарлыктан алай гына арынып булмый шул.

—Җә, җәмәгать, нинди карарга киләбез?—дип ашыктырды бәк.

—Сабыр иткән морадына житкән, ди, миңа калса, ханның үз сүзен ишетү мәслихәтрәк булыр, тәртәгә тибеп кенә эш чыкмас,—дип, иң башта Бозак бахшы үзенең фикерен җиткерде.

Карачыларның йөзләре яктырып, эчләренә җан кереп киткәндәй булды, хәтта буран да басылгандай итте, һәрхәлдә, җилнең улавы күңелгә куркыныч шом салмый иде инде. Бозак бахшы белми әйтмәс, ул ханның якын кешесе, мөхтәрәм Шаһ-Хөсәен сәедне алыштырган мәртәбәле илче.

—Әйе, әйе, бик мәгъкуль, фаразан, ханнан узу килешеп бетмәс,—дип хупладылар бахшыны карачылар.

Булат Ширинның кимсенүе бик көчле иде, күрәсең, ул әле һаман вәкаләтләрне менә шулай үпкәле рәвештә туктату, өзү фикерен алга сөрә.

Гәүһәршад исә иренең ниятен хупламады.

—Бу сине һич тә бизәми, син бик дәрәҗәле урын иясе, абруйлы бәк,—диде.

—Суык белән көрәшкәннең колагы юк, казый белән көрәшкәннең башы юк, ди, үземне ни көткәнен белә торып, кул кушырып утырыргамы?

Бикәнең йөзе ямьсезләнде, иренең төшенкелеге аның ачуын гына китерә иде.

—Мин сине аңламыйм, бәк,—диде тешләрен кысып,—бу фетнә оештырып йөргән гыйсьянчы сүзләре түгел. Хан сине ярлыкады лабаса. Минем хакка, балалар хакына. Вазгыять хәзер бик нык үзгәрде. Ул гарип кеше. Аңа синең кебек ышанычлы, төпле ярдәмче зарур. Төшенденме?

—Хан туксан тугыз катлы ул, аңа ышаныч юк,—дип, үзенекен тукыды баш карачы,—аның ышанычлылары да бар инде: Уйгын бәк, Боерган сәед, Бозак бахшы...

—Ә син егет бул, көндәшләреңне юлыңнан алып ташла,—дип киңәш бирде Гәүһәршад.

—Телнең сөяге юк...

Ачуыннан бикәнең йөзенә тимгелләр бәреп чыкты.

—Өлге булырдай егет солтаннары бар иде,—диде ул.—Кәлимәт бәк, әнә, өч ханны уч төбендә биеткән.

—Тотасың да Кәлимәтне бугазыма тыгасың, нәрсә, бикә, әллә син миңа аның язмышын юрыйсыңмы?—дип үпкәсен белдерде Булат,—минем дар агачында асылынып торасым килми.

Гәүһәршад иренең сүзләрен ишетмәде дә.

—Беләсеңме, Булат бәк, әлеге вазгыять безнең алда кичектергесез рәвештә үз фиркабызны булдыру бурычын куя,—диде.—Мәскәү кубызына да, Кырым кубызына да күп биедек. Житте! Мөхәммәдәмин хан урынына утырган бәндә Ибраһим хан кызы Гәүһәршадтан башка кыл да кыймылдатырга тиеш түгел. Ә син—минем терәгем. Җебеп төшмә. Казан-йортның хуҗасы без булырга тиеш. Без!

***

Үрбәтнен төшенә мәче керде. Һөнәрчеләр бистәсендә Мөхәммәдәмингә комган ясатып йөргән вакытта күргән көр, шома, зур кара мәче иде бу. Теге чактагы кебек ашыкмыйча, үз кадерен белеп кенә юл аша чыгып бара. Менә мин нинди күркәм, дигәндәй, тукталып-тукталып тирә-якны да күзеннән кичергәли.

—У-у-у! У-у-у!

Абау, бүре шикелле улый ич бу мәче, дип шомланып куйды Үрбәт. Йокысыннан да сискәнеп уянды. Куллары белән капшанып, җәт-җәт Мөхәммәдәминне эзләде. Ә ул юк иде. Урыныннан кубарылуын сизми дә калды. Торып баскач кына аңлады, ул соң үз бүлмәсендә ләбаса! Мөхәммәдәмин бу араларда дәүләт эшләре белән мәшгуль булганлыктан, аның янына керүче-чыгучы күбәйде. Әлеге сөйләшүләрдә ханбикәнең катнашуы соралмый. Аяк астында уралып, ханга комачау итеп йөрмәс бит инде. Шуңа күрә күченүне кирәк санады. Мөхәммәдәмин дә каршы килмәде, бераз үзенчә яшә, хәл ал, диде.

Мөхәммәдәминнең дүрт куллап төп вазифасына ябышуына Үрбәт аның үзенә караганда да ныграк шатлана иде. Ярабби, ходаем, эшләрен уң кыл, пәйгамбәрләр зирәклеге индер, тазалыгын кайтар, дип һәрдаим догаларын юллый. Бөек тә, мәрхәмәтле дә ул, Аллаһы тәгалә. Әнә, кортлап, череп яткан Әйүп пәйгамбәр дә зәхмәтеннән арынган ич. Мөхәммәдәминнең бәхет капкасы ачылыр, ачылмый калмас.

Күңел хөҗрәсен былчыратып, каян килеп чыкты соң әле бу кара мәче? Күптән оныткан иде ич инде ул аны. Һәм менә уйламаганда-көтмәгәндә төшкә килеп керде. Ни-нәрсәгә ишарә соң бу, һич аңламассың.

Җиде төн уртасында уянган Үрбәт шуннан соң керфек тә какмады. Әйләнгәләп-тулгангалап ятты-ятты да, ахыры намазына басты. Иркенләп, озаклап укыды. Шуңа теләкләре ялганып китте. Көндәгечә, аларның барысы да ире Мөхәммәдәмингә багышланган иде.

Иренеп кенә яңа көн туды. Кыш симез үгез шикелле авыр сынлы бит ул, ялкаулар фасылы. Хәтта җилбикә дә йокысыннан уянырга ашыкмый. Әнә, кала өстендә төтен баганалары боз сөңгеләредәй турыга катып калганнар, куып таратучы юк.

Үрбәт озак кына шушы салмак манзараны күзәтеп, тәрәзә янында басып торды. Үзенең дә бернәрсәгә кулы бармый иде. Күз алдында һаман теге бүречә улаучы кара мәче. И, ходаем, авырлыкларны җиңәргә көч бир. Бәлки, бу кадәр тәшвишләнергә дә кирәкмидер әле. Атае әйтә иде бит, куркыныч төш яхшылыкка ул, кызым, дия иде.

Үрбәт ничек кенә онытылырга тырышса да, эченә тәмам пошаман төште. Сарайның уянуын көч-хәл белән житкерде дә, хан катына юнәлде. Күз кырые белән генә күзәтеп багамын да, үз шөгыльләремә тотынырмын, бер генә дә мәшәкать тудырмам, дип күңеленә беркетеп куйды. Мөхәммәдәминнең тавышын ишетсә, шул җитә аңа. Шатлыгы көне буена җитә.

Хан белмәсендә ул баш карачы Булат Ширин белән йөзгә-йөз килде.

—Әссәламегаләйкем, ханәкә-солтан, ходай бәхет вә сәгадәтләр насыйп итсен,—дип сәламләде бәк Үрбәтне,—исән-сау гына яшисеңме?

—Әлхәмдүлилләһи,—диде Үрбәт ачылып,—Аллаһы тәгалә күркәм гамәлләребезгә якты юл ачсын. Аннан түземсезләнеп: "Ханның хәле ничек?"—дип белеште.

—Әле күрмәдем, кабул итүен көтеп утырам,—диде Булат бәк,—

шактыйдан инде.

Шулвакыт бүлмәдән чырае качкан табиб килеп чыкты.

—Ханның хәле авырайды,—диде ул ханбикә белән баш карачы ишетерлек кенә ярымпышылдап.

Бүре тавышлы кара мәче төшенә юкка гына кермәгән икән.

Үрбәт җилдәй очып, бүлмә эченә узды. Мөхәммәдәмин бүрәнә шикелле селкенмичә ята иде. Танырлык та түгел. Әйтерсең лә, өстеннән тәгәрмәч узган: авызы-борыны кыйшайган, сул як күзе җәя белән тарттырылгандай киерелеп каткан, ямьсез булып агы күренеп тора.

Үрбәт иренең хәрәкәтсез кулларына алмаш-тилмәш кайнар иреннәрен тигезеп алды. Мөхәммәдәмин кагылуны тойды булса кирәк, сагыш тулы мөлдерәмә күзләре белән хатынына текәлде. Исән икән, Аллага шөкер, дип куанды ханбикә. Бик озак бер-берсенә карашып тордылар. Үрбәт тырнаклары уч итен сытып кергәнче йодрыкларын йомарлады.

—Мөхәммәдәмин, җанашым, борчылма, бу Аллаһы тәгаләнең чираттагы сынавы гына, савыгырсың,—диде тавышының калтырануын басарга тырышып.

Мөхәммәдәмин әле һаман аннан күзләрен алмый, нидер аңлатырга тели иде, ахры, уң кулы селкенеп-селкенеп куя, ләкин телсез-авызсыз булу аны бичарадан-бичара хәлгә калдырган иде.

Тыны-көне бетеп, Боерган сәед килеп керде. Тиз генә Мөхәммәдәминнең баш очына урындык китереп куйдылар. Сәед кулына Коръән китабы алды.

—Йәсин чыгабыз, җәмәгать, бисмил-ләәһир-рахмәәнир-рахим. Йәсин сүрәсенең мәгънәсен Аллаһы тәгалә үзе генә белә,—диде,—ул иман китерү белән бердер, җәннәт ишекләрен ачарга булышырдай илаһи көчтер.

***

Булат бәк, ниһаять, төннәрен саташмыйча йоклый башлады. Ничә айлар буе, кайчан кулга богау салырлар инде, дип ут йотып яшәде бит. Ханның ярлыкавына бөртек тә ышанмый иде ул. Хатыны Гәүһәршадның сүзләрен дә җитдигә санамый иде.

Мөхәммәдәминнең телсез калуы баш карачыга ирек алып килде. Алай гынамы, ул үзен дәүләтнең хуҗасы итеп тоя башлады, куллары чишелеп китте, богау кигезүне көткән куллар димәссең. Аның сүзе сүз хәзер. Тәхет язмышы да аның кулында.

Тәмам тынычланган хәлдә, ул карачыларны, олы түрәләрне сарайга җыйды. Мәсьәләне кабыргасы белән куйды.

—Мөхтәрәм җәмәгать, ханыбыз үз аңында түгел. Турыдан-туры тәхеткә дәгъвә итүче тулы хокуклы варисы да юк,—диде йөзенә борчылу галәмәте чыгарып,—ил-дәүләтнең иң зарури яшәү шарты—кануни хөкем. Мәскәүгә илче юллау мәслихәт булыр сыман. Тәвәккәллик.

Булат бәк куе калын кашлары астыннан түгәрәкләнеп утырган дәүләт әһелләренә дикъкать белән күз йөртеп чыкты. Берәве дә сүз башларга атлыгып тормый иде. Чөнки тәүге сүз—куркыныч сүз, аның дар агачына китерүе дә ихтимал. Һәрхәлдә, ахыры ни белән бетәсен тәгаенли алмыйсың. Шулай булып чыкты да.

—Син, Булат бәк, Барча Казан җиренең бөек ханы Мөхәммәдәминне тәхетеннән бәреп төшерергә димлисең ич,—дип, иң элек Бозак бахшы угын очырды.

Карачыларның колаклары шәм булды. Кикерүләр дә, очкылык тотулар да бетте. Шулай булмыйча, очрашу бик кискен булырга охшап тора. Менә бит бәхәс йомгагы кайсы якка тәгәрәде, һич тә Булат бәк күрсәткән юлдан

китмәде. Хәер, бу әле бәрелешнең башы гына.

Бозак бахшы сүзен бик тә абруйлы Хөсәен бәкнең өлкән улы, атасының дәвамчысы Хөснелгата карачы элеп алды.

—Тере патша өстеннән яңа хан сорауга мин кулым-аягым белән каршы,—диде ул төкрекләрен чәчә-чәчә.—Бу бит, бәк, беләсеңме ничек дип атала? Бу... бу...

Боерган сәед хәдтән ашып сөйләшүнең яхшыга китермәвен аңлап алды, күрәсең, карачыны бүләргә мәҗбүр булды.

—Җәмәгать, барысы да Аллаһы кулында, болай дошманлашмыйк әле,—диде сүзләрен бастырып кына,—пәйгамбәребез Мөхәммәд салаллаһу галәйһиссәлам (Ана Аллаһының рәхмәте булсын) сабырлыкны, гыйффәтлелекне хуп күргән. Хәдистә әйтелә: "Иң күркәм иман—сабырлык,—диелә,—берәү түземле булса, Аллаһы тәгалә аңа икеләтә әҗер бирер".

Сәеднең вәгазе тәэсир итмичә калмады, билгеле, Булат бәк акланырга ашыкты.

—Без монда киңәш-табыш өчен генә җыелыштык,—диде гафу үтенгәндәй,—мин баш карачы сыйфатында фәкать үз вазифамны, үз бурычымны гына башкарам. Төп сүзне корылтай әйтердер. Шунысы ачык, без беребез дә дәүләтебезнең язмышына битараф кала алмыйбыз, һәм тиеш тә түгел.

—Дөрес әйтәсең, бәк, алма пеш, авызыма төш дип ята торган чак түгел,—дип корылтай башлыгы Әхмәд бәк тә сүзгә кушылды.—Бүгеннән үк җиен чарасына керешермен, Аллаһы боерса...

Янә Бозак бахшы калкып чыкты.

—Минем соравым бар,—диде.

—Рәхим ит.

—Ни өчен без хан сорап Мәскәүгә баш орабыз соң әле?—диде мутланыбрак,—аңлашылмый бу миңа, нәрсә, безнең үзебезнең башыбыз юкмы әллә?

—Илче сыйфатында Мәскәүгә син йөрдең бит, бахшы,—дип чеметеп алды Булат тегене,—әлеге матдәне Килешү ярлыгына кертмәскә иде, нигә керттегез соң? Ә хәзер без аны үтәргә бурычлы.

Бозак мондый тукмакны көтмәгән иде булса кирәк, тынып калды.

Көрәшне Хөснелгата дәвам итте.

—Казан ханлыгы—мөстәкыйль дәүләт,—диде үзенә хас булмаганча ясалма вәкарьлек белән. Ул янә кызып китүдән шикләнә иде, ахры.—Дәүләт үзенең яшәешенә зыян китерүче Килешүдән баш та тарта ала. Мөхәммәдәмин хан аның үрнәген күрсәтте инде, рәсми варисы вафатыннан соң Килешүне юкка чыгарды. Аннан китереп, тәхет язмышы хакында сүз куертабыз икән, Кырым белән Госманлы Төркияне дә истән чыгарырга ярамый дип беләм. Үз кешеләребез, үз мөселманнарыбыз, ыругдашларыбыз...

Бер капкорсак карачының әллә күзе йомылып китте, әллә җайлабрак утырмакчы булган иде, эченә җыелган нәмәхерәме шартлап тышка бәреп чыкмасынмы.

—Бер артына баш була белмәдең инде, бәк,—дип күршесе борынын җыерды.

—Әлхәмдулилләһ, дияргә кирәк, надан, ул да ходай нигъмәте,—дип сукранды ис иясе.

Булат бәк бу низагка игътибар итмәде, чөнки кәефе күтәренке иде. Күреп тора, күпчелек аның ягына күчте, аны яклый. Бозак белән Хөснелгатага иярүчеләр бармак белән генә санарлык.

Әмма алар баш карачы Мәскәүне үз итә икән дип бик нык ялгышалар иде. Аның бары тик Гәүһәршад белән бергәләп корган тозакны гына көенә китерүе. Бу чараларда Кырымга урын юк. Кырым еракта, Госманлы Төрек кочагында. Яшәсеннәр үзләренчә. Миңлегәрәйләр токымы—усал, көчле, тәкәббер токым. Кулларыннан эш килә торган токым. Ә Казанга үзенә җан, кешегә сан булырдай гына бер адәм кирәк. Шул вакытта гына Гәүһәршад теләгенә ирешәчәк.

Кисәк кенә ниндидер эчке бер шом белән Булат бәкнең күзе баш угланга төште. Ул бәхәскә катнашмыйча читтән генә бүлмәдәгеләрне күзәтеп утыра иде. Бу киребеткән эшне бозып куймагае, дигән уй бәкнең йөрәген сызып узды.

Сөйлисе кешеләр сөйләп бетергәч, әйтеләсе тәкъдимнәр әйтелеп беткәч кенә Уйгын урыныннан торып басты. Берара, үрә катып, каш астыннан гына бәккә карап торды. Бу юньнелеккә түгел иде. Кайчан бетә инде сүз боткасы дип, җыенның тизрәк бетүен житкерә алмыйча кадак өстендә утыргандай утырган ис чыгаручы өлкән яшьтәге карачыларга кадәр янә колакларын торгызды.

—Булат бәк,—дип, хәрбиләрчә катгыйлык белән мөрәҗәгать итте Уйгын баш карачыга,—син Мөхәммәдәмин ханга каршы фетнә оештырган җинаятьче кеше. Моның өчен мин сине кулга алып, башыңны гәүдәңнән аерырга тиеш идем...

Баш углан бер генә мизгелгә тукталды да, тирә-якка күз төшерде. Карачылар истән тайган иде. Беренче булып Булат бәк аңына килде. Яшелле-зәңгәрле тавыш чыгарып:

—Баш угланны зинданга озатыгыз!—дип кычкырды.

Сакчылар өлгерми калды, бүлмәгә Уйгын бәк эчкеләре кереп тулды. Баш углан алдан ук хәстәрен күреп куйган иде.

—Әле минем сүзем бетмәде,—диде ул тыныч кына,—сиңа, бәк, хак җәзаңны алырга, беләсеңме, кем ирек куймады? Хан! Туганы Гәүһәршад бикә хакына, балагыз хакына тимәскә боерды. Мин хәзер дә ханның боерыгына турылыклы. Борчылма. Ләкин бел, вакытың җитәр. Чөнки бүген янә карачыларны фетнәгә өндисең. Барып чыкмас! Хан гаскәре үз ханын якларга һәрвакыт хәзер. Баш угланга хан ошбу вәкаләтләрне үз ризалыгы белән бирде. Мөхәммәдәмин ханга дан!

Уйгын дөп-дөп басып, бүлмәдән чыгып китте.

***

Аллаһы тәгалә Мөхәммәдәмингә чир-сырхауның иң миһербансызын бирсә дә, гомерен гамәл дәфтәреннән сызып ташларга ашыкмады. Адәмне авыру җинә, авыруны аш җиңә, ди. Мөхәммәдәминнең керфек селкетерлек тә хәле булмаган беренче көннәрдә дә Үрбәт ирен ашату җаен таба иде. Ханга тиешле ризыкка беркемне дә якын китермәде. Башта үзе тәмен татып карый, шуннан соң гына авыруның авызына каптыра. Алар күз карашы аша бер-берсе белән шактый җиңел аңлаша башладылар. Мөхәммәдәминнең үз теләген җиткерү өчен бер күз сирпеп каравы җитә иде. Чирен тәгам кабул итсәң генә качар, аша, көчләп булса да аша, ди Үрбәт. Мөхәммәдәмин карышмый, хатыны каптырганны йотарга тырыша.

Ә көннәрдән бер көнне теле кайтты. Кайтты дигәч тә, әле аның сүзләре сүзгә охшап та бетми, әмма тавышы чыга. Бу инде аның өчен әйтеп бетергесез зур сикереш иде. Димәк, хәле җиңеләйтүгә таба бара.

—Зее ...э ...э ...б—б ...ә-ә...те,—диде Мөхәммәдәмин буйсынырга теләмәгән иреннәрен бөрештерә-бөрештерә,—зее...э...э...б-б...ә-ә...те...

Табышмакның табышмагы. Монда күз карашлары да көчсез иде. Үрбәт әлеге авазларны болай да гөманлап карады, тегеләй дә чамалагандай итте, тик барыбер бербөтен сүз оештыра алмады. Аннан соң иҗекләргә бүлгәләп, мәгънә эзләп карады. Шулай тырыша торгач, икенче иҗектә "бәте" тезмәсе тәгаенләнде. Бәте, бәт... Ширбәт ләбаса бу! Әлбәттә, ширбәт! Кара инде, кабыккан икән җанашы. Ә хатыны шуны да анламый. Ангыра бәрән. Хәзер, җанашым, хәзер, бераз гына сабыр ит, җәме. Иң татлы, иң файдалы ширбәт эчерәм мин сина. Анар ширбәте. Син аны элек тә ярата идең. И, җанашым, кара, ничек күзләрең мөлдерәтеп ята. Ачуланасыңдыр инде. Ачулан, ачулан. Суксаң да бер сүзем юк, терел генә, барысына да түзәрмен.

Үрбәт балалы күгәрчендәй гөрелди-гөрелди ширбәт хәзерләде дә, иренең алдына ашъяулык җәйде. Мөхәммәдәминнең иреннәрендә елмаю галәмәте кабынып алгандай булды.

—Р...ә-ә...б...ә-ә...т...

Күр, бичәсенә рәхмәт әйтә түгелме соң? И, җанашым. Әле минем турыда кайгыртып ятуы икән. Бәгырькәем.

Шушы көннән башлап, сырхауның теле күзгә күренеп йөгерекләнде. Атна-ун көн дигәндә, теле истигъфар шикелле авыр әйтелешле сүзне дә әйләндерә иде инде. Ул да Аллаһыга, Мөхәммәд пәйгамбәр үрнәгендә, көн саен йөз мәртәбә тәүбә вә истигъфар кыла башлады.

Мөхәммәдәмин хәтта ханлык белән турыдан-туры идарә итәргә талпынып карады. Тик Үрбәт ишетергә дә теләмәде.

—Өзлегеп кенә шушы хәлгә төштең, бу юлы терелеп җитмичә авызыңны да ачтырмыйм,—диде.

Сүзендә торды. Хан янына бер түрәне дә кертмәде, ирен җаны кебек саклады. Ике-өч ай эчендә бер генә ташлама ясады. Мөхәммәдәмин бик сорагач, баш углан Уйгын бәккә ханның рәсми күрсәтмәсен җиткерде.

—Дәүләт иминлеге хакына хан сиңа тулы вәкаләт бирә,—диде, ярлык тапшырды.

—Тыныч булсын, ханлык өстеннән чыпчык та очтырмам,—дип сүз бирде углан.

Бу кичтә сандугачтай сайраштылар алар. Мөхәммәдәминнең тәмам йөзе килгән иде. Арыйсың, җитәр, сүзең башка көннәргә дә калсын, ял ит, дип тә карый Үрбәт, юк, тыңламый.

—Бүлдермә әле, бикә, кәефем яхшырып китте, шул шатлыктан инде аның сүзләре дә,—диде.

—Өзлегерсең дип куркам мин, җанашым...

—Беләм, бикәм, бик яхшы беләм, мин сиңа кайгыртуың өчен бик рәхмәтлемен. Тик баядан бирле тел очымда торган сүземне әйтмәсәм, тынычланмамдыр, ахрысы.

—Озынга сузмасаң гына,—дип кисәтте Үрбәт.

—Беләсеңме, бикә, мин Алгай морзаны һич оныта алмыйм бит. Соңгы вакытта аеруча уйландыра,—диде Мөхәммәдәмин борчулы кыяфәттә.

—Мөхәммәдәмин, җанашым, бу хакта күп тапкырлар аңлашкан идек ич инде. Юк аның үлемендә синең гаебең, юк!

—Мин барыбер үземне гаепле саныйм,—диде Мөхәммәдәмин,—югыйсә, орышларда югалткан якыннарым шактый үзе. Бәлкем, Тәңре шул гөнаһларым өчен бирәдер бу сырхау-хасталарны? Авыруны гөнаһка кәффарәт[1] диләр ич.

—Мөхәммәдәмин, тагын бер тапкыр кабатлыйм, туганым Алгай морзаның шәһид китүендә синең бернинди катнашың да юк,—диде Үрбәт

[1] Кәффарәт—йолым.

еларга житешеп,—үзеңне бер гаепсезгә битәрләмә. Ир-егет өйдә туар, яуда үләр, ди. Яу кырында баш салу—каһарман өчен олы дәрәҗә ләбаса.

—Шулаен ул шулай да...

Кышкы озын кичләрдә Үрбәт белән Мөхәммәдәмин әнә шулай икәүдән-икәү генә әңгәмә корып утырырга күнегеп киттеләр. Ут яктысында бүлмә эче алтын-көмешкә коенган нииндидер әкияти мәгарәгә охшап кала иде. Шул сихри дөньяда алар үзләре дә нурга чумалар, тылсым иясенә әвереләләр.

...Алыптай мәһабәт баһадир гәүдәле Мөхәммәдәмин янында Үрбәт зифа камышны хәтерләтә. Алар бер-берсенә шулай туры киләләр ки, әйтерсең лә, Йосыф белән Зөләйха. Мөхәммәдәмин—каһарман, Үрбәт—алиһә. Икесе—links бербөтен.

—Мин сине күреп тә, сөеп тә туймадым, Үрбәт бикә, иншаллаһ, ходай ахирәттә дә беребезне беребездән аермас,—диде Мөхәммәдәмин хатынының йомшак кулларыннан сыйпаштыра-сыйпаштыра.

—Без аерылышу өчен кавышмадык, җанашым,—диде Үрбәт,—Аллаһ тәгалә сине минем өчен, мине синең өчен бар иткән. Минем бер генә көнгә дә синнән аеры торасым килми. Әлфирак[2] безгә фарыз түгел...

—Мин сине бер күз сирпеп карауда яраттым бит,—диде Мөхәммәдәмин нигәдер пышылдауга күчеп,—оят булса да әйтим, күлмәгең аша май йомарламыдай тыгыз ак тәненне, былбыл балаларыдай кыймшаныпкыймшанып алган учка гына сыярдай түм-түгәрәк күкрәк алмаларыңны, тулы балтырларыңны тоеп алдым. Су сөлегедәй җыйнак буй-сыныңны, зур коңгырт кара күзләреңне күреп тәмам җилкендем. Мангыт кәләшләре, гадәттә, юантыграк гәүдәле, түгәрәк йөзле, кыска симез бармаклы була. Ә син үз ыруыңа охшамаган. Аурупа туташларына тартым. Битең озынча, үзе ап-ак. Керфекләрең озын, иреннәрең тулы, тешләрең сәйләндәй тезелешкән. Ходай ияк очыңа мәхәббәт чокыры уярга да онытмаган...

—Уф, җир тишегенә төшеп китәрдәй иттең бит инде, Мөхәммәдәмин, күрәсеңме, йөзем чөгендер төсенә керде,—диде Үрбәт оялчан гына. Ә үзе күкнең җиденче катында иде.—Булгач булсын инде, җанашым, миңа багышлап чыгарган газәлеңне дә сөйләп күрсәтсәң, күнелем тагын да түгәрәкләнеп китәр иде...

Мөхәммәдәминнең маңгаена сырлар ятты. Чир анының хәтерен шактый таушалткан иде. Шуңа күрә исемә генә төшерсәм ярар иде дип, бик борчылды. Моны хатыны да сизеп алды, хатасын төзәтергә ашыкты.

—Җанаш, зинһар гафу ит бу җүләреңне, эредем тәки, хәерчегә ямаулык бирсәң, күлмәк сорый, ди...

—Тыңла,—диде Мөхәммәдәмин,—бүлдерми генә тыңла.

Мангыт кызы Үрбәт бикә,
Күрсәң күңел йуана.
Ак айдайын бите балкый,
Күзләр нурга куана.

Кандыздай кара чәче
Тубылынатик төшә.
Карагаттай кара күзе
Акылларны хуш итә.

Үрбәт үзенең чибәр икәнен белә иде, әлбәттә. Яше кырыктан узса да, сылу-сылу яшь кызларга да биргесез әле ул. Тик бу яшьтә матурны да матурлау зарур. Ә моның өчен шактый тир түгәргә туры килә. Матурлык—

[2] Әлфирак—аерылышу.

авыр хезмәт нәтиҗәсе дә ул. Үрбәт, әйтик, атнага ике мәртәбә мунчада бөтен тәненә бал сылатып, шул сенеп беткәнче ләүкәдә ята. Битен фәкать кәҗә сөте белән генә юа. Төрледән-төрле төнәтмәләр куллана. Гарәп, харәзем якларыннан кершәннәр, ислемайлар, сөрмәләр, иннекләр, бәлзамнәр кайтарта. Бизәнмичә бер адым да атламый. Иренмәсән генә чибәр буласың шул. Шуңа күрә һәрвакыт кура җиләге кебек күренә. Кайбер бикәләр шикелле, кияүгә бирәсе кыз түгел, ашка саласы тоз түгел, дип, көн үткәнгә генә риза булып яшәми. Мәхәббәте шулай уяу тота аны.

Үзенә карата дәгъвасе дә зур Үрбәтнең. Кулыннан килсә, буен бер-ике карышка озынайтыр иде. Тәне дә йокарак, ничек кенә тырышмасын, барыбер ит кунмый. Ир-атлар йомшак, мул тәнлеләрне хуп күрә диләр бит. Мөхәммәдәминнең ризасызлык белдергәне юк. Ләкин барыбер күңеле бимазалана: дөрестән дә ошатамы ул аны, әллә Үрбәт бирә алмаган ләззәтне башка бичәсеннән аламы? Шушы икеләнү һич тынгы бирми иде бикәгә.

—Мөхәммәдәмин, син мине бигрәк үсендерәсең инде, җанаш, хатынның ни гәүдәсе, ни тәне дигәндәй, бер карачкы шунда...

—Барча хатыннарым арасында да син иң күркәме, иң чибәре, иң сөйкемлесе булдың, Үрбәт бикә, мин Ходайга мең шөкер...

Бераздан Мөхәммәдәмин Үрбәтнең бүләк комганын соратып алды.

—Язуларын укы әле,—диде.

Үрбәт ул язуларны яттан белә. Комганның муенына: "Бисмилләһиррахманир-рәхим", дип язылган. Корсак өлешенең нәкъ урта бер җирендә "Гыйкаб" шигыреннән өзек:

> Күп голәмә вә мәшаихләр шәһид
> Булдылар дине ислам нурилә.

Астагы җөмлә боларның барысын да бер җепкә тезеп, берләштереп куя: "Әссолтанел әгъзам гыйззед-дөнья вәддин Мөхәммәдәмин баһадир хан хәлләдулла мәликәһ вә әййдәсолтанәтиһи".

Иң соңында әһле вакыт: "Тарих тугыз йөз унбиштә мөбарәк рамазан аеның уникенче көне".

—Рәхмәт, бикәм, шушы сүзләр йөрәгемә бик якын, шәт, Аллаһы тәгалә гомер дәфтәремә дә яңа сәхифәләр өстәр.

—Аллаһы тәгаләгә, Мөхәммәдәмин, син җирдә кирәк,—диде Үрбәт,—син аның илчесе. Кыласы күркәм гамәлләрең әле бихисап.

—Амин!

—Ә хәзер бәү-бәү итәбез, балам,—диде Үрбәт,—төшләр патшалыгында безне сагынганнардыр инде...

Мөхәммәдәмин татлы йокыга талды. Ә таң алдыннан аның баш очында Газраил фәрештә пәйда булды. Ул ханның җанын бирәүгә дә комачау тудырмыйча, тыныч кына бакый дөнья күгенә очырып җибәрде.

Бу—тарих мең дә биш йөз дә унсигезенче елның егерме икенче декабрь көне иде.

Әлвидаг[3], Алла колы Мөхәммәдәмин!

***

Үрбәтне иренең җеназасын җыюда катнаштырмадылар, төрбәсенә дә фәкать өчесеннән соң гына бара алды. Ул өч көнне ялгызы гына догада утырды: Коръән укыды, багышлаунамәләр чыкты. Кеше күзенә күренмәде,

---
[3] Әлвидаг—хушлашу.

авызына бер тәгам ризык капмады. Хәтта еламады да. Чөнки ул иренең көннән-көн сүнә баруын, соңгы сулышына ерак калмаганын җаны-тәне белән тоеп тора иде. Мөхәммәдәминнең соңгы көннәрдә теле ачылуы да хәле яхшырганнан түгел, киресенчә, авыр хәлен җиңеләйтүгә бер омтылыш кына иде. Онытылып тору гына.

Әзер иде Үрбәт әлеге югалтуга. Үз язмышын да тәгаенләп куйган иде.

Төрбәдә аны Мөхәммәдъяр каршы алды. Күзләре монсу, чырае киткән иде шагыйрьнең. Баш иеп кенә исәнләште дә, ханбикәне кабер янына алып килде. Тын гына басып тордылар.

—Үз теләгем белән хан төрбәсенең әһле фарраш[4] вазифасын алдым,—диде Мөхәммәдъяр,—остазымны бик хөрмәт итә идем.

—Ул да сиңа ихтирам белән карый иде, рухы сөенер инде.

—Урыны оҗмахта булыр, шөт...

Янә тынып калдылар. Шуннан соң Үрбәт әйтте:

—Сиңа, морза, үтенечләрем бар иде,—диде.

—Бәлкем сарайда иркенләбрәк гәпләшербез,—дип, Мөхәммәдъяр ханбикәгә олы ихтирамын белдерде.

—Минем ул үтенечләрем мәрхүмгә мөнәсәбәтле,—диде Үрбәт,—үзенең баш очында аңлашу мәгъкульрәк булыр.

—Ихтыярың, ханбикә,—дип килеште Мөхәммәдъяр,—үтенечләреңне игътибар белән тыңларга әзермен.

Йомышларына керешкәнче Үрбәт, күңелемә сеңдереп калыйм, дигәндәй, төрбәне җентекләп күзәтеп бакты. Кыйммәтле асылташларга төренгән бу корылма бик күркәм иде. Һәр җөеннән, һәр сырыннан ханнарга хас затлылык бөркелеп тора. Шагыйрь Мөхәммәдъярның аны карарга алынуы Мөхәммәдәмин ханның абруена бәрабәр хөрмәт иде.

—Морза, мин сине үземнең әһле вафам[5] итеп күрергә теләр идем,—диде Үрбәт,—әгәр каршы килмәсәң.

—Нинди шөгыль-вазифа буенча?—дип сорады Мөхәммәдъяр.

—Васыятьнамәмне гамәлгә ашыру мәнфәгатьләрендә, морза.

—Ашыкмыйсыңмы, ханбикә, бу эштә салкын акыл зарур дип беләм.

—Бурычыңны вакытында башкаруны китап та мактый,—диде Үрбәт сорауны читләтебрәк.

—Ихтыярың, ханбикә...

—Мин васыятьнамәмне тәгаенләдем, кануни дәрәҗәгә китердем,—диде Үрбәт,—менә кәгазьләре. Алтын-көмеш әйберләрем бик күп минем. Шуларның бер өлешенә бәдәлче сыйфатында Мөхәммәдәмин хан өчен хаҗ кылырсың. Ул өлешне хәзер үк биреп куям.

—Мәрхүм өчен хаҗ кылу фарыз микән соң?—дип шиген белдерде Мөхәммәдъяр.

—Сәедтән белештем, Коръәндә бу хакта хуплау да, инкарь итү дә юк, шулай булгач, бәндәнең үз иркендә,—диде.

—Мин әлеге изге гамәлне чын күңелемнән башкарырмын, ханбикә.

—Әлхамдулилләһ, морза, инде икенче үтенечемә колак сал.

—Мин сиңа хезмәт итәргә һәрвакыт әзер, ханбикә.

—Үзе исән чагында Мөхәммәдәминнең шигырьләр мәҗмугасын инсанга күрсәтә алмадык,—диде Үрбәт,—нигәдер ашыкмады. Үземнең дә сәвәтем[6] җитенкерәмәде, күрәсең. Мәҗмуганың зарурлыгына ышандыра алмадым.

—Бу хакта мин үзем дә хәбардар,—диде Мөхәммәдъяр,—шагыйрьлегенне

[4] Фарраш—караучы.
5 Вафам—ышанычлы зат.
[6] Сәвәт—укымышлылык

әүвәл халык танысын, ә мәҗмуганың чираты шагыйрь вафатыннан соң гына житә, дип саный иде ул. Һәм мин үзем дә шул фикерне куәтлим.

—Тәкъдимең нинди соң, морза, алайса?

—Вакыт житте дип саныйм, ханбикә, Мөхәммәдәмин атлы татар шагыйре андый мәртәбәгә лаек.

—Рәхим итеп гамәлен башла, морза,—диде Үрбәт куанычына уралып,—бөтен вәкаләтләр сиңа бирелә. Бернәрсәдә дә кытлык, житмәүчелек кичермәссең. Вәгъдәме?

—Вәгъдә!

Мөхәммәдәминнең төрбәсеннән кайткач, Үрбәт тәһарәт алып, икенде намазын укыды, урын-жирләрен алыштыртты, үзе дә өс-башын яңартты. Түшәкчесенә, кәнизәк туташларга мул гына сәдака биреп, өйләренә кайтарып жибәрде. Шуннан соң ялгызы гына шактый ара уйланып утырды. Кәгазь-каләм алып, нидер язмакчы итсә дә, язмады, тәрәзә каршына килеп басты.

Урамда барысы да элеккечә иде. Мыж килеп тора: әледән-әле чаптырып жайдаклар узып китә, жәяүлеләр тыз-быз каядыр ашыга... Кала шау-шулы тормыш кичерә. Кояш та шул сүрән кояш, көндәгечә теләр-теләмәс кенә ялкау кар төшкәли...

И, шәфкатьсез дөнья. Нигә син шулай гаделсез соң? Әйтерсең лә, берни булмаган. Нинди мәрхәмәтсезлек. Мөхәммәдәмин вафат лабаса! Барча Казан жиренең бөек ханы вафат! Адәмнәр, бәндәләр, сез ханыгызны нигә шулай бик тиз оныттыгыз? Кайгы күлмәге кияр урында, үзегезнең гадәти вак мәшәкатьләрегезгә чумгансыз. Уяныгыз, мүк йөрәкләр!

Олы югалтуның чын бәһасен Үрбәт әле хәзер генә бөтен тулылыгы белән тойды. Ләкин аның үзе өчен бу бернинди әһәмияткә дә ия түгел иде инде.

Менә ул касәгә су агызды да, аңа берничә тамчы алдан хәзерләп куелган аксыл төстәге сыеклык тамызды. Бермәл жан авазын тыңлап, тын гына басып торды. Өченче көн инде һаман шул илаһи аваз: Мөхәммәдәмин, Мөхәммәдәмин, Мөхәммәдәмин! Бу авазны Үрбәт: "Бикәм, синсез миңа бик ямансу, ятим итмә, зинһарлап үтенәм, яныма кил",—дигән чакыру кебек кабул итә иде.

Минем үземә дә яшәү яшәү түгел, җанашым, дип пышылдады аның иреннәре, тормышымның бер мәгънәсе дә калмады, минем урыным синең яныңда, Мөхәммәдәмин, никахлы ирем, хәләлем янында. Миңе бу дөньяда бернәрсә дә тотмый. Хәзер аңладым, шушы хәлләрне тәгаенләп, ходай безгә бала бирмәгән дә инде. Ир белән хатынга бергәлек фарыз. Тиздән, бик тиздән, Аллаһы кушып, жаннарыбыз янә кавышыр. Бакый—ул мәңгелек. Без дә мәңге-мәңге бергә булырбыз. Бәхетебез һич төкәнмәс.

Әлеге ләззәтле хыяллардан Үрбәтнең күңеле күккә ашты. Бу мизгелдә аның аңы тәмам томаланган иде, үз ниятенең хаклыгына һичнинди шиге юк иде. Ул зур гөнаһ кылуын да, әчкерсез ышану белән тоткан газиз диненә хыянәт итүен дә, гомер бирү, гомер алуның Аллаһы, фәкать Аллаһы вазифасы гына булуын да аңлар хәлдә түгел иде.

Агу ханбикәне бик тиз куырып алды. Фәкать елмаю кунган ирен очларында: "Мөхәммәдәмин... жанашым..." дигән жөмлә генә эленеп калган иде.

Ходаем, ярлыка бу гөнаһлы гыйшык иясен!

*2005—2006 еллар.*



Рәсимә
Гарифуллина

## КЕМ КӨЧЛЕРӘК?

ПОЭМА-БАЛЛАДА

**...Нидер булды бүген,
Җил ярсыды,
Яр талларын иде усалланып,
Чулман өсләреннән әйләнде.
Канат җәеп күккә күтәрелгән
Аккошларга килеп бәйләнде.**

**Канат каурыйларын тузгытты да:
—Мин җил,—диде,—көчле барсыннан.
Үзем генә хуҗа бу җиһанга,
Очып йөрмәгез сез каршымнан.**

**Һәм кыя тау шунда телгә килде:
—Мин көчлерәк,—диде ул җилгә.
—Бил бирмичә мине егып кара,
Каршы торып кара син силгә.**

**Күтәрелде давыл, купты дулкын,
Урман—таулар торды калтырап.
Җилне кисеп яшен күтәрелде,
Камчы утлар янды ялтырап.**

**Пар аккошлар, яшеннәрне ярып,
Томырылды ярсу дулкынга.
Ялвардылар:
—Шәфкать итче, дулкын,
Якла безне, этмә упкынга?!**

**Ярдәм көтеп талпынды пар канат,
Бар җиһанга дәште хәл сорап.
Аккошларны тыңлап дулкын тынды,
Ә җил йөрде һаман... әлсерәп:**

---

Рәсимә ГАРИФУЛЛИНА—*шагыйрә; "Бүген ярат" һәм "Синең куллар минем кулда" исемле китаплар авторы. Балык Бистәсе районында яши.*

Җил тузынды, кыя ишелмәде,
Яшен тынды, болыт таралды.
Пар аккошлар, җилдән яшеренеп,
Дулкыннарга ятып хәл алды.

Шәфкать белән дуслык берләштеләр,
Табигатьтә булмый башкача.
Аккошлары кемгә сыенып соң,
Кызгануны белми башласа?

Әйтте кыя:
—Туктачы, җил, җитәр,
Үз-үзеңне белми ярсыма!
Яшен сүнде әнә, кояш чыкты,
Дулкын тынды. ...Тынды барсы да.

Ярсуыннан туктап уйга талды
Кыя тауга ятып ялгыз җил.
Ә күкләрдән сабыр аһәң акты:
—Җиргә килсәң, шәфкать белән кил!

Кояш нурларыннан җылы алып,
Өскә күтәрелде талгын җил.
Күрде: үз җаена хәрәкәттә
Гарасаты тынып калган җир.

Нинди матур, нинди идиллия,
Пар аккошлар күккә талпына.
Ут, су, һава бергә хезмәт итә
Бу җирдәге тормыш хакына.

Рәхәт булып китте кинәт җилгә,
Хозурланды җирне күзәтеп.
Нишләр иде шушы төзеклекне
Гарасаты куйса үзгәртеп?

Оят булыр иде җир каршында,
Ут белән су, һава алдында.
Нидер эшләгәнче уйлау тиеш
Алдын-артын,
Барын, барын да...

...Нидер булды җилгә,
Кинәт тынды.
Үз-үзенә акыл өйрәтте.
— Кем көчлерәк? — диеп тузынды бит,
Җирне, күкне, суны йөдәтте.
Көчтәмени мәгънә?
Акылда бит...
Бердәмлектә, тату яшәүдә.
Авызында кара кан булса да
Кайчагында ләм-мим дәшмәүдә.

Яманлыкка акыл кирәк түгел,
Җимерергә күп көч соралмый.
Кояш көлсен, яшьнәп яңгыр яусын,
Дөнья бөтенлексез торалмый.

Иң көчлесе—җирне яралтучы,
Ул теләсә акмый сулар да.
Кыя ава, кояш чыкмый тора,
Һава җитми хәтта суларга.

Ә калганнар барсы да бертигез
Һәм үзенчә көчле-куәтле.
Тауга күтәрелеп сызгырды җил:
—Яхшылыкка җигәм кодрәтне!

Дөрес, бер-береңә юл куймыйча
Бу җиһанда откан бик сирәк.
Акыл,
Шәфкать,
Бердәмлектә ул—көч,
Менә шуны тану бик кирәк.

Әллә нәрсә булды бүген җилгә,
Дуамаллык холкы югалды.
Үз гайрәтен акыл белән җиңеп,
Ак болытка таба юл алды.

Яр талларын сыйпап торгызды да,
Чулман өсләреннән әйләнде.
Аккошларга очарга көч өстәп,
Йомшак, җылы назга әйләнде.

Шушы нәсыйхәттән кальбе, җаны
Каурый болытлар күк сафланды...
Көчнең көче – көчләү белән түгел,
Акыл белән һәрчак акланды.

Гади җисем түгел ул бүгеннән,
Кальбе сукырлыгын җиңде җил...
Рухи бөтенлеккә ирешергә
Көчең булса гына җиргә кил!

Айдар
Хәлим

# ХУНВЕЙБИН

РОМАН-ЭПОПЕЯ

...Утызынчы еллар башында Кытай баскынчыларына каршы башланып киткән Дөнгән сугышында уйгырлар тагын да канга батырыла, илдә иртән коммунист, кичен гоминьданчы, төнен тулаем фашистка әйләнгән Шен-Ши-сәй режимы урнашты. Озакламый Көнчыгыш Кытайда коммунистлар белән гоминьданчылар арасында башланып киткән Гражданнар сугышы, Харбин, Чанчунь, Нанкин тарафларыннан җайлап тәгәри-тәгәри, Шенҗан—Шәркый Төркестанга да килеп җитте. Төннәр буе ухылдап шартлаган туплардан тәрәзә пыялаларының зең-зең килеп коелып төшкәннәре хәтерендә. Соныннан ачыклануынча, бу вакыйга 1936 елның гыйнварында булган икән—иртән торып, тышка чыкса, ни күзе белән күрсен: авылны яшел киемле хәрбиләр баскан. Кытайлар аларның дөнгән күршеләре агалы-энеле Дәвер хаҗи белән Сәламәтне тезләре белән җиргә чәнчеткәннәр дә, сорау алалар:

—Ниппун алтынын кая яшердегез? Ниппун алтынын кая куйдыгыз?

Ул чакта нибары алты яшь өстенә баскан Иркен йөгереп кайтса, өйләре тулы сары солдат. Сиксән бер яшьлек картаталарын үлем түшәгеннән торгызганнар да, уллары Кәррәметдин, Әгъләметдин, Галләметдин, Фәррәхетдин белән бергә бер үк аркан белән мичкә уратып бәйләп, газаплапмы газаплыйлар:

—Әйтегез, совет ышпиуннары, ниппунга дигән алтынны кая тыктыгыз?

Йортны уратып алган хатын-кыз һәм бала-чага елаша. Соныннан, күзе ачыла төшкәч, Иркен анлар: нәкъ шул чорда Рәсәйдә урыс совет чекисты бер татарны япун ышпионлыгында гаепләп, япун алтынын таптырган булса, Шәркый Төркестанда икенче бер татарны инде Кытайның гоминьдан хөкүмәте чекисты шул ук япун ышпиунлыгында гаепләп, шул ук япун алтынын таптырып яткан булган икән. Әмма шунысы кызык: үзләре басып алган милләтләргә карата икесе дә империалист булган урыс һәм кытай чекистлары үзара көндәш булган бит...

Армия хаҗәтенә дип болай да йөз баш аты, йөз баш дөясе тартып алынган Кәррәметдин белән Әгъләметдин, кулларындагы кәгазьләрен селки-селки, шартына китерү һәм әтиләрен бәйдән тизрәк ычкындыруларын теләп, Гоминьданнардан тартып алынган маллары өчен акча таләп иткән булдылар. Тик заяга. Таләп яңа талауларга юл ачып, үз башларына булып чыкты. Япунга шымчылыкта гаепләп икесен дә алып киттеләр һәм алар

*Дәвамы. Башы журналыбызның 5 санында.*

Кизләүгә бүтән әйләнеп кайтмадылар. Икесенең дә Гоби энәләре[1] өстендә җәзалап үтерелүләре турында хәбәрләре генә килеп ирешпе.

Шулай итеп, кайчандыр кытайларга Чин империясен төзеп биргән татар кавеме инде мең елдан соң да кытайларның энәле тактасына утыртылды.

Картаталары бу ике үлемне берьюлы күтәрә алмады. Зиһене алмашына башлап, бер елдан дөнья да куйды, мәрхүм.

Шулай итеп, Иркеннең сабый зиһененә, урыс гыйфрите, урыс коммунистыннан кала, Гоминьдан исеме белән икенче тупас көч—кытай гыйфрите, кытай коммунистлары килеп керде. Аның йөрәгенә кан сауды. Бәлки барлык төр золымга каршы көрәшергә дип ул нәкъ шул минутта ант иткәндер?

Абзыкайларының Гоби энәләре өстендә җәзалап үтерелүе турындагы хәбәр дөрескә чыкты. 1954 елда Иркеннәрне, Өремче Милли университеты студентларын, Пекинга сәяхәткә алып бардылар. Анда алар Гоминьдан төрмәсендә дә булдылар, җәзалау коралларын, шул исәптән, мамык тарый торган ая сыман итеп тактага кагылган агулы Гоби энәләрен үз күзләре белән күрделәр. Диварда 1944 елда шул энәләр ярдәмендә җәзалап үтерелгән "Уйгыр-нугай фетнәчеләре"нең исемлеге дә эленеп тора. Иркен үз күзләренә үзе ышанмады... Аяк балтырлары камырга әйләнеп, урынында чайкалып куйды... Исемлектә уникенче һәм унөченче булып, аның ике бертуган абзыкайлары—Кәрәмәтдин һәм Әгъләмәтдин Сәлахиләр бара иде. Бераз һушына килгәннән соң экскурсоводтан музейда, йә булмаса, башка архив фондларында бу мөгаззәбләрнең[2] шәхси әшләре булуы-булмавын сорады.

—Юк, тәкъсир,—диде кытайлы, кояштай елмаеп.—Кызганыч, сакланмаган...

Бу минутта кытайлының нечкә сары тешләре Иркенгә шундый ук агулы Гоби энәләре, ә кытайлы инде "интернациональ" кытай Шүрәлесе булып күренгән иде. "Әгәр Жир Шарын миллиард шүрәле басып алса?"—дип сорау бирде үзенә ул чакта. Бу сиңа Достоевский "женнәре" генә булып калмас. Хәзер килеп исенә төшсә, дөрес сиземләгәнен чамалый. Нигә, кытай шовинизмы белән котырган йөз миллионлаган хунвейбиннар шул ук шүрәлеләр булып чыкмадымени? Нәкъ шул көннәрдә Голжада гоминьданчылар татар җәмгыяте нәшрияткә әзерләгән "Чатта" журналының беренче санының җыелмасын тараталар, һәр җомгада кулдан чыгып килгән "Читтә" гәзитәсен яптыралар. Соңыннан ачыкланыуынча, Гоминьдан разведкасы кулына төшкән кулъязмалар арасында мәшһүр Гаяз Исхакыйның Берлиннан җибәргән мәкаләсен, журналның Берлинда, Токиода, Оттавада, Нью-Йоркта, Истанбулда булачак хәбәрчеләренең исемлеген табалар. Гоминьдан белән коммунистлар арасында кабынып киткән сугышны, әгәр аны Рәсәй чынбарлыгына күчереп аңлаткан очракта, кызыллар белән аклар арасындагы гражданнар кырылышы дип тә атап булгандыр. Тагын да ачыграк итеп әйткәндә, 1927 елда Кытайда хакимияткә килгән буржуаз-демократик Гоминьдан хөкүмәтен 1917 елда Рәсәйдә гамәлгә куелган Керенский Вакытлы хөкүмәте белән чагыштырып була. Урыс коммунистларының Ленин-Сталин партиясе исә кытайларның Мао компартиясенең анасы иде. Кытайда башланып киткән инсаннар сугышы кытай мандариннары[3]ның кул астында изелгән уйгыр, дөнгән (саны 25 миллион чамасы булган бу кытайлы мөселманнарны икенче төрле "хуэй"

[1] Кешене тереләй—җайлап,көн саен,өлешләп тиресен тунап үтерү өчен уйлап чыгарылган махсус энәләр җайланмасы.

[2] Мөгаззәб (гарәп)—газапланган,газап чиккән.

[3] Мандарин—борынгы Кытайда эре җирбиләүчеләр.

дип тә атыйлар), казакъ, үзбәк, татар кавемнәрендә моннан мең, йөз еллар элек югалткан дәүләтчелекләрен аякка бастыру теләген уятып җибәрде. Соңгы йөз ел эчендә Рәсәй гыйфритеннән качып, тугандаш, диндәш, телдәш уйгыр халкынын куенына килеп сыенган, шунда ирек һәм мал тапкан, искиткеч тырыш, үзләрендә борынгы Болгар, Казан ханлыклары, Алтын Урда дәүләтеннән килгән һәвәслекне саклаган, укымышлы, мәгърифәтле, намуслы татарлар, саннары ягыннан чагыштырмача аз булсалар да, барлык Шәркый Төркестанга үрнәк саналып, уйгыр милли-азатлык көрәшенең шаукымлы илһамчыларыннан берсе һәм хәл каләре катнашчысы бурычын намус белән үтәделәр. Нәтиҗәдә уйгырларнын Кытай изүенә каршы утызынчы еллар башында яңадан—инде ничәнче тапкыр!—башланган милли азатлык хәрәкәте кырыгынчы елларда башка төрки халыкларның да бердәм көрәш фронтына әверелде.

Милли азатлык өчен көрәшнең башлангыч дәверендә Мао Цзе-дун Гоминьданга каршы уйгыр хәрәкәте белән бер платформада торды. Гоминьдан уйгырларны Мао кул астыннан чыгару өчен 1944 елда Уйгыр милли-демократик җөмһүриятен игълан итте. 1949 елда Гоминьданны тезләндереп, хакимияткә килгәч, Мао үзенә хас икейөзлелек һәм мөртәтлек белән яшь җөмһүриятне изеп таптады һәм кичә генә үзенә аркадаш уйгырларны һәм алар белән бер сафта көрәшкән татарларны зинданнарга ыргытты.

Чаллының "Татар ашлары" йортында уйланып яткан ватандашыбыз Иркен ага Маоның нәкъ менә шул хыянәтенең гаепсез бер корбаны иде...

Бу хакта уйланганда арка үзәге сызлый башлый. Татар баласы буларак, аны горурлыктан гайре гарьлек тә билэп ала. Нишләмәк кирәк, без бу юлы да элекке тарихларыбызны кабатладык: әйтик, ун бөртек татар яшь уйгыр дәүләтчелеге өчен кан койды, шул ук татарның бер яна Шаһгалие табылып, аны сатты. Татарның Фатыйх Мөслимов—"Фатыйх Батыр", бертуган Мәргуб, Әсгать Исхаклар, Гаяз Симәнәй, Үтәмеш Сәмит, агалары Кәрраметдин белән Әгъләметдин Сәлахи кебек асыл угыллары уйгыр милли-азатлык армиясен һәм аның беренче хөкүмәтен оештыручыларның берсе булып, бу юлда шәһит китсә, Татарстанның бүгенге Буа районының Кишер Аксуы авылыннан чыккан икенче бер Борһан Шәһидуллин дигән баласы...

Бу кешене искә алу белән Иркен аганың йөрәге еш тибә башлады.

Борһан Шәһиди... Бар микән татар тарихында аның белән чагыштырырлык икенче бер ифрат та күпкырлы, аңлап та бетерә алмаслык катлаулы шәхес? Шаһгали катлаулы, әмма кайчакта кырык халәттә кырык иман кабул итеп, кырык халәттә кырык иманнан ваз кичә, бер-берсенә капма-каршы режимнарга хезмәт итеп тә, шуны батырлык итеп күрсәтә белгән Шәһиди тегеңәрдән күпкә катлаулырак кебек. Күз алдыгызга китерегез: егерменче гасыр башларында сәүдәгәрләр җитәгендә Казаннан Шенҗанга килә, милләтеннән ваз кичеп, үзен Шәркый Төркестанның Аксу каласында туып-үскән уйгыр дип оран сала... Кичә Казанның "Мәгариф" кибетендә самавырчы малай, бүген Чүгүчәкнең сәүдә ширкәтендә хисапчы, аннан— Шенҗан губернаторы Ян-Зын-шинның шәхси тәрҗемәчесе, юл эшләре һәм шоферлар укыту идарәсе җитәкчесе, Шенҗанның Берлиндагы коммерция вәкиле, Берлин университеты студенты, Зайсанда консул, "япон шпионы", алты ел төрмә, төрмәдә язылган " Уйгырча-кытайча-русча лөгать", соңыннан "Шенҗанда үткән илле ел" китабы авторы, Шенҗан хөкүмәте башлыгы, Шенҗан КГБсына нигез салучы бөек шымчы, уйгыр милли-азатлык армиясен коралсызландырып, "халык теләге" буенча Кытай

азатлык армиясен чакырып китертеп, Шәркый Төркестан җөмһүриятен гамәлдән чыгаручы, 1949 елдан коммунист, Мао Цзе-дун урынбасары, хунвейбиннар төрмәсенең ун еллык тоткыны, кытай, уйгыр, төрки телләр буенча телче-галим, дипломат, Маоны мактап шигырьләр язган шагыйрь, публицист, дини эшлекле, Кытай мөселманнары җәмгыяте житәкчесе, гаилә башлыгы, унлаган бала атасы... Болар барысы да Борһан Шәһиди кебек күпьяклы кабилият, сирәк талант, илаһи вә шайтани сәләтләргә ия булган шәхесне ачып бирәлми. Табылырмы уйгыр-татар тарихында аны ачар язучы? КГБ архивлары ачылмый торып, мөмкин эшме бу? Әйтегез, бу кадәр катлаулы, бормалы язмыш юлларына татарның шул ук каһәрле язмышы куып кертмәгәнме? Кемнәргә хезмәт иткән ул? Кытай башкисәре Ян Зың-шингамы, фашист җәллад Шең-Ши-сәйгәме? Чан Кай-ши белән Мао Цзе-дунгамы? Сталингамы? Әллә барысына бергәме? Бу үзенчә дастани-легендар шәхес күптән түгел—1989 елда Пекинда үлә, үзе уйлап чыгарган әкиятенә тиң васыять язып, Уйгырстан Аксуының Артыш авылында җирләнә. Мамадыш ягында да бар икән андый Артыш дигән авыл...

Хәзер, еллар аша, Иркен ага үзләрен битәрли: Мао коммунизмына артык ышаныч күрсәтүдән генә кыйратылды бит ул оеша гына башлаган уйгыр дәүләтчелеге!.. Җиңелү сәбәпләренең берсе Мао мәкереннән килсә, икенчесе—Сталин мәкереннән иде. Алматыдан Себер аша Пекинга Кытай-Уйгырстан сөйләшүләренә очкан уйгыр хөкүмәте делегациясенең Байкал күле өстендә кыйралып төшүе дә, татар Борһан Шәһидинең Шенҗаң Вакытлы хөкүмәтенең җитәкчесе итеп билгеләнүе һәм аның, яна "уйгыр" Шаһгалие ролен үтәп, утыз меңлек уйгыр армиясен коралсызландыруы да, нибары бер корпуска калдырылган гаскәргә җитәкче итеп егерме өч яшьлек полковник, соңыннан Мао имзасы белән генералга күтәрелгән татар Мәргуб Исхаковның тәгаенләнүе дә, азат Шәркый Төркестан җөмһүриятенең бетерелеп, "тыныч юл белән Кытайга куштырылу"ы да—болар барысы да Мао белән Сталинның килешеп эшләү нәтиҗәләре иде. Тарихка глобаль карасаң, шушы ике "бөек" милләт—урыс һәм кытай диктатурасы арасында кысылып җан бирде егерменче гасырда уйгыр-татар милли-азатлык демократиясе. Татарны Сталин 1918 - 1922 елларда татарсыз калган "автономия" биреп алдаса, уйгырны Мао шул ук юл белән утыз елдан соң—1949 елда кытайлаштырылган Шенҗаң-Уйгыр автономиясе белән алдады. Тарихлар никадәр охшаш!..Ливон походына җитәкчелек итеп Литваны кискән "генерал-фельдмаршал", Казан ханы булып алганнан соң, аннан да куылган, урыс гаскәрен Казанга өстерәп килеп, ватанын яулап биргән Шаһгалидән кайсы җире ким бу Борһан Шәһидинең? Төрки-татарны, Шаһгалидән кала, дөньякүләм саткан икенче "бөек" төрки-татар түгелме ул? Уйгырлар аны бер килеп акларммы?

Иркен аганың уйгыр милли-азатлык хәрәкәте җитәкчеләрен һәм ул хәрәкәттә шактый җаваплы урыннар биләгән татар агайларын да аклыйсы килә: башыннан аягына кадәр әмерикән һәм совет коралы белән коралланган бер миллиард кытайлыга каршы, булса, җиде корылмалы урыс винтовкасы, булмаса, аучы берданы[4], чукмар белән коралланган, орышта тәҗрибәсез, юньләп оешмаган, саны ягыннан нибары ун миллионлы уйгыр, ун-унбиш мең татар белән каршы торып булыр идеме? Юк, хакыйкатән, юк. Уйгырстандагы милли харитә дә бик чуар һәм, сәяси аң дәрәҗәсе түбән вә тотрыксыз иде. Анда Кытайдагы йөз дә бер кабилә-шиванәнең барчасы диярлек көн итеп, шулардан биш миллионлы дөнгәннәр, берәр миллионлы мангул, казакъ һәм кыргызлар, 200 меңле төрекмәннәр, яртышар миллионлы

[4] Америка уйлап табучысы Х. Бердан системасындагы чакмалы мылтык.

"и" һәм "ту", 200 меңле "бу", 300 меңле "ва" халыклары, уң белән сулны "печән-салам" дип тә аермыйча, уйгыр инкыйлабына бөтенләй битараф калды. Ә менә татарлар, сан ягыннан йөзләрчә тапкыр кимрәк булсалар да, карындаш уйгыр халкының милли-азатлык көрәшендә шактый зур урын тоттылар...

Галәтенчә, Сталин да ике фронтка Маодан ким уйнамады. Үзен мескен күрсәтеп, Нанкиндагы совет консулына махсус рәвештә ямаулы кием киеп барганы саен, Мао Сталиннан хәерхаһны муллан алды. Моны Сталин бик яхшы төшенә, әмма "күрмәмешкә" салына иде. Социализмның бар дөньяда җиңүе хакына шулай "беркатлы уйнап", бер кулы белән мәкерле Маога коралның иң яхшысын һәм мөмкин кадәр күбрәк биргән булып кыйланса, икенче кулы белән кытайларга каршы "идән асты көрәшен" дәртләндереп торды, мөстәкыйльлек өчен баш күтәргән уйгыр милли-азатлык хәрәкәтенә дә корал белән ярдәм итеп, уйгыр сепаратизмын яклады. Ул гынамы, сүздә Мао үтенече буенча Шәркый Төркестанны Гоминьданнан азат итеп, Мао кулына тапшырырга, шуның белән "бүленмәс" Кытай төзүгә ирешергә дигән булып, гамәлдә исә Кытайны эчтән бүлгәләп таркату, СССРга ышанычлы, Маога каршы булган төрки-уйгыр дәүләтен төзү һәм аны совет йогынтысына каптыру өчен Сталин Уйгырстанга бары тик татарлардан торган укчы дивизия кертте. Яшерен шартларда чик аша корал, кием-салым, азык-төлек кәрваннары агылды. Хәрби киңәшчеләрнең күбесе "гэбист" татарлар иде.

...Иркен 1940 елның көзен Голҗада каршылады. Яңа уку елы башлану белән, Үктәбер түнтәрелеше чорында атаклы мәгърифәтчеләр Габдулла һәм Хөснифатыйма Бубилар ачкан татар мәктәбенең дүртенче сыйныфына сабакка бирделәр. Моннан берничә ел элек кенә кияүгә чыккан Зөлхәбирә апасы - Муса җизнәсендә урын булмаганлыктан, Кәрәметдин зуратасының хатыны—Мөхафизә зуринәсенең әтисе Садыйк муллада торып укыды.

Голҗаны ул үз гомерендә икенче тапкыр гына күрде һәм... таң калды. Беренче күрүендә аның, Сөләйман картатасы белән гает намазына килгән биш яшьлек сабыйның, шәһәргә, аның үзенчәлекләренә, билгеле, игътибар итәргә зиһене җитмәгәндер, әлбәттә. Бик кызыклы, бик үзенчәлекле, бик тә тәфрикълы[5] кала икән ул!.. Уйгырлар, дөнгәннәр, казакълар яшәгән Иске Шәһәр һәм күбрәк татарлар яшәгән Яңа Шәһәр "гурыты" бер-берсеннән мәгъруре аерылып торалар гүй!.. Төпкелдән килгән кечкәнтәй кодалары күңелсезләнмәсен дип, ахрысы, Иркенне барча кода-кодачалар буйлап миһман кылдырдылар. Туган-тумачалары да, ай-һай, бихисап икән. Менә шул йорттан йортка кунакка йөргәндә, Иркен күрде дә инде: тар, берьюлы ике ишәк арбасы да үтә алмаган урам якка тома сукыр, балчык дуваллар[6] белән уратып алынган, тышка шылт иткән тавышлары да чыкмаган, тәпәш, яссы түбәләрендә җиләк-җимеш кипкән озынча, үзләре дә балчыктан өелгән, бер тәрәзәсез өйләр—боларда җирле халыклар яши; киресенчә,чиста урамнарында эскәк белән чүпләргә дә чүп әсәре табылмаган, төрле төсләргә буялган капкачлары—күз кабаклары белән урамга караган якты, берничә тәрәзәле, иркен, биек, еш кына беренче катлары таштан, икенче катлары шәмдәй сары, шыптагай бүрәнәләрдән салынган йортлар—боларында Рәсәй коллыгыннан ычкына алган татарлар яши. Монда да ясалма ярларына суклыгып һәм сулкылдап арыклар ага, монда да тирәкләр тынгысыз яфраклары белән ярсу җилләргә ни-нәрсә пышылдый-пышылдый серләшәләр, тик барыбер, ничек кенә булмасын, алар берсе генә дә әле кичә генә Кизләвен ташлап килергә мәҗбүр булган

[5] Тәфрикълы (гарәп.)—аерылып торган.
[6] Дувал (борынгы төрки.)—коймa.

Иркенгә туган авылы арыкларын һәм сомгыл сынлы тирәкләрен алыштыра алмый. Әй, ничек кенәләр сагына иде беренче көннәрендә Иркен туган авылын һәм туганнарын!..

Һәм татарлык җаныма бер
Фахирәнә[7] көйләнә,
Бар татарлык каннарым саф
Алсу сөткә әйләнә,
Таш күңелем эреп бер
Чын мәхәббәткә әйләнә...

Тагын да шул Сәгыйть Рәмидән. Аның шигырьләрен Голҗадагы гарәп теле укытучысы хәзрәти Габделгаскәр ярата һәм ятлата иде. Мәктәп мөдәррисе хәзрәти Габдулла Кормаши белән икәүләп алар һәр яңа ел алдыннан Сәгыйть Рәми шигырьләрен нәфис уку буенча “Сызла, күңлем!” дигән ярышлар уздыралар.

Барысы да заманны бар иткән кешеләр иде алар. Габделгаскәр хәзрәтләренең үзен генә ал. Гасыр башындагы татар әдәбияты һәм матбугатының, соңыннан мөһаҗирлектә чыккан татар китап вә белешмәләренең иң бай көтепханәсе анарда иде. Мөхтәрәм Гаяз Исхакыйларның Берлин, Токио, Истанбул эмиграцияләрендә дөнья күргән “Милли юл”, “Яңа милли юл”, “Төрек йорты” кебек гәзитә-мәҗмүгаларының тулы төпләнмәләре бары тик аның киштәләрен генә бизи иде... Шәркый Төркестанның иң укымышлы татары, яше туксанга җитүенә карамастан, унлаган баласы берлә биш гектарлык җиләк-җимеш бакчасы асрады, табигате белән сизгер табиб, барлык Шәркый Төркестанны күк чәй һәм как белән тәэмин итте. Эре сөякле, ап-ак сакаллы бу инсан, китап-каләмен өстәлгә кую белән кулына үзеннән дә зур китмәнен алып, авыр михнәттә булды. Каләмнән, белемнән тыш, абруйны, малны, азыкны һәм байлыкны менә шушы Олы Китмән дә китерде аңа. Әгәр киләчәктә Шәркый Төркестанда татарга һәйкәл куелса, ул мотлак уң кулына каурый каләм, сул кулына җир шары кадәр китмән күтәргән Габделгаскәр хәзрәт булырга тиеш... Габделгаскәр хәзрәтләрен... хунвейбиннар... ...Бу хакта сөйлисе килми!..

Күз аллары караңгыланды.

Хунвейбин дигән сүз телгә килү белән күз алдына көрәштәшләре килеп баса. Әнвәр Локман... Үтәмеш Сәмит... Рәүф Габит... Ике туган агасы Горфан Сәлах... Мәҗит Сәфәргали... Тәлгать Биктаһир... Зәңгәр күзле, ишелеп төшкән чәчле, кем? Рәүф Борындык... Фарук Сиражи... Какча гәүдәле, тиен кебек җитез үсмер, кем иде әле ул? Зыя Алдагар, әйе, нәкъ үзе!.. Гыйләҗетдин Хәйри...

Ул бармакларын бөгеп санады. Унмы? Ун. Уйгыр туганнарның милли дәүләтен төзү өчен көрәшкә чыккан ун татар егете. Беренче мәртәбә ул дусты Әнвәр белән 1944 елның 6 ноябрендә кулга алынды. Аңа нәкъ ундүрт яшь иде. Гоминьданга каршы татар, уйгыр, казакъ телләрендә өндәмәләр ябештергәндә эләктерделәр аларны. Төрмәдә тимгелле тиф йоктырды. Бары тик өч айдан, мәктәп мөдәррисе Кормаши китергән ышанычнамә кәгазеннән соң гына азат иттеләр мәхбүсләрне. Озакламый Гоминьдан уйгыр-татар яшьләрен көчләп армиягә ала башлады. Хәрби хезмәттән баш тартырга чакырып, өндәмәләр ябештергәндә Әнвәр ахирәте белән тагын да чак-чак эләкми калдылар. Ниһаять, яңа оешкан уйгыр милли-азатлык армиясе белән Гоминьдан арасында канлы сугышлар кабынып китте.

[7] Фахирәнә (гарәп.) – горур булып.

Голжада йорттан-йортка күчеп, яшерен яшәгән яшьләргә гимназиядә уку мөмкинлеге беткән: әгәр мәктәпкә барсалар, аларны шундук кулга алачаклар. Әнвәр белән Иркен ике дә уйламый Гаяз Сәмәнәй оештырган өч йөз кешелек татар батальонына язылдылар. Күп тә үтми, уйгыр гаскәрләре белән кушылып, уйгыр-нугай бригадасы булып йөретелә башлады.

Нибары унбише белән генә барган Иркен милли-азатлык сугышында үткәргән ике елы эчендә ир-егет булып чыныкты. Нинди генә хәлләргә очрамады да, нинди генә шәхесләр белән танышмады! Алар арасында өлкән яшьтәге көрәштәшләре—уйгыр-нугай бригадасы командиры полковник Мәргүб Исхак, аның урынбасары полковник Рәфыйк Байчура, соныннан Шәркый Төркестан Җөмһүриятенең баш сәркәтибе булачак Рәхим Сабирхаҗиев, журналист-шагыйрь Хәмит Төхфи, телче галим Гыйләҗетдин Госман барысы да татарлар иде.

Егет яшь дәүләтчелекнең язмышын хәл иткән Ачалы Түбә, Шуга Тау, Озын Болак авыллары янындагы атаклы сугышларда катнашты. Милли армия җитәкчелеге, корал-ядрә саега башлагач, Иркен кебек 15-18 яшьлек үсмерләрдән генә оештырылган диверсион төркемгә, Эләә хәрби округына үтеп кереп, Гоминьданның яшерен саклагычларыннан корал алып кайту бурычын куйды. Манас елгасын кичеп, Тәнре-Шәм тауларының алты мең метрга җиткән биш сыртын—Арал Түбә, Баш Түбә, Үлем Түбә, Башчыкмас Түбә, Тәнре Түбәләрне үтеп, җиде көн, җиде төн эчендә ач-ялангач булып, дошманның Бора-Таладагы цейхгаузларыннан йөз илле баш атның сыртына төяп, корал алып кайттылар.

Бу сәфәрдә мыек төкләре төртеп кенә чыга башлаган үсмерне кырлачлардан атылып төшкән чишмәләр, түбәләре болытларны тишеп чыккан тауларга караганда да ныграк таң калдырганы... сүнгән борынгы учакларны үз артларыннан яңартып бару булды. Моннан сигез гасыр элек кеше аягы басмаган биек тау кыяларында борынгы бөек Чыңгыз-хан баба, Уйгыр каһанатларыннан калган, ташландык сигнал манараларын очраттылар алар. Аңлады, мәңгелеккә үзе кичереп аңлады Иркен: ташландык ут-учакларны яңартудан, үз артыңнан маяклар калдырып барудан да илаһирәк гамәл юк икән дөньяда. Әйе, алар, ялангач куллы һәм ялангач йөрәкле татарлар, башлары йолдызларга орынган табигать балалары, нәкъ сигез гасырдан соң, уйгыр туганнары һәм үз азатлыклары өчен алышка чыгып барышларында борынгы манараларның серле күзәнәкләрендә утлар ялтлатып, һәр күзләүдә янган ут, янган ут янында кизү, азык һәм ягулык сумала калдырып бардылар да бардылар. Караңгы төннәрдә тау араларындагы көмеш томаннарда күнелләргә җылы нурлар сибеп, утлар җепселе талпына иде алар артыннан... Төрки бабаларның моннан сигез гасыр элек күтәргән манаралары бүген шул ук баскынчыларга каршы көрәшкән татар-уйгыр балаларына ярап куйды. Әле дә, көндәлек тормышын авыр сынаулар, шик-шөбһәләр биләп алган минутларында, кайчандыр яшь күнеленә уелып калган бу хатирәләрне ул һәрчак тетрәнеп искә ала һәм Тәнре-Шәмнең Башчыкмас түбәләрендә мәңгелеккә мирас итеп шәмдәлләр бөҗрасы яндырып калдырган бабалары белән очрашып киңәшкәндәй була...

...1944 елның язында киңәйтелгән татар мәктәбендә укучы яшьләрнең Гоминьданга каршы яшерен оешмасы оешты. Иркенне бу оешмага сыйныфташы Әнвәр Локман алып керде. Ул татар яшьләренең иң югарыдагы оешмасы җитәкчесе Гаяз Сәмәнәй белән таныш икән. Гаяз һәр татар мәхәлләсендә дошманга каршы шундый тәшкилят[8]ләр төзүне бурыч кылган, имеш. Аларның тәшкилятенә мәктәптән барлыгы унбиш

[8] Тәшкилят (гарәп) – оешма,бүлек.

сабакташы кушылды. Уйгыр гаскәренең Гоминьданга каршы сугышы татар өчен дә изге сугышка әйләнде, чөнки уйгыр дәүләтчелеге аякка баса алмаган, Гоминьдан хакимияте җиңгән хәлдә, урыс коллыгыннан качып килгән татар кытай коллыгына кереп батачак иде. Менә хәзер, ул вакыйгаларга илле өч ел узгач, чорлар һәм дәверләр чаршавын сыдырып, ул милләтенең алтын тамырыннан пәйда булган бу сирәк егетләрне күз алдыннан үткәрә башлады. Алар тарихтан исемсез югалдылар бит... Соң аларны тарихта калдыру исән көрәштәшләре, шул исәптән Иркеннең дә бурычы түгелмени?! Юк, язарга кирәк бу китапны, язарга кирәк!.

Шәркый Төркестан гаскәре сугышчыларының кигән формалары ифрат та матур һәм уңайлы иде. Иркен дә бик яратты аларны. Күзгедәй ялтырап торган күн итек, бүлтәеп торган зәңгәр галифе һәм кайма кесәле китель, аның өстеннән аркылы-торкылы күн пәртупи, зур йолдызлы ятма-погоннар, як-якка янтайган каракүл башлык, башлыкта кикрик, кикриктә ярымайлы йолдыз. Бу кадәр фырт һәм ыспай киемнәрне кемнәр тегә иде, дисез? Шул ук татар кызлары тегә иде аларны.

Биредәге өч меңләп татар гаиләсе арасында сөт аерту сепараторы һәм атаклы "Зингер" маркалы тегү машинасы булмаган гаилә бар иде микән? Юк иде. Алар бит заманы өчен бүгеннең иң соңгы маркалы "мерседес", "ролс-ройс"лардан да зуррак мөлкәт санала иде. Советларда мондый мөлкәте булган күпме кешенең башы катырга китте! Менә шуңа күрә дә Төркестандагы һәр татар гаиләсе яшь уйгыр гаскәре өчен кием тегү фирмасына әйләнде. Гаскәргә келәтләрдән олау-олау иген, карбазлардан бал, май һәм ит агылды. Ул гынамы? Гаскәргә сугышчы бирмәгән татар гаиләсе калмады. Әнә, Голҗадан унбер кыз үстергән Бәйрәмбикә түтки, малайлары булмагач, изге сугышка берьюлы өч кызын озатты. Сәлимә, Галия, Кадрия атлы иде алар. Исәннәрме? Әллә башкайлары сөргеннәрдә череде микән?

Урыс-Баскан, Тоз-Түбә, Чинга Йир тарлавыкларында берничә мәртәбә җимергеч җиңелү кичергәннән соң, артыннан СССРдан кертелгән корпус, уң тарафтан уйгыр милли гаскәре, алдан Маоның Кызыл гаскәре арасында торып калган Гоминьданга милли-азатлык хәрәкәте юлбашчылары белән сөйләшүләр башларга туры килде. Ниһаять, Маога каршы көрәштә ышанычлы арка булдырырга теләп, ул уйгыр халкының мөстәкыйль Шәркый Төркестан Җөмһүриятен (ШТЖ) төзү хыялы белән килешергә һәм 1944 елның 12 ноябрендә бу хакта бар дөньяга игълан итәргә мәҗбүр булды. Әмма монысы да чираттагы кытай хәйләсе белән типчеңгән иде...

1944-48 еллар сугыш шартларында аякка баса алмаган яшь җөмһүрият өчен фаҗигале, акланмаган өметләр чоры булып калды. Уйгырларның кытай изүенә каршы исәпсез-сансыз баш күтәрүләренең монысы да унышсыз тәмамланды. Дәүләт асрау тәҗрибәсе кулыннан алынган милләтнең яңадан дәүләтле булу хыялы да капчык төбендәге ком бөртекләре генә икән ул. Әйе, дәүләте хакында хыялланган милли мәнфәгатьчеләрне алдау-йолдау авыр түгел. Ничә мең еллаган дәүләтчелек тәҗрибәсенә нигезләнгән, дәүләти хәйләкәрлеге капчыгыннан тулып ашкан Гоминьдан һәм Мао Цзе-дун хөкүмәтләре, тирәннән уйланылган хәйлә нигезендә һәм нәкъ әнә шул ватандашыбыз Борһан Шәһиди ярдәмендә, имеш, үзләре тарафыннан "танылган" Шәркый Төркестан Җөмһүрияте гаскәренең искергән коралларын яңага алыштырабыз дигән булып, әүвәлдә барлык уйгыр-татар әфисәрләрен коралсызландырды да куйды. Гаскәр башсыз калды.

Иркеннәрнең диверсион төркеме, Голҗага үтеп, бу хәбәрне совет консулы Федотовка җиткергәч, консул әллә махсусан, әллә чын күңелдән "ялгышкан" булып кыйланып, ошбу хакта ачык матбугатта "кискен" нота

белән чыкты. Әмма Гоминьданның бу нотадан соң шылт итеп керфеге дә селкенмәде. Аның контрразведкасы исә, шуны гына көтеп торгандай, Иркеннәрне төрмәгә ыргытты.

Шул ук көннәрдә Гаяз Сәмәнәй житәкчелегендәге егерме татар каһарманы, кулга алынып, хөкемсез-нисез башлары киселде һәм коега салынды. Бу вәхшилек барлык Кытайны тетрәтте. Борәдәрләре шәһитләрнең богаулы аяк-кулларын, гәүдә кисәкләрен генә табып алып җирләделәр. Башларының әле булса табылганы юк. Кайларда череде икән бу алтынга бәрабәр татар башлары?

Уникe татар егетен төрмәдә алты ай тоттылар. Сукалы сабаннарга дүртәрдән җигелеп, җир ермачлады. "Шушы мәйданны сөреп чыксагыз, үзегезне азат итәбез", дисеннәр дә, ничек ышанмыйсың? Иркен аңлады: золым кешедән җир дә сөрдерә икән. Кайчак алтын күзләре, чокырларыннан тәгәрәп, сөрелгән кара туфракка төшкәндәй тоела иде.

Алтын дигәннән. Ата-аналары, туганнар хак алтын тапшырмаган булса, аларның алтын башлары да шул сука астындагы туфракта черер иде, бәлки. Кытай кешесенең акчага, бигрәк тә алтынга, туган ата-анасын сатарга әзер торуы борынгыдан билгеле нәрсә. Татар җәмәгатьчелеге, мәхбүсләрнең ата-аналары, туганнары, ришвәт биреп, зиндан шартларын яхшырту өчен бихисап ижтиһат кылдылар. Ахыр чиктә, гәперә торгач, килештеләр: бар татар җәмәгатеннән кеше башына берәр кило—җәмгысы уникe кило алтын җыештырып, төрмә житәкчелеген сатып ала алдылар. Алтын дигәнен кытайлар кесәсенә кергәннән соң, бу уникe егетнең зиндан документлары, имеш, "янгынга очрап, юкка чыктылар" да—алар, үзләре дә, ниһаять, иреккә чыктылар.

1948 елда Гоминьдан җиңелде.

1949да Кытай халык җөмһүрияте төзелде. Хакимият Мао коммунарлары кулына күчте.

Шул ук көннәрдә Мао уйгырларның 1944 елдан бирле "суверен дәүләт" исәбендә йөрегән Шәркый Төркестан җөмһүриятен йотты. Мондый йотыш Сталин белән Гитлер арасындагы Мюнхен килешүенең кытай-уйгыр варианты булды. Сталин мона кадәр үзе яклаган булып кыланган төркиләрне кытай авызына ыргытты да, кытайга каршы уенга мангулларны кертеп, аларны дөньякүләм күтәргән, үстергән булып уйнаклый башлады.

Мао да йоклап ятмады.

Гоминьдан уйгыр дәүләтчелеген булдырмаячагын яшермәгән иде. Шуна күрә җирле милли лидерларны үстермәде. Алар урынына Борһан Шәһиди кебек "нугайлар" асрады. Мао Цзе-дун исә уйгыр дәүләтен булдырабыз дигән уен уйнап, уенга сәяси көч булып өлгергән уйгыр вәкилләрен түгел, ә һаман да шул билгеле цирк көлкечесе—үзенең милли мәсьәләләр буенча "урынбасары" Борһан Шәһидины кертте. Маога милләте ягыннан уйгырга якын, "Татарстан Аксуы"нда түгел, ә ясалма рәвештә "Төркестан Аксуы"нда туган" дип игълан ителгән "вакытлы исәвән"—җирлексез каһан кирәк иде. Аның исәпләвенчә, уйгырның вакытлы ханы бурычларын рухи-тарихи мәнфәгатьләре, дине, теле ягыннан уйгырга бик тә охшаган "нугай" үти алачак иде. Шәркый Төркестанның дәүләти киләчәге турында сөйләшүләр алып бару өчен совет самолетында Пекинга юл алган ШТЖ житәкчелеге, шулар арасында ике нугай-татар министры, Байкүл өстендә "һәлакәткә" очрап, кыйралып төшкәннән соң, Мао, уйгыр оппозициясенең каршылыгын җимереп, Шәһидины Шәркый Төркестан Җөмһүриятенең Вакытлы Хөкүмәт премьер-министры итеп тәгаенләүгә ирешге. 1949 елда Кытай Халык Җөмһүрияте оешкач, Борһан Шәһиди Сталин һәм Маодан төшкән "тарихи бурычын" үтәп, ШТЖ гаскәрләрен тулаем

коралсызландыра алды. Аһ, ни зар, 1949-55 елларда Шенҗәң хөкүмәтенең башлыгы булган ватандаш-милләттәшебез Борһан Шәһиди кулы белән кытай империалистлары уйгыр мөстәкыйльлегенең соңгы валчыкларын ашады...

Үкенеч, бик тә кызганыч иде бу хәлләр. Явыз Иванга Казанын, Арча, Мамадыш, Алабугаларын яулап биреп, татарны урыска кол иткән Шаһгалиләр, Камай морзалар, Үктәбер түнтәрелешеннән соң янараллар кылычы аша совет зинданына кертелгән Урта Азияләр аша инде шул ук татар Борһан Шәһидилар кулы белән кытай зинданына кертелгән уйгырлар—бу без, болгар-татарлар, үзебез кол була торып та, башкаларны да коллыкка илтә торган "батырлыклар" өчен яратылганбызмы әллә, Раббым?! Солтангалиевләрен төрмәгә тыгып, татар Татарстаны урынына калдыктан калган чуаш-чирмеш Татарстаны оештырган Сәедгалиевләр—безме бу?! Иркен аганың ишетеп белүенчә, Казанда кемнәрнендер Борһан Шәһидины бер яклы гына бәһаләп,аны бары тик "милли каһарман"лык, алты мең кытай иероглифын белгән зур телче галим-голәмәлек күрсиенә утыртасылары килә, имеш. Юк, уйгыр-татарны кытай империясенә саткан яңа бер Тәфкилев кенә ул. Тагын бер "янарал". Үзе дә алданганмы? Әллә төптән уйлап эшләгәнме? Ничек кенә булмасын, Борһан Шәһиди—татарның сирәкләрдән сирәк бер фаҗигаи улы. Хакимияткә хунвейбиннар килгәч, татар милләтчесе буларак, тугыз баласы белән бергә кулга алынган һәм ун ел төрмә шулпасы ашаган бу искиткеч катлаулы адәмзат, Иркен ага уйлавынча, татар милләтенең бары тик "гарьлек тупсасы"нда гына тотылырга тиеш түгел. Көн килер, татарның ачык күзле тарихчылары аңа һәм башкаларга гадел бәясен бирер, иншалла!..

Соңыннан, Әмрикәгә күчкәч, Иркен ага Хәсән Туфанның уйгырларга теләктәшлек белдереп язган шигырен укыган иде. "Кем көчлерәк" дигән бу әсәр аңа "Казан утлары" журналы аша килеп ирешкән иде.

"Кем көчлерәк илдә—шул яши",—дип,
Уйгырларны йота Маолар...
Ерткычлык бит, бабай, вәхшилек бу
Күсәк белән җинә алулар...

Кичә генә уйгыр дәүләтчелеге өчен җан атып йөрүчеләргә кара көннәр башланды. Шул чорда оешып кына маташкан Берләшкән Милләтләр Оешмасының күз алдында Шенҗәң төрмәләре һәм Тәкла-Мәкан катыргалары "уйгыр-нугай сепаратчылары" белән тутырылды. Советлар Союзы һәм башка "халык демократиясе" илләренең күзен каплау өчен, Мао кичәге "мөстәкыйль" ШТҖ урынына кесә курчагы ШУАВны, ягъни "Шенҗәң уйгырларының автономияле вилаяте"н оештырды. Бер уйгырга ун кытай исәбеннән Уйгырстанны кытайлаштыру башланды. Кытай халык армиясе әмрикән студебеккерларга төяп, көне-төне миллионлаган кытайны Шәркый Төркестанга күчерде. Ун ел эчендә кайбер вилаятьләрдән күчерелгән кытайлылар саны гомумхалык санында бер проценттан житмеш процентка җиткерелде. Уйгырларга мал бәйләр, аяк басар урын калмады. Моңа кадәр эшсезлек, ачлык, ялангачлыкның нәрсә икәнен белмәгән Шәркый Төркестан ачлык дәрьясына чумды. Бер үк вакытта Әмрикә, Бөекбритания, Франция кебек бөек мәмләкәтләр алдында төчеләрдән дә төче, чын мәгънәсен Сталин белән Мао үзләре генә аңлаган, белгән, чынлыкта исә кем кемне ныграк алдый, шомарта ала дигән принциптан чыгып оештырылган "совет-кытай дуслыгы" башланды. Ике хәйләкәр төлке чабуыннан чыккан бу "дуслыкның", кем әйтмешли, май агып ташласаң, эт тә ашамас кайбер "милли" формалары,

мәсәлән, Уйгырстанда гамәлгә ашырылды.

Һәм... һич тә көтелмәгәнчә. Кечкентәй генә мисал. 1952 елда булса кирәк, Шенжән вилаяте авыллары һәм шәһәрләрендә "Кубанские казаки" дигән совет фильмы күрсәтелә башлады. Иркен аны соңыннан урысчадан "Коман качаклары" дип тәрҗемә итергә мөмкин икәнлеген белде: Кубань—ком, команнар иле, казак—качак дигән төрки сүзләр бит. Бу ике төрки сүздән торган урыс тәгъбиредер кү!.. Югарыдан төшкән махсус күрсәтмә боеруынча, аны карамаган кеше калмаска тиеш иде. Карар үтәлешен махсус органнар күзәтте. Кино башланыр алдыннан һәм тәмамлангач, ниндидер шикле Барый Мәрдән дигән бәндә ачыктан-ачык совет паспортлары алырга өндәде, СССРга кайтырга димләде. Голҗа татарлары бу фильмны йәрминкә клубында биш көн буе карадылар. Тамашачыларга татлы чәй эчерделәр. Икешәр фунт дөге тараттылар. Дөге төенчекләреннән тулган залда алма төшәрлек тә урын калмады. Шунысы хәтердә: фильмны урысчадан татарчага шул ук Барый—татарларга бөтенләй таныш булмаган кеше татарчага тәрҗемә итеп барды. Иркен ул кешене бүтән күрмәде. Соңыннан аңлашылуынча, ул органнар тарафыннан махсус йөретелгән шымчы-тәрҗемәче булган. Совет дәүләтендә калхуз тормышының никадәр гүзәл булуын, аш-сулардан сыгылып торган өстәлләрне, җыр-моң яңгырап торган авыл мәйданнарын шәрехләгәндә ул мактауларның чиген белмәде. Барысы да яхшы! Совет Ватанына кире кайтыгыз! Анда сезләрне көтә-көтә көтек булганнар!.. Ватанын сагынган татарлар куанычларыннан вә таң калуларыннан туктаусыз тел шартлатты. "Ничек кәттә яхшырган икән тормыш безнең илләрдә! Ничек гүзәл икән безнең ватаннарда эчке вәзгыять!"

Татарлар арасында ватанга кайту өянәге кузгалды. Теләүчеләрдән имза, акча җыю башланды. Совет һәм кытай хакимиятләренә бары шул гына кирәк булган икән. 1953 елның язында татарларның СССРга кайтырга чыккан ике йөз кешелек төркемен кытай сакчылары мылтык уты белән каршылады. Күпме кеше үтерелде, күпмесе гомерлеккә гарип калды, күпмесе хәбәрсез югалды!

Ватанга кайтып ирешү турындагы татлы уй капкынына Иркен үзе дә капты. Ул ата-анасыннан рөхсәт алып, нәселдән беренче булып туган илгә сукмак салырга ният итте. Әмма моннан алдарак булган фаҗигаләр кабатланмас микән дигән шөбһә тынгы бирми иде. Шуна күрә яшьләр оешмасы, бернинди һәлакәткә юл куймас өчен, кытай ягы белән бу хакта алдан килешеп, татар яшьләреннән 600 кешелек тәхәшшед[9] туплады. Тәхәшшед ришвәт өчен шактый сумма акча вә алтын туплады. Әүвәлдә аларны чәчәкләр белән кытай чик сакчылары каршылады. Ришвәткә дигән акча кытайлар кулына күчкәч, капкалар ачылды, ниһаять, аларны, елмаеп вә чәчәкләр күтәреп, совет чик сакчылары каршылады. Мөһаҗирләрнең яртысыннан күбесе Казан, Уфа, Пенза тарафларына юл алырга тиешләр иде. Әмма, совет чиген үтү белән, аларны Казанга түгел, хәтта Алматыга да үткәрмәделәр. Панфилов калачыгындагы резервациядә ипи-суда яшәтеп, алты ай буе чик буе корылмаларын төзеттеләр дә, как-сөяккә калдырып, Кытайдан чакыртылган студебеккерларга төяп, кире Шенжәнгә кайтарып ыргыттылар. Һәм... "нугай сепарат-автономчылары" дигән исем тактылар. Бу исем белән беркая, бернинди эшкә урнашып булмый иде. Уйгыр әйтмешли, хураз[10] кайда да бер төрле кычкырды.

Сәяси һәм хәрби көрәшләрдә шактый зур тормыш тәҗрибәсе туплап өлгергән Иркен туган Кизләвенә кайтып төшкәндә егермесе өстендә иде.

[9] Тәхәшшед (гарәп.) — тупланма, төркем, армия.

[10] Хураз ( уйгыр.) — әтәч.

Шәркый Төркестанда булып үткән инсаннар сугышы Иркеннең атасы белән ике бертуган агасы Кәррәметдин, Галләметдин белән бергә алардан туган туганайлары Хәсәншәех белән Илбарисны, туганнан туган сылуы Зөлхиҗҗәне вакытыннан алда гүргә керткән иде. Ул авыл зиратында вакытлы-вакытсыз тормыштан үткән Сәлахиләрнең җәсәдләрен зират итеп, дога кылды.

Авыл зураеп киткән иде. Барлыгы илле алты утар. Һәр утарында атасы яктырткан электр уты бар. Ул күрмичә торган алты ел эчендә буй-сын җиткереп, башлы-күзле булып өлгергән туганайлары һәм сылукайлары, гаиләләреннән бүленеп, башка да чыкканнар. Бу алты ел ата-анасын да ярыйсы гына талкыган, күрәсең. Олыгаеп, тартылып калганнар. Фәррәхетдин улы кайту хөрмәтенә бар нәселен җыеп, аш мәҗлесе үткәрде. Мәҗлес алдыннан ул Иркен белән аерым сөйләште.

—Ярар, угълым. Булыр-булмас җөмһүрият өчен житәрлек көрәштең. Хәзер үзең турында кайгырырга вакыттыр. Коммунистлар динне тоттырмыйлар. Без, Сәлахиләр, ары таба мулла булалмабыздыр кеби... Муллалыкны яшертен кылыш кирәк...

Аны өйләндермиләрмени? Атасы нидер әйтеп бетермәде. Кардәш-ыру җыелган мәҗлеснең һәр тын алышында Иркен атасы авызыннан теге хикмәтле сүзне көтте. Бу сүз аның өйләнергә тиешлеге хакында булырга тиеш иде кебек. Булды хикмәтле сүз. Тик, ни гаҗәп, өйләнү турында түгел иде.

—Монда чит кеше юк,—дип сүзен башлады Фәррәхетдин. —Барыгызга да мәгълүмдер ки, минем угълым Иркен бу—күпме быгырдаса да пешмәс җөмһүрият өчен алты ел сугышты, канын түкте, саулыгын сарыф итте. Әлхәмделиллаһ, исән-аман илләребезгә кайтты. Вәләкин, бик теләсәм дә, мин аны әлегә өйләндерми торырга карар иттем...

Табын авыр тын алды. Иркеннең сулышы кысылды. Мич арасында йөрегән әнкәсе каз бәпкәсе сыман нечкә генә итеп "кһе" дигән аваз чыгарып куюдан ары узмады.

—Әйе, Иркен угълыма әлегә өйләнү кирәк имәс. Бераз иртәрәктер. Аңа Голҗадагы яңа татар мәктәбендә укышын дәвам итү зарур. Авылыбызны саклыйсыбыз килсә, минем угълыма мөгаллимлеккә укыш кирәк... Укыш! —Атасы агара төшкән кашларын сикертеп, бу сүзне кәррә-кәррә кабатлады. —Иртәгәдән!.. Мин гимназия мөдәррисе Габдулла әфәнде Кормашига хат язып, аны тәкъдир итәчәкмен. Ил өчен көрәштә укыштан аерылган угълымны кабул кыл, диячәкмен. Кытайда—укымаган татар кем ул? —Ул үткер карашы белән Иркенгә карады. Егетне гүя булат кылыч айкап үтте. —Кытай мәмләкәтендә... укымаган татар—кол ул!.. Арба-кәш[11] ул!.. Минем угълыма укышка сезләр дә фатихагызны бирерсез, иншаллаһ. Авылыбызның мөгаллимәсе Фатыйха тутакайга да алмаш кирәк, шулай бит? Угълыбыз авылга мөгаллим булып кайтса, начар имәс иде, ә?

Ниһаять, барысы да Иркенгә карап, иркен тын алды. Алар куанган иде. Авылларына үзләренең мөгаллиме болады!..

—Токиода яшәп яткан шагыйремез Фәрит хәзрәтләре Ибраһим нәрсә дигән?—дип дәвам итте атасы.—

Башка бернәрсә кирәкми,
Халкым какмый караса,
Сызган кара буявым
Татарыма яраса,—

дигәнме? Безгә әнә шул кара буяуның өзлексез сызылып торуы зарури

[11] Арба-кәш (фарсы)—"арбалы кеше", арбада йөк ташучы, кучәрбашы.

гамәлдер, кардәшләр...

Табындагы һава тагын да сафлангандай итте.

—Аннан... Без... —Ул озак итеп сүзен алып китә алмый торды. —Без, Сәлахиләр, үзегез беләсез, Явыз Иван Казанны аударган көннәрдә Колшәриф мәсҗиде түбәсеннән орыс сөңгесенә сикергән арыслан—имам Колшәриф нәселен дәвам иткән дин әһелләребез. Муллалар, имам-хатыйплар, ягъни мәсәлән. Әмма бүгенге коммун Кытаенда дин тыелган, мөселман дине—аеруча зур золым астында. Бәс, шулай булгач... минем угълым... —Атасы як-ягына каранды. —Тыелып кына... яшерен генә булса да сабыйларыбызга дөньяви галәмәтләр белән бергә дин аслы-тамырларын да бирә алган булыр иде. Аннан, Голҗа татары—телен бозмаган татар!..

—Картая төшмәсме, Фәррәхетдин?—дип сак кына сорап куйды кемдер.

—Ирләр картаймый,—диде Фәррәхетдин тавыш килгән якка башын да борып азапланмыйча. —Ирләр йә ир була, йә ир булмый...

Иркеннең миендә ниндидер кояш ялт яктырып куйды. Гүя табынга нур балыкты, күк йөзенә яна йолдыз вакыйгъ булды. Тар урыннар кинәйде. Моңа кадәр кысылып утырган табын таманланды да куйды. Һәркем үз алдына канәгатьлек белән тамак кырып алса да, ризасызлык күрсәтү, борын астыннан мыгырдану кебек нәрсәләр колакка чалынмады.

Атасының шушы сүзләреннән соң Иркен нәкъ менә шушы мизгелдә ир-егет һәм мөселман ир-егете булып житеште кебек. Ул атасына карады. Атасы да, барлык табын да, хәтта әнкәсенең тәрәзә кашагаларына элгән чүпләм тастымаллары да нурлы иде. Ул бәлки гомерендә менә шулай аңлы рәвештә беренче тапкыр жирдә көч, сугыш, суеш исәбенә яшәүне, тупас көчне чит-ят күргән мөселман иманында яратылуына куанды. Ул шушы мәжлестән соң әтисен бар күкрәге, бар тын алышы белән яратты. Ул шушы мәжлестән соң татар шигъриятенең нинди көчкә ия булуына тагын бер кәррә инанды...

1951 елның көзендә, бер сыйныфка артка чигертеп, аны Голҗаның соңгы елларда зурайтылып, "гимназия" дип тә атала торган татар мәктәбенең алтынчы сыйныфына укырга алдылар. Голҗа татарларында туган телләренең яхшы саклануына бик тә куанды Иркен. Үзенең татарчасы өчен дә ул шул Голҗага бурычлы. Атасы бер нәрсәдә бихәбәр булган: татарның сирәк тәрбияче-галимнәренең күбесе, шул исәптән атаклы педагог Габдулла Кормаши да Голҗада юк иде инде. Соңыннан, бик күп еллар узгач, күпләр кебек, аның да "Кубанские казаки" кебек тамашаларга алданып Союзга кайткач, ГУЛАГта җәзаланып үтерелүе мәгълүм булыр. Гимназияне мактаулы шәһадәтнамә белән тәмамлаган Иркенне, "аз санлы кавем" вәкилләренә атап бүленгән Мао вакансиясе нигезендә, Өремче Милли университетының биология бүлегенә имтихансыз кабул иттеләр.

Уку уйгыр һәм кытай телләрендә алып барылды. Укытучылар арасында татарлар да бар иде. Алты мең иероглифтан мең иероглифны белсәң, кытайча укып-язып була. Шунысы гаҗәп: бер иероглиф ун төрле укыла. Бу Пекин диалекты белән Шанхай сөйләшен, боларын башка жирле сөйләшләр белән бутамаска ярдәм итә.

Университетта укыган чорда ул булачак хәләле—Мәдинәсе белән танышты. Өремче мөселман җәмгыяте мөтәвәлие Зариф хәзрәт кызы иде ул. Бик тә диндар, бик тә тәкъва Зариф хәзрәт намазларын күбесенчә мәчеткә килеп укыган Иркенне ифрат кыналар да яратты. Кызын жиде сыйныфтан ары укытмаган иде ул. Өендә генә калфаклар, кәләпүшләр, күкрәкчәләр тегә һәм аларны путал белән каеп, энҗе белән чигеп кенә утыра Мәдинәсе. И-их, аның чибәрлеген күрсәгез!.. Күз тимәсенгә ташлары ачык зәңгәр,

Кыска буйлы, йомры тәнле. Нәкъ куен иркәсе. Нәрсә төс, кеше төсе? Ул караңгыда да күренә алган матурлык. Ул сабыр, ә менә Иркен ут иде. Алар икәүләп шушы тормышның Вакытын вә Аралыгын сабыр ут белән тутыра. Тутыруын тутыра, тик менә Мәдинәсе генә чигү чигеп утыра. Атасы Зариф хәзрәт Мәдинәне беркая, хәтта абзар артына да ялгызын җибәрми. Бер-берсен сагынышкан яшь йөрәкләргә бер генә юл—хатлашу гына калды. Хатны тапшырырга да кеше кирәк бит әле, биллаһи газыйм!.. Анысыннан да чара таптылар. Кешелек тарихында мәгъшукларның бу кадәр хәйләкәр, бу кадәр башкитәр ысул белән хат йөртү очрагы булганы булмагандыр бәлки: мәчеткә килгән Зариф хәзрәтнең уң калушасындагы олтан астына сала торган булдылар алар мәктүпләрен. Мәктүпне уку бер ләззәт китерсә, аны олтан астыннан тартып чыгару яшьләргә икеләтә ләззәт, икеләтә шигърият, икеләтә яну шәфәгате өсти иде!..

Ике мәгъшук, иркендә калгач, үзләре генә анлап, шырык-шырык көләләр иде.

Алар яратышып өйләнештеләр. Бар тирә-як, туганнары мәгъшукләрне Таһир-Зөһрә дип атый иде. Берсен-берсе бер генә көн күрми торса да, үләргә җитеп сагыныша иде.

Иркен аганың күз алдында башта Кизләүнең аргы очы барып тоташкан куе кара урман, андагы кечке кояш нурлары белән шыплап тулган Йолдызлы Чоңгыл чокыры пәйда була. Әнә алар, кияү белән кәләш, җитәкләшеп, таулардан төшәләр дә, Йолдызлы Чоңгылның корыган нарат энәләре белән түшәлгән сары сукмагыннан киләләр... Кояш арба эзләренә сузылып төшкән шәүләләрне озынайта... Әнә алар, кияү белән кәләш, капка баганасы башына еш кидерелү-салдырудан чак кына өзелми түзгән бау бөҗрасын ычкындырып, ихаталарына керәләр... Күп тә үтми бу күренешне Сент-Льюистагы утарлары алыштыра. Анда картын көтеп-көтеп көтек булган, әмма килеп туган шартларда ике хезмәтчесе ярдәмендә менә бер елга якын инде дөньяны сөйрәп барган Мәдинәсе... Менә ничә ел инде тын кысу—астма чире белән җәфалана мескенкәй. Дымлы Нью-Йорктан коры һавалы Висконсин штатына күченеп китүе дә шул Мәдинәнең сырхавы белән бәйле иде. Биредә көтелмәгән бәхетсезлекләре өчен ир жаны бары тик үзен гаепләп, бары тик үзен талады. Ул, уйланып, күзләрен йомды... Юк, йомшарырга ярамый!..

Кортлары, умарталары нихәлдә икән? Аерталардыр инде. Тере гаилә булгач, аертмый була диме. Аерта күрсеннәр. Тик яшь көчләр читкә генә очып китмәсеннәр. Бер мәлне шулай, умартасы аертып, очып китәргә җыенган күч аның үзенә сарды. Умартачы язмышында сирәк күренеш диделәр моны. Басып торган җирендә коңгырт-сары баганага—кабыклы түмәр умартага әверелде ул. Бу хакта "Висконсин глоб" гәзитәсе язып та чыкты, аның кортлар сарган фотосурәтен дә бастырды.

...Институтны тәмамлар алдыннан, өйләнешеп, 1960 елда алар Кизләүгә кайтып төштеләр. Һәм мөгаллимлек итә башладылар. Озакламый ике балалары—Чыңгыз һәм Гөлмәрфугалары дөньяга килде. Шулай туганнары, ата-аналары белән бергә, гүзәл табигать кочагында дөнья көтеп, мал асрап, балалар үстереп, авыл мәктәбендә сабыйларга дөнъяви һәм яшерен генә булса да дини сабаклар биреп яткан вакытта, барлык континенталь Кытайны кара корым, кара болытлар, янган-көйгән кеше һәм мал тиресе, йон исләре белән биләп, Кизләү тарафларына көтелмәгән афәт килде...

Хәтерләүләр бер-берсенең өстенә менеп, туктау белми, аны торган саен үткән заманнар чоңгылына батырды. Ул хәтта Чаллы мәхкәмәсенә барасы икәнлеген дә онытты...

## VI

...1966 елнын май аенда "бөек ишкәкче" Мао Цзе-дун сиздереп кенә куйган "мәдәни инкыйлап", кинәя-кинәя, яна уку елы башланып торган көннәрдә Кизләү кебек кечкенә кышлакларга да килеп житте. Бу "инкыйлап" масштабы ягыннан Сталинның "халык дошманнары" эзләп "сыйнфый чистарынуыннан" күп тапкырга кинрәк, тирәнрәк, мәкерлерәк иде. Үзенә Алладай табындырып, чикләнмәгән диктатурага ирешү юлында төп чара итеп мәкер, миллион фанатикларның тупас ихтыярын сайлаган Мао тегермәне аша ун ел эчендә миллиард кытайлы үтте һәм шуларның йөз миллионы ошбу "инкыйлапның" корбаны булды. Пекин университетының жиде гыйльми хезмәткәре исеменнән "Ректор Лу Пин—антипартиячел кара юлбасар, этбаш, ревизионист!" дип диварга эленгән дацзыбао[12]сы икенче көнне үк Кытай Компартиясенең Үзәк "Женьминь жибао" газетасында күчереп басылды һәм барлык Кытай бер көн эчендә дацзыбаолар белән чәчкә атты. Мао башлаган көрәш, имеш, Үзәк Комитеттагы "этбаш-ревизионистлар" Лю Шао-ци, Дэн Сяо-пин, Чжу Дэләр житәкчелегендә тамыр жәйгән буржуаз-байбәтчәлеккә, "баеп черү"гә каршы көрәш иде. Илнең барлык юл чатлары барабан какты, быргы кычкыртты. Мао үзе "янарырга, яшәрергә чакырып" котырткан илле миллион яшь хулиган-хунвейбин туган илен армия һәм эчке органнар ярдәмендә "буржуаз черүдән коткару" өчен һөҗүмгә күчте...

...1966 елнын 18 августы. Кытайда башланган "Бөек мәдәни инкыйлап" рәсмиләштерелгән көн.

Пекин. Тяньаньмынь мәйданы. Бар дәүләттән җыелган егерме миллионлы башыбозык хунвейбиннар массасы алдында ак китель кигән Мао—Будда үзе күренде. Егерме миллион хунвейбин аякка егылып, тәүбәдә инанды:

—Коу тоу!..[13]

Хунвейбиннар барабан астында Маоның беләгенә "Хунвейбин" дип язылган иероглифлы бәйләвеч кидерде. Ул яна Будда, Гитлер кебек, берсүзсез, уң кулын югарыга ыргытты. Шундук мондый бәйләвечне илле миллион хунвейбин да беләгенә киде. Бу, гадәттә, бөек диктаторларның гына кулыннан килә торган "Яңа инкыйлап"ка—Бөек Тукмауга чакырган сигнал иде.

Секунд—хунвейбиннар барлык ил буенча үзләре жыеп алып килгән һәм тәртәләргә бәйләгән "этбашлар, советчыл ревизионистлар, сатлык жаннар, шпионнар, бандитлар, буржуаз контрреволюционерлар, жинаятьчеләр"не, борыннары белән жир сөрдереп, башларына кара башлык кидерде. Арттан ак экран пәйда булды. Анда "Дошманыңны төртеп ек һәм уң аягың белән анын өстенә бас!" дигән әмер язылды. Шундук аны жиргә орылган кара калпаклы "ревизионист" һәм анын өстенә аягы белән басып торган хунвейбин сурәте алыштырды.

Секунд—ил буйлап парткомнарда, заводларда, кооперативларда, уку йортларында, яшьләр, балалар оешмаларында "бөек чистарыну" башланды:

—Мине таптагыз! Мине изегез! Мин агулы елан!..Мин гаепле!..

—Мин үләттән калган үгез малы! Асыгыз! Кисегез!..

—Мин халкыма каршы жинаять кылдым!.. Үтерегез, гафу гына итегез!..

Мао хакына үлү—бәхет. Үлгәннәрне крематорийда яндыруның хакы өч тиен. Анысын да мәрхүмнең гаиләсе үзе түләргә тиеш. Ижтимагый алгарыш, прогресс нигезендә курку ята. Шәхеслек ихтыярыннан азат

[12] Дацзыбао (кытай)—язу, прокламация.
[13] Тәүбә итәбез! (Кытай.)

кеше генә алга бара ала. Мао шулай уйлый. Сәер капма-каршылык: Мао башлаган "инкыйлап" менә шушы карурман, шүрәле куркуы, кытыклап үтерелүдән куркуда тәрбияләп, бер миллиард халыкны сүзсез буйсыну аша һич тә көтмәгәндә бүгенге реформалар Кытаена китереп чыгарды. Гаҗәеп хәл: нәфес факторы шәхес факторына килеп ялганды.

Шенҗән-Уйгыр вилаятендә "Бөек Кытай социализмын юк итәргә маташкан уйгыр, казакъ, татар, төрекмән милләтчеләре"нең башларына кара капчык кидертергә тотындылар. "Җирле милләтчелек"не тар-мар итеп, интернационализмы нигезендәге кытай милләтчелеген чәчкә аттыру көндәлек күренешкә әйләнде. Болай "чистарынуга" түзә алмыйча, үзләрен юк итәргә теләгәннәр "хезмәт лагерьларында" электрлы чыбыкларга ыргылды, үзләре ясаган баскыч белән күккә менеп, үзләре төйнәгән элмәккә кереп асылынды, атылды, беркая да сикерә, элмәккә керә һәм атыла алмаганнар акылларыннан язып, чыпчык куа башладылар.

"Бөтен ил армиядән үрнәк алып яшәргә тиеш!"

"Галәм стихиясе никадәр тәртипсез булган булса, җәмгыятьтә дә шулкадәр тәртип һәм гармония була. Җәмгыятьтә мондый гармония булсын өчен аны һәр 7-8 елга бер тапкыр тетрәтеп, калтыратып, куркытып алырга кирәк. Рух җирне тетрәтсә, без кешене тетрәтәбез. Табигатьтәге тетрәнүләр җәмгыятьтәге тетрәнүләргә тиң булганда гына бар әшәкелек, пычрак адәм җаныннан үзеннән-үзе калкып, юкка чыга. Без бу пычрактан шулай чистарынырга тиешбез".

Мао күрсәтмәләре буенча һәр ун хунвейбиннан торган төркемгә бер хәрби цзаофань беркетелде. Хунвейбиннар белән Маоның 8341 санлы шәхси гвардиясе җитәкчелек итте. Штабның махсус элемтәсе, махсус транспорты, махсус финансы, махсус яшәү системасы булдырылды. Хунвейбиннарның кара колонналары илне нәзек кылыч белән аркылыга-буйга телгәләп чыкты. Маодан үрнәк алган һәр җирле җитәкче, аңардан да арттырып җибәреп, үз хунвейбиннарыннан армия оештыра башлады. Алар арасында үзара бәрелешләр кузгалды.

Иң көчле корал—танклар да, туплар да түгел, Илаһи Мао идеялары икән. Кытай компартиясе Үзәк Комитетының 1966 елның 5 августында үткән XI пленумында Мао Цзе-дун үз кулы белән диварга иң беренче дацзыбаоны язып элде: "Ревизионистик штабларга ут ачыгыз!"

Ил буйлап Мао рухнамәсе язылган миллиард бөти таратылды. Төшкә кадәр борчак өстенә тезләнгән хәлдә дога-цитат ятлыйсың. Төштән соң тез астындагы борчагыңны ашыйсың да—"этбаш, советчыл ревизионистларга, кара бандаларга каршы" һөҗүмгә күчәсең.

Классик мирас—Гомер, Шекспир, Гете, Толстой, Ван Вэй һәм Ли Болар учакларда дөрләп янды. Бер үк вакытта хунвейбиннар Тибәт башкаласы Лхасада унбер башлы, мең куллы, һәр кулында зәңгәр күз янып торган Будда һәйкәлен җимерделәр. Алар, Кытайның бөек рәссамы Ци Бай-ши каберен актарып ташлап, сөякләрен этләргә ыргыттылар. Алар Шанхайдагы Пушкин һәйкәлен җир белән тигезләделәр. Бүгеннән башлап Будда да, башка Илаһлар да кирәкми һәм була да алмый иде. Инде хәзер Мао үзе Буддага әверелде.

Шул исәптән, Голҗадагы классик татар көтепханәсе—кулъязма "Идегәй"ләр, "Йосыф вә Зөләйха"лар, Габдулла Тукайның "Шүрәле"ләре, Мирхәйдәр Фәйзинең "Галиябану" лары, Газиз Әлмөхәммәд, Салих Сәйдәш җырулары язылган тәлинкәләр көлгә әйләнде.

Эш тәмам. Аш тәмам. Уку тәмам. Матур киенү, сөенү, сөелү тәмам. Китаплар, фильмнар чыгару, уку, шигырьләр сөйләү, бию—барысы да тәмам. Болар барысы да буржуаз череп чыгуның соңгы чагылышлары.

“Череп чыккан” шәһәр халкы, пролетариат, зыялылар мылтык астында авылга—коммуналардагы тормышны өйрәнергә һәм яхшыртырга дип юлга чыкты. Хәрбиләштерелгән коммуналарның кичәге иген һәм дөге игүчеләре—крестьяннар шул ук мылтыклар сагында шәһәрләргә юнәлде. Шәһәргә авылны, авылга шәһәрне алга җибәрергә боерылды. Бер халык, бер ана-ата балалары, юл өстендә очрашып, бәрелеште һәм үзара “чистарынды”. Авылга килгән эшчеләр “батрак дошманын” көтеп, яланда, урылмаган басуларда, заводка килгән крестьяннар исә, “пролетар дошманын” көтеп, бетон иденнәрдә аунады.

“Эшче дөгене игенче-дөгечедән остарак үстерә! Игенче-дөгече детальләрне эшчедән дә остарак ясый!. Эшче игенчене, игенче эшчене алыштыра алсын!..

“Шәһәрләрдәге металлургия заводлары—буржуазия калдыгы! Авыллардагы һәр керәстиән хуҗалыгын металлургия заводына әйләндерик!”

Заводлар туктады. “Буржуаз тимер станоклар” кырып җимерелде. Мао күрсәтмәсе буенча керәстиән кооперативларына ун миллион тонна корыч җитештерүгә ирешү буенча социалистик салым салынды.

Алар һәр адәмзатка миллион чебен-черки, мең чыпчык, мең суалчан, мең тычкан үтерү салымын салдылар. Кытайда чыпчыклар кунар чыбык тапмады. Кая барсалар да, куылып, кунар урын тапмый, хәлләре бетеп, капчыкка үзләре егылып төштеләр. Агачларны ак корт, көя, тәннәрне, чәчләрне—бар дөньяны тимрәү басты. Тәлинкәдәге шулпада селәүчennәр йөзеп йөреде. Буржуаз черүдә гаепләнгәннәрне өсләренә бүре, аю тиресе ябындырып, аренага чыгардылар һәм аларны дөге аракысында тилергән бурзайлардан талатып үтерделәр...

...Иртәнге сәгатьләр иде. Сабакка чакырып, мөәзиннең азан әйтүе булды—Голҗа юлыннан авылга барабаннар кагып, мегафоннар кычкыртып, музыкалар акыртып, як-якларына кызыл комачларга чатый-ботый иероглифлар язып тутырган хәрби студебеккерлар керде. Юньле хәбәрләргә сусаган шәкертләр тәрәзәләргә ябырылдылар, әмма һәр автомобильдә шыплап тулган кораллы адәмнәр, чалыш йөзләр, радиаторларына асылынган эт башлары күреп, “Китапны—утка, үзен—хезмәткә!” “Эт-баш”ларны, “сыер-аяк”ларны изәбез!” кебек һәм башка шундый шигарьләр укып, сабыйларның йөзләре кара янды. Шундук мәктәпне башларына кызыллы-каралы яулык бәйләгән кораллы яшьләр уратып алды. Алар кытай һәм татар телендә акырып-бакырып, бар мәйданны кызыл гунсандан[14] байраклары белән тутырдылар.

—Гадәттән тыш игълан! Барыгыз да мәктәп мәйданына!. Сабантуй!..

Мәктәп мөдәррисе Иркеннең вакыт белү өчен түш кесәсеннән сәгатен чыгаруы булды, озын буйлы, кызыл яулыгы астыннан түбәтәй читләре күренеп торган бер Олыдөрес аны чылбыры-ние белән йолкып, идәнгә томырды:

—Хезмәт кешесенә сәгать кирәк имәс!.. Сәгатьсез яшәргә таярланыгыз![15]— диде икенчесе. —Яшәсен Мәңгелек Сәгатебез—Мао!..

—Хау!—дип куәтләде аны кытайлы. —Хау хензе[16]!

Сәгатьнең күзгә күренмәс бер сиртмәсе, корпустан очып чыгып, тәрәзә пыяласына орылды да, зеңләп куйды.

Халыктан таланган сәгатьләр учакка очты. Анда йорттан-йортка йөреп җыелган дивар сәгатьләре, кайчылар, эскәкләр, тимер-томыр, алтын-

[14] Гуңсандан(кытай.) – коммунист.
[15] Таярлану (гомумтөрки) – хәзерләнү.
[16] Яхшы! Булдырдың! (кытай.)

көмештән ясалган һәммә әйбер-сәйбер, тормыш, бизәнү кирәк-яраклары яна иде инде...

Иркен тирәннән, бик тирәннән ниндидер бер алтынчы тоемы белән тойды—бу көтелмәгән гыйсъянның, көтелмәгән Бөек Җимерелүнең башлангыч минутлары гына иде. Бу башыбозык гыйсъянчылар Тормыш Сәгатен йөрешеннән туктата алмасалар да, ошбу минуттан башлап Сәгатьнең күчәренә аркылы таяк тыгып, аны алга түгел, бары тик артка гына йөртә башлаячаклар икән. Безнең эрага кадәр биш мең ел элек шумерлар гамәлгә куйган Кояш Сәгате дә, безнең эрага кадәр ике мең ел элек хәяткә кытайлар үзләре алып килгән Су Сәгате дә, моннан мең ел элек дөньяга гарәпләр бүләк иткән Ком Сәгате, Җил Сәгате, Шәүлә Сәгате, Җир Сәгатьләре барысы да Кешелеккә һич кирәкмәгән нәгъләт кенә булганнар икән, тәүбә вә әтәүби!.. Кешелек уйлап табып җәфаланган шул барлык төр сәгатьләрнең бүген без кулланган бөек варисы—моннан дүрт гасыр элек милләте белән һолланд Христиан Гюйгенс уйлап тапкан Маятниклы, ягъни Телле Сәгать бүгеннән башлап Вакыт исәбен түгел, Җинаятьләр исәбен генә исәпләячәк икән...

Хунвейбиннар халыкны һәм укучы сабыйларны мәктәп мәйданына дүрт почмаклап тезде. Җәмәгать уратып алган мәйдан уртасына сәхнә итеп куелган ачык әрҗәле студебеккерны кораллы хәрбиләр бөжрага алып ураткан. Шулчак репродуктордан Кытай Халык Җөмһүрияте гимны яңгырады.

Моңа кадәр гимнны мең тапкыр тыңлаган һәм мең тапкыр кушылып җырлаган гавам бу юлы да, гадәтенчә, көйне эченнән генә көйли башлаган иде, хәрбиләр кулларындагы эрзин таяклар белән халыкның тезләрен чүки башлады:

—Тезләнергә! Тезләнергә!..

Тезләнүнең нәрсә икәнен күптән белгән өлкәннәр кушканны шундук үтәде, ә менә әлегә аның нәрсә икәнен белеп өлгермәгән, кушканга куштан булып бармаган сабыйлар тегеләр эрзин таякларын тез башларында фортепиано уйнап чыкмыйча, тезләнүне бар дип тә белмәделәр.

—Мәктәпләрне ябу лязим! Укыш бүгеннән туктатыла!—дип үкерде калай репродуктор. —Хезмәтчәннәрдән байбәтчә тәрбияләгән буржуй китаплар утта үртәлә![17]

Кемдер мөгаллимәләрнең өстенә савыты белән кара сипте. Мәдинәсе кайда? Ул да алар арасында булырга тиеш!.

Шул мизгелдә мәйдан уртасыннан алтын телле ялкыннар күтәрелде һәм хәрбиләр кочагыннан кочак-кочак китап учакка очты. Анда чормалардан, мәктәп көтепханәсеннән җыелган әсбаплар, тарихи Ватанда яндырылудан исән калып, туган ил, чит мәмләкәтләрдән мөһаҗирләрнең арка капчыкларында, ат йөкләрендә, паровоз идәннәре астында качырып-постырып ташылган изге "Коръән", "Кыйсса—әль-әнбия", "Һәфтияк"ләр, барлык иске вә яңа мәгърифәти байлык—Тукайлар, Исхакыйлар, Кәримиләр, Тинчуриннар, Такташларның китаплары, биредә бердәнбер данәдә булса да саклана алган "Ил", "Тормыш", "Яшь юксыл", "Эшче", "Яшь көрәшче" һәм башка бик күп билгеле һәм билгесез басмалар, алардагы меңләгән авазлар, аһәңнәр, аһылдаулар, пышылдаулар, каргышлар һәм лаф орулар кеше тавышлары чыгарып яна башлады...

Һәм—яндыручылар татарлар, татар хунвейбиннары иде.

—Нәсел тикшереп, милләтчелек белән шөгыльләнү—буржуйларга хас сыйфат! Нәсел-нәсәп дигән искелекне онытыгыз! Нәсел шәҗәрәгезне—утка!..

[17] Үртәү (гомумтөрки)—яндыру, ут төртү.

Иркен үз күзләренә үзе ышанмады: картатасы кулында берничә генә тапкыр күрә алган нәсел агачы-шәҗәрәне—махсус иләнеп, махсус үлән сыгынтыларында тотылып, кәгазь калынлыгына калган һәм ана көрән каләм белән буыннар исемлеге язылган бозау тиресен-пергамонны бу тукмак борынлы Олыдөрес, ике дә уйламый, утка томырды. Каян, кайсы Сәлахи чормасыннан кулга төшергәннәр аны?!

Аһ!.. Иркен учакка таба тартылды.

Әмма ул хәрбиләрнең тимер кыршавы эчендә иде.

Күрмәсеннәр, дигәндәй, күзләрен чытыртатып йомды. Ул арада—абайлап та өлгермәде—Бораганский боерыгы белән шәҗәрәне уттан алып чыктылар. Каяндыр адашып килеп чыккан юлчы янгыр сибәләп алды. Янгыр тамчылары чыжылдап, фасоль борчагы кебек, ут өстендә шартлый башладылар.

Авазлар үксеп елый иде. Тәкате бетеп, күзләрен ачты. Янгыр туктаган, учак дөрли иде. Ул тагын алга ыргылды. Кыршау нык, бик тә нык иде.

—Менә ул сезгә кирәкле бердәнбер әсбап—бөек ишкәкчебез Маоның үлемсез "Тәгълимат"ы!—дип каркылдады татарча калай тавыш. —Иртә таңнан кичкә кадәр без юлбашчыбызның шушы "Иман шарты" буенча яшиячәкбез! Иртәгәдән таң белән бөек Маоның "Иман шарты"н яттан сөйләми торып, сез хәтта йомырка да сата һәм сатып ала алмаячаксыз!...

Хәрбиләр Мао кыяфәте төшерелгән кечкенә бөти сыман кызыл китапчыклар таратып чыкты. Автомобиль әрҗәсенә бер төркем кызыл яулыклы яшьләр сикереп менде. Араларыннан озын буйлы, бака уылдыгы кебек чүмечбашлы, шыксыз озын куллары өстендәге аклы-каралы кителе буйлап тезеннән дә аска төшкән, шуның аркасында төсе-башы арба күчәре тиеп дегетләнгән башакны хәтерләткән егет ишарәте алга чыкты һәм нотык тота башлады. Икенчесе аның авызына мегафон китереп тыкты. Чүмечбаш бер авазда да ялгышмады, гүя язманы төне буе ятлаган иде.

—Мин бөек ишкәкчебез Мао башлаган мәдәни инкыйлабның Голҗа төрки-татар хунвейбиннары шурасының рәисе Хажгали Бораганский булам! Аркадашларым белә, мин Бораганский гына түгел, мин барча шайтаннарны кимергәнский вә җимергәнский!... Бүгеннән биредәге татар тормышы Голҗа төрки-татар хунвейбиннары шурасына буйсыначак! Миңа, аңлашылдымы? Мин бүгеннән татарның казанчысы да, казначысы да, каһаны да! Кытай социализмын җимереп, совет ревизионистларының тегермәннәренә су койган уйгыр-татар сепаратистларының тамырын корытачакбыз! Шылдымы?

—Шылды! Шылды!..—дип шуылдашты халыкны уратып алган хунвейбиннар. —Шылмаса, шылдырырбыз!.. Яшәсен бүленмәс Кытай җөмһүрияте!..

Теге табан борынлы Олыдөрес шушы Бораганский үзе икән. Ул каяндыр үз тирәсеннән, кесәсеннән чыгарган сыман, бер лилипут-кешечекне өстерәп чыгарды:

—Менә бу Голҗадан сатлык җан, этбаш-ревизионист Рәхимҗан булыр! Без аны күргәзмәгә үзебез белән җөртәбез!.. Ул быелтыр Советлар мәмләкәтендә сәяхәттә булганда Идел парахутларыннан Казанга сокланып карап торган, патшабикә Сөембикә манарасын манзара кыйлып, Татарстанны тарихи ватаныбыз дип атаган! Кичә Голҗа канткомы аның эт-башын вә сыер-аягын бөек Мао Цзе-дун хәзрәтләренең коммунистлар фиркасеннән чыгарып, чүплеккә ыргытты! Ул үзенең бүленмәс Кытай мәмләкәтенә хыянәт итте. Әйт, рәхимсез Рәхимҗан, син бердәм Кытай мәмләкәтенә хыянәт иттеңме?

—Иттем, иттем!—дип елан сыман сыргаланды Рәхимҗан. —Бүгеннән

башлап, тарихи ватаным Татаристан да, Магулистан да түгел! Ун мең еллык тарихы булган Цинь вә Хань мәмләкәте!..

—Ишеттегезме, җәмәгать?!—дип дәвам итте сүзен Бораганский. —Рәхимҗан кебек һәр сатлыкҗан белән шулай булачак. Хәзер мин сезләргә "Хунвейбиннар Манифесты"н җиткерәм! Тыңлагыз! Без—яңа ислахчылар[18], кызыл хакимиятне кара көчләрдән саклаучылар! Бөтендөнья пролетариатын буржуаз ревизионистлардан азат итү—безнең бурыч! Мао тәгълиматын тормышка ашыруда... соңгы тамчы каныбызны да кызганмаска ант итәбез! Хәзер нотык—Кашгар яшьләре лидеры Җирән Сафага!.. Кайда төртенеп йөрисең, Җирән Сафа?

—Мин монда, каһаным!

—Гәпер, Җирән Сафа!..

—Мин даһи Маоның тугры шәкерте—"Мәдәни тазарыну инкыйлабы"ның Кашгар Татар Ширкәте рәисе Сафа Галимәрдән булам...—дип сөйләп китте Җирән. —Ул мине сезләргә вәхи[19] кылды. Шенҗаң татарлары өстеннән хакимлек итү безнең кулга күчә. Без—күмәк. Бүген без йөз, иртәгә мең булачакбыз. Бүгеннән башлап без татарлар арасында Маога тугрылык буенча сәтсиәлистик ярыш ачабыз. Безнең рөхсәттән башка яшәгән урыннарыгыздан кузгалу түгел, базарда хураз да сата алмаячаксыз!.. Яшәсен Мао!..

—Болар Кашгардан да, Голҗадан да түгел...—диде кемдер. —Болар Борһан Шәһидинең Пекиннән китерткән сатлык татарлары ди!.. Халкымызны моннан кудырту өчен бик зур акча алганнар ди...

—Советлар мәмләкәтендә, безнең тарихи ватаныбыз Идел-Урал штатларында тормыш ифрат та начарайды кү,—дип дәвам итте Җирән Сафа. —Өч тапкыр Советлар Союзы каһарманы очучы Муса Гәрәй кардәшемез бүген Уфа базарында катык сатадыр кү!.. Советлар Союзы каһарманы шагыйрь Муса Җәлилнең китаплары яңадан чыгарылмай башлады, Әминә дигән ясалма исем астында йөргән җәмәгате—керәшен хатыны Нина Константиновна төрмәдә утырады!.. Кем Советларга кайтырга теләй? Рәхимегез!

Сафаның башы утынлык түмәре кебек тумпак, чәчләре кызыл-җирән һәм аның кызыл-җирән чәчләре маңгаенда урын калдырмый кашларына кадәр үскән иде.

—Безне Төркестанның барлык җәмәгате мәсъүл күрә һәм инана. Хунвейбиннар тәшәббесе[20] сезгә тамаша алып килде. Аның беренче кыйсемендә Голҗа хунвейбиннары концерты, икенче кыйсемендә Кизләү авылы халаегының Бөек ишкәкчебез Маоны котлау сабантуе булачак! Коу тоу!..

—Коу тоу!—дип кабатлады өер.

Автомобиль әрҗәсенә бәбәй итәкле ак күлмәк кигән, чәчләренә калфак кадаган татар кызы атылып чыкты һәм өзелеп-өзелеп шигырь укый башлады:

И арышым, арышым, сәндә бәнем, табышым.
Сәндин башка юктыр, бәнем, бу дөньяда тормышым.
Мао Зе вансуй!..

—Яшәсен Мао!—дип кабатлады өер. —Мао Зе, вансуй!..

И богдаем, богдаем, бирде сәни Ходаем.
Башың тулуб үсүб йитсәң, үзем килеб ураем.

[18] Ислах (гарәп.)—яңарыш, реформа.
[19] Вәхи кылу (гарәп.)—күңелгә иңдерү, югарыдан төшерү.
[20] Тәшәббес—(гарәп.)—башлангыч, инициатива.

Алтын сәнин сакалын, көмүш сәнин саламын,
Ходай сәни бирсен дийүб яхшый йиргә салаем[21].
Мао Зе вансуй!

—Мао Зе ун, вансуй!—дип жикерде хунвейбиннар. —Яшәсен Мао!..
—Яшәсен Мао!—дип кабатлады сәхнә.
—Мао Зе ун, вансуй!..—дип жикерде хунвейбиннар.
—Яшәсен Мао!—дип үкерде мәйдан.

Чакырылмый килгән гүзәлләр гөсләләр, кубызлар һәм мандолиннар чене астында Маоны данлаган татар биюе башланды. Аларны аларган күзле, әллә анаша ашап, әллә аракы эчеп юнәлешен югалткан, торганы белән шыр тилене хәтерләткән кыз алыштырды. Ул сары сарафанының гармун итәген жилләрдә өерелдереп, ыштансыз шәрә ботларын алдан да, арттан да күрсәтә-күрсәтә, саф урыс телендә жырлап биеп алды:

На столе стоит стакан,
А под ним тарелочка.
Мой миленок цзаофань,
А я—хунвейбиночка!..

—Ас-са-а-а-а!—дип гөрләп кул чапты сәхнә. —Ас-са-а-а!..

Иркен шәрә хатын өчен укучыларыннан оялып, карашын жиргә төшерде. Каян тапканнар? Үзләре белән йөртәләрме? Шәркый Төркестанда иске имандагы старовер-дутовчылар гомер кичерә. Ай-һай, аларның балаларын болай йөртеп вә жырлатып булырмы?

—Хәзер тамашаның икенче кисәгенә күчәмездер кү,—дип сүзен дәвам итте Жирән Сафа. —Бондагы халкымыз дүрт парәгә бүленер, сабантуй күрсәтер кү: кыз вә ир балалар, оныклар вә онычкалар—ике парә! Ирләр вә хатын-кызлар—ике парә! Агалар вә бабалар, апалар вә әбиләр—ике парә!..

Иркен инанды: алда аларны моңа кадәр күрелмәгән тетрәнүләр көтә икән. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Аллаһым, бер үзең рәхимлек күрсәт!.. Хунвейбиннар этә-төртә ир-ат, хатын-кыз, ир һәм кыз балаларны төркемнәргә бүлә башлады. Кемдер мөдәрриснең борынына камчы сабы белән төртте:

—Уйгыр-татар милләтчесе—сепаратор Иркен Сәлахи үзү болады!..

—Әйдә, безнең көчне күреп баксын!.. —Күкрәгенә шундук кара хурлык тактасы—"хэйпай" китереп тактылар. Аңа "Эт-баш ревизионист" дип язылган иде.

Ул кыршауның эченнән чыгарга омтылыш ясады. Бу мөмкин түгел иде.

Тәртипсез халык диңгезендә үзе дә бер йомычкага әйләнгән Иркен һәркайда Сәлахиләр нәселен—1944 елда Гоминьдан зинданында жаннары кыелган Кәррәметдиннең, Әгъләметдиннең хәләл жефетләре Мөфәхафизә белән Оркыя жиңгәләрен, аларның балаларын, балаларының балаларын абайларга тырышты. Чайкалган диңгез дулкыннарында йөрәкне парә-парә телеп Сәлахиләрнең таныш чалымнары чалынып киткәндә, аларның кем булуын ачыкларга теләп уктала, әмма дулкын кайный, бутала: байтак гомерен читтә үткәргән мөгаллим авылының яртысын тәшкил иткән Сәлахиләрнең кайберләренең исемнәрен дә хәтерләп бетерми иде!..

Ул хатын-кызлар төркемендә Мәдинәсен күреп калды. Йә, Ходай!.. Йөрәге жу итеп урталай теленде. Аның бәбәй итәкле, ак алъяпкычлы

[21] Гаделсез репрессияләнгән шагыйрь, тарихчы, педагог Касыйм Биккол шигыре кулланылды (1868–1937).

күлмәге хунвейбиннар сипкән карадан каралган. Ул бит өченчеләренә көмәнле!.. Күзләрен кан басты. Саклый күр, Ходавәндә!.. Исәнлек бир!.. Шунда ук карашында бертуган апасы Фәгыйлә, ике туган энекәшләренең һәм агаларының хәләлләре Гадәния, Хәмдия, Кәшифәләр чалынды. Дүрт яшьлек Чыңгызы, ике яшьлек Гөлмәрфугасы өйдә кем кулында икән?! Галләметдин агасының хатыны Сөмбелә җиңгәсенең, аларның балаларының һәм оныкларының, аларга кушып, әнисенең, Суфия тутасының берәдә күренмәве аңарда бераз гына өмет тудырды. "Балаларны алып базга качкан булырга тиешләр,—дип уйлап алды Иркен. —Мотлак шулайдыр."

Моңа кадәр балаларның бары тик шатлык авазларын гына ишеткән мәктәп мәйданы күз ачып йомганчы кычкырыш, елаш, тарткалаш мизанына әверелде.

—Хәзер бөек бер шаркылдык тамаша күрсәтәмез!—дип кычкырды Җирән Сафа. —Сабыйлар агузларына кашыйк кабып, йомырка чаптырырлар!..

Хунвейбиннарның бер төркеме балаларның авызларына кашык тыгып, анда эрзин йомыркалар салып, камчылый-камчылый, йөгертә башлады. Камчы астында киләчәккә йөгерүчеләр арасында Сәлахиләрнең яшь буыны—Сәрдәрләр, Мәгъфүрләр, Камилләр, Фәхернисалар бар иде.

—Хәзер ир-җегетләр ике парәгә бүленеп аркан тартырлар!.. Яшәсен Мао!..

Башка хунвейбиннар, аны-моны төшенеп тә өлгермәгән ирләрен ике төркемгә бүлеп, аркан тарттыра башлады. Хунвейбиннар кыршавындагы Иркен исә, арканчыларның уртасында калды. Ике каршы якка бүленгән татар бер-берсен җиңәлми тартыша, өстери, ә Бораганскийлар аларны үзара янә дә өстереп, һау-һаулап кыйный иде:

—Сөйрә, уйгыр-татар сепараторы!.. Өстерә, этбаш-ревизионист!

Бу юлы аның сыртында да ут чәчрәтеп, камчы ялтлады.

Иркен авыр гер булып арканга асылынды. Каршы яктан арканны туганнан туган энекәшләре Сабирлар, Сәйфетдиннәр, Шакирлар тарта иде.

—Апа-җаннар вә әбиләр, нибәрә-чибәрәләр,[22] аяк очларуна капчык киеп, мәйдан йөгертүрләр кү!—дип үкерде мегафон. —Агалар вә бабалар шыррак баганага шуышып менерләр кү!.. Яшәсен Мао!..

—Коу тоу!.. Коу тоу!.. Коу-тоу!..

Аксакаллар төркемендә... ул ни күзе белән күрсен... сиксән дүрт яшьлек Гыйльметдин зуратасын, җитмеш җиде яшьлек атасын күреп телсез калды. Иркен аларга таба тартылды, әмма аны һаман да җибәрмиләр иде.

Дистәләгән көчәйткечләрдән кытай музыкасы яңгырады. Бырғы кычкыртты. Барабан дөбердәде.

Хунвейбиннар аякларына капчык киеп алган апалар һәм әбиләрне, көмәнле киленнәрне, житкән кызларны, ир-егетләрне камчы астында барысын бер юлы сикертеп-сикертеп йөгертә, йомырка каптырып чаптыра, гер ташыттыра, аркан тарттыра, чүлмәк ваттыра, зиһеннәренә ни килсә, шунысын кыландыртып, ат кәмите башлады. Чынлап та, бу тамаша көлке булган хәлдә дә халык үзеннән көлми, көлә алмый, ә бәлки кинәттән генә өстенә ишелеп төшкән кайгысын эченә йотып, сыкрап сулкылдый иде...

Иркен үзе дә сизмәстән арканны кулыннан ычкындырды, ике ягындагы тотып торган түгәрәк йөзле яшь хунвейбиннарны селтәп очырып, өердән читкәрәк тайпылып чыкты да, бер-берсенең өстенә менеп таптый, изә башлаган ташкынга каршы китте:

—Тукта-а-а-а!.. Тукта-а-агы-ыыз!..

—Шымыгыз!.. —Җирән Сафа ишарә итүгә музыка шавы да, бу ат

[22] Нибәрә (төрки)—онык; чибәрә—оныкның баласы.

кәмите дә тынды. —Уйгыр-нугай милләтчесе, Кытай социалистик дәүләтен таркатып, бөек уйгыр җөмһүрияте оештыру тәкълидчесе[23] Иркен Сәлахи үзе!.. —Ул ана сөлге ыргытты. —Әйдә, бик көчле булсан—көрәшәек!

—Татар көрәше—иреклe. Мин камчы астында көрәшә алмаем!

—Бәлки, камчы астында гәпләшә алырсыныз?! Без яшь буынга бөек сабак бирәчәкмез. Багыныз!..

Хунвейбиннар Иркенне һәм анын укучыларын өстерәп, уртага чыгардылар.

—Кояшыбыз Мао төзегән социалистик җәннәттә яшәү хокукына сез тәүбә аша гына ия була аласыз!—диде Хажигали Бораганский, кечек Будда рәвешенә кереп. —Сез бүгеннән мәдәни инкыйлапнын "кызыл сакчылары"! Тоу хоу!..

—Сина кояшыбыз Маонын жирдәге урынбасары Борһан Шәһидидән сәлам килтердек!.. "Мин бүленмәс Кытай дәүләтен жимереп, уйгыр дәүләтен төзүче нугай ышпиунымын",—дип Коръән үп! Мин Микиткрүчүк белән Ләнитбрижныпп[24] агенты, дип ант ит, этбаш!

Жирән Сафа Иркеннең башына басып, борынын Коръәнгә төртте.

—Мин, татар-нугай буржуаз милләтчесе, совет ышпиуны, бүген Кытайдан Ысысысырга чыгып качам!—диген. —Ант ит!

Хажигали Бораганский, кумтасыннан чыгарып, Жирән Сафага нәрсәдер бирде. Жирән Сафа исә аны үзенә хас гасабилык белән Иркеннең аяк астына ыргытты:

—Үз аякларың берлән шәҗәрәнне тапта!.. Кытайдан, атан-ватаныннан ваз кич!..

Иркеннең аяк астына аккош сыман канатланып, аксыл-саргылт тукыма очып килеп төште. Янә дә күзенә күренәме әллә: бу—иләнә-иләнә, махсус үлән төнәтмәләрендә тотыла-тотыла, киптерелеп, аяда киерелеп, кәгазь калынлыгына калган, актан-ак, якты йөзенә көрән каләм белән бар нәсел тарихы язылган, бая, күз алдында инде бер тапкыр учакка ыргытылып, гүя көлдән очып чыккан һөдһөд кошы кебек, уттан исән чыккан бозау тиресе-пергамон—Сәлахиләрнең нәсел шәҗәрәсе иде. Картатасы үлгәннән соң йола буенча иң өлкән агалары—Кәрәметдин гаиләсендә яшерен сакланган сөекле истәлекне үз гомерендә берничә тапкыр гына күргән, хәзер исә күрү белән Иркеннең йөрәге чыгып ычкынырдай булып типте. Каян тапканнар? Ничек белгәннәр?! Агыйдел, Тубыл, Иртеш елгалары, Бараба далалары, Алтай таулары аша ат арбасында һәм җәяүле бабаларының җылы култыгында Төркестаннарга килеп житеп, нәселгә тарихи барлык вә борәдәрлек биреп, илаһият эстәгән бу Бөек Тамыр тарихы—Олуг Шәҗәрә юкка чыгу алдында иде...

—Иманыңа кил! —Иркен хунвейбиннар арасыннан Будда сыны сымак күтәрелеп каткан Бораганскийның алдына барып тезләнде. —Син бит бөек Туран баласы!.. Әле безнең эрага кадәр барлык Чин империясен дер калтыратып торган халык син түгел иденме?! Алтай-Хинган тауларын урталай ярып, дөнья могҗизасы булган Бөек Кытай диварын жужаннар синнән котылу өчен төземәгәннәр идеме?! Үзеңне түбәнсетмә, борәдәрем!.. Син—татар баласы!

—Мин татар да, нугай да түгел! Мин Мао баласы—хунвейбин! Кызыл сакчы!.. Боргычлагыз үзен!..—диде Бораганский. —Сез уйгырлар берлән Бүленмәс Кытай мәмләкәтенә кул күтәргән иденезме, менә алыңыз!.. Без, халыкара бәйнәлмиләлчеләр, татар милләтчелеген тамырыннан корытамыз!.. Яшәсен Мао!..

[23] Тәкълидче (гарәп.)—яклаучы,башкаларга ияреп эшләүче,бу урында "башкаларның көрәштәше" мәгънәсендә.

[24] (Бозып әйтү). СССР житәкчеләре Никита Хрущев,Леонид Брежнев.

Бораганский, Жирән Сафа һәм башка хунвейбиннар Сәлахиләрнең нәсел шәҗәрәсе өстендә алмашлап бии башладылар. Күрән кына гөле калдырган гарәби эзләр өстендә шайтан туе башланды. Иркен карашын ташламаска тырышкан саен күзгә керә иде бу манзара. Гөпе-гөпе бииләр, биегән саен шәҗәрә тиресенең күрән каләм язган канатлы гыйбарәләреннән утлы күзләр чәчрәп чыга. Гөпе-гөпе: әнә, иң ерак бабасы Сәлах-карачның күзләре! Гөпе-гөпе: әнә, Сәлах-карачның угылы Җиһанголның утлы күзләре! Гөпе-гөпе: әнә, Җиһангол угылы Ходайколның күзләре чәчрәп оча!.. Иркенгә билгеле булган унөч буын—Ходайкол угылы Айтуганның, Айтуганның угылы Таңтуганның, Таңтуган угылы Көнтуганның, Көнтуган угылы Хәсәнбәкнең, Хәсәнбәк угылы Касыймның, Касыймның угылы Габделһадиның, Габделһади угылы Мөхәммәднең, Мөхәммәд угылы Ягъкубның, Ягъкуб угылы Сөләйманның, Сөләймән угылы Фәррәхетдиннең күзләре көлтә-көлтә нур булып чәчрәп чыга да, бу чәчрәп чыккан күзләр һаваларга очып, йолдызларга әверелә...

—Кызганыңыз! —Ул канатларын җәеп, Шәҗәрәне каплап, җиргә ятарга омтылды.

Бирмәделәр. Өстенә ташландылар. Укытучыларын яклап, Иркен артыннан Кизләү мәктәбенең йөзгә якын укучысы ябырылды.

—Бола кут-тәрәсезме? Фетнә?!

Дистәләгән куллар шакарып алып, мөгаллимне баганага боргычлап бәйләде.

Кулында картатасыннан калган бүре суккан чукмар юк иде шул.

Әйе, болар кайчандыр дөньяның санитары бурычын үтәп, илләргә илләр, дәүләтләргә дәүләтләр биргән, әмма бердәмлек җитмәү аркасында, бөек төрки-һуннуларның нәселе булудан туктаган корт-паразитлар иде; әйе, болар төрки-һуннарның туры варислары булган төрки-татарлар түгел, болар инде төрки-татарның чит-ят җирләрдә гарипләнеп, үзенә каршы үрчеп өлгергән шайтаннары—хунвейбиннары болады.

Болар—һунну-төрки һәм чин кавемнәре арасында моннан өч мең ел элек башланып киткән низагның бүгенге дәвамы, бу—кайчандыр тугыз йөз туксан тугыз хань кәбиләсен буйсындырган тугыз йөз дә туксан тугыз меңлек һунну-төркиләрнең, үз гайрәтләренә урын таба алмыйча, Манжур, Амур, Орхон-Йәнәсәй җәйләүләреннән һау-һаулап чыгып, Адриатика ярларына кадәр барып житеп, илсез-дәүләтсез калып чигенгән, инде торабара үзләре тугыз йөз туксан тугыз меңгә калып, үзләре ук миллиардка җиткереп үрчеткән ханьнәр арасында торып калып, жужан мәкере, жужан шымчылыгы, жужан вәсвәсәсенең коллары сыйфатында инде үзләренә каршы яңа кырылышны башлаган төрки-татар курчаклар иде...

Болар—Ленин-Сталин һәм Мао коммунизмнары арасында илсез, динсез, телсез калдырылып, инде Никита Хрущев, Леонид Брежнев һәм Мао коммунизмнары арасында йоласыз, бәйрәмсез дә калырга тиешле татар балалары—Иркеннең үз энекәшләре иде...

Шәҗәрә инде юк иде. Үзен хурлык баганасына өстерәгән арада ул аны күзеннән яздырды. Шулчак күзеннән язып барган Төп Шәҗәрәне ул Жир Шарының теләсә нинди почмагында эзләп табарга, нәсел агачы—Шәҗәрә белән бергә нәселнең исән тармакларын, чыбык очларын барларга, бәйләргә, төйнәргә, бер чыбыркы итеп үрергә ант итте...

—Кизләү мәктәбе сабакыларына мәңге онытылмас сабак!.. Яшьләрне буржуаз тәкәбберлек һәм дини горафатка батыруда карт буын—аксакаллар гаепле. Болардан чистарыну йоласын аларның "сәтсиәлистик ярышын"нан башлыйбыз!..

—Хи-хо-хо-хи!—дип хырылдап җавап бирде күк гөмбәзе Жирән Сафаның

гырылдык боерыкларына.

Кая карама, казан асканнар. Әгәр биредә мона кадәр биредә бу аксакаллар бар тирә-якка суган-сарымсак, асыл тәмләткеч, гөреч[25] исләре анкытып, итле пылау кылган булсалар, бүген исә хунвейбиннар бу казаннарда халыкны пешекләү өчен су кайната иделәр... Кытайлар коткысы буенча үз милләттәшләрен җәзалаудан ләззәт тапкан татар хунвейбиннары аркаларыннан төрткәли-төрткәли, сакалларыннан сөйрәп, каяндыр Голҗа татар гимназиясенең гарәп теле мөгаллиме Габделәскәр хәзрәтне, әтисен, зурәтисе Галләметдинне, аннан тагын да ике аксакал—Җамалетдин белән Зөлфәкәр абзыйларны алып килделәр һәм бишесен дә баганаларга терәтеп куеп, балакларын сызгандырдылар.

Габделәскәр хәзрәт... Ничәмә-ничә еллар узуына карамастан, оныта алмый Габделәскәр хәзрәтне Иркен. Бу вакыйгаларны оныта алмый. Онытырлыкмы шушы бөек Шәҗәрәнең бер очкыны булган мондый ил бәһасе кешене?!

Кешегә ифрат дәрәҗәдә йомшак мөгамәләдә иде ул. Мөлаем иде. Иркәләп, кем әйтмешли, "ислемай сибеп" кенә үстергән мөслимин сакалмыегыннан бар тирә-якка нурлар чәчелеп тора. Күзләре аның кытай ефәге кебек яшелсу-сөрмәле иде. Карашы да нindидер серле, шаукымлы. Балаларына түгел, хатынына да " ых" дип әйтмәс бер гүзәл холыклы инсан иде. Аның гавам халкындагы ләкабе "Чү-чү, Хәкимә" булды. Әгәр Хәкимәсе, шәт, төшенгәнсездер, хәләл җефете, балаларына аз гына булса да тавышын күтәрә башладымы, Габделәскәр хәзрәт шундук үзенең барлыгын сиздерә: "Чү-чү, Хәкимә!" Шуннан да катырак әйтә алмый. Аның бар дорфалыгы—ягъни "сүгенүе" шуннан гыйбарәт болады. Хәзрәтнең икенче бер кызык сыйфаты—ул хатын-кызны ир-ат күзеннән яшерде. Юк, бу ниндидер бер очсызлы көнләшү касафаты гына түгел иде. Бу сыйфат хатын-кызны ислам тәгълиматы кушканча илаһилаштырудан килгән, күрәсең. Бер генә мисал. Иркен Габделәскәр хәзрәтнең үз йорты ихатасында гаиләсе белән фотога төшүен хәтерли. Хәзрәтнең холык-фигылен яхшы белгән яшь фотосурәтче Сәлимхан абзый, күрәсең, эшенә тотынырга җөрьәт итмичә, тәүдә аппарат өчаягын, аннан карый торган көзгесен—объективын озак кына рәткә китергән булып азапланды. Әмма хәзрәт Сәлимхан абзыйны "Чү-чү, Хәкимәләргә" хәтта объектив көзгесе аша да караттырмады. Аппарат чәкетмәсен урам себерүчеләре Нигъмәтулладан чәкеттерде...

Җирән Сафа "сәтсиәлистик ярышын" хәзрәт белән зурәтисе Галләметдиннән башлады. Әүвәл аларны Мао алдындагы "гаепләрен" танырга һәм гафу үтенергә мәҗбүр итеп матапты. Нинди гаеп? Нинди җинаять?!

—Дуңгызлар, этбашлар!.. Сезгә Бөек ишкәкче алдындагы гаепләрегезне йолу өчен келт[26] табарга кирәк!.. Ошбу сүзләрне безнең арттан тәкрарлагыз!—дип җикерде Җирән Сафа. —Без мона кадәр Председатель Мао турында әшәке уй уйлый идек, хәзер асыл уй уйлыйбыз, диегез! Кабатлагыз!

Җирән Сафа карт мөгаллимгә кадаклары чыгып торган таяк белән сукты.

—Хи-хо-хо-хи!—дип шаркылдап шартлады хунвейбиннар көтүе.

Җирән Сафа зурәтисенә сукты.

Иркеннең күз аллары караңгыланды.

—Мин ялгышканмын, диген! Тезләнеп сәҗдә кылам, диген! Моннан соң Председатель Мао турында беркайчан да әшәке уй уйлау түгел, бу хакта уйлый алу турында уй да уйлаштырмаячакмын, диген! Мао—безнең

[25] Гөреч (үзбәк)—дөге.
[26] Келт (уйгыр-татар)—ачкыч.

Ай! Мао—безнең Кояш! Мао—безнең күктән төшкән Тәкъдиребез! Сәҗдә кыл!..

Сафа тагын да сукты.

—Хи-хо-хо-хи!—дип янадан шартлады шайтаннар өере.

Көтелмәгән халәттән йөзләре агарган, күзләре аларган, нәрсә булганын, нинди афәт килгәнен әлегә аңлап өлгермәгән картлар үзләрен каты ихтыярда тоттылар.

—Хәзер без аксакалларның яшьләр өчен үрнәк сабантуен башлыйбыз! Кем дә кем багана башына алдан менеп житә, шул "сәтсиәлистик ярыш алдынгысы" итеп игълан ителә һәм аңардан "буржуазия бурзае" атамасы алып ыргытыла! Төшкәч, намазын укый! Анда сезне, әнә, нинди бүләк көтә! —"Кызыл сакчы" Сафа багана башына ымлап күрсәтте. —Әйдәгез, бер яшьлектә, бер картлыкта, бабакайлар!

Багана башындагы "бүләк" исә—ул СССРның урак-чүкечле әләме иде. Аны җиңүче алып төшеп яндырырга тиеш.

Аксакаллар мондый гарьлекле гамәлне үтәргә теләмәде. Боерылганны үтәттерү максатында хунвейбиннар хатын-кыз, бала-чаганы чыр-чу китереп, кайнаган су белән пешекләргә тотынды. Гаепсез халыкның елашы астында Габделәскәр хәзрәтне, Галләметдин зурәтисе белән әтисен, кыйный-кыйный баганага менгезә башладылар.

—Әйдә, әйдә! Кем тизрәк? Кем тизрәк?

Арттан сумала сылап, баганаларга ут төрттеләр. Күпмедер үрләгәннән соң, беренче булып, читекләре, ыштан балакларыннан ак сакалларына кадәр янган, үзе дә сумалаланган "шүрәле" рәвешенә китерелгән хәзрәт багана төбенә капчык кебек лапылдап килеп төште. Мәйданда китапханәсе янган Габделәскәр инде килеп, сабантуй баганасында үзе янды. Татар Төркестанының Бөек Бакчачысы, Бөек Китапчысы, Бөек Китмәнчесе—туксанга җитеп барган аксакал йөрәге шартлап җан тәслим кылган иде... Шунда ук, баганадан ычкынып китеп, зурәтисе җиргә капланды. Бу татардан беренче ике корбанны "ирекле" Кытайның үз хунвейбиннары—татарлар җәзалап үтергән иде.

Берничә минуттан ялкынланып янган баганадан көеккә әйләнеп, җиргә ком капчыгы булып атасы лапылдады. Аңа ярдәм кулы суза алмау гарьлегеннән бәргәләнгән Иркенне хунвейбиннар студебеккер әрҗәсенә ыргыттылар һәм Голҗа төрмәсенә илтеп тыктылар.

"Багана ярышы"ннан ярымүлек булып чыккан әтисе озак яшәмәгән. Иркен Тәкла Мәкан катыргасында сука тартканда алды ул атасының вафаты хәбәрен. Хәзрәтне, зурәтисе белән әтисен соңгы тапкыр күрүе булган икән. Хунвейбиннар Шәркый Төркестанның акыл иясе, асыл тәрбиячесе Габделәскәр хәзрәтне, Галләметдин зурәтисен һәм Шәркый Төркестанның беренче электрик-яктыртучысы булган атасы—Фәррәхетдинне Кизләү зиратында җирләргә рөхсәт итмәгәннәр. Халык аларның җәсадын җиде чакрым күтәреп барып, күрше уйгыр кышлагы Сарыкамышта дәфен кыйлган. Атаклы казакъ акыны Сарбай бу корбаннар хакына өч көн үлән әйткән.

Болардан тыш, шатлыклы хәбәр дә килеп тапты Иркенне төрмәдә: хунвейбиннар үткәргән сабантуйда капчык кидереп йөгертелгән Мәдинәсе, Аллага шөкер, бәбиеннән исән-сау котылган икән. Яңа туган кыз балага, Иркен теләгәнчә, Гөлфаный дип исем кушканнар.

Хунвейбиннар Иркенне әүвәле "СССР файдасына шымчылыкта, уйгыр җөмһүриятен оештыру"да гаепләп, Кашгар төрмәсендә тоттылар. Анда татарлар һәм уйгырлар белән бергә шундый ук гаептә гаепләнгән казакъ, алтайлы, кыргыз, дөңгән милләтчеләре утырды. "Мин Бөек Туран

империясенең премьер-министры булырга тиеш идем" дип раслату өчен Иркеннен үкчәләрен резин таяклар белән төйделәр...

Бу төрмә әле урта гасырларда французлар тарафыннан төзелгән классик жир асты зинданы - төрбә иде. Үлгән кешеләрнең табутларын саклау өчен яртылаш жир астына салына торган төрбәнен һәр хөжрәсендә унбиш-егерме кеше утыра. Бәдрәфләре дә шунда. Ашаган ризыклары—тозсыз дөге, тозлы балык, алабута өйрәсе. Сорау алыр алдыннан өсләренә бүре тиресе кидереп, төрмә мәйданына чыгаралар һәм бурзайлардан талаталар. Хәтердә калганы шул—этләр кече телләренә кадәр кызыл авызлы иде. Бурзайлардан талатканнан сон, сорау алып тормыйча, янадан ябалар. Аны эттән генә талатып, сорау алмыйча, бер ел интектерделәр. Жир асты зинданыннан качу мөмкин булмаса да, алар богаулы иде. "Гадел хөкем сәгате"нә барып житә алмаган йөз мәхбүснен өчтән берен—суык, өчтән берен—ачлык, өчтән берен бет талап үтерде. Төрмәнең биек дуваллары эчендәге бердәнбер радиотапшыргыч "Огиньский полонезы"н уйный башласа, көт тә тор—жәзалаулар башланды...

"Огиньский полонезы"... Иркен аны хәзер дә тыныч кына тыңлый алмый. "Полонез"ның беренче авазларын ишетү белән тамагына төер, күзләренә яшь тыгыла. Күнелен авыр, каршылыклы, үкенечле хисләр биләп ала. Ул Огиньскийнын һәм үзләренең заяга үткән гомерләрен кызганып үкси башлый. Ул бу иляһи моннын авторы атаклы ләх композиторы, ләх азатлыгы өчен башын салган бөек демократ Михал Клеофас Огиньский икәнлеген ирекккә чыгып, Штатларда яши башлагач кына белде. Ижаты бу кадәр дә үкенечле максатларда—кешене жәзалаган чакта кулланылган башка берәр композитор бар микән жир йөзендә? Бу әсәрен генә түгел, барлык ижатын Рәсәй төрмәләрендә ижат иткән бөек ләх инкыйлабчысы Михал Огиньский, әгәр хунвейбин дип аталачак бу кыргыйларның, дөньяның барча азатлык көрәшчеләре гимнына әйләнгән "Полонез"ын, үзе үлгәч 133 елдан сон, мондый кешелексез, хөсет максатларда—кеше аһын, әрнешләргә түзә алмыйча, жан ачуы белән кычкырган тавышларын каплап тору чарасына әйләндерелеп кулланылачагын белсә, аны язган, яза алган булыр иде микән? Хунвейбиннар моны аңлап кулландымы, әллә аңламыйчамы? Вәлякин тагын да мәзәге шул иде: нинди шартларда, нинди максатларда файдаланылуына карамастан, иляһи музыка, ижатчысына хыянәт итмичә, хәтта дарда да корбаннарның түзә алмаслык газапларын жиңеләйтеп, залимнәргә каршы эшли иде...

Огиньский музыкасынын чөгермәкле чоңгыллары астында тәннәре туналган Эстәрлетамак татарлары бертуган Ильяс һәм Наил Габитовларны онытырга мөмкинме?! Советлардан качып килеп, монда "совет шпиуны"на әйләнгән һәм гәүдәсе тәгәрмәчләрдә урталай ярдырылган Нижгар мишәре Ташбулат Үмәровны ничек онытырсың?! Жәзаланырыннан алда Иркеннең хөжрәсенә атаклы уйгыр шагыйре Үткер Теләшне керттеләр. Мао режимына каршы көрәшкәне өчен "акылдан язуда гаепләнгән" бу даһины анын белән бергә утыртулары Иркенне сындыру һәм үзен дә акылдан яздыру өчен соңгы чара иде, күрәсең. Сәгатьләр буе Тукайны һәм Жәлилне яттан укыган Үткер Теләшне таң алдыннан алып чыктылар. Ул үзенең Гоби энәләренә утыртыласын белә иде. Ихатада Огиньский полонезы яңгырады. Үткер Теләш, ишекне атлап чыгардан алда, Иркеннең күзләренә текәлде дә, гүя бу күзләр аша бар дөньяга аваз салды:

—Иркен бавырдасым! Без үлемсездер гуй! Жасасын уйгыр-нугай туганлыгы вә озодлиги! Жасасын бүйүк татар әдәбияты—устадлик мәктәби! Жасасын

И, туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнен тели!..

Соңыннан, Татарстаннан магнит язмалар алдыра башлагач, ул ләхләр кебек урыслар тарафыннан изелгән татарларда "Огиньский полонезы"на тиң ике музыкаль әсәр—Заһидулла Яруллинның "Тукай маршы" һәм Салих Сәйдәшевнең " Кызыл Армия маршы"дигән әсәрләре барлыгын белде. Ләкин ул аларның икесенең дә "марш" дип аталулары белән килешеп бетми. Алар шул ук полонез, шул ук кайгылы мәрсия. Татарлар аларны куркудан гына "марш" дип атарга мәҗбүр булганнар. Урыс күзлегеннән татар бары тик марш язарга һәм шул марш астында урыс өчен үләргә генә хокуклы. Әйе, тетрәткеч-моңлы илаһият илә тулы бу мәрсияләр. Татар полонезлары. Азатлык парвәрләре. "Татар, азат буласы килсә, иртәсен дә кичен шушы ике маршны тыңларга тиеш,"—дип уйлый Иркен ага шушы көнгә кадәр. Ул Татарстан радиосының әле һаман Казан артыннан арырак яңгырамавына шаклар ката һәм радиодан ошбу иляһи маршларның соңгы елларда бөтенләй яңгырамавы серен аңлый алмый җәфалана...

Аларны тыңлаганда Иркеннең күз алдына, нишләптер, карурман, каезланмаган ярык бүрәнә һәм башын-күзен йон баскан Шүрәле пәйда була. Ләкин ул Шүрәле Казан арты Шүрәлесе түгел, имеш, ниндидер табак битле Пекин арты Шүрәлесе, китайоз, хунвейбиноз Шүрәле, имеш. Ул Казан арты Шүрәлесе кебек ике күзле, ике мүгезле түгел, бер күзле, бер мүгезле—Иркенне кети-кетигә чакыра. Гүя Иркен—Казан арты Батыры, ә менә китайоз Шүрәле—Пекин арты хунвейбины, имеш. Йә Иркен хәзер хунвейбиноз Шүрәленең кулын бүрәнә ярыгына кыстырып кала, йә хунвейбиноз Шүрәле хәзер аның үзен кытыклап үлтерергә өлгерә...

Үткер Теләш кебек асыл затлар да корбан булганнан соң, Иркен яшәүнең мәгънәсен югалта язып куйды. Ул сорау вакытларында каршы торудан туктады һәм сорау алучы нәрсә теләсә, шундый шаһитлык күрсәтә, ягъни үзенә-үзе каршы сөйли башлады. Инде аның өчен барыбер иде. Ахыр чиктә, биргән җавапларында ул үзе генә түгел, хәтта сорау алучылар үзләре дә буталып бетте. Аны өч мәртәбә атарга алып чыгып, атмыйча калдырдылар. Хунвейбиннарда шундый җәза бар иде. Мәйданга чыгарып тезәләр, исемлекне укыйлар, әмма һәр икәүне атып, өченчене исән калдырып, борчак өстенә тезләндерәләр дә, хәлдән тайганчы Мао бөтиен ятлаталар. Тәүбә иттереп, әсирдә тенкә өянәге кузгаталар. Бу өянәктән әсир җир тырнап елый башлый. Боларның барысын да исән-аман үткән Иркенне, ниһаять, хунвейбиннарның кыр хөкеме, тәгаен ун ел биреп, Эчке Төркестанның тәмугы саналган Тәкла-Мәканга—"Лаучой дюй", ягъни "хезмәт тәрбиясе" концлагерьларына сөрде.

Тәкла-Мәкан—борынгы уйгырчадан "бездән түбәндә яткан туйдыручымыз", "җир астындагы байлыгымыз" дигәнне аңлата. Андагы комлык катламнары шыплап нәфт-газ белән тулган. Аны Аллаһы Тәгалә мөэмин-мөселманга җир йөзенең һәр почмагында бүләк иткән. Нәфт-газы белән генә түгел, Кызыл-Ком, Кара-Ком, Бетмәк (Битбак) Дала кебек чүллекләре белән дә атаклы төрки-мөселман дөньясында иң хәтәр, иң куркыныч булып саналган Тәкла-Мәкан чүллеге илнең көньяк-көнбатышында аркылыга биш йөз, буйга мең чакрымга сузылган, туфрактагы кышкы(төнге) һәм җәйге (көндезге) температура урыны-урыны белән минус җитмеш белән плюс җитмеш арасында тирбәлгән үтә дә континенталь чүллек иде.

Тәкла-Мәкан!.. Кучкән комнар моңы!.. Монда табигать һәм һава торышы кешене юкка чыгару өчен яратылган.

Концлагерь төзелгән казанлык җир дингез өсте тигезлегеннән мең метрга түбәндә урнашкан. Тамырлар кан басымының кирегә сикерүенә түзә алмыйча шартлый. Биредә җәен яңгыр, кышын кар яумый. Анда җәе җәй, кышы кыш булмаенча, адәм баласын мәгънәсез хафага батыра. Нибары биш миллиметр тәшкил иткән еллык явым-төшем чыпчык томшыгына да кунып өлгерә алмыйча юкка чыга. Андагы җил-давыл, үзәк өзгеч гарасатлар тереклекнең әллә нинди сәер мәхлукларын бар итә. Февральнең илле дәрәҗәгә җиткән ыжгыр суык җилендә дә бармак башы кадәрле чебен-черкиләрнең була алуын, аларның адәмзатны ничек кенәләр итеп үтереп талавын күз алдына китерергә мөмкинме? Алар сөяккә җиткереп чеметә, алар чеметкән төш кан чыгарып шешә. Андагы ком бураннары тын юлларын дыңгычлап тутыра, ашказаны күбенә һәм син укшып ауный башлыйсың...

Тәкла-Мәкан! Күчкән комнар җыруы!.. Бу исемне ишетү белән арка үзәгеннән суык үтә. Баракларда кышын иң җылы температура—минус биш, җәен исә—плюс кырык. Тырнак астында җәлладләр керткән бамбук шырпысы каный. Кичтән кадыйлар. Йокла. Иртән суырып чыгаралар.

Нинди йокы?! Иртән аякка басу—сәгать биштә. Инкыйлаби кытай музыкасы астында тән язу, һаман да шул борчак өстенә тезләнеп, Мао бөтиен ятлау.

Ундүртенче цитат: “Бөек Мао әйтте: безне ач итүчеләр—чыпчыклар. Ләкин без чыпчыклардан да күбрәк. Шуңа күрә без чыпчыкларны Ватансыз итәргә һәм алардан Ватанны коткарырга тиешбез.”

Егерме җиденче цитат: “Зур елгалар шау-шусыз ага. Кытай компартиясенең, тарихның иң зур елгасы буларак, ревизионистик маякларга мохтаҗлыгы юк. Безнең кораблар дингездә маяксыз да йөзәргә тиеш”.

Утыз алтынчы цитат: “Бөек ишкәкчебез алтмыш чакрым ераклыкка йөзә! Һәркем, алтмыш чакрымга йөзеп, имтихан тапшырырга тиеш!”

Аннан—черегән балык шулпасы белән тамак ялгыйсың. Аннан—уң кулыңа көрәк-кәйлә тотып, сул кулыңа даһи Мао сурәтен күтәрәсең дә, “Мао безнең кояшыбыз” дигән җыру җырлап, кораллы сак астында “хезмәт дәресләре”нә юнәләсең. Ошбу җыруны җырлап, кулларына кечкенә кызыл әләмчек тотып, Тәкла-Мәкан концлагеренең иң карт тоткыны—йөз дә ике яшьлек уйгыр карты Сәрдәретдин дә, Сәрдәретдин бабасы аркасында биргә эләккән иң яшь тоткын Сәрвәретдин дә бара... Анда һәркемне җирнең өстендә дә, җирнең астында да уф-алла арбасы, камыш тырыслар көтә. Кемдер, Лобнор күленнән чүл буйлап мәңге булмаячак арык-каналлар казый да, казып беткәч, каналны су белән тутырасы урында аны янадан ком белән тутыра башлый һәм бу Сизиф хезмәте тагын да кабатлана; кемдер, кәрзингә салып, көн саен ике кубометр туфракны биш йөз метрга ташый да, иртәгә шул ук туфракны кире урынына күчерә...

Соңыннан совет концлагерьләре тоткыны татар шагыйре Хәсән Туфан иҗатыннан эзләп тапты ул Тәкла-Мәкан чүлләрендәге кеше ихтыярын сындыру ысулларын шул кадәр кыска вә дөрес итеп сурәтләгән менә бу юлларны:

Муеннар түгел монда—
Чуеннар шартлап сына...

Иркен бер тапкыр исәпләп тә маташкан иде: аркылысы-буе, биеклеге уртача утызар сантиметр булган тырыс күтәреп, ике кубометр туфракны 500 метрга күчерү өчен тоткыннар бу араны көн саен уртача 300 тапкыр ураганнар, ягъни илле кило авырлык күтәреп, унбиш чакрым юл үткәннәр

икән. Әгәр кушканны үтәүдән баш тартасың, аеруча, Маоның даһи әйтемнәрен ятлаганда тырышлык күрсәтмисең икән, сине чүлгә чыгарып ыргыталар: анда мыжлап торган чаяннар, каракортлар, тарантуллардан беркем дә берничек тә котыла алмый. Бигрәк тә тарантул агуыннан исән калу мөмкин түгел диярлек. Аңа дәва да, дару да юк. Иркен бу бәладән дә котылырга өйрәнде: тарантул агуын кеше тәненнән эһ дигәнче авызың белән суырып чыгарып төкерү өчен, ана секундның нинди микъдары җиткән икән? Әгәр кайнап торган пыяла сыман тарантул агуын телеңдә тоеп өлгерсәң—үзең үләсең, димәк. Мондый адымга барыр өчен сирәк дуслар кирәк шул. Бар иде андыйлар Иркеннең дуслары арасында, бар иде алар!..

Шундый дусларының берсе үзе белән бергә хөкем ителеп, төрмә шартларында хәбәрсез югалган Үтәмеш Сәмит иде. Алар, Голҗада кулга алынып, сәер шартларда төрмәдә югалган атаклы татар фотографы Сәрвәр Хисаметдинның язмышын ачыклау өчен, Мао Цзе-дун исеменә алты тапкыр гозер яздылар. Бу алты гозер өчен аларны алты тапкыр кыйнап, алты тапкыр чүлгә тарантулларга азык итеп ыргыттылар. Тәкла-Мәкан катыргасында карцер дигән нәрсә юк, чүлгә чыгарып ыргытылу ябык бинада карцерга утыртылудан күпкә хәтәр иде.

Аларны төрмәнең баш каравылчысына чакырттылар.

—Ц зан ю[27] Сәмит! Ц зан ю Сәлах!—дип мөрәҗәгать итте аларга төрмә хакиме гүя бөтенләйгә ябылган күз кабаклары аша.—Сезгә, ташбаш кинд за дзо[28]ларга, инде өч ел утыруыгызга карамастан, һаман акыл керми. Сез һаман Председатель Мао исеменә хатлар язасыз һәм төрмәләр арасында үрнәк сәтсиәлистик тәртип өчен көрәштә безләрне артка өстерисез. Әгәр тагын бер тапкыр мондый гозер җибәрсәгез, сезләргә тагын унар ел өстәргә дә күп сорамабыз...

—Әйе, без ташбаш кинд-за-дзолар, уйгыр-нугай азатлыгы өчен, кирәк икән, тагын да йөз ел утырырга да әзербез!—дип җавап бирде аларга Үтәмеш Сәмит.—Сез Бөек Кытай диварын безгә каршы безнең үзебездән салдыргансыз бит!..

—Зма доу шау хуа, кинд за дзо!—дип ырылдады хытайча төрмә каравылчысы ачуыннан. —Зма лау дау ни, кинд за дзо[29]!..

Шушы сөйләшүдән соң озак та үтми, Үтәмеш Сәмит мәңгелеккә югалды. Кичке тикшерүләрнең берсендә исемен атауга җавап бирмәде.

Чират Иркенгә килеп туктады.Аны көтелмәгән хәл, сәяси уен коткарып калды.

...1969 елның көзендә икенче тапкыр президентлыкка чыгып маташкан АКШ Президенты Линдон Джонсонның Кытай Халык җөмһүриятенә сәяхәте әзерләнә башланды. Бу унайдан, Әмрикәнең демократик оешмалары Кытайда кеше хокукларын бозу, Тәкла-Мәкан катыргасында сәяси тоткыннарга карата адәм ышанмас җәзалаулар кулланылу уңаеннан, ифрат та зур халыкара гауга күтәрде. Мао үткәргән ахмакый эчке һәм тышкы сәясәт нәтиҗәсендә төп башына утырган кытай икътисадын, ничек кенә булса да, ничек булса да җиргә төшерергә кирәк иде. Сәяси тоткыннарны коткарган хәлдә, Әмрикәнең акча бирергә әзер булуын һәм икътисадны җанландыру Әмрикә инвестицияләреннән башка мөмкин түгел икәнне "анлаган" Мао, бу юлы да үз хәйләкәрлегенә тугры калып, мондый мөмкинчелектән файдаланып калырга, "эт-баш-сыер-аяк империалистлар" белән сөйләшүләр алып барырга мәҗбүр булды. Сөйләшүләрнең уртасында

[27] Ц зан ю (кытай) – тоткын.
[28] Кинд за дзо (кытай) – татарларга карата мыскыллы атама.
[29] Зма доу шау хуа,кинд за дзо! Зма лау дау ни,кинд за дзо! (кытай) – Артыгын сөйлисең,татар! Һаман буйсынмас татар!..

Маоның генераль даирәсеннән туп-туры хунвейбиннар төрмәсенә барып кергән кытай базарчысы—икътисад реформаторы Дэн Сяо-пинны һәм “колониаль коллыктан котылу өчен көрәшкән” купмилләтле Кытайның кытай, вьетнам, кореян, уйгыр, нугай-татар, дөнгән, казакъ, төрекмән диссидентларын коткару мәсьәләсе торды. Нәтиҗәдә, “Әмрикә шымчысы”, “СССР шымчысы”, “милләтче-сепаратор” намы астында гаепләнгән мәхбүсләр иреккә чыгарыла башлады. Дэн Сяо-пин белән башланган шундыйлар исемлегендә торган Иркен Сәлах та азат ителде.

1970 елның августы иде. Өремчедә эшли генә башлаган Әмрикә вәкиллегенә алып килеп, аның кул-аякларыннан богауларын салдырдылар.

Хуш, Тәкла-Мәкан!.. Уйгыр-татар сөякләрен чаяннар сырып алган Тәкла-Мәкан, хуш!..Татар угылы Иркен синең төнлә бозга каткан, көндез корыч булып эрегән чүллек базларында ташкүмер чыгарды. Татар угылы Иркен синең тозлы комнарың эчендә әкәм-төкәм булып боргаланып арыклар, каналлар казыды. Татар угылы Иркен синең далаларыңда сабаннарга жигелеп, жир сөрде, ком бөртегеннән дөге бөртеге житештерде. Кайда гына булмасын, ниләр генә эшләмәсен, Аллаһы Тәгалә аны кем белән генә очраштырмасын, ул—Кеше, Адәм угылы Кеше булып калды, аның теле, һәрдаим табигатьнең якты яфрагы булып, күңеленә балачагыннан сеңеп калган шушы сүзләрне тәкърарлады:

Сөт калыр, Ватан китәр!
Сөт калыр, Ватан китәр!..

Ватан китте. Тарихи ватанның кулдан киткәненә биш гасыр булып киләдер гуй.

Туган-яшәгән ватан да кулдан китәргә торадыр, гуй.

Әмма ирендә ана күкрәгеннән имгән сөт тәме калды. Ул—Туган Тел.

Яшәсен Ана Сөтенең тәме—Туган Тел!.. Кайда да сакланган тел!..

...Чүл сәхраләрендә көл түсенә кереп саргайган, ябыккан, янаклары ат янаклары сымак тартылып какланган, колаклары исә, шиңгән яфрак сыман, бәлҗерәп, шул какланган янаклары буйлап сузылып төшкән Иркенне анасы беразга танымый торды. Атасының вафатыннан соң, ул бирешкән иде. Аны күрү белән Мәдинәсе чак аңын югалтмады. Күз аллары караңгыланып, талчыбык кебек, кочагына сыгылып төште. Балалары исә бөтенләй диярлек бер атнадан гына ияләшә башладылар. Ул сөргендә чакта дөньяга килеп, инде өч яшькә житкән кызлары Гөлфанийга исә ул бөтенләй ят кеше иде.

Үзенең рәвеше белән кешеләрне куркытырмын дип, ун көн чамасы өеннән чыкмыйча ятты. Мәдинәсенең ана эчермәгән үләне, каптырмаган җиләге, авыз иттермәгән азыгы калмады.

Кайчандыр атларның бер-берсен чакырып кешнәүләре, кешеләрнең шат тавышлары белән яңгырап торган Элә үзәнлегендәге Кизләү авылы дөнья ахырын көткән сыман тынып, кайгыга төшкән иде. Ул сөргендә чакта Шәркый Төркестанны кытайлар баскан.

Үзе дә хунвейбиннар карцеры аша үткән казакъ акыны Сарбай Иркеннең исән-сау котылуы хөрмәтенә өч көн буе үлән әйтте. Әмма үләннең кытайчага тәржемәсен алдан кытайлы хакимгә күрсәтергә тиеш булдылар. Хунвейбиннар сабантуенда баганада йөрәге ярылган Габделәскәр хәзрәтнең ике улы әле булса сөргеннән кайтмаганнар. Исәннәрме? Хәзрәтнең бар Шенжәңгә атаклы җиләк-җимеш бакчасы караучысыз калган. Кайчандыр үзенән дә зур китмән күтәреп, арыклар үткәргән, комлыкны сугарып, тәкый гажәп бакчалар үстергән Габделәскәр хәзрәт, бар татар дөньясына үзе койган как белән үлән чәе эчергән Габделәскәр хәзрәт, бер кулына

Коръән, икенче кулына зур китмән тоткан Габделәскәр хәзрәт—туарлар микән янадан татар дөньясына аның кебек рухи Алыплар?

Иркен сөргендә вакытта бер ата-анадан туган балалар, туганнан туганнар кайсы кайда тарала башлаган. Шулай булса да, Сөләйман хәзрәтнең нәселе әле авылда шактый тамырлы, шактый җегәрле иде. Бу хәл аны, бер яктан, куандырса, икенче яктан, шөбһәгә дә салды—нәселдән исән калганнарның аның аркасында гына да җирле хунвейбиннар золымына эләгәчәге көн кебек ачык. Тик... үз башыңны гына түгел, өч бала, хатыныңның башларын да алып, кая таба олагырга? Аларны кем, кайда көтә? Советлар Рәсәенә, Татарстанга качып чыгу турында уйларга да ярамый. Житмәсә, аннан бик тә әшәке хәбәрләр килә. Чынмы, ялганмы?

Ул гаиләсен алып качарга әзерләнә башлады. Мондый эшне бу шартларда бер ялгызың гына үтәп чыгу мөмкин түгел иде, әлбәттә. Хатын-кыз булса да, бу хакта ул беренче итеп анасы белән киңәшергә булды.

Анасы аны ярты сүздән аңлады.

—Дөрес уйлыйсың, балам,—диде ул моңсу караш ташлап.—Борынгылар "Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар" дисәләр дә, сезгә, яшьләргә, әле исән чакта, бирәдән ычкынып өлгерергә кирәк... Илне сарылар басты. Әнә бит, гаеткә дип симертелгән сарыкларыбызны гурты белән талап алдылар, имансызлар... Барча уйгыр, дөнгән, татар, казакъларны көчләп чүллекләргә күчерәләр... Без инде—картлар, яшисен яшәгән, ашыйсын ашаганбыз... Бары тик шушында гына гүр иясе булырга насыйп итсен...

—Серемне әйтсәм, үз нәселемнән кемнәр күтәрер, анам?

—Серенне, үз нәселең булса да, хатын-кызга ачарга ашыкма,—диде анасы.—Мондый эштә хатын-кызга ышаныч юк. Уйгырда "Яман хатун үзүлмәс тасма, андак тасмани билинга асма", дигән мәкаль бар. Ир-ат туганнарың белән генә эш ит. Хәтта мине дә кыстырма. "Каты булса да жир яхшы, алама булса да ир яхшы," дигән борынгылар...

Иркен үзенә ярдәмгә ышанычлы туганнан туган карындашлары Сабир белән Шакирны сайлап алды. Бу җегетләр белән ат урлап та, кыз урлап та була. Алар тулы теләктәшлек күрсәттеләр. Ул сак кына итеп Мәдинәсенә дә чишелде, чөнки хатын белән киңәшми торып, гаиләне бу авыр юлга алып чыгу мөмкин түгел эш иде. Иркен таң калды: ул аны белми икән! Мәдинәсе аның иң тәэсирле илһамчысы булып чыкты ләбаса!

—Иртәгәдән, иртәгәдән башлаек, жаным!..—диде ул Иркенне назлы куллары белән иркәләп.—Болар безне монда бетерәде!.. Чик аша үзебез үтә алсак, иншалла, аннан, бу җәһәннәмнән, берәм-берәм туганнарны да суырып чыгарырбыз, Иркен!.. Үземезгә, балаларымызга кием-салым, юлга жылы юрган-толыплар, азык-төлек, башка кирәк-яраклар өчен—энәсеннән җебенә кадәр үзем җаваплыдыр!..

Ул ашыга-ашыга колагыннан алтын алкаларын, кулларындагы йөзек-беләзекләрен сала башлады.

—Голҗа базарында сатарсың! Болар гына житмәс... Сафьян читекләрем, юфты итекләрем бар!..

—Син нәрсә?! —Иркен аны кискен хәрәкәт белән туктатты. —Кыз акчасы—тоз акчасы! Сәлахиләрнең хатын-кыз колагында асылынып торган алтын-көмешкә калган көне юктыр!.. Болар сиңа, иркәгем, мин биргән бүләкләрдер гуй! Алар синең белән бергә гүргә керергә тиеш, ишеттенме, Зариф хәзрәт кызы?!..

—Чик сакчыларына ришвәткә!—дип үрсәләнде колакларына алкаларын янадан кияргә теләмәгән Мәдинә.—Сары халык акча дигәндә кадалып барады!

—Теленнән жил алсын, Мәдинәм!..

Мөһажирлеккә әзерлек ярты елдан артыгракка барды. Юлга төп азык итеп киптерелгән, какланган, ысланган ит һәм шулай ук киптергән сөт-корыт, озак искерми торган табикмәкләр хәстәрләнде. Мәдинә-иркәге балалары өчен кара каен бөресенен сутында кайнатылган махсус казылык ясады. Мондый казылык үтә дә майлы булуына карамастан, сабыйларның эчләрен дә китәрми, күнелне дә биздерми иде. Учак ягып, пешеренеп-нитеп тормыйча, ат-дөя өстендә барышлый бу казылыкның кәгазь калынлык, үтә күренмәле бер генә калҗасын теленә салдынмы—димәк, көне буе туксын. Азык капчыгына кипкән инжир, йөзем, уйгыр хөрмәсен дә салдылар. Үркәч өстендә мавыгып барыр өчен балаларга курчак, уенчыклар алырга да онытмадылар. Хаста, тау бизгәге тота калса дип, Мәдинә балаларына вакцин да кадатты, дарулар, үләннәр, төрле төнәтмәләр дә хәстәрләде. Биектә, һава житмәгән очракта, янганда тын алышын жинеләйтә торган тѳтенлек—артыш утыны алдылар. Мәдинә үзләренә, балаларга һәм озата баручыларга дөя йонынннан махсус сырмалар сырды. Бер-бер хәл чыгып, туктаган очракларда кирәге чыгар дип шул ук дөя йонынннан сырып, жылы тирмәләр дә әтмәлләде. Киеләсе киемнәрне, юлда очраячак зарарлы бөжәкләрдән саклану өчен, дарулы суга салып тотты...

Юлга чыгу сәгате тау елгалары тынып, Тәнре-Шәм, Һиндекышларның бозлы сыртлары язгы яшь дәрьялар белән ярсып күбенүдән туктагач, ягъни кояшның җәйге фазасы магнит бураннарыннан Айның тынычлык фазасына кергән чорга—июль башларына тәгаенләнде. Тәгаенләнгән көннен ике-өч көнгә алга-артка күчерелүе бернинди әһәмияткә ия түгел иде...

Озата баручылар, дөресрәге, тиешле урынга чыгарып куючылар булып барырга, туган-тумачалары Сабир белән Шакирдан тыш, бу тирәдәге тауларны, тау үзәннәрендәге юлларны, андагы һава алмашын, табигать шартларын биш бармагы кебек яхшы белгән егет—борынгы дуслары, хунвейбиннар тарафыннан үтерелгән Нургали-әкәнен ике туган энесе Фәхрелназыйм теләк белдерде.

Үзләре белән юлга биек таулардагы кислород ачлыгына чыдый торган зур үпкәле Тәбәт дөяләре һәм атларын алырга булдылар. Башта алар йөкнен күп өлешен Озын Болак, Туккүз, Сары Сөмбә кебек татарлар яшәгән кышлакларга илтеп куярга булганнар иде. Фәхрелназыйм мона каршы төште. Жирле хакимияттә бернинди шик тудырмау максатында анын тәкъдиме белән йөкләрне күрше уйгыр кышлагы Сарыкамышка алып барып урнаштырдылар һәм ике дөяне шунда калдырып кайттылар.

Иртәгә юлга кузгаласы көнне, өйләдән сон, ул Кизләү зиратындагы ата-баба, ага-эне, әби-апа, бәби-сәби—барча туган-тумачаларынын каберләрен зират кылды. Картатасы Сөләйман хәзрәт, картинәсе Бибикамал абыстайдан башлап, һәркайсына исме-әгъзам атап укыды ул догаларын. Сенлесе Өммерәйханнын җәсаде дә биредә бит!.. Кем белә, бәлки хушлашу мәнгегә булыр дип, күзләреннән аккан яшьләре белән сугарылган тупрак та алды үзе белән. Кичләтеп, Мәдинәсе белән икәүләп яшьлекләре үзәне—Элә буйларын, Чыңгызлары яратылган Йолдызлы Чонгыл әрәмәләрен урап килделәр. Туктап тынладылар: колак төпләрендә генә пар сандугач ярыша-ярыша сайрады.

—Тегесе бабай былбыл—син буласындыр кү. Монысы—әби сандугач, мин буламдыр кү!.. —Баласымаклыгын югалтмаган Мәдинә ана сыенды. —Сайрап та сайрайлар!..

Мәдинәнен "әби сандугач" дигәне артык сузалмый, тыны кысылгандай, еш өзелеп өздерә иде...

Һаман да шул кеше шикләндермәс өчен хушлашу мәҗлесе җыеп тормадылар. Чит-ят күзләргә артык чалынмыйча, Иркен үзе генә

Кәрәмәтдин агасы белән Мөхафизә җиңгәсе, Әгъләметдин агасы белән Оркыя җиңгәсе, Галләметдин зуратасы белән Сөмбелә җиңгәсе, Голҗаның Шәрәфетдин атлы кибетчесенә тормышка чыккан бертуган Фәгыйлә апаларына барып саубулашып кайтты. Әлбәттә, әнисен соңгы мәртәбә күрәмдер дип уйламады ул чакта. Анын каберен, туган авылын, якын туганнарын Мао Цзе-дун үлеп, бу вакыйгаларга унбишләп ел үткәч, Кытай житәкчелегенә Дэн Сяо-пин реформаторлары килгәч кенә кайтып күрә алачагын уйлый ала идеме? Әтисенең җәсәден Сарыкамыштан газиз әнкәсе янына—Кизләү зиратына күчереп күмәрмен дип хыяллана ала идеме? Ул чакта, сиксәненче еллар азагында, менә тагын да унбишләп ел үтәр һәм ул Татарстан дигән дәүләт тарафыннан Казанның үзенә—Бөек Татар Корылтаена чакырылырмын дип фараз кыла ала идеме?!

...Әлегә—күк йөзендә 1971 елның 5 июле кояшы яна иде.

Бу ураза гаете көне һәм шуңа күрә дә махсус сайланган иде.

Бәйрәм көнне, аеруча гает намазыннан соң, туганнар, барча гаилә белән сәхрага сәйранга чыгу табигый йола булганлыктан, үркәченә палас-киез, юрган-корган, аш-су казаны һәм башка кирәк-яраклар төялгән дөя, атларда авылдан чыгып баручыларга беркем дә аптырамаслык иде.

Сау бул, Яңа Кизләү!.. Аллаһка әманәт!..

Артка борылып карамаска! Бары тик алга!..

Картатасыннан калган чукмар беренче дөя үркәчендәге киез астында иде.

Шулай итеп, нәкъ йөз элек Мәккәгә дип Рәсәйдән Шәркый Төркестанга мөһаҗирлек кылган Сөләйман хәзрәт Сәлахнең оныгы Иркен Сәлах нәкъ йөз елдан соң Шәркый Төркестаннан яңа мөһаҗирлеккә (кая юл тотканлыгын үзе һәм аны озата баручылар гына гөманлый!) чыкты. Ничекләр генә тап килүен кара: әгәр картатасы гаиләсен урыс хунвейбиннары коллыгыннан Шәркый Төркестанга "Бөек Ефәк Юлы"ның Каракорымнан Бохарага илткән Төньяк божрасы буйлап чыгарган булса, оныгына гаиләсен Шәркый Төркестандагы кытай хунвейбиннары коллыгыннан Һиндстан тарафларына нәкъ йөз елдан соң шул ук бабайларның "Бөек Ефәк Юлы"ның инде Ханбалыктан Хотан, Тизнаф кәнд[30]ләре аша Тарыйм инкүлекләре, Тәкла-Мәкан чүллекләре астыннан Фәйзабадларга илткән Көньяк божрасы буйлап алып чыгарга туры киләчәк. Сулда—Һималай, унда—Памир, каршыда Һиндекыш сыртлары басып торачак. Бөек сынау. Әйтерең бармы!.. Әйе, кире тарихи ватанга—Рәсәйгә, төньяк-көнчыгышка түгел, киресенчә-көньяк-көнбатышка! Тарихи ватанга юл ерагайганнан-ерагая барып якыная. Әйе, Аллаһу насыйп итсә, Һиндстанга чыгып, түбәнгә, Һинд океанына ... Бу хакта шаулама, мондагы җилләр уенны да ишетә!..

Әнә алар—хатыны, өч баласы, өч озата баручысы, барлык кирәк-ярагы өч дөя (икесендә—йөк, берсе алмашка ял итеп бара), биш атка төялгән кәрван—Сарыкамыштан юлга чыкты. Әүвәлдә Жунгар, аннан Тарыйм инкүлекләре буйлап туктый-туктый килеп, дистәләгән зур вә кечкенә инеш-иделләрне кичеп, бер ай дигәндә, Голҗа-Аксу-Караболаклар аша Кашгарларны үтте. Ниһаять, Һиндстан, Пакистан, Әфганстан араларындагы дәүләт чикләрен сакчылардан бигрәк, бербөтен төен итеп төйнәп, биек таулар сагында яткан Ташкорганга исән-аман килеп житте.

Алда юлның иң хәтәр, сынауның иң куркыныч өлеше иде.

Үзен юлдаш итеп алуларының никадәр хак булуын Фәхрелназыйм тагын бер тапкыр раслады. Ул тыныч, сабыр вә тыйнак, кеше белән мөлаем мөгамәләдә була белә. Әле яшьлекләре белән күп нәрсәне аңлап

[30] Кәнд (гарәп.) – шәһәр, утрак бистә, кальгә, ныгытма.

бетермәгән, еш кына каудар кыйланган Сабир һәм Шакир белән дә уртак тел таба ул. Фәхрелназыйм мондагы халыкның күпчелеге сарт[31] булуын, сөйләшкәндә алар телендә гәперергә тырышуларын үтенде. Ул мөһаҗирләрне Ташкоргандагы бер "чыбык очы" булган Ислам әкә[32]сендә өч көн буе миһман кылдырып, әл-хәл иттерә алды. Киңәшә торгач, шул элекке фикердә туктадылар: әйе, юллары бердәнбер һәм ул бары тик Кашмир аша гына. Дөрес, бер өлеше Пакистан, икенче, Җәмму-Кашмир дип аталган өлеше Һиндстан йогынтысы астында булган вилаятьтә тулы хакимлекләрен урнаштыру өчен бу мәмләкәтләр вакыт-вакыт чәкәләшеп торалар. Бу өстәмә куркыныч тудырмасмы? Мондый буталчык вәзгыять, киресенчә, сезнең файдага гына, диде Фәхрелназыймның әкәсе. Сугыш тауларда түгел, кышлак-калаларда бара. Балахшан тау-түбәнлекләреннән Кашмир башкаласы Сринагарга сугарга кирәк...

Мәдинә табиблар белән киңәшеп, алда көткән хәлләрнең барысына да әзер иде. Әмма аның иң курыкканы "тау бизгәге" иде. Фәхрелназыймның алар туктаган әкәсе Ислам, рәхмәт төшкере, чиктә бары тик Кытай ягыннан гына сак торуын, үзара сугыш халәтендә көн күргән Пакистан-Һиндстан ягыннан чикнең әлегә бөтенләй диярлек ачык калып, ике арадан елышып, Кашмирга үтеп булуын, кытай сакчыларының гамәл-гадәт, үзләрен тотышлары, яту-тору тәртипләре турында бәйнә-бәйнә аңлатты. Иркен белән Фәхрелназыйм үзләре белән алган географик атласларны кат-кат өйрәнде, тикшерде.

Кытай белән Пакистан, Әфганстан арасында халыкара рәсми чикне бар да, юк та дип әйтергә мөмкин. Алар бар, тик күбрәк юридик сурәттә. Анда Европа өчен хас гамәли чик сызыклары үтми. Гамәлдә бу чик Памир, Һиндекуш, Һималай таулары белән генә билгеләнә. Чикне сакчылар түгел, таулар саклый. Туңып, адашып үлмичә үтә алсаң, чик аша үттем, дигән сүз. Һиндстан Кашмирына үтәргә теләгән адәмзат Пакистан Памиры аша атлаганнан соң гына тәртәләрен Кашмирга таба бора ала. Һиндстан, Пакистан, Кытай арасында талаш сөягенә әйләнгән һәм географик харитәдә масштабларын хәтта күрсәтергә дә мөмкин булмаган бу чик Һиндстанның Җамму-Кашмир вилаятенә очлы чөй булып килеп төртелә. Бары тик биек таулар гына тудыра алган, кеше үтәлмәс дәрәҗәдә табигый каршылыклы мондый чикне география фәнендә орографик чик, диләр. Иркеннәр нәкъ менә шул "орографик чөйгә" килеп төртеләләр дә иде. Биредә юллар түгел, сукмаклар гына. Аларын да гөрзә еланнар, тау кәҗәләре һәм арысланнар салган. Сукмак—бөек табыш. Язмыш. Сукмак кая алып чыга, син шул ил мөһаҗире саналасың...

Кытай чиге аша ришвәтсез чыгуның мөмкин түгеллеге китап аныклыгы белән ачыкланды. Фәхрелназыйм Ташкорган хакименнән үзе озата барган гаиләнең милләте ягыннан сарт булуын, Кашмир ягында яткан сарт кышлагы Сөләйманиядәге кардәшләрен күреп кайту өчен бер атнага кунакка барулары турында шәһадәтнамә дә яздырып алды. Буш кәгазь кисәге, әлбәттә. Әмма юлчыларга мондый " кәгазь кисәге", чиктә мотлак ришвәт алулары билгеле булганга күрә, сакчылар алдында йөз суын каплап сүз куерту өчен аеруча кирәк шарт иде.

Алар Ташкорганнан борынгы Ефәк Юлыннан Шайман-Ментәкә-Мисгар аша Кашмирга юнәлеш алып, иртәнге намаздан соң кузгалдылар.

Дөяләр өстенә ясалган бишекләренә йокыларында килеш салынган сабыйлар, күзләрен дә ачарга өлгермичә, йокыларын инде дөяләр өстендә тирбәлә-тирбәлә дәвам иттеләр.

[31] Сарт (милләт-ара төрки)—үзбәк.
[32] Әкә (үзбәк.)—ага,агай,ир туган.

Таулардагы юлның төп авырлыгы кояш кагыйдәсе—табигать шартларына бәйле булуы көн кебек ачык иде. Биредә, алар килгән "Тарыйм инкүлеге" каршында, гүя Жир Шарының үзәге иде. Таулар—жирнең бораулап ныгыткан үзәкләре ул. Дөньяның иң биек һәм иң бөек өч таулыклар тезмәсе—Һиндекышнның тугыз мең метр биеклегендәге Чамаланма (Эверест), Тәңре-Шәмнең жиде мең ярым метр биеклегендәге Тәңре-Тау, Һималайның жиде-сигез мең метр биеклегендәге Олуг-Музтау, Алтынтау түбәләре күгәреп ятып, ак башлы борау булып шул Жир Шарына бормаланып-бормаланып керәләр дә, урыны-урыны белән ике мең метрга кадәр түбәнәеп, бер тау тезмәсе икенчесе белән гармун күрекләре сыман ярыша-ярыша буталышып, кайнашып, мул сулы, матур табигатьле үзәнлекләр хасыйл итеп, безнең мөһажирләрне үзләре максат итеп куйган тарлавыкларга китереп чыгардылар.

Әнә, кояш!..Таң-сабах кояшы!..Таулардагы беренче кояш чыгыш!.. Таулардагы таң, таулардагы сабах, таулардагы иртә иманлы, якты һәм садә иде. Кояш уң тарафтан Чамаланма, Тәңре-Шәмнең, сул тарафтан мәгърүр Һималайның Каракорым, алдан Памирның ак вулкан сыман өскә таба тарая барып күтәрелгән түбәләрен алтын сөт белән коендырды. Алар шулкадәр чиста ак, шулкадәр дә чиста алсу иде ки, алма чәчкәсен хәтерләткән бу төсләргә текәлеп карасаң, күзләр әчетә башлый. Сарт, юк, ыграк казакъ-кыргыз хатыннарына охшап ак тукымага уранган, башына да ак төрбән киеп, иң арттагы дөя үркәчендәге әржәгә менеп кунаклаган Мәдинә үзе дә нәкъ Чамаланманың кечкенә ак уймак вулканын хәтерләтә иде.

Чик буена илткән таш юлда әлегә таң салкыны хөкем сөрә. Сафлыкта үлән кыяклары сөңге булып тырпайган. Төн эчендә кичәге көннең утлы тузаны басылган, сирәк-саяк кына очраган ишәкле, Иркеннәр кебек атлыдөяле мөсафирләрне санамаганда, хәрәкәт сүлпән, бөтенләй дә юк диярлек. Чиккә кадәр житмеш чакрым бар әле. Озакламый балалар да уянды. Тәгам жыюлары дөя үркәчендә булса да, алар озакламый, сынык сәгать теле сыман, болай селкенеп барудан ялыктылар—жир буйлап йөгерәселәре, уйныйсылары килә башлады. Ун яшенә чыгып килгән Чыңгыз үзе белән бер әржә-бишектә утырган жиде яшьлек сылуы Гөлмәрфуганы, инәләре исә өч яшьлек Гөлфаныйны сабыйларда адым саен яңарган бу теләктән тыеп карасалар да, кулларыннан килмәде, шуңа күрә Иркен ешрак туктап, кунып, тәннәре белән бергә күңелләре дә оеп, шешенеп китмәсен дип, балаларны күбрәк ял иттерергә тырышты. Моңа озатучы егетләр дә каршы булмады. Шакир белән Сабир гына, бүген юлда кунып, иртәгә кичкә, караңгы төшкәнче чикне үтеп өлгерергә теләп, кәрванны ашыктыруны мәгъкуль күрделәр.

Ә жир йөзендәге тормыш дөя үркәченә артмакланган бишеккә караганда күпкә мавыктыргыч иде шул! Һәр нәрсәгә тартылып, зиһеннәре ачылу чорына кергән сабыйлар анда нинди генә үсемлекләр, нинди генә агачлар, нинди генә бөҗәкләр, кошлар, жанварлар күрми иде! Һәр тарлавыгында үз яктылыгы, үз кояшы, үз ае-йолдызлары булган карлы тауларда төсләрнең уйналышы, андагы ташларның, мәгъдәни кыяларның катламнан катламга үкси-үкси төсләрен, рәвешләрен үзгәртеп яңара баруы алар өчен гүя бер мәктәп, табигать сабагы, өстәвенә шушы гади, бер караганда, "аяк астында аунаган" төсләр үзгәреше аларның алдагы көннәрендә, киләчәк тормышларында кешеләр хәятенә әйләнәчәк дингезнең тере бер дастаны иде. Һәр туктаган саен Сабир белән Шакир абыйлары балаларга төрле матур ташлар, киптереп, һушың китәрлек бөҗәкләр, чәчкә таҗлары бүләк итә. Чыңгыз исә, атларга, дөяләргә болай да авыр дип, ташларны сабыйлар күрмәгәндә генә юл буена ташлап бара... Нишләмәк кирәк: гомер хакына

матурлыктан ваз кичү—үзе батырлык! ..

Көндезен таш юлдагы хәрәкәт ярыйсы гына жанланып куя икән. Чик алды хәрбиләренен бер тапкыр бәйләнеп маташуларын исәпләмәгәндә, сәфәр болай хафасыз үтте.

Төн куну өчен туктар урын итеп Зур Таган дигән тау елгасы ярын сайладылар. Кичке ашны, учак ягып, шушында ашадылар. Мондагы урман-сәхрәдә балалар беренче тапкыр Һиндекыш тәвәсен, һөдһөд кошын, күк гөмбәзенә нокта булып эленеп, сәгатьләр буе канатын да какмыйча асылынып тора ала торган тау бөркетләрен күрделәр. Иркен соңыннан аңлады: аның балаларындагы төркилек тойгысын шушы тауларда яккан учаклар тәрбияләгән булган икән. Бу төркилек гомумкешелек туганлыгының иң югары чагылышы, аның шовинизм, череп чыккан милләтчелеккә бернинди дә катнашы юк. Мәдинәнең юлга дип сырган жылы киемнәре әлегә кирәкмәсә дә, сырган жылы тирмәләре төнге тау һавасы шартларында йоклаганда бик тә кирәк булды. Гомергә ишетмәгән кошларның гажәеп моңлы сайраулары, жанварларның гажәеп серле итеп бер-берсенә аваз салулары, якында гына керт-керт үлән кимереп йөргән атларның, дөяләрнең хәерле мыштырдау тавышлары астында, инәләренең әкиятләрен тыңлый-тыңлый, балалар изрәп йоклап та киттеләр. Фәхрелназыйм, Сабир һәм Шакир табырны саксыз калдырмадылар. Кәрванны озата баручылар гаиләгә тулы ял бирделәр, алмашлап сакта торып, алмашлап черем иттеләр.

Бу сәяхәттә Иркен Мәдинә-иркәсе белән гомер итүнең никадәр жиңел булуына куанып бетәлмәде. Ул синең уеңны, теләгеңне әле әйтеп өлгермәстән аңлый. Монысы кадимгедән шулай иде шулаен. Әммә бу кадәр дә авыр, сынаулы юлда хәләлеңнең синең өчен сөйкемле сөяк кенә түгел, ә бәлки камил акыллы, камил хиссиятле булуы алтын бәрабәренә тиң сыйфат икән. Мондый камил зат һәр халәттә янадан туа, янадан ачыла икән. Әлегә өч бала белән ат-дөя өстендә бара торган юлның бер авырлыгын да тоймый кебек. Гүяки ул балаларын күрми, аларның үзе белән бергә булуын сизми. Алар юктыр. Әмма алар бар. Сиздерми генә. Бу шулай булырга тиеш. Иркен борынгы төркиләрнең "Изге хатун—ожмах хуры, яман хатун—дөнья гүре", дигәннәрен төптән аңлап күрде.

Иртәнге чәйдән соң кузгалдылар. Сабыйларны, бигрәк тә кечкенәләре Гөлмәрфуга белән Гөлфаныйны, тарлавыктагы тере тормыштан, андагы кошлар, эре яфраклы, камыш сабаклы үләннәрдән, бихисап бөжәкләрдән, алар өчен жиргә түшәк булып түшәлгән яшел ментармак-мүктән аерып алып китеп булмады. Соңыннан, үсеп житкәч, Чыңгызының сирәк ташлар һәм минераллар буенча укып, гранит-мәрмәрче, Гөлмәрфугасының кошлар фәне—орнитология буенча белгеч (Гөлфаные исенә төшкәч, Иркен ага күзләрен челт-челт йомды) булып китүләрендә шушы сәяхәттә—Һиндекыш тауларының башлангыч тупсасында алган беренче тәэсоратлары хәлиткеч роль уйнагандыр дип уйлый иде...

Чик сызыгына өченче көннең ахшам намазы алдыннан килеп терәлделәр. Балалар йоклавын дәвам итте. Ниндидер кискен әхваль килеп чыккан очракта, өстәвенә вакытсыз да уянып китеп, юктан гына елый-борчыла башламасыннар, начар кәеф белән олыларның тенкәләренә тиеп, шуның белән генә дә көтелмәгән кыенлыклар китереп чыгармасыннар дип, чиккә житәрәк, беразга туктап алып, туйганчы йоклатырга булдылар. Иркен, хәлнең көтелмәгән ызаннардан кереп китүенә әзер булып, ришвәтне ике бүлемгә бүлде: йөз мең юаньне алгы, йөз мең юаньне арткы кесәсенә салды. Мәдинә сарыгаскәрләрнең комсызлыгы турында дөрес әйткән булган. Әгәр дә болар житенкерәмәгән очракта хатыны кумтасына керергә мәжбүр булачак иде.

Кытай чиге дигән нәрсә соры таш юлны ике яктан алкага алган тәбәш кенә биналардан, сакчыларны кояштан, явым-төшемнән саклаучы япмадан һәм аклы-карага буялган аркылы агач—шлагбаумнан гыйбарәт иде.

Дүрт сарыгаскәр аларның барлык йөген кайсын дөяләр өстендә, кайсын юлдан бер читкәрәк чыгарып, энәсеннән-җебенә кадәр күздән үткәрде. Бер күзенә монокль кигән әфисәр зур игътибар белән кадалып, дүкәмәтләрен тикшерде. Ул Кашгар хакименең мөһерен, имзасын үзендә булган оригинал басма белән тикшереп карады. Сарт гаиләсенең сарт авылы Сөләймания авылына бер атналык миһманлыкка баруына шиге калмаган да иде бугай. Кинәттән генә ул сорап куйды:

—Үзегез белән азык-төлек, әйбер-сәйберне нигә бу кадәр күп алдыгыз? Качарга уйлыйсыз, димәк?!

—Ходай сакласын!—диде Иркен, эчкерсез елмаеп. —Туган ватаныбыз Кытайдан, Бөек Ишкәкчебез Мао Цзе-дун кул астыннан читкә китәргә башыбызга дөя типмәгән ләбаса! Әйберләргә килгәндә... Болар белән баеп булмастыр, гуй... Сөләйманиядә бертуган абзабыз яши. Күптән түгел йорты-курасы белән утырып янды. Иске-москыларны аз булса да ярдәм булмасмы дип алып барган көндәбез...

Әфисәр Иркенгә—һәм нишләптер Мәдинәгә дә!—аның артыннан барырга ымлап, штабларына юнәлде.

Штабның эче Мао сүрәтләре һәм аның бөтиләреннән хикмәтле өндәмәләр белән тулган иде.

Әфисәр якын килеп, моноклле күзен Иркеннең күзенә текәде.

—Сезгә кире кайтырга туры киләчәк. Мөһерегез искергән. Кашгар хакиме кичә генә яңа мөһер ясатып алды.

Иркенгә эсселе-суыклы булып китте. Әмма ул тиз генә аңына килде. Бу—аңа ым һәм бу ым аңлашыла иде.

Иркен әфисәрнең монокленнән күзен алмыйча кулын кесәсенә тыкты. Тегененең керфеге дә селкенмәде. Ул акчаны өстәлгә куйды. Әфисәр аны санап тормыйча, күләменнән генә чамалап, өстәл тартмасына ышырып төшерде.

—Аз. —Әфисәр Мао сүрәтенә караш ташлады. —Кашгар хакименең мөһере кичә чынлап та үзгәрде...

Иркен арт кесәсеннән чыгарып, өстәлгә тагын да йөз мең юань салды.

—Аз. —Әфисәр Мәдинәнең алтын алкаларына ымлады. —Гей во[33]!.

Иркеннең йөзе Тәкла-Мәкан чүленең ком төсе кереп бүртенде. Ул әфисәрне чәйнәп ыргытырдай кыяфәткә керде.

—Син нәрсә? Тиле бәрән орлыгы ашадың мәллә? —Аларга ияреп кергән Сабир әфисәргә таба омтылды.

—Сабир, акылыңа кил!.. —Мәдинә иренә таба борылды, ашыга-ашыга колагыннан Иркененең туй бүләкләре булган алтын алкаларын сала башлады. —Әйе, әйе, әфисәр иптәш!.. Мао Зе вансуй!..

Иркен идәннән күзен алмады.

—Мао Зе вансуй!.. —Алкаларны да өстәл тартмасына ышырып төшергәч, әфисәр сирәк тешле авызын колакларына кадәр ерып елмайды. —Кашмирдагы кардәшләрегезгә бөек ишкәкчебез Мао Цзе-дун сүрәтләрен һәм аның үлемсез фикерләрен алып барыгыз! —Ул идәннән өстәлгә ике зур төргәк күтәреп куйды. —Хау?

—Хау! Хау!—дип кабатлады Иркен төргәкләрне алып.—Яхшы, яхшы!..

Чиктәге сират күперен алар шулай таланып үттеләр. Шулай да куанычлары эченә сыймады.

[33] Гей во! (Кытай.) — бир!

Кытай ягыннан шактый киң булып килгән таш юл үрдән үргә күчеп күтәрелә, тарая башлады. Һиндекышның Ментәкә сыртларына житкәч, Фәхрелназыйм мөһажирләрне Фәйзабад, Талуканга алып барган Ефәк юлыннан кискен сулга, көньякка—Кашмир тарафларына борды. Ул гаиләне максатка Һиндекыш белән Тәнре-Шәм арасында яткан тарлаудан—ин биек түбәләре чагыштырмача түбән—дүрт мең ярым метрдан артмаган Сөләйман платосының Карлыгаш сырты аша алып чыгарга булды.

Көне буе селкенеп килүдән, күрәсең, Гөлфаныйлары күнеле уйнап укшый башлады. Кичекмәстән туктарга кирәк иде. Карангы да төшеп килә. Тауларда еш кабатлана торган ташлы өермәдән, аннан, бигрәк тә эттән, кош-корттан, арыслан-юлбарыстан сакланырга теләп, алар төнгелеккә куну урынын ачык жирдәнрәк сайладылар. Иркен канәгать иде. Ул төнге учакны кытай әфисәре биргән Мао сурәтләре һәм аның хикмәтле фикерләре язылган кәгазьләр белән кабызып жибәрде. Мәдинә кызыл кәнәфер төнәтмәсе эчергәннән соң Гөлфаныйның укшуы басылгандай итте. Йокысызлыктан интеккән Сабир белән Шакир жанварларны өркетеп кую өчен берничә тапкыр кушкөбәкле мылтыктан шартлатып алдылар.

Юлга чыгуларына, кайда кышлакларда туктап, кайда яланда кунып, утыз тәүлек дигәндә, күз алдында Карлыгаш сыртының мәһабәт сыны ачылды. Ул, чынлап та, карлыгач кебек аеры канатлы, мәнгелек бозлар һәм карлар белән капланганлыктан, аклы-каралы, якты-чуар канатлы иде...

Ул галибәнә куркыныч һәм галибәнә мәгърур иде.

Юл тар сукмакка, тар сукмак нибары эзләргә әйләнеп калды.

Югарыга үрләгән саен, дөнья яктырды, күз аллары карангыланды.

Тауларда күк күкрәгәндәй итте. Озакламый тын житмәве сизелә башлады.

Мона кадәр бер-бер артлы килгән дөяләр һәм атлар хәзер тар сукмактан берсенең койрыгына икенчесе борынын төртеп, таярга тотынды. Мона кадәр чагыштырмача тигез жирдә алга карап утырып барган балаларны хәзер йөзләре белән артка каратып һәм әржәләргә бәйләп утыртырга туры килде.

Фәхрелназыйм әйтүенчә, алда әле тагын да ике тәүлеклек юл бар иде. Иркеннең "Гаиләмне үлемгә алып чыкмадым микән?" дигән фикер еш борчый башлады. Вәлякин ул аны беркемгә, хәтта Мәдинәсенә дә сиздермәде.

Озакламый, төнге ялга тукталыр алдыннан, мәнгелек бозлавыкка аяк бастылар. Дөяләрнең, атларның тояклары котылгысыз тая башлады. Фәхрелназыймның әйтүенчә, алар менә-менә Карлыгаш сыртының түбәсенә менеп житәргә тиешләр. Мәдинә үзенең казнасыннан жиргә чүпрәкләр ыргытты. Ирләр малкайларның тоякларына чүпрәкләр бәйләделәр. Ләкин алар тиз онтала, тетелеп юкка чыга иде.

Ир-егетләр, киңәшкәннән соң, төнгелеккә сыртта түгел, ә сыртны бераз булса да үтеп, түбәнгәрәк төшеп, тын алышы жиңеләя башлагач туктарга кирәк, дигән фикергә килделәр. Әмма, күрәчәгең алдына килсә, уйгырлар әйтмешли, "Дәръяларда кара үлмаз, әжәл килсә чара үлмаз" икән шул...

Тын житмәүдән йөрәкләр йорт куяны кебек сикерәнә, колаклар дөпелдәп гөжли башлады. Балаларның йөзе агарып калды. Гөлмәрфуга туктаусыз косарга тотынды. Кечкенә кулларының алсу бармакларына тау мумиесыннан ясалган шәмне кысып тоткан, шуны иснәп тын алышын жиңеләйтергә тырышкан балалар өчесе бер булып төчкерергә кереште...

Дөяләр, атларның атламы чеметемгә калды. Иркен, Сабир, Шакир өчесе өч кәйлә тотып, кыяларның бозлы тунын чокый-чокый малкайларга юл сапты, Фәхрелназыйм исә аларны арттан һау-һаулап барды. Дөясеннән

төшеп, ун яшьлек Чыңгыз да кулына кәйлә алды. Ир-егетләр инде бишәү булдылар. Иркен җитди карашлы угылына карап сокланмый булдыра алмады.

Бу һиҗрәт[34] иде. Бу—картатасы Сөләйман хәзрәттән соң йөз ел эчендә Сәлахиләр нәселе кичергән икенче бөек һиҗрәт болады. Аларның беренчесе Уралтау-Иделдән Алтын Ай далалары аша Шәркый Төркестанны Ватан итсә, икенчесе—монысыннан инде өченче ватанны эзләп һиҗрәт кичү иде...

Тауларны төнге караңгылык били, өерелтеп кар ява башлады. Туктап калу да, алга бару да үлем белән бер иде.

Тау-таш бозлавыкны кәйләсе белән чокып, алдан беренче булып баскыч ясап барган Иркен нәселенең язмышын бер Аллаһ кулына тапшырды. Хәер, ул язмыш болай да Аллаһ кулында. Вәлякин аның хәтта Тәкла-Мәкан катыргасында да әҗәл белән бу кадәр бер-берсенә күзгә-күз текәлеп калганы юк иде...

Бер адым алга атлау белән аның артыннан нәселе дә бер адым алга атлый. Татарның хәйләсез кәйләсе белән чокылган бу жайпак баскычлар гүя аның җир өстендәге кабере, гүре, татарның атаклы Донбасс, Лодзь, Силезия шахталарыннан Тәкла-Мәканнарга кадәр чокып өйрәнгән шахтасы иде. Әнә борынгыдан калган кәрван сукмагының гамәлдә бер генә адәмзат, бер генә кәрван малы үтәрлек таш сукмагыннан, боз эченнән, гүя ак салган чучка күзләре сыман, аның милләтен, өммәтен, нәселен, гаиләсен, балаларын, аның үзен бу кадәр җәфаларга дучар иткән урыс баскынчыларының, кытай хунвейбиннарының күзләре карап тора. Чокый, ат тоягы, адәмзат табаны баса, нәселе алга бара алсын өчен чукый аларны Иркен кәйлә очы белән—әмма алар ыжламый да! Бу күзләр каный да белми. Алар кан эчеп кансыз калган. Ә ул, төрки юлбарыс, үзен кол иткән дошманын юк итү, талау түгел, хәтта тырнак белән дә чиертми, киресенчә, барысын да тиз онытып, яхшатланып, аларны яклый, аклый, аркаларыннан сыйпый. Нишләп шулай бу? Һиндекыш-Тәнре-Шәм-Сөләймантау сыртларында боздан баскыч ясап гаиләсенә сукмак салган Иркен шушы көннәрдән соң нәкъ егерме ел үткәч мөстәкыйльлек игълан иткән Татарстан җөмһүрияте туграсындагы акбарысны беренче тапкыр күргәч, аның мондый шома кролик йөзле, нәзәкатьле, йомшак аяклы-куллы булуына аптыраган иде. Нишләп ауропалы чехларның, ләхләрнең һәм башкаларның туграларындагы җанварлар үзен уратып алган тирә-ягына карата горурлык белән ыжгырып карап тора да, безнең Татарстанның туграсындагы акбарыс йомшак, шома ал аягы белән дошманының аркасыннан сыйпарга әзерләнә? Ул хәзер генә килеп аңлады: без, төркиләр, гарьлекне, кайтарыр үчне онытабыз, тиз гафу итәбез, үзебезне басып алган дошманны кыйныйсы, орасы, тарихи җәзага тарттырасы урында, аның аркасыннан сөябез, сыйпыйбыз. Әйе, с ы й п ы й б ы з. Нигә хәзер бозлар астыннан урыс ушкуйниклары, кытай хунвейбиннары түгел, ә аптыраштан акайган күзләре белән үз бабалары карап тора?! Әйе, алар а п т ы р а ш т а. Әллә ул биш мең ярым метр биеклектәге тау кырлачында үз бабаларының күзләрен чукыймы?! Ий, Аллаһ!.. Моның гөнаһларын кая куяр?! Төркиләр, шушы сыйфатлары аркасында, үз дәүләтләрен әләф-тәләф итеп бетереп, башкаларга дәүләт-тел ясап биреп, үзләре дәүләтсез-телсез, башкаларны иркәләп-кадерләп, көйләп-чөйләп, үзләре иркәсез-кадерсез, үзе көйсез-чөйсез калган түгелме?! Беренче тапкыр—Казанны алганда һәм алгач, икенче тапкыр—тереләй тунап чукындырганда, өченче тапкыр—Питыр падишаһ көчләп әрмегә

34 Һиҗрәт (гарәп.) – күчү,күченү,качып китү. Иҗтимагый төшенчә буларак,ул Мөхәммәт Пәйгамбәрнең милади буенча 622 елда Мәккәдән Мәдинәгә качып китүе белән бәйләнгән.

куганда һәм лашман тарттырганда, дүртенче тапкыр—ата-бабаларының Коръәнле арбаларын тау астына аударып, туган авылларында чиркәү төзеткәндә, бишенче тапкыр—большевиклар мәсҗедләрне җимергәндә чукытмадымы, алтынчы тапкыр—инде менә бүген килеп, кытай хунвейбиннарыннан таланганда—чукытмыймы үз күзләрен бу бөек түзем иясе булган төрки кавем? Кайчанга кадәр? Билгеле: тарих белән бергә яралган хунвейбинлыкның милләте юк. Ана каршы чара тапмаган милләтнең киләчәге юк. Менә бит ул нинди ике канатлы көянтә: кайда хунвейбинлык—шунда тупас көч, үтереш, кайда тупас көч, үтереш—шунда хунвейбинлык...

Җитмәсә, тауларда кар көчәеп, давыл көчәйде. Балалар, бигрәк тә кечкәнтәй Гөлфаный, кислород кытлыгыннан ютәлләп, тагын буыла, укшый, бәргәләнә башлады. Мәдинә, аны ютәл бумасыннан коткару өчен, нәрсә генә эшләмәде!..

—Әф-фарин, Сөләйман-тау!..Без өч мен ярым метр биеклектәге Карлыгаш сыртындамыздыр!—дип кычкырып җибәрде кинәт Фәхрелназыйм.—Без таутюпенин кыраз[35]ындамыздыр!..

Алар төнгелеккә туктадылар. Ирләр кешене дә очырып алып китәрлек җил-давылдан тамырларга тотынып, бер-берсенә баулар белән бәйләнеп, көч-хәл белән түң тауга казыклар каккалап, җылы тирмәләрне урнаштыра алдылар. Мәдинәнең үз акылы белән тегелгән бу тирмәләрнең никадәр кирәк булачагын Иркен җир түбәнендә чакта күз алдына да китермәгән иде югыйсә. Мәдинә белән балаларны тирмәләргә керттеләр. Чыңгыз сылуларының сулышын җиңеләйтү өчен тирмә авызында артыш утыныннан учак тергезде. Төтен беренче карашка тын алышны бераз иркенәйткән кебек тоелса да, файдасы артык зур булмады шул.

Буран аша күк йөзенә нәзек урак булып ай сызылды. Сызылды да, тауларга төшеп, атларның көзге кебек ялтырап тирләгән янбашларына кәкре кылыч булып ятты. Җирдә, тауларда күз ачкысыз буран, юеш, төшкәндә үк туңып, боз элпәсенә әверелә барган карлы давыл котырды.

Һиндекыш белән Тәнре-Шәм арасындагы ин тәпәш саналган Сөләйман-тауның Карлыгаш сыртында гаиләсе, туганнары, Фәхрелназыйм атлы уйгыр кардәше, туганнан туганнары Сабир һәм Шакир белән үлемгә барган Иркен котырган давыл астында, беркем дә ишетмәсен дигәндәй, пышын-пышын килеп Аллага ялварды. Күктә якты Ай, җирдә—кара каза иде. Тауларга - ташлардан инабәт ялварды ул.

Күктә сөннәтле Ай, җирдә—һәлакәт иде. "Исән калдыр!"—дип ялварды ул Айның үзенә. Күктә—нурлы Ай, җирдә—өметсез мәхшәр иде.

Төн уртасы булгандыр, йокысыз табыр яңа бер бәлагә тарыды: пычак кебек күккә кадалган кыя ышыгына куелган өч тирмәнең икесен давыл ботарлап ыргытты.

Бу кара өермәдә атсыз да, дөясез дә калмас өчен алар малкайларның барысын бергә бәйләделәр, аларга күз-колак булсынга Сабирны тәгаенләделәр.

Җылы сырмаларга тиенеп алган ирләрнең төп бурычы Мәдинә белән балаларны коткарып калу иде. Фәхрелназыйм, Шакир һәм Иркен Мәдинә белән балалар утырган соңгы тирмәне дә очырып алып китмәсен өчен, аның итәген ташлар белән ныгыттылар. Аннан өчесе өч таш булып үзләре дә яттылар. Чыңгыз белән Гөлмәрфуга кислород кытлыгыннан бәргәләнде. Гөлфаныйның хәле бөтенләй дә авырлашты. Сабыйның үпкәләренә тауларның артык саф, кискен, салкын һавасы ярамады, суык тидереп, җилсенде. Тәне шешенеп, кызыша башлады. Тын җитмәүдән атлар, кешни

[35] Кыраз (гомумтөрки)—тау түбәсе,очы. Таутүбәнең очы.

дә алмый, үзара тешләшә, дөяләр дә һавада һавасыз өзгәләнеп, уфыра, йөрәк ертып, кычкыра иделәр.

Таң алдыннан Гөлфаный инде буыла башлады. Үзләренә урын таба алмаган Иркен белән Мәдинә шәмне кабызып, тирмә эчендә буталдылар. Баланың йөзен, йөзенең төсен күреп булмый иде. Озакламый кызчык сорауларга җавап та бирми башлады. Саташты.

Тирмәдәге шәм түнүгә—тәндәге җан сүнүгә бара иде. Мәдинәнең шушы минутта чигә чәчләре агарды. Иркеннең чәчләре сөргеннән кайтканда ук ап-ак иде инде.

Таң да сызылды, Гөлфаный да үтте.

Күк йөзендә чыкта юынган урак булып Ай сызылды. Давыл да басылды. Бу давыл, бу сызылган Ай, бу үзәкләргә үткән җил моңлы мәрсия, таулар гына уйный алган моң торбалы полонез булып мәңгелеккә хәтердә калды.

Тауларда шылт иткән тавыш ишетелмәде. Ай Карлыгаш сыртына төшеп үк утырды.

Бу кайгыны кичерерлек сабырлык, аңлатырлык сүзләр юк иде.

Акылдан язмас, үзен нәрсә белән булса да мавыктырыр өчен Иркен тирә-ягына күз салды. Әкәмәт: баш өстенә ап-ачык Ай сүрәте сызылган, аны сузылып өзеп тә алырга мөмкин. Шул ук вакытта кар да ява. Ул мондый манзараны табигать җәннәте буларак танылган Элә буйларында да күргәне юк иде. Кар юеш, җепшек булса да, салкын җилдә шундук бар дөньяны бозга катыра. Мондый өч капма-каршылыкны бары тик Һиндекыш сыртлары гына бар итә ала шул...

Иркен елый да алмыйча үкседе. Өч яшьлек Гөлфаныйның җеназасына табигать шундый матур манзараны саваплы һәдия итеп бирде.

Мәдинә дингез өсте тигезлегеннән өч мең ярым метр биеклектә баласын югалткан беренче төрки ана булгандыр, бәлки. Бәлки кешелек тарихында мененче шундый ана булгандыр. Дөньялык чиратында беренче гел соңгыга, соңгы гел беренчегә әйләнә икән. Рухы, җаны-тәне белән саф мөслимә Мәдинә бары тик шуны аңлый алганы өчен генә акылыннан язмады. Ире кебек, ул да елый алмады. Сабые өстенә сыгылып та төште—һәм тавышын да югалтты.

Бары тик Гөлмәрфуга гына үксеп елады да елады. Аны тыючы булмады.

Ала канатлары белән киләчәккә очып барган Карлыгаш сыртын җиде яшьлек сабыйның әрнеше басты.

Күздән пылт итеп сытылган яшь кебек, Иркен тирмәдән чыкты. Ул сүзсез генә урын күрсәтте. Фәхрелназыйм, Сабир, Шакир ата кешенең ихтыярын үтәп, күрсәтелгән төштә кабер казый башладылар. Кабер дигәннәре боз, ләхет дигәннәре боз, тупрак дигәннәре боз иде.

Сабыйның гәүдәсен үзләре белән юлга алырга кирәкми микән диган уй аларны шактый бимазалады. Башта бу хакта һәркайсы аерым уйлап шөбһәләнде. Аннан, фикерне уртага салгач, бәхәсләшеп тә алдылар. Мәдинә сүзсез катып калган иде. Гүя аның теләген башкаларга инде ун яшендә үсмер-ир корына кереп барган улы Чыңгыз җиткерде. Атларга, дөяләргә ипи, шикәр каптырып, күнелләрен күреп азапланган малай, шашкан күзләре белән тирә-якны айкап, буыла-буыла, әтисенең янына килде дә, изүеннән талкый башлады:

—Әгәр сылуымны биредә калдырсагыз, мин дә биредә калачакмын.

—Ашыкмачы, угълым,—диде Иркен. —Әйдә бергәләп уйлашыйк. Максатыбызга кайчан барып җитәчәгебез анык билгелеме? Юктыр. Сылуыңның гәүдәсен үзебез белән дөягә йөкләп китеп, без аны пакь,

садә килеш саклап калып, ислам кушканча кабергә тапшыра алырбызмы? Юктыр. Аны үзебез белән алып, без үзебезне һәм аны кая алып барачакбыз? Оҗмахкамы? Әллә тәмугъкамы? Мәетне вакытында һәм мөселманча җиргә тапшырмау—үзе зур гөнаһ, балам. Изге Китабыбыз Коръәнкәримдә мондый гамәл бидгать, ягъни мәрхүмәнен фәрештәдәй җәсады өстеннән көлү булып бәяләнәдер... Без аны йоласын үтәп, тупракка индерик, киләчәктә Аллаһы кушса, без аны тарихи Ватаныбызга алып кайтып җирләрбез, иншаллаһ...

Нинди җирләү, кемне, кая җирләү?! Иркен ул чакта үзенең Татарстанга кайтып, туган тупрагын үбә алачагы турында хыяллана да алмый иде. Бу хакта Аллаһу үзе әйттерде түгелме?!

Чыңгыз моның белән килеште кебек. Яшь җепшегән күрсәтмәде. Күзләреннән ут- яшен уйнатып тирмәгә—әхирәткә үткән сеңлесе янына кереп китте.

Мәдинә кар суын эретеп, сабыйның мәетен юды. Чыңгыз белән әтисе исә, тешләрен кысып, һәр соралган нәрсәне сузарга әзер булып, тирмәнең тышкы ягында кизүдә торды. Булды дигәч, Мәдинә гәүдәне, үз йөрәгеннән өзелеп төшкән ит кисәген, дүртенче катка—инде хуш исле үлән шифасы белән—сөннәтләде. Юлга алган ак җаймәсеннән төпчек кызына кәфенлек—әхирәт күлмәге тегелер дип уйлаган идеме?

Әлегә кадәр шушы шартларда, таш йөрәк кебек, бер тамчы яшь чыгармыйча, бу кадәр дә авыр, бу кадәр дә газаплы, бу кадәр дә үкенечле гамәлне ана буларак үти алуын үзенең кешелек сыйфаты итеп бәяләргә акылы җитте. Юкса акылдан язарга мөмкин болады!.. Инде сабыйны җылы гүрләренә керткәнче шундый ихтыяр көче бирсә иде Аллаһы!..

Кабер әзер иде. Гөлфаныйның ап-ак кәфенгә төрелгән бер кушуч гәүдәсен кыйблага каратып, тирмә алдына куйдылар. Ирләр—Фәхрелназыйм, Сабир, Шакир, Чыңгыз сул канатка, хатын-кызлар—Мәдинә белән Гөлмәрфуга уң канатка, Иркен исә кызының күкрәк турына басып, изге догага керде. Һавада бүленә-бүленә Коръәнкәрим авазлары—ясин сүрәсенең аятьләре яңгырады.

Ясин укылып, җеназа догалары кылынганчы көн тәмам яктырды.

Мәет тиз арада ап-ак боз белән капланып өлгерде.

Иркен юлдашларына баш какты.

Сабир белән Шакир, бер-бер хәл була күрмәсен дип, җиңгәчиләрен култыкладылар.

Иркен сабыйның җәсаден күтәреп һәм бозда таеп егылудан куркып, аяклары белән капшана-капшана, тирмәдән бер ун адым чамасында чокылган соңгы куышына таба китте. Башкалар да аның артыннан кузгалдылар.

—Аллаһы Тәгалә, миңа һәм юлдашларыма сабырлык бир!..

—Соңгы тапкыр...—дип пышылдады бер мизгелгә сабыр төененнән чишелә язган Мәдинә. —Соңгы тапкыр... йөзкәйләрен күрсәт!..

—Ярамый, Мәдинә иркәм... Кабер өстендә тыелган... Син бит аның анасыдыр, гуй!..

—Ә син... аның атасыдыр!.. Кызган, Иркен... Соңгы тапкыр!..

Мәрхүмәнең кәфенен сыдыра биреп, анасына соңгы тапкыр сабыенын йөзен күрсәттеләр.

Күзләрен йомган Мәдинә эһ иткән аваз да чыгармыйча урынында таш булып каткан, ул үзе дә бу һич туктамас карлы җилдә, мәет һәм аны җирләүчеләр кебек, боз кабырчагына әйләнгән иде.

Кабер дигәннәре пыяла сыман үтә күренмәле куыш, боз сүрүе—якты табут, агымсудай көмеш саркофаг иде.

Җәсәдне табутка куйдылар. Табутны ләхеткә керттеләр. Боз ләхетеннән ул тагын да яктыра төште. Догалар укып, өстен бары тик нур катламыннан гына торган боз кыйпылчыклары белән капладылар. Боз кисәкләреннән кечкенә таучык өйгәндәй иттеләр. Иркен гүя бер хиссиятсез тимер ихтыяр төененә әйләнгән иде. Жаны-тәне белән тетрәнеп, ул Аллаһы Тәгалә каршында, бу бәлаләрдән котылгач, кайчан да булса бер килеп, мөмкинлекләр һәм сәяси һавалар ачылгач, үзе һәм балалары аякка баскач, шушы сабыеның якты гәүдәсен бу бозтауларыннан табып, тарихи Ватаны булган Татарстанга алып кайтып җирләячәгенә нәзер китерде. Ул хәтерендә калдырырга тырышты: "Һиндыкыш, аның көньяк-көнбатышындагы Сөләйман таулары, Карлыгаш сырты, Ташкорган-Аскүл сукмагы буйлап 3521нче биеклек."

Җеназада беркем дә үксү өне чыгармады. Мышык-мышык та килмәде. Мылтыктан да атмады. Нииндидер галәми кайгы тойган, әле телләрендә Чыңгыз энекәшләре каптырган кара ипине чәйнәп, телләрендә әвәләгән атлар һәм дөяләр генә, тыныч пошкырынып һәм сыскылдашып теләктәшлекләрен белдерделәр.

Дингез өсте тигезлегеннән өч мең ярым метр биеклектә, Сәлахиләр нәселенең тарихи Ватаннарыннан куылуларына нәкъ йөз елдан соң, алар чит-ят туфракта тагын бер корбаннарын калдырды. Бу юлы алар биргән корбанның кабере Идел буенда да, мангул Алтын Аенын Күлтәгин бабамыз кабере итәгендә яткан Баян-Элге комлыкларында да, Элә буйларында да түгел, галәм Һималайлары, галәм Тәңре-Шәмнәре, галәм Һиндекышларының иң биек түбәсе Чамаланма даирәсендә иде...

Кабер өстендә атаның соңгы хушлашу догасы яңгырады.

Мәдинә күзен ачты. Әүвәлдә ул кабер өстеннән тырпаеп торган озын таякны күрде. Ул дөя куа торган артыш таягы иде. Аннан, һушына килеп, күзләрен ачса—ябык күзләре алдында әле генә күмелә генә башлаган йөрәк пәрәсе Гөлфаные, күзләрен ачуга, инде күмелгән килеш тә, гүя ап-ак бишек, якты тирмә, үтә күренмәле пыяла табут, агымсудай көмеш боз саркофагы эченнән йөшмә ташы шикелле зәңгәр күзләре белән дөньяга карап ята...

Мәдинәнең соңгы чиккә җитеп тартылган сабырлык җебе өзелгәндәй итте һәм ул үзен култыклаган кайнешләрен читкә җилпеп ташлап, баласының үтә күренмәле ак бишегенә ташланды:

—Китмим! Монда калдырыгыз! Китмим! Монда калам!..

Ул, акылыннан язгандай, бәргәләнеп-бәргәләнеп елый башлады.

Анардан күреп балалар да елаша башлады.

Иркен аларны бу мәҗүси халәттән чыгара алмады.

Нишләргә? Кинәт ул үзе дә сизмәстән азан әйтә башлады:

—Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр!.. Лә иләәһә иллаллаһү!..

Гүя бу югарыдан төшкән фәтва иде. Мәңгелек бозтаулар киңлегендә яңгыраган иляһи азаннан елау тавышлары тынып калды.

Ул Мәдинә иркәсенең бер төн эчендә суырылып калган йөзен, эчкә баткан күзләрен, агарган чигә чәчләрен үбәргә, теленә килгән һәммә фикерне тәкрарларга тотынды:

—Жаныем! Иманга кил... Сәлахиләр хакына!.. Син—мөселман хатыны!.. Сабыебыз—оҗмахта! Ул безне янына алачак! Фәрештәләр аның ак биләүдәге ак сөякләрен Ватаныбызга үзләре алып кайтачак! Аның җәсаде биредә мәңге тере сакланачак!.. Тынла, әнә атлар да, дөяләр дә җырлый!..

Тыны беткән Мәдинә, колагын искәртеп, бераз тынычлана төште. Ул йөзе белән Иркеннең күкрәгенә капланды.

—Гафу ит, Иркен җан... Авыр бит, җаныем, читен бит...

—Ишетәсеңме, атлар җырлый!.. Безнең атлар!..

Иркеннең колагында чынлап та җырулар яңгырады. Ул Илһам Шакир башкаруындагы "Карурман" иде. Әмма ана бу җыруны әле Илһаметдин балакай Шакир түгел, ә атлар, дөресрәге, атларның, алар белән бергә дөяләрнең җилләрдә какланган, бурадай киң күкрәкләре—йөрәкләре җырлый иде. Аның кайдандыр атларның күкрәкләре белән җырлый белүе турында укыганы-ишеткәне бар иде.

Атлар хәзер Мәдинәнең колакларына да җырлый иде.Кызын калдырып киткән таулар аның өчен инде үз фатыйры, үз йорты, үз оҗмахы булып тоелды. Ана җылы керде. Бу йорт оҗмах-йорт иде һәм анда аның төпчеге Гөлфаный мәңгелек фәрештә булып калачак иде. Кинәт тауларның саф һавасында унай серкәләр артып китеп, Мәдинәнең дә тын алуы авырлашкандай булды. Ул читкә карап, янтайды.

—Күземә кара!.. Мин сине яратам!.. Яратам!..

Иркен Мәдинәсенең карашын үзеннән читкә җибәрмичә, сөйләде дә, сөйләде. Бу сүзләр сөю хакында иде. Ул бу кискен мизгелдә хатынын бары тик ярату тойгысы—сөю хисләре белән генә коткарып кала ала иде...

Соңыннан алар Гөлфаныйларының Һиндекыш таулары түбәсендә калган ак биләве дөньяның иң чиста, иң якты төрбәсе, иң садә мавзолеедыр, дигән фикергә килделәр: бөек фиргавен Хеопслар, Навуходоносорлар, кансыз диктаторлар Сталин, Димитров, Чайболсан, Мао Цзе-дун, Ким Ирсеннарның сөякләре череп яткан төрбәләрендәге торгын һаваны җилләтеп булмый; аларны бары тик тарих үзе генә җилләтә ала; аларда гына ярала торган йогышлы көч микроблары Җир шарын агулап йөрүдән туктамый торып, кешелек халәтендә кайгы-әрнеш беркайчан да бетмәячәк...

...Карлыгаш сыртында яңа кабер калдырып, һавадагы кислородны соңгы байлык, мәңгелек шифа итеп йота-йота, Сәлахиләр янадан юлга кузгалды.

Тагын да өч тәүлектән аларның кәрваны Җамму-Кашмир чиген үтеп, аска, раузагөлләр белән чәчкәләнеп утырган Зәркән үзәнлегенә килеп керде. Аннан юл Кашмир башкаласы Сринагар, Лахор, Суккур, Хәйдәрабадлар аша Гарәп диңгезе, Һинд океаннары аша Әмрикә Кушма Штатларына юнәлә иде...

Алар белән бергә биш илдә биш декларация язылып, Штатларга картатасының чукмары да үтәчәк иде...

... Кемдер сак кына ишекне шакыды.

Уйлар белән уйганып, урынында оеган, хәтта үзенең кайда, нишләп ятуын да исләп җибәргән Иркен ага, тәмам һушсыз-ихтыярсыз калып, ишек шакучыга аваз да сала алмады.

Тагын шакыдылар.

—Керенез...—диде ул, хәлсез генә урыныннан күтәрелә төшеп. —Кем анда?

# ЕЛЛАР. ГАИЛӘЛӘР. ЯЗМЫШЛАР...



*Дуслар, туганнар белән Агыйдел буенда күңел ачу. Сулдан икенче—Солтан Габәши (скрипка белән). Моннан йөз еллар элек алынган рәсем.*



*Гафур Коләхмәтов апасының кызы, булачак язучы Гайшә Шәрипова белән. 1917 ел.*



*Драматург Таҗи Гыйззәт (1895—1955) гаиләсе белән. Хәрби киемдәгесе—улы Казбек. Гыйззәтов Казбек Таҗи улы (1925)—философ, галим. Татар телендә фәлсәфә буенча дәреслекләр авторы. 1954 ел.*



*Фатих Әмирхан (уңда) бертуган энесе Ибраһим белән. Үткән гасырның 20 нче еллары.*



*Муса Җәлил һәм Гази Кашшаф гаиләләре белән Кара диңгез буенда. Ялта. 1940 ел.*

# ШАГЫЙРЬ ГОМЕРЕ—УТЛЫ КҮМЕР...

Әйе, бу чыннан да шулай. Күренекле башкорт шагыйре Ирек Киньябулатов шигырьләре белән танышканнан соң моңа ихластан ышанасың, менә-менә җаныңа ут кабар шикелле тоела башлый, бу катлаулы заман шаукымыннан иелә төшкән башларың күтәрелә, күңел күзләренә яңа бер балкыш сирпелә һәм инде син берничек тә битараф кала алмыйсың. Югыйсә ул әллә ни зурдан купмыйча:

*Минем гомер—утлы күмер,*
*Башкаларга тик бер сабак... -*
("Тик бер кабат")

дип кенә язган кебек иде бит! Әнә шулай гади генә сүзләр белән дә йөрәккә үтеп керә белү куәсе хас Ирек Киньябулатовка. Шагыйрьнең әсәрләрен басмага әзерләгәндә мин моны яхшы тойдым. Каян килә бу сыйфат, тамырлары кайда аның, сәбәбе нидә?

*Шигырь мине үзе эзләп табып,*
*"Менә хәзер утыр, яз!"—диде.*
*Өстәп аңа әрнү, сагыш куштым,*
*Монысы да әле аз иде...*

Алар гына аз, бик аз булыр иде әлбәттә. Һәм шагыйрь үз шигырьләренә тормышны, бөтен дөньяны, халыкның, заманнарның уй-кичерешләрен кушарга алына, моны гомер буена ювелирлар осталыгы белән башкарып та килә.

*Һәр туган көн яңа сорау куя,*
*Мең-мең сорау ала халкымнан.*
*Әллә дөнья шулай акыл туплый,*
*Әллә яза булган акылдан?*
("Елкы елы")

Уйларның, кичерешләрнең киңлеген, тирәнлеген сыйдырыр өчен инде өстәл өстендәге кәгазьләр генә җитми башлый:

*Йөзең якты, нурлы йөзең балкый,*
*Җирем—башланмаган ак дәфтәр...*
("Җирем—ак дәфтәр")

Әнә шулай яңа гына кар явып киткән ап-ак җир йөзе, сафлык үзе кулай булыр сыман Ирек Киньябулатов шигырьләрен язар өчен.

Башкорт шагыйрьләре белән байтактан аралашып яшәргә туры килде миңа, кайберләренең китапларын да туган телебездә чыгарырга насыйп булды. Әмма әлегә кадәр бу каләм остасының әсәрләре белән таныш түгел идем. Бик олы байлыктан мәхрүм булып яшәгәнмен икән ләбаса! Менә хәзер дөньям түгәрәкләнә төште, Ирек Киньябулатов иҗатында мин рухи туганымны таптым шикелле.

Шагыйрь Зөлфәт үзенең бер мәкаләсендә шигырь анализларга алынуны гамәлгә яраксыз бер хәл, ахмаклык дип бәяләгән иде. Мин дә әнә шул ахмаклыкны эшләүдән курка-курка гына булса да, Ирек Киньябулатов шигырьләрендәге көтелмәгән сурәтлелекне, хәтергә кереп урнашу гына түгел, җаннарны әйләндереп сала алырлык сүз куәтен әйтмичә кала алмыйм. Аның шигырьләрендә "көн

белән төн бәрелешкәннән чаткы булып кояш чыга", "тоташ кояшны күтәрә, әнә, агач башлары", "авыры—дөньяның ярасын яралы йөрәктә саклавы". Гади адәм баласы:

*Ачсам күзем дөньяга мин—*
*Сабый кебек кенә.*
*Ә барласам кичергәнне,*
*Мең яшь кебек миңа...—*

дип юкка гына язмагандыр, мәңгелек белән, илаһи затлар белән ниндидер бәйләнеше бар аның. Житмеш ел эчендә (быел 15 июльдә шагыйрьгә 70 яшь тула) мең яшькә житә алыр идемени ул югыйсә! Шуна күрә язганнарын үзең күздән кичерергә, ул дөньяга үзең керергә, анда үзең яшәп карарга кирәктер.

Сүземне утлы күмердән башлаган идем. Күпме күргәнебез бар: утлы күмердән эз кала, янган эз... Шагыйрь гомереннән дә заманга, чорга төшкән эз ярылып ята. Әйдә, сездә дә калсын ул эз: яныгыз-көегез, борчылыгыз һәм шатланыгыз, сөегез һәм сөелегез—әмма бернәрсәгә дә битараф калмагыз. Утлы күмернең тоташ ялкынга әйләнәчәген барыбыз да белә. Аның яктысыннан сез дә балкып китәрсез, мин моңа ышанам. Амин, шулай була күрсен!

**Харрас ӘЮП**



# Ирек Киньябулатов

## Гомер

**Узган гомер агым судай, диләр,**
**Шулай диләр...**
**Алай түгел лә.**
**Су юллары җирдә тиз уңала,**
**Гомер юлы ята күңелдә.**
**Су юлларын беләм: уңай ага,**
**Кешенеке алай буламы?**
**Урау—урау яткан тормыш юлын**
**Хыялымда әле буйладым.**
**Шулар гына белә юл шатлыгын,—**
**Кемнәр юлда җиңә алырлык.**
**Ул булмаса, сиңа нәрсә кала**
**Юлларыңны искә алырлык?**
**Әй, юлда бул таңнар атканчы,**
**Гомер үтәр керфек какканчы.**

Ирек КИНЬЯБУЛАТОВ (1938)—*башкорт шагыйре; "Басу юлы", "Сыерчыклар бала очыра", "Сөю иртәсе" һ.б. китаплар авторы, Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Уфада яши.*

## Уралда таң

Кояш чыгып килә, таулар аша
Түгелергә торган ут сыман,
Итәгендә үскән карагайлар—
Атылырга корган ук сыман.

Утлар, уклар күргән, кайгы төргән
Уралымның һәрбер карышы.
Кайгы күргән җирдә каен үсә,
Карагайлар белән ярышып.

Каен үскән җирдән кайгы киткән,
Дөнья шомы хәзер—ук түгел.
Таулар аша чыгып килгән кояш—
Яулар кабындырыр ут түгел.

Каенлы җир кайгы күрмәсен лә,
Чыкмасын ла кояш ут булып;
Кайгы эчкән җирдән карагайлар
Очмасын ла тагын ук булып!

## Казлар китә

Соңгы яфракларга сары куна,
Соңгы казлар китә тезелеп.
Казлар китсә, сары яфрак болгап,
Ияреп чаба идек без элек.

Кая очты алар, кайда ул чак,
Казлар очып җитмәс аралар?
Яфракларга һаман сары куна,
Шул ук юлдан казлар баралар.

Ничәнче көз икән китә алар,
Ничәнче яз кире кайталар.
Киткән–кайткан каз юллары, җайлап,
Маңгайларга икән яталар.

Тагын менә кыр казлары китә,
Кул болгамый калам күз атып,
Казлар белән кире кайтмас якка
Байтак гомеремне озатып.

Каңгылдашып казлар кайтыр бит ул,
Яшьлегенә кайтыр җир генәм.
Яшьлегенә җирем ел да кайта,
Ә без нигә икән—бер генә?..

## Язгы һава

Яз һавасы каен суы сыман,
Күпме эчмә—кайтмый тансыгым.
Басуларым буйлап атлап килəм,
Кояш белән бергә таң чыгып.

Шул җирләрдә йөреп алдан тоям
Шаулар башакларның тавышын.
Борын төрткән минем шатлыгыма
Яшел дәрья килеп кавышыр.

Каен суы ише генә мени
Пешәр башакларның исләре?
Яшел дәрья алтын төскә керсә,
Шатлыгыма бәхет өстәлер.

Ак карлардан кара җиргә басып,
Яз һавасын сулап йөримен.
Сәламлимен кулым болгап күккә
Канат каккан кошлар өерен.

***

Тагын яшен, тагын яңгыр,
Каршы язмыш чарасына.
Яшен яктысында барам
Ут белән су арасыннан.

Уты белән, суы белән
Әллә тормыш сынап уза.
Сиңа илткән юлы белән
Утын суза, суын суза.

Мин ризамын барысына,—
Күңелемне кайтсам чишеп.
Гомер итәргә әзермен
Яшен йотып, яңгыр кичеп.

Менә сиңа юлым өзек,
Яшен, яңгыр узды ничә.
Мин еракта тын көндә дә
Утлар йотып, сулар кичәм.

## Җирем—ак дәфтәр

Ап-ак җирем—чиксез сихри дөнья,
Бөтен нәрсә чумган шатлыкка.
Гүя, акка төшәр кара беткән,
Кайгы өреккән ап-ак сафлыктан.
Йөзең якты, нурлы йөзең балкый,
Җирем—башланмаган ак дәфтәр!
Карлар хәтта кузгалырга кыймый,
Әйтерсең лә, сабыр, сак дәртләр.
Агачларга ялтыр бәсләр булып
Сәер моң сарылган тавышсыз.
Кышкы кошлар гына аңлыйдыр ул
Шушы моңның чын, хак аешын[1].
Җирем, синдә татлы хыялымы
Туй күлмәге кигән яшь кызның?
Кыекларда боз бармаклар ялтлый—
Көн битендә нигә яшь койдың?
Мөгаен, ул—шатлык яшьләредер,

[1] Аеш—мәгънә, эчтәлек.

Көлгәнсеңдер күңел аязда...
Кояш күпме җиргә якынайган,
Килеп чыккан көндез ай каян?
Алар сиңа сокланалар шулай,
Сокланалар карап якыннан.
Ай соң нәрсә уйлап туктап калган
Синең белән кояш хакында?
Ул—мәңгелек изге мөнәсәбәт,
Намустай саф сезнең арагыз.
Син бит, гүя, ак биләүдә генә,
Ә кояшның—тәүге карашы.
Йөзең якты, җирем, балкый нурың,
Күңелләрдә—ярсу, саф дәртләр.
Ихласлыкка гына ачылган ул,
Ак җир—башланмаган ак дәфтәр.

## Чыкты

Көн белән төн бәрелештә:
Чаткы булып кояш чыкты;
Тәүге ләйсән җиргә сеңде—
Кинәт шытып кыяк чыкты.

Чит берәүнең шатлыгыннан
Куанычлы яшем чыкты.
Бер туң йөрәк эндәшмәүдән
Йөрәгемнән яшен чыкты.

Кем соң әле—үрләү өчен—
Җан дустыннан аша чыкты?!
Башка берәү чит өчен дә
“Җылы” җирне ташлап чыкты.

Бик буталчык хәлләрне дә
Теге мескен ерып чыкты.
Мин шуларны күреп тордым,—
Шуңа шушы җырым чыкты.



Зәки
Зәйнуллин

# КАВИ НӘҖМИ ДИГӘН ЯЗУЧЫ...

РОМАН[1]

Актүбә каласы. 1917 елның март урталары.

Сәкедә, такта дивар янында яткан ананың зәгыйфь тавышы ишетелде:

—Кави улы-ым!

Кави әнисенә борылып карады:

—Әйие, әни! Тыңлыйм сине.

—Куй эшеңне! Кулыңны ю да, утыр әле, балам, минем яныма.—Ана зур авырлык белән кузгалып, торып утырырга тырыша башлады. Кави сәкедә аякларына басып әнисенә утырырга ярдәм итте. Ястык өстенә салган мендәрне диварга терәп, әнисен ябык аркасы белән шуңа сөяде. Кулбашларына, алдына иске корама юрганны япты. Әнисе ике учын бите алдына куеп, кыска гына дога укыды да, гыжлап тын алуын басарга тырышып, акрын гына:

—Утыр яныма! Тыңла мине!—диде.

—Тыңлыйм, әни.

Ана ябыгып беткән уң кулы белән юрганны сыпыргандай итте дә, яшь тулы күзләре белән улына текәлде:

—Син зур балам минем. Әтиең вафатына ике ай тулып узды. Инде бүген-иртәгә мин дә атагыз янына китәрмен, ахрысы. Хәлләрем бик начар.

—Әни-и!

—Бүлмә мине, бал-ла-ам! Хәлем юк. Әйтәсе сүзләремне әйтеп калыйм.

Башын ия биребрәк, дәшмичә хәл җыеп алды да, тонык вә калтыравык тавыш белән дәвам итте:

—Өч туганың да сиңа калалар инде, улым. Мин сиңа өметләнәм инде. Башкача өметләнер кешем юк монда. Син ул өч сабыйга әти дә, әни дә инде, мин киткәч...

Сулышы кысыла башлады.

—Бик хәерче инде без. Ярлы. Син, ничек кенә булса да, Нижгар ягына, үзебезнең авылга, Кызыл Атауга алып кайтып кит туганнарыңны. Бабаң

[1] Журнал варианты.

йортында яшәгән Ярулла бабакаең янына. Әтиеннең бертуган абзасына. Азрак кырыс инде холкы кырыслыкка. Шулай булса да мәрхәмәтле, туган җанлы ул бабакаең. Тәлгать туганыңа ике яшь тә юк бит әле—аны күтәреп йөр. Рәшит белән Ләмиганы җитәклә. Иң авыры сиңа, балам. Ходай ташламас, иншалла, кайтып җитәрсез.

Ананың ике күзеннән дә мөлдерәп яшьләре ага башлады. Ул иң авырын әйтергә җыена иде, ахры.

—Моннан, Актүбәдән пуез белән китегез. Билит алырлык та акча юк. Сиңа сораныrга кала инде, балам.

—Мин бит сорана белмим, әни.

—Әй, бала, бала! Туганнарыңны юлда кайтканда ашатырга, эчертергә кирәк бит. Өчесе дә бәләкәйләр, бер нәрсә дә аңламыйлар бит әле. Ә сиңа юллык та акча юк. Сатарга да бер нәстә дә юк.

Икесе дә дәшмичә байтак утырдылар.

—Юлга пычак, дүрт кашык, зур бакыр чәйнекне ал. Минем күлмәгемне юып ал, чүпрәккә кирәк булыр. Баш яулыгымны. Април азагында, көннәр җылыткач чыгып китегез. Балаларның бишмәтләрен ямадым. Өсләренә кидер. Көн эссе булса да салдырма. Кичкелеккә, төнгелеккә дә киендереп яткыр. Йоклаганда өшемәсеннәр. Еш сидер. Кысталмасыннар. Зур тәһарәтләрен дә оныттырма. Артларын ю. Кайнамаган су эчермә—эчләре китәр. Стансаларда кипәтүк һәр җирдә бар. Чәйнекне шул кипәтүккә дип ал. Көненә бер генә мәртәбә булса да дога укы. Туганнарыңны да өйрәт. Ләмига белә догаларны. Инде җиде белән китте бит. Ул да өйрәтсен энеләренә догаларны. Дога укыганда әтиегезне, мине искә алыгыз. Алладан аерылмагыз...

Икесе дә сүзсез генә байтак утырдылар. Әнкәсе сөйләп бик нык арыган иде.

—Мине иплә кенә яткыр да, керләреңне юып әл. Нәфигулла абзый белән Хәсби җиңгигә аңлатып куйдым мин. Җирләү турында. Мине күмгәндә үзең генә бар зиратка. Сабыйларымны йөртмә—әниләрен җир астына күмгәнне күреп йөрәкләре бозылуы ихтимал...

Кави башын игән хәлдә сүзсез генә утыра иде. Күңеле тулып, аның бер генә сүз әйтерлек тә хәле юк иде инде.

Өч көннән ананы җирләделәр...

Дүрт ятим бала, туган якларыннан еракта-еракта, казакъ далаларында утырган кечкенә Ак Түбә исемле, күпчелеге балчыктан катырылган йортлардан торган, кала димәсәң хәтере калырлык урында, урамда, хәерчелектә торып калдылар. Ике айдан берничә көнгә генә артык вакыт эчендә—гыйнварда әтиләре, март азагында әниләре вафат булды. Иң зурлары Кавига декабрь аенда унбиш яшь тулып кына үтте, Ләмигага алты тулган, Рәшиткә дүрт, ә иң кечеләре Тәлгатькә ике яшь тә тулмаган. Ул әле сөйләшә дә белми. Өч кечкенә сабый белән япа-ялгыз торып калган Кави абыйлары тормыш китереп суккан кайгы-хәсрәттән каушады. Кайгы, нужа, хәсрәт, хәерчелек—зурдан... Кала читендә урнашкан кәкре-бөкре өч урамда күпчелек ярлы татарлар, казакълар яши иде. Тирә-яктагы күршеләр мәрхәмәтле булып, дүрт ятимгә кем ашарга кертте, кем иске-моски кием китерде. Айга якын күрше-тирә, таныш-белеш китергән ризык белән азрак булса да тукланган дай итеп яшәде дүрт ятим бала.

Апрель аеның яртысы узгач, Кави өч туганы белән ерак һәм озын юлга чыкты. Кечкенә Тәлгатьне әнисенең шәленә төреп аркасына асты. Уң кулында азрак азык-төлек белән бик зурдан булмаган төенчек. Шул төенчеккә уң яктан Ләмига тотынган. Сул кулы белән Кави Рәшитне җитәкләгән. Дүрт ятим Ак Түбә тимер юл стансасына таба атлады. Балаларны озатырга күршеләре Нәфигулла абзый белән Хәсбиямал җиңги дә бардылар. Чөнки Нәфигулла

абзый тимер юл стансасында вагоннарны бер-берсенә эләктерүче булып эшли һәм аның стансада дуслары, танышлары байтак иде.

Балаларны Хәсбиямал җиңги белән берлектә перронда калдырып, Нәфигулла абзый вокзал эченә кереп китте. 15-20 минутка кадәр юк булып торды да, вокзал бинасыннан йөзе яктырып килеп чыкты.

—Ярты сәгатьтән Ташкенттан Ырымбурга бара торган пуез үтәчәк. Шуңа утыртырга тырышырмын инде сезне, балалар, Алла бирсә!

Һәм Алла бирде дә. Пассажирлар йөртә торган поездда ике вагон туп-тулы сугышка китеп баручы солдат халкы иде. Нәфигулла абзый байтак яшәп, күпне күргән кеше. Балаларны вагон янында, перронда калдырып, вагон эченә үрмәләде. Кергән уңайга ук үзебезчә сәламләде:

—Әссәләмугаләйкум, солдат кардәшләр!

Вагон түрендәге тәмәке томаны эченнән җаңга җылылык биреп, татар тавышлары ишетелде:

—Әйдүк, түрдән уз!

—Кем йөри анда, болайрак кил!

—Вәгаләйкүм вәссәләм!

Тавышлар килгән якка атлады да агай гозерен чыгарып та салды:

—Мөселман туганнар! Дүрт ятим баланы Ырымбурга хәтле үзегез белән алыгыз инде. Әти-әнисе ике ай эчендә вафат булдылар. Туган якларына кайтырга чыгалар бүген. Зинһар, ярдәм итсәгезче!

Кара чәчле, кара күзле, таза гәүдәле чибәр татар егете утырган җиреннән генә сорады:

—Кайда ул балалар?

—Тышта, вагон янында.

—Әйдә, абзый, күрсәт.

Озак та үтмәде, Рәшитне күтәреп, калган өчесен ияртеп, егет вагонга кире килеп тә керде.

Туган илләреннән, бала-чагаларыннан, хатыннарыннан, күз төшеп йөргән кызларыннан аерылган солдатлар, дүрт баланы елмаеп, ачык йөз белән каршы алдылар. Үзләре ясаган сәндерәдән урын биреп, ятар өчен шинель-брезентлар җәйделәр. Балаларны урнаштырып азрак күңеле күтәрелгән Нәфигулла абзый рәхмәтләр укый-укый балаларны кочаклап чыкты. Һәм Кавига соңгы киңәшен бирде:

—Кави улым! Нәрсә генә килеп чыкса да солдат халкына сыен. Бала-чагасыннан аерылган солдатка да җиңел түгел. Йөрәге яна аларның, әллә кайтам сугыштан, әллә юк дип. Иншалла, солдатлар сезгә ярдәм итәр дип уйлыйм.

Туган якларына җылы мөнәсәбәт һәм тамак туклыгы эзләп кайтырга дип юлга чыккан дүрт ятим балага солдат вагонына эләгү зур бәхет иде. Йокларга урын—киң итеп тактадан ясалган ятаклары бар. Аларга калын итеп узган елгы бөге саламы түшәлгән. Вагон түшәменнән салынып төшкән дүрт тимер чыбыкка түгәрәк пыяла куыклы дүрт керосин фонары эленгән. Караңгы төшә башлагач, шул фонарьларны яндыралар. Көненә өч мәртәбә ашаталар икән әле монда. Күрше вагонда поход өчен эшләнгән ике тәгәрмәчкә утыртылган аш, ботка пешерергә юл кухнясы бар икән. Эреле-ваклы тимер юл стансаларында, разъездларда туктый-туктый, озаклап шуларда тора-тора, ике тәүлеккә якын паровоз гудокларын тыңлый-тыңлый, кайчандыр урысның казакъ даласына китереп салган крепосте Ырымбурга килеп җиттеләр. Килеп җитү белән дүрт әфисәр солдатларны перронда тезә дә башлады. Берсе вагоннан чыккан Кавига һәм ул җитәкләгән түбәтәйле ике кечкенә малайга, бала итәкле күлмәк кигән кызчыкка карады да, солдатларны тезгән арада, фельдфебельгә эндәште:

—Никита Иванович! Откуда оказались в вагоне эти гололобые татарчата?

—С самого Актюбинска, Ваше высокородие. Сироты. К родным едут.
—Куда?
—В Ниженовгородский уезд. Сироты. Родители недавно померли.
—Да. Сироты, значит?
—Так точно!
Әфисәр түш кесәсенә тыгылып өч берлек акча чыгарып Кавига сузды.
—Держи, сынок! Счастливой дороги вам!
—Ыспачибо, дядя!—диде Кави.—Ыспачибо.
Әфисәр Кави янында басып торган кечкенә Тәлгатьнең башыннан сыйпады да, фельдфебельгә боерык бирде:
—Солдатларны Кәрван сарайга алып кит. Ул шәһәр үзәгендә. Кәрван сарай дип сорашып бар—табарсың.
—Слушаюсь, Ваше благородие!
—Хәрәкәтләнегез!
Уң кулын фуражкасы козырегы янына китереп хәрби честь бирде дә, өч офицер белән берлектә, вокзалдан чыгу ягына китеп барды.
Фельдфебель Кавига кул биреп саубуллашты да, сул кулын ачып көмеш бер тәнкәлек акча сузды.
—Тот, улым! Башкача акчам юк. Исән-сау кайтып җит иленә.
Фельдфебельдән рөхсәт сорап сафтан дүрт татар солдаты чыктылар Кавиның учына азрак вак акча салдылар. Бер-бер артлы ятимнәрне кочакладылар. Күзләре тулы яшь иде татар солдатларының...
Фельдфебель команда биреп, солдатлар сафын алып китте.
—Смирно-о! Нале-е-во!!!! Шаго-ом марш!
Дүрт бала перронда моңаеп басып калдылар. Кечкенә Тәлгать киткән солдатлар артыннан уң кулын сузып елый башлады: аның яхшы солдат абыйлардан аерыласы килми иде.
—Йә, йә, елама!—диде Кави Тәлгатькә.—Алар ерак китәләр. Нимес белән сугышырга. Ә безгә үзебезнең авылга кайтырга кирәк.
Ырымбурда балалар бер атна яшәделәр. Поездга билет алсалар, ашарга акча калмый. Билетсыз утыртмадылар. Таякка таянган, түгәрәк мескен бүрек кигән бер татар бабае Кавига вокзалда киңәш бирде:
—Әйдә, улым, минем белән. Ырымбурның күпчелек татар яшәгән өлешендә, тоташы белән таштан салынган мәчет бар. Мәзине—минем бертуган энем. Шунда кунып торырсыз. Юлга чыгарга артык кабаланма. Туганнарың бик кечкенәләр. «Юл газабы—гүр газабы», дигәннәр бабайлар. Стансаларда туктый-туктый узыгыз юлны. Бу сабыйлар ул тимер юл вагуннарында кагылып-сугылып, йончып, авырып китмәсеннәр. Шул таш мәчет мәхәлләсендә тоташ татарлар яши. Йорттан йортка йөрерсең, тамак туйдырырлык бирерләр, иншалла. Хәлле сәүдәгәрләр, байлар байтак анда...
Дүрт бала таш мәчеттә бер атна яшәделәр. Аркасы азрак кәкрәебрәк торган чал сакал-мыеклы мөлаем генә бу мәзин бабай көн дә кич, ахшам намазына килгән чакта, тастымалга төргән балчык чүлмәк белән токмачлы җылы аш алып килде. Шуңа өстәп һәр килүендә бер түгәрәк арыш ипие дә була иде. Дүрт бала таш мәчеттә ашап-эчеп, идәнгә җәелгән келәмдә йоклап яшәделәр. Мәзин бабай аларга ике иске палас һәм искедән булса да, дөя йонынннан сырган зур калын җылы юрган бирде. Шуларга өстәп, каралганрак булса да, тышлы өч мендәр дә бар иде.
Рәшитне Ләмигага карарга калдырып, Тәлгатьне күтәреп Кави иртән таш мәчет мәхәлләсе урамнары буйлап... хәер сорарга чыгып китә. Әчке бер кушуга буйсынып, ул ишек алдына керер алдыннан рәшәткә, койма ярыкларыннан карый: «Этләре бармы? Булса, бәйдәме, түгелме?» Шуннан соң гына, этләре булмаса, яисә бәйдә утырганын күргәннән соң гына, ишегалдына уза.

Өйләренең ишек төбенә барып житкәч, Тәлгатьне жиргә төшереп янына бастыра да, ике кулын бите алдына куеп, кычкырып дога укый башлый. Күбесенчә бу яраткан догасы «Әлхәм» була:

—Әгүзе-билләәһи-минәшшәйтаанир-ражииим, бисмилләһир-рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи-рабилгааләмиин...

Дога укый башлауга, озак та үтми, ишектән хуҗа хатын, яисә асраулары күренә. Кулларында һәрчак нинди дә булса ризык була. Дога укыган абыйсы Кавиның ботына ике куллап ябышып, хуҗабикәгә өмет белән зур кара күзләрен текәп басып торган кечкенә сабыйны күргәч, һәрбер чыккан хатын-кыз каушап төшә, күзләренә ирексездән яшь тула, куллары калтырый башлый. Үзе дә сизмәстән, такмаклап-такмаклап сораша да, зарлана да башлый:

—Ә-эй, Ход-дай-йы-ым! Каян киләсе-ез, кая китеп бар-рас-сы-ыз, сез бол-лай, сабыйла-ар! Бәх-хет-сез замана-ала-ар! Би-игрәклә-әр бәләкәч бит бу бала-а! Уйнап, йөгере-еп, тәгәрә-эпләр үсә торган чагы гына бит сабый-йны-ың. Әй, Ход-дай-йы-ым!

Кавинын догасы тәмам булганны түземлек белән көтеп ала да, кулындагы ризыкны анарга тоттырып, сөйләнә-сөйләнә кире өенә кереп китә:

—Китми тор, туганым! Хәз-зер чыгам! Хәз-зер!

Кереп китә дә, озак та тормый, тагын берәр ризык күтәреп килеп тә чыга. Күпчелеге капка төбенә кадәр озата. Изге теләкләр белән капка төбендә елап торып кала.

—Исән-имин йөрегез туганым. Берүк карый күр инде сабыеңны. Авырып үлә күрмәсен. Бигрәкләр дә кечкенә бит, сабый! И-и, Ходаем, нужа-михнәтләр агач башыннан йөрми, без татар—мөселман башыннан йөри шу-ул! Ходай ташламасын үзегезне.

Таш мәчеттә яшәп берничә көн узгач, мәзин бабай таза гына бер кешене алып керде балалар янына. Матур кара кырма сакал-мыеклы, зур гәүдәле, алсуланып торган битле, зурдан булмаса да, түгәрәк корсаклы татар бае иде шикелле ул абзый. Идәндә, келәм өстендә тезелешеп утырган дүрт балага билле прәннекләр тоттырды. Һәр кулга булсын дигән уй белән, ахрысы, прәннекләрне икешәрне бирде. Каршыларына—идәндәге келәмгә утырып байтак кына сорашты: каян киләләр, әти-әниләре кем иде, кая китеп баралар? Нәселләрендә укыган кешеләр, сәүдә итүчеләр бармы? Китеп барган якларыгызда кемнәрегез бар?

Төпченеп сорашкач, Тәлгатькә ымлап: «Бу кечкенәнең исеме ничек?»—дип сорады.

—Тәлгать!—диде Кави сагая төшеп.

—Ала-ай икән! Күпмелек инде бу малай кисәгенә?

—Ике тулып килә.

Абзый, дәшми генә, күзен Тәлгатьтән алмыйча, нәрсәдер сорарга җөрьәт итмичә утыра иде, ахрысы. Мәзин бабай ярдәмгә килде:

—Кави, улым! Кайтасы юлыгыз ерак. Язгы, җәйге көннәр. Эче китеп, яисә башка авыру тиеп бу кечкенәнең вафат булу ихтималы бар бит. Менә Мөхәммәт Әмин абзаң Тәлгатегезне уллыка алу теләге белән килгән. Шуны синнән үтенә. Дөньясы киң, мул. Үзе Ырымбур сәүдәгәрләренең бик дәрәҗәлесе санала.

Кави каушап төште, дәшә алмады. Кечкенә Тәлгать үзен каядыр алып китәргә теләүләрен шунда ук аңлап алды. Тиз генә торды да, килеп Кави абыйсының алдына кереп утырып, аны муеныннан кочаклап, башын селки-селки елый башлады. Кечкенә малайның туганнарыннан аерыласы килми иде. Кави авырлык белән тамагына килеп утырган төерне йотты. Тәлгатьне кысып кочаклады да, тотлыга-тотлыга әйтте:

—Юк, абзыйлар. Юк! Бирмибез Тәлгатьне бүтәннәргә.

Ләмига белән Рәшит тә, абыйлары Кавины, энеләре Тәлгатьне кочаклап, елый башладылар.

Мөхәммәт Әмин бай, камзул кесәсеннән зур, кызыллы, яшелле яулык чыгарып тирләре чыккан кызыл битен, күзендәге яшьләрен сөртеп, урыныннан торды.

—Ярар, оланнар, исән-сау кайтып җитегез. Син, Кави улым, иртәгә җомга намазыннан соң минем белән ияреп, миңа кайтырсың әле. Кибеттән азрак кием-салым бирермен бу сабыйларга. Ярармы?

Баш кына селкергә көч тапты Кави. Сүз әйтерлек хәле дә юк иде.

Бай киткәч, мәзин бабай Кавины балалардан читкәрәк алып китте дә, пышылдады:

—Иртәгә байга үзең генә бар. Тәлгатьне алып бара күрмә. Алып кала күрмәсеннәр диюем...

Курка төшкән Кави икенче көнне иртән иртүк җыенып, туганнарын алып, тимер юл вокзалына китте. Мәзин бабай пышылдаганнан соң Кавида да шик туды: «Чит кала! Тәлгатьне алып калып яшерсәләр һәм без алмадык дисәләр! Кемгә барасың ярдәм сорап?» «Ырымбур—Самара» поездына утырып кына бара торган вагонга үзенә генә билет сатып алды Кави. Берсен күтәреп, ике баланы җитәкләп вагон янына килде. Таза, олы яшьләрдәге кондуктор Кави сузган билетка, дүрт балага азрак карап торды да, карлыкканрак тавыш белән сорады. Урысчалап:

—Әти-әниегез кайда?

Кави кондукторның күзенә карап акрын гына тавыш белән җавап бирде:

—Әти гыйнварда, әни март аенда Актүбәдә үлделәр.

Кондуктор Кави биргән билетны кулындагы күп бүлекле букчага тыкты:

—Вагонга кергәч, аны тоташ үтеп, туалетның бу ягына урнашыгыз. Ике зуррак туганыңны өске полкага урнаштыр, үзең кечкенә малай белән астагы бер полкага урнаш. Башкалар кереп сезнең урынны алырга итә башласалар, кондуктор, дядя Вася, бу урыннарны безгә бирде, диген. Нык тор. Тавыш чыга башласа, мине чакыр. Аңладыңмы?

—Әййе, аңладым. Рәхмәт.

—Бар, урнаш. Чәйлек шикәр дә бирермен кичен.

—Рәхмәт.

Икенче көнне Идел-Су ярында утырган Самара дигән зур калага барып җитте поезд. Идел-Су булгач, димәк, Нижгар да шул су ярында бит инде! Туган як бик ерак булмаска тиеш. Кави күңелләнә төште. Аңа карап кечкенә балаларның да күңелләре күтәрелде. Рәшит чыккач, абыйсының үзен җитәкләгән кулын селкетте:

—Абый! Тәлгатьне беркемгә дә бирмибез. Әййе бит?!

—Әййе, Рәшит! Бирмибез. Үзебез белән Кызыл Атауга алып кайтабыз аны.

Рәшит тынмады. Тәлгатьне чит абзыйга бирмәгән Кави абыйсына малайның яхшылык эшлисе килә иде.

—Абый! Бир, Тәлгатьне мин күтәреп барыйм.

—Авыр бит ул.

—Бир инде, абый! Арыгач та кире бирермен.

Абыйсы биргән Тәлгатьне аркасына күтәреп, аның алга таба чыккан аякларын тезләре астыннан ике кулы белән тотты. Тәлгать бәләкәй абыйсын муеныннан кочаклап елмая иде. Бәләкәй абыйсының күтәрүе аңа кызык иде, ахрысы. Тик ул кызык озакка бармады—Рәшитнең бите тирләп чыкты, тын алуы гыжылдауга күчте.

—Мин арыдым да инде, абый. Бәләкәй булса да авыр икән бу Тәлгать, чыннан да.

Кави көлде.

—Мина бир. Менә сина гомерлеккә исендә калды инде бу күтәрү. Тәлгатьне күтәрүнең авыр икәнлеге. Мин инде ун көннән артык аны күтәреп йөрим. Тәлгать үскәч, сөйләрсең үзенә. "Мин сине Актүбәдән кайтканда күтәреп алып кайттым",—диеп.

Рәшит бирешмәде:

—Синең хәтле булып үскәч, абый, мин дә Тәлгатьне унар көн күтәреп йөрермен. Ярармы!?

—Ярар, ярар, күтәрерсең. Тик син Тәлгатьне үсмәс дип, шул килеш торыр дип уйлыйсың, ахрысы.

Самарада Нижгар ягына китә торган поездларга утыра алмыйча өч тәүлек җәфаландылар. Акчалары бетте. Бу яктагы халык Ырымбур татарлары кебек мәрхәмәтле түгел иде. Күпчелек каян өзгәләп, урлап алырга белмичә йөргән ач урыслар. Тәүлеккә якын ризык күрмәгән өч кечкенә балага карап, Кавиның йөрәге телгәләнә башлады. Ләмига белән Рәшитне вокзал эчендә тезелгән артлы тимер эскәмияләр артына кертеп идәнгә утыртты.

—Шушында гына утырыгыз. Сиясегез, яисә зурысы килсә, менә шушы чәйнеккә итегез...

Зур бакыр чәйнекне күрсәтте.

—Бик кысталмасагыз, итмәгез. Мин Тәлгать белән базарга, анда хәер бирмәсәләр, берәр мәчет янына барам. Үзебезнең мөселман татарлар берәр нәрсә бирерләр әле.

Һәм Кави ялгышмады. Базарга керә торган капка төбендәге биш хәерче янына, шуларның иң читтәгесе янына утырды да «Әлхәм»не укый башлады. Дога укый башлагач, абыйсы Кавига ошатып, кечкенә Тәлгать тә кулларын бите янына догага күтәрде. Базарга дип килгән мөселман ирләр, хатын-кызлар тиенләп хәергә акча бирделәр, базардан чыкканнары төрле азык-төлек сузды. Яхшы киенгән бер яшь кенә чибәр татар егете Кавига биш тәңкә акча тоттырды:

—Татар күренәсен—йөзең нурлы. Тот энем, игелеген күр.

Кавиның күзенә яшь килде:

—Рәхмәт инде абый. Дүрт бала без, Нижгар ягына кайтып барабыз. Икебез вокзалда.

—Кайтып китә алмасагыз, җомга намазына кил. Исемем Вахит минем. Тагын ярдәм итәрмен.

—Ходай Тәгалә көтмәгән җирдән бирсен сиңа, рәхмәт абый...

Зур авырлыклар белән ике тәүлектән соң Кави, югалтусыз, исән-имин туганнары белән Нижний Новгородта татарлар "Нижгар" дип йөрткән кала вокзалында вагоннан төште. Вокзал алдына чыккач, кулындагы төенчекне, Рәшит күтәргән бакыр чәйнекне җиргә куйдылар. Кайсы якта икәнлеген кояшка карап чамалап, туганнарын йөзләре белән кыйбла тарафына каратып тезеп бастырды. Үзе аларның сул ягына басты. Мөрәҗәгать итте:

—Нижгарга кайтып життек, туганнарым инде авылыбыз Кызыл Атау да бик ерак булмас. Ат-олау туры килмәсә, җәяүләп булса да, авылдан-авылга хәер сорашып булса да кайтырбыз. Көннәр жылы—атларбыз да атларбыз. Арысак, яңа чыга башлаган үләнгә ятып ял итәрбез. Ә хәзер, Нижгарга кайтып житкәнгә, Алла бабайга рәхмәт әйтеп, дога укыйк...

Нижгар белән Кызыл Атау авылы арасы сиксән биш чакрым. Шул араны өч кечкенә бала белән Кави дүрт көндә көч-хәл белән уза алды. Соңгы чакрымнар бигрәк тә авыр булды. Ләмигада табигать тарафыннан бирелгән, хатын-кызларда гына була торган чыдамлык, түземлек һәм әрсезлек тә бар

иде. Юлны ат белән күп йөргән татар ирләре, йөк җинелме, авырмы, якын юлга алаша яисә айгыр җигәләр. Чөнки алар кыска юлны тиз үтәләр. Ә юл ерак булса, алаша да, айгыр да бирешә, барган саен арый. Шунлыктан безнең халык ерак юлга бия малын җигә. Хатын-кыз да бия малы кебек, юл үтәргә чыдам була.

Кызыл Атауга кайтып җитәргә сигез-ун чакрымнар кала кырдан сүзсез генә атлаган Рәшит бирешә башлады. Җәяүләп күп чакрымнар узудан аның ялан аяклары шешенә башладылар. Тәлгатьне тәпиләп атлатып, Рәшитне күтәрде Кави. Тик кечкенә Тәлгать ярты чакрым тирәсе дә узмады, җиргә ятып елый башлады. Кечкенә сабыйның атларлык хәле юк иде...

Бер чара да калмады. Чакрым саен туктап, юл читенә утырып, берәр сәгать хәл алгач кына кузгалып тагын атладылар.Тагын озаклап утырдылар, тагын балаларны елата-елата, Кави юлны дәвам итте...

Еракта Кызыл Атау күренде. Ялан аякларының табаннарына күпертмәләр чыккан сабыйлар торырга көч-хәл таба алмыйча, юл читендәге яна чыккан яшел чирәмгә аудылар. Соңгы сынык арыш ипиен абыйлары пәке белән дүрт бертигез кисәккә бүлде. Юлда, үзеннән-үзе килеп чыккан гадәт буенча, беренче итеп ипи кисәген бисмилла әйтеп кечкенә Тәлгатькә тоттырды. Башта ипине аңа бирмәсән, кечкенә малай кычкырып елый башлый иде. Ач калырмын дип курка сабый. Кыз бала булганлыктан, икенче ипи кисәге Ләмигага бирелә. Аннан соң инде ир-егет Рәшит белән абый кеше Кавига...

Ипине ашап бетергәннән соң кружкага теге бакыр чәйнек борыныннан җылынган суны агызып эчтеләр. Тик, торып тагын атлый башларга балаларның көче дә, теләге дә юк иде. Ашаганнан соң аларны йокы баса башлады. Җәяүләп атлап, төннәрен очраган авылларда, йә абзар артында, йә читән буенда йоклап төн уздырып, сабыйлар бик нык йончыганнар иде. Өстәвенә Ырымбурдан чыккач поезд вагонында аларны бет басты. Үзләре йоклыйлар сабыйлар, үзләре тыжык-тыжык кашыналар. Кечкенә Тәлгать бет ашаганга чәбәләнеп еларга тотына. Ярый әле урамда җылы. Кави малайның алмашлап күлмәген, ыштанын салдырып, кием җөенә тулган кара сыртлы бетләрне үтерергә тотына. Тәлгать, абыйсының «эшенә» карап, сабыр гына көтеп утыра...

Өч кечкенә сабый юл читендәге чирәмдә тирән йокыда. Өчесе бергә, берберсен кочаклап ятканнар. Тәлгать уртада. Чөнки ул йоклаганда тынгысыз— үзе йоклый, үзе үрмәләп читкә китә. Шунлыктан, аны уртага салалар.

Кави утырган килеш йокламаска тырыша. Яңа гына унбиш яшен тутырган, авыр абыйлык йөген өстерәгән Кави да нык йончыды. Соңгы ике көндә атлаган чагында аның күз аллары караңгыланып-караңгыланып китә. Шул караңгылык эчендә сары, яшел төстәге түгәрәк божралар йөргән кебек итеп хәрәкәт итәләр. Башы әйләнә, колаклары чыңлый. Кави, һич көтмәгәндә егылып китәрмен дә, аркага күтәргән Тәлгать имгәнеп куяр дип бик курка. Андый чакларда ул юл читенә чыгып утырырга тырыша, хәл алып күз аллары яктырганны көтә...

Еракта Кызыл Атау авылы күренә. Кавиның һәм балаларның өмет белән кайтып барган авыллары ул. Әтисенең, әнисенең, димәк, аларның да туган авыллары, ничек итеп каршы алырлар икән инде аларны?..

Авыл ягыннан килгән җигүле ат юлның теге як читендә туктады. Буш, кабык җәелгән, арбадан салам эшләпә, бишмәт, тула оек, чабата кигән утыз биш-кырык яшьләр чамасындагы ир кеше төште. Арбада дилбегә тотып ун яшьләр чамасындагы яланаяклы, түбәтәй кигән бер малай утырып калды. Арбадан төшүче чыбыркы тоткан.

Тез башлары ямаулы, буйлы киң төпле ыштан кигән абзый кеше үләндә йоклаган балалар һәм аларны саклап утырган малай янына якынлашты. Ул килеп җитәргә өч-дүрт адым кала, Кави аягына басты. Килгән кеше куе кара

кашлары астыннан юл читендә йоклап яткан балаларны бик җентекләп карап чыкты. Басып торган Кавига эндәште:

—Кая китеп барасыз болай җәфалана-җәфалана?

—Авылга кайтабыз.

—Авылыгыз ни исемле?

Борылмыйча гына кулы белән бик еракта булмаган авылга төртеп күрсәтте Кави.

—Әнә тора—Кызыл Атау.

—Кызыл Ата-ау?

—Әйе .

—Мин бит шул авыл кешесе. Гафиятулла минем исемем. Мин бит сезне беренче күрүем. Кемгә кайтасыз, кайдан?

—Актүбә исемле каладан без. Ярулла бабакайга кайтабыз.

—Яруллага?! Кайсы Ярулла ул? Безнең авылда өчәү алар: Мулла Ярулла, Акчасыз Ярулла, Озын Ярулла.

—Мулла бабакайга кайтабыз без.

Гафиятулланың йөзенә гаҗәпләнү чыкты.

—Тукта, тукта! Актүбәдән?! Әллә сез Ярулла мулланың энесе Һибәтулла балаларымы?

—Әййе.

—Әти-әниеннәр кая?

—Үлделәр.

—Икеседәме?

—Икесе дә.

Ир, авыз эченнән генә дога укып, битен сыпырды:

—... урыннары оҗмахта булсын инде!

Аннары:

—Нәстә эшләп тезелешеп яттыгыз монда юл читендә?—дип сорады.

—Ачлар, арыдылар, бара алмыйлар...

—Ала-ай!

Борылып аты ягына карап алды да, Кавига сөйләгәндәй итеп, сүзләрен тезеп китте:

—Кичә кичләтеп күрше авыл тегермәненә тарттырырга дип сигез капчык бодай илткән идем. Зур малаем төнгелеккә шунда куна калды. Төнен тартып бетергән булырга тиеш. Шул онны алырга китеп бара идек кече малай белән...

Әйдә, энем, без болай итик. Уят туганнарыңны иплəп кенә. Мин сезне ат белән Ярулла хәзрәтнең өенә кадәр илтеп куйыйм. Әтиең мәрхүм белән мендәр мамыгын туздыра-туздыра бәрешеп, мәдрәсәдә бергә укыган идек. Уят иплəп кенә туганнарыңны...

Кабаланып аты янына барды да, малае кулыннан дилбегәне алып, атын кузгатып, борып китереп юл читенә туктатты. Өстендәге бишмәтен салып арбага җәйде. Юл читендә күзләрен уып, уянып бетмәгән Рәшитне күтәреп алды. Үзе елмаеп сөйләнде:

—Мен-нә, минем үскә-ән улы-ым. Атка утырып кайтабыз хәзер авылга. Мунча керәбез бездә-ә. Кайнар бәрәңге ашыйбыз майлап, майлы коймак. Аннан чәй эчәбез кәҗә сөте-е белә-ән!

Биек манаралы агач мәчет янындагы зур агач йорт янында тукталдылар. Гафиятулла абзый арбадан егетләрчә житез, сикергәндәй итеп төште дә, ишегалдына керә башлаган унайга ук сөрән салды:

—Мулла абзы-ый, бер көтү бала-чага кунаклар алып кайттым сезгә. Чык, куан, алып кер. Энең Гибәтулла балалары. Дүртәү, берәү генә дә түгелләләр!..

Өйнең биек болдырында чалара башлаган сакал-мыеклы Ярулла бабакайлары күренде. Аның артыннан Гафиятулланың шаулавы ишетелә башлау белән ук елый башлаган әбекәйләре төшеп килә иде...

Дүрт бала авыр юл газапларын узып, исән-имин, ачлы-туклы, бет баскан хәлдә әтиләренең бертуган абыйсы Ярулла бабакайларына кайтып житү бәхетенә ирешteләр. Мулла белән абыстайның ай-ваена карамыйча, Гафиятулла абзый дүрт баланы кире алып чыгып арбага утыртып үзләренә алып китте: күрдегез, хәзергә булды, сабыр итебрәк торыгыз.

—Бездә мунча әзер. Хәзер чишендереп чабып, эсседә бетләрен бетереп, чәчләрен кырып, юындырып, атта чаптырып китереп житкерәм. Сез әле кайчан ягасыз мунчагызны, кайчан өлгерә дигәндәй, ә безнең мунча әзер. Парларын бөркеп утыра...

Караңгы төшеп килгән чакта мунчада юынып, беттән котылып кайткан дүрт бала сәкедә тезелешеп утырып пешә-пешә кайнар, майлы кыстыбый ашыйлар иде. Беркем дә көтмәгәндә, әле бер сүз дә сөйли белмәгән Тәлгать телен ачты. Майлы бармагы белән Яруллага төртеп күрсәтеп, елмаеп әйтеп куйды:

—Баб-бай!

Бер мизгелгә табын тып-тын торды да, бар да шаулашып көлештеләр.

—Сөбханалла-а!—диде Ярулла бабакае.—Мең яшә улым, зурладың безне.

Күп нужа, хәерчелек күргән, ятим калган дүрт татар баласы бабакае белән әбекәенә кайтып егылдылар...

***

Тормыш дәвам итә...

1922 елның җәе иде...

Хәрбиләрчә киенгән Кави Нәҗметдинов Мәскәү поезды белән Казанга килеп төште. Сул кулына тоткан кечкенә чемоданы белән кабаланмый гына Казан урамнары буйлап атлады. Бу—егерме бер яше белән барган яшь, чибәр егет, Актүбәдән өч туганын Нижгар ягына поезд белән, хәер сорашып аларның тамакларын туйдыра-туйдыра, ачлык белән күзенә ак-кара күренмичә көрәшкән унбиш яшьлек малай түгел иде инде. Дастуен егет иде!

Шул 1917 елның маенда авыллары Кызыл Атауга кайтып төшкәч, дүрт бала бабакае Ярулла йортында яшәделәр. Кави авыл мәдрәсәсендә укыта башлады. 1918 елның көзе бетеп һавада ак карлар күренә башлаган чакта Мәскәүдән кунаклар кайтып төште. Алар әтиләре ягыннан туганнары икән. Дәү әтиләре белән кунак абзыйның да дәү әтисе бертуган булганнар икән. Бер көнне кичке аш янында йорт хуҗасы бисмилласын укыганнан соң сүз кузгатты:

—Улым Кави! Кайттыгыз, исән-сау яши башладыгыз. Үзең безнең мәдрәсә-мәктәптә замана фәннәре һәм урыс теле укытасың. Иншалла, белемең әйбәткә ошаган. Хәзер инде киләчәк көнкүреш турында сүз алып барыйк. Сез дүртәү, без җиңгәң белән икебезгә—янә биш бала. Кашык күтәргәннәрнең исәбе өй эчендә унбер кешегә җитә. Авыррак кына түгел яшәүләре, авырга туры килә. Иншалла, мал-туар да бар, мәхәллә дә карый безне. Шулай булса да, яшәү өчен туган-тумача, атай-әнинең ярдәменә мохтаҗбыз инде без дә бүгенге көнне. Менә Мәскәүдән кайткан абзаң белән апаң. Аларның фамилиясе—Сатдиновлар. Абзаң белән Зөһрә апаң инде болар. Кәлимулла абзаң Мәскәүдә дбурник булып эшли. Ундүртенче елны Герман сугышында раный булып Мәскәү гуспитәлендә яткан. Төзәлә башлагач, иртәләрен гуспитал ишегалдын себерешкән шундагы дбурникка. Шуннан терелеп беткәч, гуспитал башлыклары яхшы эшләгәнен ошатып шунда калдырганнар эшкә. Дбурник итеп инде. Менә унбишенче елдан бирле шунда яшиләр. Хатынын Мәскәүгә алдырды, моннан, авылдан. Тормышлары әйбәт. Байдан булмаса да,

тамаклары тук, өсләре бөтен. Торырга урыннары да бар. Хәзер инде Мәскәүдә, Тула каласына чыга торган юл ягында үз йортлары белән яшиләр. Тик менә балалары юк—дөньяның бер чите китек алар өчен.

Ярулла бабакай туктап торды. Сүзсез генә барысын да күзеннән кичереп чыкты да, Кавига гына мөрәҗәгать итте:

—Кави улым! Мин сезнең әтиең ягыннан бабакаегыз булсам да, син, Кави улым, бүгенге көнне бу балаларга әти дә, әни дә. Бик авыр юлга чыгып, аны үтеп бу сабыйларны исән-имин авылыбызга алып кайтып җитүгә ирештең. Инде хәзер киләчәктә аларны үстерергә вә һәм дә аларны укытып белемле, һөнәрле итәргә дә кирәк. Бу эш синең белән минем генә кулдан килерлек түгел. Синең әле үзеңне аякка бастырырга кирәк...

Менә Кәлимулла абзаң белән Зөһрә апаң, туганлык хисе күрсәтеп, Тәлгать улыбызны үзләренә уллыкка сорыйлар. Теләкләре изге—Тәлгатьне үз уллары итеп, үз фамилияләренә яздырып, үзләре белән алып китеп, ана тәрбия, белем, һөнәр биреп, яхшылап үстерергә исәплиләр. Сиңа үтенечләре бик зур һәм изге: Тәлгать туганыңны син аларга бир, уллыкка.

Ишеткәненнән Кави каушый төште. Балалар өйдә юк, алар ишегалдында качышлы уйныйлар иде. Тирә-яктан җыелган үзләре кебек вак-төяк малай-шалай һәм кызчыклар белән.

—Тәлгатьне Мәскәүгә алып китәләрме?—дип сорады Кави.

—Исәпләре шулай инде. Тәлгать бит аларның улы булса, әти-әнисе белән бергә яшәячәк инде.

Кавиның күңеле тулып Тәлгатьтән аерыласы килмичә елыйсы килә башлады. Шулай да ул аңлый, нужалы, фәкыйрь елларда Ярулла бабакаена көтмәгәндә икеләтә диярлек артып киткән гаиләне туендырып дөнья көтүе авырга туры килгәнне. Бик аңлый.

Байтак кына сүзсез утырдылар. Кави, тынлык озакка сузыла башлаганны чамалап, акрын гына үз уен җиткерде:

—Үзебезнең туганнар да булгач, үзләре теләп уллыкка алырга риза булгач, мин каршы килеп тормыйм инде. Аерыласы килми дә бит Тәлгать белән, тик нәстә эшләмәк кирәк? Уллары итсеннәр, какмасыннар, сукмасыннар туганымны. Үстерсеннәр...

Шулай итеп алар Тәлгать белән аерылыштылар. Икенче көнне яна әти белән әни Тәлгатьне авыл кибетенә алып чыгып баштанаяк киендерделәр, иске-москы киемнән башканы күрмәгән, инде дүрт яше белән барган Тәлгать, әллә каян килеп төшкән бәхеткә аптырагандай, яңа күлмәген, чалбар-камзулын, өр-яңа сырган бишмәтен, колакчын бүреген бер киде, бер салды. Кави кечкенә энесен кочаклап, аңа киләчәк яшәешен аңлатырга тырышты:

—Сине Мәскәү дигән зур калага алып китәләр. Сиңа яңа бишмәт, яңа бүрек, яңа чалбар-күлмәк сатып алган шушы апа белән абый—әни белән әти булалар. Еламыйча гына, аларны тыңлап яшә, Тәлгать, ярармы. Ә без синең янына кунакка барырбыз...

Үзен өр-яңадан киендергән яңа әти белән әни әле өч яше генә тулып узган Тәлгатькә бик тә ошадылар, ахрысы. Өстәвенә, яңа әнисе, Кави абыйсы сөйләгәндә, кәгазьгә төргән ике кәмфит белән бергә бер прәннек тә бирде бит әле...

Кечкенә Тәлгать яңа әти-әни белән Мәскәү каласына поездга утырып китеп барды. Ул шунда Мәскәү татары булып үсәчәк һәм гомере буена Сатдинов Тәлгать Кәлимулла улы булып яшәячәк. Сугышка кадәр водолаз булачак. Кызыл Армиядә хезмәт итеп кайтканына ике ел дигәндә сугыш башланачак. Сугышның башыннан азагына кадәр фронтта булып, ике тапкыр каты һәм өч мәртәбә җиңелчә яраланып, бик нык ватылачак. Сугыштан соң водолазлыкка сәламәтлеге буенча ярамагач, кул һөнәре белән көн күрәчәк. Пенсиягә

чыкканчы Немирович-Данченко исемендәге театрда техник җитәкче булып эшләячәк. 1992 елда 77 яшендә вафат була.

1919 елның гыйнвар башында Кавины Сембер каласына ун айлык укытучылар курсына укырга җибәрәләр. Нижний Новгород өлкәсеннән егерме биш яшь укытучы урыс телен өйрәнү өчен укырга китә. 1919 елның ноябрь башында ун айлык укуны тәмамлаган унсигез-егерме ике яшьлек ир-егетләр «үзләре теләп» Гражданнар сугышы фронтларына, Кызыл Армия сафына басалар. Сембер каласында оештырылган курсларда атарга, граната ыргытырга һәм штыклы мылтык белән кул сугышына, окоп казырга ашык-пошык ике ай чамасы өйрәткән кебек итәләр дә, шул курсантлар бригадасын егерменче ел язында Украинага, Махно гаскәренә каршы сугышка ташлыйлар...

1920 елның июнь башында кызылармеец Кави Нәҗметдиновны Украинадан Мәскәүгә укырга озаталар.

Яңа Совет хакимияте Гражданнар сугышы барышында ук Русиянең киләчәген кайгыртып, яңа тормыш өчен, Советлар өчен сугышып йөргән белемлерәк сугышчыларны сайлап алып, тылга, белем алырга, укырга озата башлый. Шул укуга китүчеләр исемлегенә урысча да, татарча да белеме ярыйсы гына булган, әле унтугыз яше дә тулып җитмәгән, чибәр, тырыш, тәвәккәл татар егете Кави да була. Аны Мәскәү каласына югары хәрби педагогия институтына укырга озаталар.

Биредә уку ике елга сузыла. Халыкның күпчелеге укый-яза белмәгән Рәсәй өчен, заманасы өчен ул институттан бик белемле саналган командир-комиссарлар чыга.

1922 елда әлеге уку йортын тәмамлаган Кави Казанга эшкә җибәрелә. Ул Татар-башкорт хәрби мәктәбенә хәрби укытучы итеп билгеләнә. Гражданнар сугышында зур батырлыклар күрсәтеп сугышкан, Советлар өчен утка-суга кереп сугыша белгән татар, башкорт егетләреннән армия өчен тугрылыклы командирлар хәзерләү башлана. Татар егетләре арасында татарча да, урысча да белемлеләре байтак булса да, башкортлар тоташлары белән диярлек надан булалар. Азрак татарча укый-яза белгәннәре дә татар авылларына якынрак утырган башкорт авылларыннан була. Революциягә кадәр башкортның әлифбасы да, мәктәп-мәдрәсәсе дә булмаган. Башкортның беренче әлифбасын 1923 елда Казанның татар галимнәре төзеп биргәннәр.

1922 елда кайтып Казан татар-башкорт хәрби мәктәбендә эшли башлаган Кавины башта урысча укытырга куялар. Һәм ул көннән-көн тырышып эшләп, бер ел үтәр-үтмәстә белемле, аңлы укытучыларның берсенә әйләнеп китә. Исеме, дәрәҗәсе үсеп, 1924 елда хәрби боерык белән Кави Татар-башкорт хәрби мәктәбенең комиссары итеп билгеләнә. Шулай итеп, хәрби мәктәп белән җитәкчелек иткән ике кешенең берсе Кави була.

Ул комиссарлык эшен 1928 елга кадәр дәвам итә. 1928 елда аны округта татар телендә чыга торган “Кызылармеец” газетасының баш редакторы итеп билгелиләр.

Редактор вазифасын үтәү белән бергә, 1929 елда Кави Нәҗми Пролетар Татар язучылар ассоциациясе (ТАПП) рәисе итеп сайлана.

ТАППның ни өчен төзелүен зур талантлы, татар халкының чын улы һәм патриоты булган Һади Такташ иң беренче булып аңлап ала. Һәм шуңа бәйле рәвештә «Такташ үлде» шигырен яза. Шул шигырьдән соң озак та үтми, Һади Такташ коммунистлар кысуы буенча Мирсәет Солтангалиевны сүгеп шигырь яза: «Солтангалиевтай этләргә...» Ә бит Һади Такташ дус була Мирсәет белән.

1928 елның июль азагында “Урицкий” пароходы белән Максим Горький Казанга килә. Ул Казанда 16 яшеннән 20 яшенә кадәр яшәгән була (1884-99 еллар).

Горький татарларга зур ихтирам һәм мәхәббәт белән карый. Татар язучыларына, татар әдәбиятын аякка бастыруда ярдәме ифрат зур. Татар язучылары арасыннан Максим Горькийның игътибары бигрәк тә Кави Нәҗмигә карата зурдан. Ул, Горький белән танышкач, аңа үзенең урысчага тәрҗемә ителгән «Шобага» дигән хикәясен тапшыра. Горькийның «Шобага»ны укыгач, К. Нәҗмигә язган хатыннан өзек. «...Сезнең бүләкне алдым—«Шобага» исемле хикәянең кульязмасын. Рөхсәт итсәгез, мин Сезгә гадиерәк тел белән язарга киңәш итәр идем. Чын матурлык һәм акыллылык (мудрость) һәрвакыт гади була!» "Дусларча, мина ярдәм итеп, өйрәтеп язган ул хатны алу минем өчен иксез-чиксез шатлык булды. Шул хаттан соң мин барлык язылган хикәяләремне янадан карап чыктым"...—дип яза К. Нәҗми.

1929 елның август аенда Горький тырышлыгы белән Татарстан язучыларының һәм сәнгать әһелләренең пароходта Идел буйлап башланган сәяхәте оештырыла. Сәяхәтнең маршруты: Казан—Астрахань—Махачкала—Баку—Тбилиси—Батуми—Ялта—Харьков—Мәскәү—Казан. Сәяхәттә катнашучылар: Галимҗан Нигъмәти (җитәкче), Гомәр Гали, Кави Нәҗми, Шәриф Камал, Кәрим Тинчурин, Һади Такташ, Салих Сәйдәш, Гадел Кутуй, Шакир Шамильский, Мөхәммәт Гали, Гомәр Толымбайский, Сәрвәр Әдһәмова, Закир Гали, Зариф Бәшири, Исмәгыйль Рәми, Гаврил Беляев, Лев Рубенштейн һәм яшьләрдән—Мирсәй Әмир, Демьян Фәтхи, Газиз Иделле.

Бу төркем айдан артык вакыт эчендә төрле-төрле калаларда булып, Дагыстан—Әзәрбәйҗан—Грузия—Кырым—Украина аша үтеп, төрле халыклар, язучылар белән очрашып, башка халыклар тормышын күреп, аларның иҗаты белән танышып, үзләрен—татар язучыларын да күрсәтеп бик җылы һәм матур очрашулар оештырып сәяхәт итәләр. Кырымда Ялтага кереп, Галимҗан Ибраһимов белән очрашып, ул яшәгән йортта кунак булып, байтак сөйләшеп утыралар...

Сәяхәт азагында Мәскәүдә Максим Горький һәм бер төркем урыс язучылары белән очрашу, әңгәмә була...

Кави үзенең беренче шигырен 1913 елда Актүбәдә уникe яшьлек малай чагында яза. Ул шигырь «Көз» дип атала. Һәм шул ук елны Михаил Кольцовның «Лес» дигән шигырен татарчага тәрҗемә итә.

1922 елда Казандагы хәрби татар-башкорт мәктәбенә укытырга кайткач, Кавиның таланты ныклап ачыла, ул татар язучылары арасында Шәриф Камал, Галимҗан Ибраһимов һәм Мәхмүт Галәү белән бер сафта иң күп язучы һәм иң сәләтле язучыларның берсе булып китә. Язучыларны оештыручы һәм аларның җитәкчесе булып та таныла башлый.

Кави Нәҗметдинов туган авылы Кызыл Атауда авыл мәдрәсәсендә укыганда «Безнең иҗат» исемле кульязма журнал чыгара. Шул журналда үзенең, авыл укытучыларының һәм белемле кешеләрнең язмалары урын ала. Журнал Кави авылдан Сембергә укырга киткәч тә чыгуын дәвам итеп, 1941 елга кадәр чыга.

1924 елдан соң яшь язучының (аңа тик 23 яшь кенә) күпсанлы хикәяләре, поэмалары, публицистикасы һәм шигырьләре басылып чыгып, дөньяга билгеле булып тарала. Иң мөһимнәрен күрсәтеп китик.

1924 елда «Өермәләр» исемле шигырьләр җыентыгы басылып чыга. Бу инде Кавиның иң беренче шигырьләр җыентыгы булып, аның иҗат юлын уңышлы башлап алып китүдә зур урын били. Бер-бер артлы чыккан әсәрләре: «Кабыргасы белән тора» (1925 ел. Хикәя), Галимҗан Ибраһимов белән бергә чыгарган «Татары и башкиры в Красной Армии» (1926), «Шобага» (1926. Хикәя), «Иң соңгысы» (1927. Хикәя), «Миңлебикә кодагыйның кайгысы» (1927 ел. Хикәя), «Таштугайга кайтмыйбыз» (1929), «Яр буенда учаклар» (1928 ел. Повесть), «Якты сукмак» (1929, Повесть), «Көязлы яңгыр» (1930ел. Повесть).

Кави Нәҗми, язучы буларак, үскәннән-үсә, остарганнан-остара бара. Табигать биргән талантына искиткеч эшчәнлек кулланып, ул язучылар арасында иң белемле, эрудицияле шәхескә әйләнә. Әгәр дә шәхес, табигать тарафыннан бирелгән талантына таянып кына, үзенең белемен үстерүгә омтылмаса, ныклап, тырышып эшләргә өйрәнмәсә, ул юкка чыгачак. Талантка таянып кына яшәргә тырышкан, яшьли зур уңыш белән яза башлаган һәм күпмедер вакыт узгач, үз өстендә эшләүдән, язудан туктап инде иҗат итә алмыйча эчә башлаганнар язучылар арасында байтак. Кави Нәҗми, Аллага шөкер, һәрвакыт белемгә омтылып, үз өстендә эшләп, талантын кулланып, классик, халык язучысына әйләнеп китә.

Утызынчы елларда (1937 елның җәенә кадәр дип ныклы әйтеп була) Кави Нәҗми, хатыны Сәрвәр Әдһәмова һәм бердәнбер улы Тансык (1927 елның мартында туган) белән Казан каласының Международная 19 нчы йортында яшиләр. Бүгенге көндә ул урамның исеме—Кави Нәҗми. Кавилар яшәгән фатир үзеннән-үзе әдәби клубка әйләнә. Атна саен шул фатирда бер, йәисә ике мәртәбә татар язучылары җыела торган була. Алар үзара фикер алышалар, бер-берсенең язганына бәя бирәләр, иптәшләрчә тәнкыйть итәләр, бер-берсеннән җиңелчә, шаярып көлә дә беләләр. Сәрвәр Әдһәмованы мандолинада уйнатып җырлаталар. Чибәр хатынның моңлы тавыш белән мандолинада уйнап җырлаганына сокланып, Салих Сәйдәш үз уен әйтеп сала:

—Сәрвәр! Җаным! Синең урының сәхнәдә! Ташла шул тәрҗемәчелегенне! Сине бит искиткеч сәхнә даны көтә!

Сәрвәр иң оста тәрҗемәчеләрнең берсе булып өлгергән инде. Салихның шундый сүзләр белән үзен мактаганына ул елмаеп кына җавап бирә дә, мандолинага кушылып тагын җырлый башлый.

Кави Нәҗми фатирындагы язучылар мәктәбен үтеп, оста, атаклы язучы булып киткән затлар: Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов, Шамил Усманов, Фатих Кәрим, Мирсәй Әмир, Ибраһим Салахов. Үзләрен Кави Нәҗми укучылары итеп саналган тагын бик күпләр бар. Чөнки Кави Нәҗми, башка кешенең уңышыннан көнләшә белми торган хөсетсез, ачык йөзле, киң күңелле кеше дә, язучы да булган. Кавиның төп максаты: халкының әдәбияты, сәнгате үссен, тормышы матурлансын. 1937 елның җәенә кадәр Кави Нәҗми оештырган тагын бер матур күренеш бар.

1933 елда Татарстан Язучылар берлеге оештырыла. Коммунистлар партиясе Татарстан язучыларын тулысынча үз идеологиясенә буйсындырып, үз күзәтүе астына, аларның иҗаты өстеннән үзенә, диктатор һәм цензор вазыйфасын ала. Татар халкы өчен кирәк дип янып-көеп иҗат итеп эшләгән чын татарча патриотик язучыларның баш өстендә репрессия болытлары куера башлый. Тик язучыларның берсе дә әле ул турыда шикләнми дә, уйламый да. Аларның күпчелегенә татар әдәбияты киң колач салып алга йөзә, алга бара булып тоела. Киләчәк ал да гөл, яз да яз гына татар өчен!..

Кави Нәҗми Язучылар берлеге рәисе итеп бертавыштан сайлап куела. Хәтта көнчелек утында янган уртакул язучылар да аңа каршы чыгарга җөрьәт итә алмыйлар. Аны кимсетергә, йәисә юк итәргә җае чыгарлык түгел—дәрәҗәсе, исеме, таланты зурдан, шунлыктан көч җитәрлек түгел. Әлегә!..

Кави зур оештыручы таланты күрсәтеп эшләвен белә. Зур эмоция белән, зур нерв киеренкелеге белән эшләгән, язган халыкка ял да кирәк. Совет хакимиятендә утыручыларның кабинетыннан кабинетына йөреп, Кави алардан акча таба. Һәм әдәби фонд директоры Сәмитов белән берлектә Иделнең Казанга каршы як ярында утырган Түбән Ослан авылында яшәүчеләрнең өендә егермеләп бүлмәгә, акча түләп, җәйлеккә язучыларга шунда ял оештыралар.

Кави Нәҗминең улы Тансык истәлегеннән:

—Түбән Осланда, шунда үз йорты белән яшәгән кешеләрнең өендә берәр бүлмә алалар иде Язучылар берлегенә. Акча түләп инде. Һәр язучыга берәр бүлмә. Гаиләсе белән шунда урнашып берәр ай ял итәләр. Яр башына басып Иделгә карап торырга ярата идем мин. Басып торасың текә яр башында. Ә Идел-Су буйлап ак пароходлар йөзә. Икесенең исеме әле дә исемдә: «Жемчужина» һәм «Алмаз». Икесе дә бик борынгы пароход инде. Заманында бай купецларныкы булганнардыр инде. «Волга-Волга» киносында күрсәтелгән «Севрюга» исемле пароходныкы кебек, шул ике пароходның артында әйләнә торган зу-у-ур су тәгәрмәчләре куелган. Су агымына каршы да йөзә. Без, вак-төяк бала-чага, яр башыннан шул пароходларга төялеп, каядыр китеп барганнарга кул болгыйбыз. Алар да безгә кулъяулык болгыйлар. Безгә шул кызык тоела инде!

Июль-август айларында бурлаклар аркан белән яр буйлап атлап баржаны өстериләр. Су агымына каршы. Утыз алтынчы елда да Иделдә бурлаклар бар иде әле. Шул бурлаклар өстерәгән баржаларда туп-тулы карбыз-кавын була. Камышин, Астрахань якларында үстергән зур-зур карбызлар инде. Идел-Су белән бурлаклар ул карбыз-кавын төягән баржаларны калаларда сатарга дип өстериләр инде. Кичтән сөйләшеп куеп, таң ата башлауга, әти язучыларны оештырып балык тотарга яр буйлап Иделгә һәм якын-тирәдәге кечкенә күлләргә алып чыга. Кич булды исә Түбән Осланда ачык тәрәзәләрдән урыс җырлары яңгырый башлый. Осланда күпчелек урыслар яши һәм һәрбер өйдә диярлек патефон бар. Ачык тәрәзәләрдән салмыш урысларның кычкырып-кычкырып сөйләшкәннәре, көлгәннәре ишетелә. Патефоннан Шаляпин, Утесов, Михайлов, Лемешов, Козин, Виноградов, Шульженко җырлыйлар. Урысларның яраткан җырлары «Я и моя Маша», «Утомленное солнцем», «Кукарача», «По диким степям Забайкалья», «Дубинушка» дигән моңлы җырлар яңгырый. Кич тагын шул Түбән Осланда ял иткән язучыларны әти озын җәтмә белән балык тотарга алып чыга. Балык тотарга ихлас җаннар җыела: Шәриф Камал, Гадел Кутуй, Галимҗан Нигъмәти, Закир Сәмитов, Кәрим Тинчурин, Тажи Гыйззәт һәм иң активы—Салих Сәйдәш инде. Җилкәсенә җәтмәне салыр иде, миңа чиләк тоттырып, үзеннән калмаска кушып, яр буеннан сузылган сукмактан, әтигә ияреп икенче булып атлар иде. Бик күңелле кеше иде Салих абый, һәрчак җор сүзле, елмаеп сөйләшә торган абзый иде ул...

Барып житәләр. Чишенеп балык сөзә башлыйлар. Җәтмәнең бер ягына Кутуйябыша. Салих абый белән җәтмә очы өчен һәрчак алар арасында бәхәс куба—кем тота җәтмәнең тирән яктан йөрткән очын. Гадел абый терсәге белән Салих Сәйдәшне читкә этә, үзе көлә:

—Син, атаклы Сәйдәш, балык дип тирәндә йөреп батып үлсәң, Кәрим Тинчуринның пьесаларына кем музыка яза? Ту-ты менә! Шунлыктан сине, татарның бөек композиторын, без сакларга тиешбез.

Салих абый да көлә:

—Мин батмасын дип үзең батып үлсәң?

—И-и, Сал-лих! Минем кебек уртакул язучылар Казан урамы тулы. Мнугы—как нерезанных собак. Мин батканнан, еласа, хатын елар, балаларны кем туендырыр инде хәзер дип. Бик җәтмә өстерисең килсә, бар, тегe очынаябыш та, ярдан бик тирәнгә кермә...

Бик эчкә кермичә, яр читендәге кечкенә күлләрдән җәтмә белән йөреп балык сөзәләр. Без, алты-җиде яшьлек малай-шалай, Галимҗан абый җитәкчелегендә ярга өстерәп чыгарган җәтмәдән чиләкләргә балык тутырабыз. Ниндиләре генә юк: табан балык, алабуга, чабак, сирәк-мирәк кенә шамбы да, слә балыгы, күпсанлы ташбаш. Җәтмәне судан ничек итеп кайсы якка өстерәү белән Шәриф Камал җитәкчелек итә. Аны да буш итмиләр, көләләр

анардан да. Бигрәк тә инде Салих Сәйдәш «тырыша»:

—Илләмә дә Каспийдагы промыселларда балык тотып шомаргансың син, Шәрифулла абзый. Каспий акчарлаклары тавышлары һаман исеңдә ахрысы. Тавышың да көр чыга—слә эләгә инде болай булгач...

Яр буенда учак ягып уха пешерә башлыйлар. Күбесенчә мине яр башына озата эти. Үзе көлә:

—Бар әниеңнәрне, бала-чага дусларыңны чакыр. Әйт: бөек язучылар үзләренең шулай ук бөек хатыннарын уха ашарга чакыралар, диген. Тиз килсеннәр дип әйтте эти, тик ярдан йөгереп төшкәндә егылып китеп, чибәрлекләренә зыян китерә күрмәсеннәр, дип әйттеләр диген!

Уха пешерү белән эти командалык итә. Бәрәңге, борыч, тоз, суган барысы да—аның куллары аша үтә. Пешерергә тотыныр алдыннан эти, Салих Сәйдәшне чиләкләре янына якын җибәрмәскә дип, учак янына Гадел абыйны сакка куя. Салих абый көлеп, һәрчак исләренә төшерә:

—Сезгә үч итеп ухага күп тоз салганыма өч ел тулып, дүрткә китте бит инде. Башкача салганым юк бит инде. Шуны һаман онытмыйсыз, әй!

—Кайсыдыр бер елны Салих абый ухага тоз чумырган икән—ашамаслык булып, яңадан пешергәннәр икән.

Шау-гөр килеп хатын-кыз, бала-чага ярдагы сукмактан уха ашарга дип төшеп киләләр. Янган учак яктысында үләнгә җәелгән палас, брезент өсләренә тезелешеп утыралар. Һәркем үзе белән алып төшкән савытка эти уха сала. Галимҗан абый Нигъмәти ярыйсы гына зурлыктагы киндер букчага тыгылып, сөйләнә:

—Мәе булмаса, балык шулпасы инде ул, мәй булса, урысчалатып инде, уха дип атала.

Балчык кружкага мәй сала да, беренчесен Шәриф Камалга суза:

—Каспийда балык тотканда салгалап, сугышып тукмалганнарыңны исенә төшер! Тот, Шәрифулла абый.

Уха ашау башлана... Шау-шу, уен-көлке, бер-берсеннән шаяртып дусларча көлү, юмор...

Шул репрессияләр башланыр алдыннан, утызынчы еллар уртасында булган күңелле балык тотулар, уха пешерүләр кебек еллар минем тормышымда башкача булмады да... Нинди шәхесләр иде ул балык тоткан кешеләр! Инде хәзер төштәге кебек кенә күз алдына килгәлиләр. Сагындыралар бик нык итеп, үзәкләрне телгәләп, йөрәк кылларын өзгәләп...

1936 елның җәе Кави Нәҗми өчен һәм үз фикере белән яшәргә омтылучы һәм яшәүче язучылар өчен соңгы тыныч җәй булган. Кави Нәҗми янында тупланган талантлы язучы дуслары Татарстан тормышының һәр тармагына якты йогынты ясап, нурлы итеп, кешелекле итеп яши белгәннәр.

1937 елның 11 июне. Мәскәүдә «Хәрбиләр заговоры» дигән хәрбиләр төркемен «хөкем итеп», 12 июньгә каршы төндә аталар. Ул төркемдә Кызыл Армиянең иң атаклы, иң башлы, исемле командирлары була. Алар: Советлар Союзы Маршалы Михаил Тухачевский, I ранг командармнары Иона Якир, Иероним Уборевич, II ранг командармнар Корк, Эйдеман, Фельдман, Виталий Примаков һәм Путна булалар. Бу командирларны атуның сәбәбе—Сталин житәкләгән хакимиятнең СССР дигән илне тиешенчә, уңышларга ирешеп эшләтә алмыйча, зур кризиска кереп баруыннан. Илдә тоталитар репрессия башлана. Исемнәре бөтен Җир шарына билгеле булып, чит илләргә курку салып торган атаклы, исемле командирларны урам бандитларын аткан кебек, җинел генә итеп юк итү, СССР дигән илне, иң кечкенә, хәерче булган кешедән алып, наркомнарга кадәр тетрәндерә, шөбһә-куркуга сала. Исән калырга тырышып, халыкның күпчелеге берсе өстеннән берсе НКВД исеменә, Нарком Ежов исеменә, район милициясе, НКВД начальнигы исеменә шикаятьләр

язарга тотына.

Казанда исә «буржуаз татар милләтчеләре» барлыкка китерелә. Ачыктан-ачык, оятсыз, фактларсыз иң алдынгы зыялыларны, игелекле, сәләтле, акыллы, эшли белә торган затларны, юк итү башлана. Репрессиянең тегермән ташлары астына бик күпләр эләгеп юкка чыга. Обкомга «сигнал» артыннан «сигнал» ага башлый. Аерым язучылар өстеннән дә, Язучылар берлеге рәисе Кави Нәҗми өстеннән дә берсеннән-берсе пычрак яла яга торган шикаятьләр агыла. Язучылар берлеге рәисе Кави Нәҗмине март аенда, июнь башында бер-бер артлы Татарстан обкомына чакыралар. Обкомда аның белән «җаваплы коммунист җитәкче» икәнен күз алдында тотып, бик каты «сөйләшәләр». Анардан Язучылар берлегендә «үзләренә оя корган» «халык дошманнары»н фаш итеп, Союздан кудыруын таләп итәләр. Ул «халык дошманнары»—Гомәр Гали, Евгения Гинзбург, Шамил Усманов, Хәсән Туфан, Фатих Кәрим. Шулар өстенә Язучылар берлегендә байтак «троцкистлар» да яшеренеп ята икән. Аларны эзләргә, табарга, фаш итәргә һәм Берлектән куарга кирәк!

Моның өчен Язучылар берлеге рәисе Кави Нәҗми кичекмәстән гомуми җыелыш җыеп, язучылар арасыннан пролетариатның дошманнарын һәм «татар милләтчеләрен» эзләп табуны, аларны юк итүне оештырырга тиеш була. Тик Кави ашыкмый. Язучыларга уйланырга, булачак «дошманнар эзләү» җыенына әзерләнергә мөмкинлек бирә. Ул җыен тик 5 декабрьдә генә була. Обком карары чыгып бер ай сигез көн узгач кына. Обкомнан «жандарм» ролен башкарырга килгән инструктор Таһир Имаметдинов, җыен узгач, икенче көнне обкомда хәбәр итә: «Җыен парад кебек зур шау-шу белән үтте. Кави Нәҗми зур доклад ясады. Тик докладта критиканың әсәре дә юк иде. Бик озак һәм көчле кул чабулар барды. Нәҗминең ясаган докладында бер генә җитешсезлек тә күрсәтелмәде, бер генә язучы әсәренең дә кире ягы билгеләп үтелмәде. Кави Нәҗми ясаган докладының исеме дә пафослы иде: «Бөек иҗат юлы белән!» Язучылар җыелышында күпчелек сөйләшү һәм чыгышлар тик татар әдәбиятын үстерү юллары хакында гына барды. Һәм бу җыелышта барган татар әдәбиятын үстерү турында гына сөйләшү, Татарстан обкомының «Дошман элементларын юк итүдә актив чаралар күрергә кирәк!» дигән таләбенә җавапмы? Бу нәрсә?"

Әлеге җыелыш обкомны ярсуга китерә. Кичекмәстән Язучылар берлегенең «эшен тикшерү өчен» обком тарафыннан махсус комиссия төзелә. Комиссия җитәкчесе итеп Т. Имаметдинов билгеләнә. Язучылардан комиссияга Ш. Камал, Г. Усманов-Иделле кертеләләр.

Комиссия өч ай эшли. Һәм дөньяга коточкыч фаш итә торган «Татарстан Язучылар берлегенең эше» исемле документ чыгарыла.

Татар язучыларын нәрсәдә генә гаепләмиләр: «Икейөзлеләр, контрреволюционерлар, антисоветчы элементлар, кыскасы, халык дошманнары!" Комиссиянең 1937 елның 28 апрелендә ясаган нәтиҗәсенә таянып, Татарстанның ВКП(б) өлкә комитеты үзенең чираттагы карарын кабул итә: «Татарстан Язучылар берлеге турында». Бу карар Татарстан язучыларына аяктан егарлык итеп сугу, аларны тар-марга китереп туздырып ыргытып, талантлыларын бөтенләй мораль яктан да, физик яктан да юк итү була. Карарның «а» пункты белән Кави Нәҗми рәислектән төшерелә.

Тагын Язучылар берлегенең гомуми җыелышы уздырыла. Ул 28 апрельдән алып 5 майга кадәр бара—сигез көн туктамастан җыелыш!..

Мондый трагик, куркыныч җыелыш—Татарстан язучылар тарихында бердәнбер. Залда әйтерсең лә инде җинаятьчеләр өстеннән суд бара. Төп гаепләүчеләр—язучылыкның ни икәнен дә белмәгән, партийный шигарь-лозунглардан башканың бер нәрсәсен дә аңлый алмаган ярым надан обком күселәре Т. Имаметдинов белән Г. Мөхәммәтҗанов...

Тәнкыйтьнең төп уты, иң көчле ялкыны—Кави Нәҗмигә.

Аның белән эшләгәннәрнең байтагы троцкист-зиновьевчылар булып чыгалар да, шуларга карата һәм рәис булып эшләгән Кавига, урысчалап әйтсәң, «беспредел» башлана. Кеше өстеннән шикаять язып, аны аттыру, төрмәгә тыгу бик ансатка әйләнә. Илдә «халык дошманнары»н күпләп-күпләп юк итү башлана.

1936 елның җәй азакларыннан ук Татарстан Язучылар берлегенә төрле гайбәтләр, имеш-мимешләр чыгып, язучылар арасында бер-берсе турында төрле "тарихлар" сөйләү, бер-берсен пычратып юк итүләр башлана. Шул гайбәтләрнең, пычратуларның, ризасызлыкларның күбесе Кави Нәҗми башына һәм талантлары зурдан булган күренекле язучылар исеменә туры килә. Татарстанга, Мәскәү тарафыннан бирелгән күрсәтмә буенча, репрессиянең кара болытлары якынлаша. Обком тарафыннан шул сигез көн барган җыелышка җибәрелгән обком "эшмәкәрләре" Т. Имаметдинов һәм Г. Мөхәммәтҗанов иң талантлы язучыларны юк итеп чыгышлар ясыйлар. Т. Имаметдинов утыз мәртәбә Кави Нәҗминең исемен телгә алып, аны мәсхәрәли, таптый, яла яга. Г. Мөхәммәтҗанов (обком секретаре) үз чыгышын тик Кави Нәҗмигә багышлап, аны таптый, пычрата, юк итәргә тырыша.

Халык ачуын юнәлтергә «дошманнар» кирәк Татарстанда! Һәм 1937 елда җитәкчелек итә белмәгән коммунистлар иң зур «халык дошманнары»ның берсе итеп Кави Нәҗмине сайлап алалар. 1937 елның апреленнән башлап ел азагына кадәр «Кызыл Татарстан» гәҗитендә Кави Нәҗмине сүгеп, аның әсәрләренең сәяси яктан зыян китерүләре» турында язалар. Гәҗиттәге бер мәкаләдән өзек: «...үзе янына антисовет элементларны туплап, дошманнарын оештырып, Язучылар берлегенә фашистик-троцкистик идеалларны татар әдәбиятына кертеп эшләде». Аның язган әсәрләрен «контрреволюцион, Советларга каршы!»—дип матбугатта ике мәртәбә язучы Фатих Хөсни мәкалә белән чыга. 1937 елда бик күп дус булып йөргәннәр дә, куркуларыннан Кави Нәҗми артыннан төрмәгә эләкмәс өчен,сыналар, саталар, икейөзлегә әйләнәләр.

Кави Нәҗмигә «халык дошманы», «буржуаз татар милләтчесе» дип исемнәр тагып, Обкомның беренче секретаре А. К. Лепа чыгыш ясый. Бер ел үтәр-үтмәстән «халык дошманы» дип аның үзен аталар...

1937 елның 12-14 июнендә Кави Нәҗминең «Персональ эшен» Берлек идарәсендә «тикшерәләр». Хәсән Туфан, Әхмәт Фәйзи, Фатих Кәрим, Гомәр Толымбайскийны да Кави Нәҗми «эшенә» кушалар. Алар «буржуаз татар милләтчесе» дип, «антисовет идеяләрен пропагандалауда» гаепләнәләр һәм бишесенә дә «халык дошманы» дигән исем тагыла. Бишесен дә Язучылар берлегеннән чыгаралар. Берничә көннән 1919 елдан бирле ВКП(б) әгъзасы булган Кави "Нәҗмине партиядән куалар... Аның үзе, хатыны Сәрвәр һәм ун яшьлек улы Тансык өчен караңгы көннәр, куркыныч төннәр, мәсхәрәле тормыш башлана...

Кави Нәҗмине 1937 елның 2 июлендә кичке унбердән соң алырга киләләр. Зәңгәр түбәле, кара козыреклы фуражка, кин каеш буган гимнастерка, галифе чалбар, хром итек кигән дүрт ир кеше фатирга килеп керәләр. Ишек төбендә туктап та тормыйлар, әйтерсең лә бу фатирда алар хуҗа. Туры зур бүлмәгә, идәнгә шак-шок атлап үтәләр. Лев Толстой хикәяләрен урысча укып утырган ун яшьлек уллары Тансык куркуыннан ап-ак була. Кергәннәрнең иң алдагысы Кавига карап, урысчалатып сорый:

—Сез буласызмы Кави Гибатович Наджметдинов?

—Мин булам!

—Без НКВД хезмәткәрләре. Сез кулга алынасыз. Менә арестка ордер.

Үзе белән килгәннәргә борыла да бу, боерык бирә:

—Тентүне башлагыз!

Дивар кырыенда куркынып басып торган ике хатынга да сорау ява:

—Сез кемнәр буласыз?

—Мин Кавиның хатыны!—ди Сәрвәр.

—Ә сез кем?

Бу сорау—Кавилар белән бергә яшәгән Хатирә апага.

—Мин туганнары. Бу ике язучы хуҗалыгын алып барам, улларын карыйм.

НКВД кешесе аңламый, ахрысы, төпченә:

—Домработницамы?

—Түгел. Туган тиешле. Урысча—родственница, Сәрвәр ягыннан. Ятим кеше мин. Ялгыз яшәве авыр, шунлыктан мине үзләренә яшәргә алдылар.

—Анлашылды. Домработница, димәк. Шулай дип язып куярбыз.

Хатирә апаның Кавига авырга төшмәсен дип үзен «Домработница» иттереп яздырасы килми. Ул каршы төшә:

—Мин «домработница» түгел, туганнары.

Зәнгәр фуражкалы Хатирә апага акрын гына, тоташ гәүдәсе белән борыла:

—А ну, сука, заткнись! Мин сасы көзән дигәнмен икән, димәк, ул нәстә сандугач килеш тә сасы көзән булачак! Син—Домработница! Димәк, янарак кына коммунист булган бүгенге «халык дошманы»» Кави Нәҗметдинов кеше яллап эшләтә үзенә. Димәк, буржуй һәм капиталист! И, баста-а!

Аннары янә хатыннарга җикерә:

—Барыгыз, кухняга чыгыгыз!

Өстәл артында куркуыннан тын алудан да туктап, ап-ак булып утырган ун яшьлек Тансыкка бармагы белән төртеп күрсәтә:

—Бу көчекне дә үзегез белән алып чыгыгыз!

Бергә килгән өч кеше фатирның бүлмәләрендә барлык нәрсәнең астын-өскә китереп тентү ясый.

Башлык Кавига шом тулы тавыш белән сорау бирә:

—Әй, син, пижамалы! Кесәңдә наганың юкмы?

—Юк.

—Нарком, маршал Ворошилов бүләк иткән исемле наганың кайда?

—Кабинетта, өстәл тартмасында.

—Күрсәт.

—Әйдәгез.

Алдан атлап үзе кабинетка кереп китә. Бусаганы атлау белән галифелы боерык бирә:

—Тукта. Кулларыңны күтәреп диварга йөзең белән бас.

Кави аның боерыгын үтәп баса.

—Наган кайда?

—Әнә, тәрәзә янындагы өстәлнең уң як тартмасында.

—Селкенсәң, атам! Шул хәлеңдә генә басып тор!

—Курыкмагыз! Селкенмәм!

—Мин синнән курыкмыйм!

Өстәл янына үтеп, Кавины күзеннән ычкындырмыйча, ул үрелеп өстәл тартмасын тартты. Аннан кобуралы наган алды. Тагын нәрсәдер күрде—чылбырыннан тотып кесә сәгате тартып чыгарды.

—Бу каян?

—Иптәш Ворошилов бүләк иткән исемле көмеш сәгать.

—Сволочь! Хәтта нарком маршал Ворошиловны да алдап исемле наган белән сәгать алуга ирешкәнсең.

Кави кулларын дивардан алып НКВДшникка йөзе белән борылды:

—Син кушылган пычрак вазифаңны үтә, вә ләкин мине мәсхәрәләмә. Мин сволочь түгел, ә татар халкының язучысы.

НКВДшник револьверын күтәреп Кавига таба төзәде:

—Борыл диварга! Куй кулларыңны шул диварга! Ну!!!

—Ат йөземә! Борылмыйм мин!

НКВДшник урыныннан кузгалып Кавига таба атлый.

—Тукта шунда!—ди Кави.—Мина сугарга уйласаң, мин каршы торачакмын.

Туктый теге. Күзләре ялтырый.

—Ну, татарская морда! НКВДга барыйк әле! НКВД лейтенанты Никодимовның кем икәнен күрсәтермен мин сиңа.

—Күрсәтерсең! Кулыңнан килсә!

—Килә. Сез татарларның без урысларны өч йөз ел изгәннең үчен мин синнән алачакмын. Чык теге бүлмәгә!..

...Берничә сәгатьтән фатир асты өскә китерелеп тентелгән иде. Кавиның, Сәрвәрнең кәгазьләрен үзләре белән алып килгән күн капчыкларга тутыралар. Мендәрләр, матраслар пычак белән туракланып идән, өстәл тулы каз мамыгы, матрас мамыгы агарып ята. Идән каз мамыгы белән ак кар кебек капланган...

Тентү бетеп, капчыклар тутырылганда таң атып килә иде инде...

Кавины алып чыга башлыдылар:

—Кулларыңны артка куй! Атла урамга!

Кухнядан атылып Сәрвәр килеп чыкты да, кулларын җәеп иренә ташланды:

—Кави-и! Бәгъре-ем!

Кочаклаштылар. Кавины арттан йөгереп килеп улы Тансык кочаклады. Кухня ишеге төбендә Хәтирә апа сыктап елый. Тегеләрнең берсе аны шуннан чыгармады. Кави Сәрвәренә, аны кочаклап, иркәләп дәште:

—Сәрвәркәй-йем! Үзеңне, Тансыкны саклый күр. Тиздән бар да ачыкланыр. Мин нинди «халык дошманы» булыйм ди инде?! Батрак малае! Гражданнар сугышында кызылларда сугыштым, Кызыл Армиягә ундүрт ел гомеремне бирдем бит мин. Нык бул!

Кулларын артка куйдырып алып чыгып киттеләр. Сәрвәр белән Тансыкны фатирдан чыгармадылар. Кави баскычтан төшеп барганда артыннан улы Тансыкның илереп елап кычкырганын ишетте:

—Кая алып китәсез минем әтиемне-е? Җибәр-регез! Әтием бит ул минеем.

Кулларын артка куйдырып ишек алдына алып чыктылар. Анда бер жинел һәм бер йөк машинасы көтеп тора иде. Кәгазьләр тутырылган зур өч күн капчыкны, ике китап шкафы, бер өстәл, матур гына артлы дүрт урындыкны йөк машинасына төяделәр. НКВДда шкаф, өстәл-урындыкларга кытлык иде. Кавины кара төстәге җинел машинаның арткы өлешенә утырттылар. Ике ягына ике галифелы утырды. Тентү, арест белән җитәкчелек иткәне алга, шофер янына кереп утырды. Кулындагы револьверын алдына салды да, шоферга боерык бирде:

—Киттек.

Машиналар бер-бер артлы кузгалдылар. Дүрт катлы кирпеч йортның берничә тәрәзәсеннән шунда яшәгәннәр, пәрдә артыннан күренмәскә тырышып, курыккан күзләре белән карап озатып калдылар.

Утыз җиденче елның җәендә СССР дигән илне тоташы белән курку басып алган иде инде...

Кулга алып, Кремль янындагы төрмәгә китереп япкач, Кавины унбер көн буена бимазалаучы булмады. Камерада егерме өч тоткын иде. Шул камерада

ятканнар ана, төрмә кануннары буенча, ишек төбендәге параша янындагы топчанга урын күрсәттеләр. Көне буе каты топчанда, үзенә урын таба алмыйча бер торып, бер ятып көн үткәрде. Ашау бик начар. Тик бала чагында ярлылыкта, хәерчелектә яшәгән Кави өчен бу көтелмәгән хәл түгел иде. Нәрсә бирсәләр, шуны ашады. Икенче көнне Кави үзенә карата ниндидер начарлык сизә башлады. Башта әллә ни игътибар итмәскә тырышса да, тора-бара, сагайды. Ялгышмаган икән. Ятагында урнашып йоклый гына башлаган иде, башын сасы бишмәт урап капладылар да, берничә кеше тавыш чыгармыйча гына аны дөмбәсләп кыйнарга керештеләр. Берсе акрын гына кисәтте:

—Акырсаң, буып үтерәбез!

Берничә минут каты гына бәргәләгәч, башына ураган бишмәтне алып киттеләр.

Кави, зур авырлык белән торып, топчанына көчкә үрмәләп менеп ятты. Башында бер генә уй: нигә кыйнадылар?

Иртәгесен озак күзәтеп утырды топчанында Кави. Һәм каршы дивар ягында, аргы почмакта яткан кырык яшьләр чамасындагы тоткынны башкалардан аерып карый башлады. Ишектәге дүрткел тишектән алюмин кашыклы тәлинкә белән иртәнге суынган ботканы бирәләр. Теге тоткын торып барып алмады, кырыенда яткан яшь кенә егет китереп бирде. Теге ашап бетергәч, егет буш тәлинкәне алып барып ишек төбендә торган зур агач өстәлгә куйды. Аннан соң тегенең күлмәген күтәреп аркасын кашыды, ана массаж ясады. Камерадагы тормыш итү шушы тоткынга буйсынганын Кави аңлап алды. Һәм, теге аркасына ятып өстенә бишмәтен ябынгач, барды. Ятагы очына басты да, сорады:

- Сез бит минем кем икәнлегемне белмисез. Нигә кыйнаттыгыз мине?

Иренеп кенә, куе кашлары астыннан яшел ике күз Кавига кызыксынып текәлде. Иреннәре арасыннан кабаланмый гына берничә сүз чыкты:

—Мин кыйнатмадым сине. Отстань!

—Алайса кем кыйнатты?

—Кыйнаганнардан сора.

—Мине ни өчен кыйнаганнарын сез беләсезме?

Теге саран гына мыскыллап елмайды:

—Беләм.

—Ни өчен?

—Арзамас каласы төрмәсеннән монда күчерелгән элекке прокурор син.

—Кем шулай ди?

—Безне саклаучы төрмә козгыннары.

Кави турая төште:

—Мин прокурор түгел. Язучы мин. Исемем Кави Нәҗми. Язучылар берлеге рәисе. Язучы мин.

Тоткын торып утырды. Аның янына тагын берничә тоткын килде.

—Си-и-ин?! Язучы Кави Нәҗмиме-е?

—Әйе! Мин Кави Нәҗми.

Тоткын кычкырып камерадагыларга эндәште:

—Безнең арада Кави Нәҗми исемле язучыны белгән кеше бармы?

Камера түреннән почмактан берәү күтәрелде. Якынрак килде.

—Мин белмим Кави Нәҗмине. Күргәнем юк. Ә укыганым бар.

Аның бик шәп «Шобага» исемле хикәясе бар. Гражданнар сугышы еллары турында. Хәйрулла исемле кызылармеец турында...

Тоткыннарның берсе Кавига кызыксынып карады:

—Син Кави Нәҗми булсаң, сөйлә шул хикәяне безгә.

—Ул бит татарча.

—Сөйлә. Мин татар малае. Мин татарча беләм. Революциягә кадәр

Казанның яхшы гына бай малае идем мин. Хәзерге көнне базар короле—кесә карагы. Ел саен эләгеп бирәр ай утырып ял итеп чыгам. Яле, сөйлә «Шобага» дигән хикәяңне. Тынлап карыйк, ниндирәк язучы икән син...

"Пахан" янындагы яшь егеткә дә дәште:

—Урындык куй, минем топчан янына. Утыр, Кави.

Кави биргән урындыкка утырды да, тамагын кыргалап алды, тирә-ягына җыелган биш-алты кешене карап чыкты. Татарлар хикәя тыңларга җыелганнар иде. Сөйләп алып китте...

Шылт иткән тавыш та юк. Аңлаган татарлар бирелеп тыңлыйлар. Татар булмаганнар да тавыш-тынсыз гына, кем яткан, кем утырган, кем баскан килеш хикәятне тыңлый. Аңламасалар да, җанга рәхәт,—күрәсең чын язучы сөйли бит, чын язучы...

Хикәя сөйләнеп бетеп, тәмам булгач, тынчу камерада тынлык бозылмыйча байтак торды әле. Сөйләргә кушкан тоткын телгә килде:

—Фазулла исемле булам мин. Казан татары. Әтием чыгышы белән Мамадыш ягыннан. Шәп сөйлисең, әй! Ничәнче елгы син?

—Беренче елгы.

—Ә-ә! Миңа абый икәнсең. Ярар, Кави абый. Таныштык. Урының минем янда, бер кеше аша булыр. Беркем дә тимәс сиңа. Әгәр дә прокурор булган булсаң, гомерең бер атна иде синең. Ярый әле язучы икәнсең.

Кыска гына итеп көлде:

—Без татарларның күңелен күрдең. Урысча берәр хикәятме, әкиятме сөйләп, башкаларның да күңелен күр инде син.

—Нәрсә сөйлим икән алайса?

—Соң, язучы булгач, тап инде син.

—Ярар, алайса. Мин сезгә Максим Горький дигән бик зур язучының «Челкаш» дигән хикәясен сөйлим әле.

—Нәрсә турында ул?

—Бер бур турында.

—Алайса, безнең турыда икән. Әйдә, валяй!

«Челкаш» хикәясе камера эчендәгеләргә «Шобага»га караганда да ныграк ошады, ахрысы. Хикәя тәмам булгач, бик озак дәшмичә утырдылар. Шуннан соң гына берсе уйлангандай нәтиҗә ясап әйтеп куйды:

—Проститутка белән вор иң борынгы профессияләр алар җир йөзендә. Игенче белән аучы гына өлкәнрәкләр...

Фазулла көрсенде:

—Мин бервакытта да бу борынгы профессия белән үземә икмәк табармын дип уйламаган идем. Язмыш, анасын саткыры—беркая качып булмый, язмышны узып, яисә аны алдалап...

Шул көннән соң язучы Кави Нәҗми һәр кичне үзен уратып алган камерадашларына төрле хикәяләр, әкиятләр сөйли башлады. Көтмәгәндә сөйләгәннәр арасыннан тоткыннарга иң ошаганы Габдулла Тукайның «Шүрәле»се булды. Ул аны башта татарча сөйләде....

Бераз сөйләгәч, Фазулла аның беләгеннән тотып туктатты. Матур итеп елмая иде:

—Кави абый! Калганын үзем сөйлим әле?

—"Шүрәлене" беләсеңмени?

—Габдулла Тукайны белмәгән татар баласы юк. Мин бит—мәдрәсә шәкерте. Әтием Тукайның «Кисекбаш»ын яттан белә иде. Тукайны ул әүлия, изге җан дип кенә сөйли иде. Әти белән икәү Тукайны күмүдә катнаштык без. Шунда беренче һәм соңгы тапкыр әтинең елаганын күрдем мин. Ярар, тыңлагыз!—диде дә көчле вә моңлы тавыш белән сөйләп китте:

Кисә башлады утынны
Балта белән тук та тук...

Карангы, сасы төрмә камерасы эчендә имгәтелгән, кимсетелгән җаннарга Кырлай урманнарындагы өянке, имән, каен, шомырт, усак, карама яфракларының исен, аларның шаулау тавышын алып килеп, Габдулла Тукайның сихри «Шүрәле»се кайчандыр татар бае малае булган, бүгенге көнне Казад базарының атаклы кесә буры Фазулла тарафыннан зур осталык вә дулкынлану белән башкарылды.

Икенче июльдә төрмәгә ябылган Кави Нәҗми дигән язучы төрмәчеләр өчен бөтенләй юк иде, ахрысы. Камерага китереп уголовниклар арасына тыктылар да, оныттылар. Күрәсең, уголовникларга Кавины прокурор итеп күрсәтеп, камерадан аның мәетен алырга көтеп торганнардыр. Тик Кави исән калып, камерада, үзе әйтмешли, «әдәби түгәрәк» оештырып җибәрде.

1937 елның 14 июль иртәсендә Кави өчен мәхшәрле көннәр һәм төннәр башланды. Палачлар карамагындагы көннәр һәм төннәр ел ярымга сузылып, Кавины мәңгелеккә гарип итеп ташладылар...

Иртәнге ашатудан соң бер сәгать чамасы вакыт узгач, тимер ишек ачыла башлады. «Хәзер кемнедер алачаклар!»—камера эче тып-тын булды. «Йә Ходай! Мине генә алмасалар ярар иде!» «Ворон» кушаматлы надзиратель икән тагын. Тонык, тоз төсендәге күзләре белән камераны айкап чыкты да сорады:

—Кем Кави Нәҗметдинов?

Соравын сорады, ә үзенең күзләре Кавига карап тукталган иде.

—Синме Нәҗметдинов?

Кави урыныннан торып басты.

—Мин.

—Язучы Кави Нәҗмиме?

—Әййе.

—Алайса, әйдә, киттек архангелларга.

Кави сүзсез генә чыгарга атлады.

—Ходай ташламасын, Кави абый!

Моны пышылдап кына Фазулла әйтте.

—Амин! Шулай булсын.

Ворон:

—Нәрсәләрең бар, үзең белән ал. Син бу камерага кире кайтмаячаксың.

Азрак елмайгандай итте:

—Сине бүген классный камерага күчерәчәкләр. Әйдә, атла! Киттек!

Озын коридорны үтеп, баскычтан подвалга төштеләр. Анда салкынрак иде. Ворон бер ишекне какты. Эчтән тавыш ишетелде:

—Керегез!

Ике метр чамасы киңлектәге, тимер челтәрле бер тәрәзәле генә бүлмәгә килеп керделәр. Өстәл артында ябык кына бәндә ишек төбендә туктап калган Кавига елмаеп татарча эндәште:

—Үт өстәл янына, утыр урындыкка, татар халкының атаклы, зур язучысы Кави Нәҗми.

Тоткынның эченә азрак җылы йөгергәндәй булды. Аллага шөкер! Үзебезнең татарга эләктем бит болай булгач! Ходай үзе саклый булыр!

Кави сүзсез генә алга үтте, утырды. Ике кулын да тезләренә куйды. Чакырган кеше графиннан кырлы стаканга салып су эчте. Гимнастеркасының түш кесәсеннән тарак алып сирәкләнгән чәчен тарады. Тамагын кыргалап алды да, телгә килде:

—Кави Нәҗми—псевдонимы. Фамилиясе тулысынча Нәҗметдинов Кави

Гибәтулла улы. 1901 елның 14 декабрендә Кызыл Атау авылында туган. Чыгышы—крестьян. Кулга алынганчы Татарстан Язучылар берлеге рәисе. 1919 елдан коммунистлар партиясендә саналган. 1937 елның июнь аенда халык дошманнарын яклаган өчен партиядән куылган. Болар бар да дөресме?

—Дөрес!—диде Кави акрын гына.

—Та-ә-әк! Дөрес, димәк. Ярар.

Уң кул бармаклары белән өстәлгә тыкырдатып алды.

—Таныш булыйк, алайса. Мин сезнең эш буенча тикшерүче итеп билгеләнгән кече лейтенант Усманов Сагир булам. Итак, тотындык синнән сорау алырга.

—Мине нәрсәдә гаепләп кулга алдыгыз?

—Кави Нәҗметдинов! Монда сорауны мин бирәм, син түгел. Мин!

—Ни өчен кулга алдыгыз? Ни гаебем бар минем?

—Мин сорау ала башлагач, гаебеңне үзең үк аңларсың. Ә сине кулга алуның беренче сәбәбе шул: халык дошманнарын яклап, аларны татар язучылары формасына кертеп, Язучылар берлегендә яшеренеп ятарга мөмкинлек тудыргансың син. Пока шул. Аннан соң синең допроста тоткан поведениең күрсәтер сине нәрсә эшләтергә икәнлекне. Әййе, күрсәтер, дополнительно... нәрсәдә гаепләргә...

Өстәлдәге юк-барны кузгаткалап алды да, бер папкадан ак кәгазь алып алдына салды.

—Башлыйк допросны. Беренче сорау. Ни өчен Язучылар берлегендә 1937 елның июль башына кадәр бер генә язучыга карата да персональ эш ачылып, Совет хөкүмәтенә каршы башкарган гамәлләре тикшерелеп, халык дошманы булган кешеләргә каршы чаралар күрелмәгән?

Кави, ничек итеп җавап бирергә дә белмичә, сүзсез генә утыра иде. Усманов, әйткән һәр сүзенә басым ясап, аны ашыктырды:

—Син, рожай давай! Ни өчен язучылар булып исәпләнгән «халык дошман»нарына каршы рәис буларак чара күрмәден?

—Кемнәр алар, сез «халык дошманнары» дигән язучылар?

Усманов тиз генә өстәлдә сул яктарак яткан кара күн тышлы папканы ачып карап алды.

—Менә алар, рәхим ит: Гомәр Гали, Хәсән Туфан, Фатих Кәрим... Өчесе дә махровый халык дошманнары...

—Мин аларның икесен, 1922 елдан бирле беләм. Өчесе дә намуслы, талантлы, татар халкы өчен тырышып эшләүче һәм язып хезмәт итүчеләр. Алар халык дошманнары түгел.

—Димәк, син, Кави Нәҗми, аларның халык дошманнары булуын, без әйткәнгә каршы килеп, расламыйсың?

—Минем сорау бар сезгә, иптәш Усманов.

*Ахыры киләсе санда.*

**РЕДАКЦИЯДӘН:** ***Танылган язучы, техник фәннәр докторы, җәмәгать эшлеклесе, журналыбызның актив авторы Зәки Лотфулла улы Зәйнуллинга шушы айда 75 яшь тула.***

***Аны юбилее белән ихлас котлыйбыз, ныклы сәламәтлек һәм яңадан-яңа иҗат уңышлары телибез.***

# ШИГЪРИЯТ ГАЛӘМЕНДӘГЕ ДӘРВИШ

Райнер Мария Рильке—немец телендә язучы Австрия шагыйре. 1875 елда Прагада туган һәм 1926 елда Швейцариядә вафат булган. Рус теленә тәрҗемәләре 1955 елда гына басылып чыга. Соңгы берничә дистә ел дәвамында аның әсәрләрен русчага тәрҗемә итү шактый активлашып китте. Әйтергә кирәк, аны тәрҗемә итү аерым бер житлегүне таләп итә, дип саный Рилькены русча яңгыратучы танылган рус шагыйре Вячеслав Куприянов үзенең 1998 елда Мәскәүдә басылып чыккан китабында. Анда Рилькеның төрле елларда иҗат иткән шигырьләре кертелгән. Шунысы үзенчәлекле, шигырьләр немец һәм рус телләрендә янәшә бирелеп бара, һәм татарчага тәрҗемә кылганда, үзара чагыштыру өчен, зур уңайлык тудыра. Дөрес, минем бу тәрҗемәләрем—Рилькеның иҗат диңгезеннән чумырып алган "бер уймак" кына. Шулай да татар укучысына әлеге шагыйрь турында бераз гына күзалларга һәм кызыксыну уятырга ярдәм итәр дип уйлыйм.

Рилькеның язмышы бик гыйбрәтле. Аның турында мин Ганс Эгон Хольтхузен китабыннан укып белдем. (Русчага Николай Болдырев тәрҗемә иткән. 1998 ел.) Нәрсәсе белән җәлеп итте соң мине Райнер Мария Рильке? Беренчедән, үзенен әсәрләре һәм шигъри образлары белән. Икенчедән, аның дөньяга карашлары һәм иҗат принциплары гаҗәеп үзенчәлекле. Аннары, ул үзе гәрчә христиан булса да, Ислам диненә күңеле белән бик якын торган һәм аны бик хөрмәт иткән. Изге Коръән белән ул Испаниягә һәм гарәп илләренә сәяхәтләре вакытында якыннан таныша. Аның Ислам динен бик нечкә тоюы һәм христиан диненең инде искерүе турында әйткән фикерләре бик кызыклы. Бу хакта ул үзенең химаячесе һәм иң якын дусларыннан берсе—княгиня Таксиска язган хатында ачыктан-ачык әйтә: "Мин тәмам мөселманга әйләнеп бетәм бугай инде... Алла белән һәр иртәдә рәхәтләнеп сөйләшергә, ана арадашчысыз-фәлсәфәсез, турыдан-туры мөрәҗәгать итәргә мөмкин...",—дип үзенең тәэсирләрен уртаклаша ул. Аның Исламга хөрмәте торган саен арта бара. Чөнки ул дингә ниндидер күрсәтмәләрне үтәү дип түгел, бәлки җаның-тәнең белән кабул иткән эчке бер тормыш-яшәеш чарасы итеп карый. Шулар өстенә Рилькеның гомере буе диярлек "ватан эзләве" дә бик гыйбрәтле. Дөрес, ул бу хакта ачыктан-ачык кычкырып йөрми, әмма аның иҗатында шушы тема пәрәвездәй нечкә һәм өзелмәс бер җеп булып сузыла.

Ул шау-шулы вакыйгаларда катнашырга бик атлыгып тормый. Шулай да дөньядагы сәяси вакыйгаларны игътибар белән күзәтеп бара, аларга үз бәясен бирә. Мәсәлән, ул Беренче бөтендөнья сугышын, кешелек җәмгыятенең әхлакый дәрәҗәсе коточкыч түбән булудан килеп чыккан дәһшәт дип саный... Бу сугышта ул турыдан-туры катнашмаса да, берара хәрби архивта хезмәт иткәннән соң, нерв авыруы көчәеп, әлеге вазифадан азат ителә.

Рильке бик йөремсәк кеше була... Сугышка кадәрге 4 ел дәвамында 50 дән артык яшәү урынын алыштыра, ягъни бер илдән бер илгә күчеп йөри. Нигездә—Европа буйлап. Кешеләр белән аралаша да, гел ялгызлыкка, үзаерымлыкка омтыла. Бу аның шагыйрьлеге белән бәйләнгән булса да, үзен гаепле итеп тә сизә башлый. Чөнки хатыны белән кызы була торып, гомере буе алардан аерым яши. Ялгызлыкны ул кемнәрдер ташлап киткән яки кемнәндер аерылып калган кеше ялгызлыгы итеп түгел, бәлки Күкләрдән, үзе әйтмешли, "ачык киңлектән" ышанып тапшырылган бер Миссия буларак кабул итә. Шагыйрь өчен тынлыкны, уйларга комачау итмәгән урын табуны иң мөһим шарт дип саный, шул рәвешчә генә Аллага якыная баруын тоя... Француз шагыйре Поль Валери аны нәкъ менә "Аллаһка якынайган инсан" дип

атый да. Ялгызлык анын өчен—дөнья көтүнең исәпсез-хисапсыз мәшәкатьләре белән тыгызланмаган иҗат кинлеге, вакыт иркенлеге, үзенә-үзе баш булу мөмкинлеге... "Мин ялгызлык иленнән",—дип яза ул бер шигырендә. Бу эгоистлык түгел, бу шагыйрьнең асылы турында яшермичә әйтеп бирү. Бу хакта ул үзенең "Васыять" эссесында да язып калдыра. Шагыйрь хезмәте өчен вөҗданын газапламый торган тыныч иҗат ялгызлыгының ничек мөһим булуын аңлатып, эссесын ул менә нинди сүзләр белән тәмамлый: " әйе, бүген мин, тезләнеп, үземне яратучылардан бераз гына мәрхәмәт сорыйм. Алар миннән үзләрен бәхетле итүче кеше эзләмәсеннәр, бары тик минем теләктәшләрем генә булып калсыннар иде..." Хәлбуки, ялгызлыкка омтылса да, байтак кына зур шәхесләр белән аралаша, алар аша үз дөньясын да баета. Яшь чагында ул биш ел буена Парижда атаклы скульптор Роден йортында яшәп, аның шәхси секретаре булып тора һәм зур гыйбрәтләр ала. Әйтик, бөтен бер сынны хасил итү өчен аерым-аерым кисәкләрне берләштерү зарурлыгына зур мәгънә салынганын төшенә, иҗатында һәм яшәештә Бербөтенне җыю идеясен үзләштерә...

...Аңа кадәр, әле 24-25 яшьләрендә ул Россиягә дә сәяхәт ясый. Әйтергә кирәк, Рильке Россияне бик яраткан һәм әле Лев Толстой исән чагында ук Мәскәүдә һәм башка шәһәрләрдә ике тапкыр булып киткән. Толстой янына Ясная Полянага да барып чыккан. 1900 елның җәендә Киевта, Петербургта була, хәтта Идел буйлап пароходта Сембер, Казан, Новгород аша да уза... Россиягә килер алдыннан ул бик тырышып рус телен һәм әдәбиятын өйрәнә, күп укый. Россия тормышы һәм аның кешеләре аңа бик нык тәэсир итә. Шуның нәтиҗәсе буларак, ул рус язучыларын тәрҗемә итү белән дә мавыгып китә. Чехов, Лермонтов әсәрләрен, хәтта "Слово о полку Игореве"ны немец теленә тәрҗемәли, һәм бу әсәрләр аның үз иҗатына да уңай йогынты ясый. Достоевскийны укып, үзе әйтмешли, рухи катарсис кичерә... Рильке Праганы да, Мюнхенны да, Берлинны да үз ватаны итеп хис итми. Россияне исә үзенең эчке бер рухи ватаны итеп тоя, аның киңлеге һәм табигыйлыгына соклана, "мин бу илдә яши алыр идем",—ди... "Россиягә барганчы күреп яшәгәннәрем ул җир, елга, күк йөзенең образы гына булган икән. Ә монда мин аларның үзен күрдем",—дип яза. Шунысы кызык, Рим шәһәренең ул күгенә кадәр яратмый , анда үзен тыны кысылган кебек хис итә...

Гомеренең соңгы елында Рильке М. Цветаева белән хат языша. Аларны Борис Пастернак таныштыра. (Заманында Рильке Пастернакның әтисе белән якыннан таныш булган). Кызганыч, аларның хатлары турында бер сүз башында гына әйтеп бетерүе мөмкин түгел. Әмма алар бик гыйбрәтле, һәм ике шагыйрьнең дөньяда яшәү рәвеше никадәр аермалы булуын күрсәтеп тора. Рус шагыйрәсе аннан ниндидер коткаручы эзләгән кебек, ә Рилькенең үз хәле хәл: ул савыкмаслык чиргә дучар. Шулай булса да ул М. Цветаеваның үтә көчле шагыйрә булуын аңлый һәм аңа багышлап элегия яза. Алар очраша алмыйлар, Рильке вафат була.

...Мин Рильке иҗатына бәя бирүче түгел, фәкать аңлаган һәм иңләгән кадәре генә булса да аңа сокланучы, гыйбрәт алучы гына. Ул, татар әйтмешли, шигырьнең дә, яшәешнең дә тәмам "аръягына" барып чыккан шагыйрь. Гомумән алганда, Рильке иҗатында экзистенциаль карашлар, ягъни тереклек-яшәешнең "аргы ягына" күз салу, "теге дөнья" белән "тере дөнья" серләрен берләштерү хас. Ул шушы юнәлештә шигъри ачышлар ясый, кешенең эчке дөньясы белән тышкы дөнья арасында мәңге өзелмәс бәйләнеш булуын хәбәр итә...

Рилькенең Элегияләре һәм Сонетлары шулай ук үзара эчке бөтенлекне хасил итә. "Орфейга сонетлар"ында ул Орфейны җыры белән космосны коткаручы шагыйрь итеп күзаллый. Ул тереләр һәм үлеләр дөньясын берләштерүче итеп сурәтләнә. Әлеге әсәрләрне бер утыруда гына укып, колачлап бетерү мөмкин түгел, аларны шагыйрьләр үзләре өчен бер дәреслек итеп тотарга тиештер дип уйлыйм. Кайтып-кайтып укыр, уйланыр һәм илһамланыр өчен...

Райнер Мария Рилькенең кайбер фикерләрен киңәш сыйфатында яшь шагыйрьләргә дә житкерәсем килә. Тема сайлау турында ул болай ди: реаль чынбарлыкка җавап бирсен, заманча һәм зарур булсын... ("Васыять", 1921 ел.)

Аннары ул "Иҗади эшеннең колы булу кирәк" дигән фикерне алга сөрә.

Шагыйрьгә ул "әзер" сүзләрне язып утыручы итеп түгел, ә үз эшенә буйсынган, димәк ки, хуҗа да булган, үз эшен үзе башкаручы Хезмәт иясе итеп карый. Шулай ук ул шагыйрьне үзенең образлары һәм геройларының "тарихын"—үсешен күрсәтә белергә өнди. Рильке дөньяда барган һәр фәнни ачышка, вакыйга-яңалыкка бик сизгер була. Беренче бөтендөнья сугышыннан соң ул "Яңа дөнья сәгате сукты", дип яза. "Эон белән эон гәпләшә" дигән юллары Лермонтовның "Йолдыз белән йолдыз сөйләшә"сен хәтерләтсә дә, бу инде конкретрак, фәннирәк һәм заманчарак, әмма шигъри нечкәлеген һич җуймый... Гомумән, ул Алла биргән сәләтне төрле чыганаклар аша бертуктаусыз туендырып, үстереп тору кирәклеген искәртә.

Бу җәһәттән, ул үзен "автодидакт" дип саный. Чөнки күбесенчә үзлегеннән укып өйрәнә, үзен-үзе тәрбияли... Шулай ук ул мәхәббәт һәм секс өлкәсендә дә үзенчәлекле карашлары белән аерылып тора. Мәсәлән, яратса да, яратудан качу... Чөнки ул Поэзияне, иҗат эшен үзенә бер тулы мәхәббәт дип исәпли.

Рильке һич кенә дә "коры хыялый" шагыйрь түгел, киресенчә, гаять нечкә реалист. Ул шигърияткә "аналитик эш" дип караган, иң нечкә хисләрне дә аналитик акыл аша күзәткән... Ул берьюлы реалист та, романтик та...

...Әлеге кереш сүз ахырында мин янәдән Рильекенең күңеле белән изге Коръәнгә якын торуы хакында әйткән сүзләрен искә төшердем. Баштарак телгә алынган княгиня Таксиска хатында ул: "Мин Коръәнне укыйм... һәм анда үзем өчен бик тә таныш тавышны ишетәм..." дип яза. Яшерен-батырын түгел, мин дә Рильке белән якыннанрак танышкач, гаҗәпләнү катыш сөенү кичердем.

Чөнки аны укыганда, үзем өчен бик тә "таныш тавышны ишеткән" кебек булдым. Әйтерсең лә, мин аны яшьтән укып өйрәнгәнмен дә, аңа ияргәнмен... Минемчә, шигърият галәмендәге аһәңдәшлек һич тә очраклы хәл түгел. Бу—безнең бер Җир шарында яшәвебез, бер Кояш вә Ай астында уйланып моңлануыбыз һәм башка бик күп уртак сыйфатларыбыз белән дә бәйләнгәндер... Һәм бу, бәлки безнең бер Аллаһ сулышын тоеп яшәвебезнең шигырь телендә чагылыш тапкан ышандыргыч бер гүзәл дәлиледер...

Кереш сүземне Рилькега багышлап язган сонет белән тәмамлыйм:

## Рилькега Сонет

*Гомерең буе "ватан" эзләп, үзватаннан*
*мәхрүм килеш, әзерләнгәч Үлемеңә,*
*Күкләр гөмбәзе астында иң гүзәл җир*
*сайлап алган сине сөеп... Күңелеңә*

*Сыендырып һәр шөбһәне, һәр Әйберне,*
*җан сәфәрен дәвам итеп кабергәчә,*
*Шул җаныңны озаткансың шигъри җилдә,*
*җилләр исә исеп тора хәзергәчә...*

*Син Дөньяның эчен-тышын бер күргәнсең,*
*бер Бөтенгә җыя барып Вак серләрен...*
*Һәрбер диңгез, һәрбер инеш сине көткән,*
*чайкасын дип безнең суда пакь кирләрен.*

*Коръән кичеп кергәнсең син Үлемеңә,*
*хыянәтсез—беркемгә һәм Күңелеңә...*

*гыйнвар, 2008*

**Лена ШАГЫЙРЬҖАН**

# Райнер Мария Рильке

## Шагыйрь үзе турында

Вакыт! Син бит мине ташлап китеп,
яралыйсың канат җилең белән.
Бер ялгызым мине калдырасың—
нишлим төнем белән? Көнем белән?

Мин—йорт—җирсез, куркам югалтудан,
тапканчы ук йөрим хафаланып.
Җаным сеңеп калган һәрбер әйбер
кире кага мине, һаваланып.

* * *

И, Җир, безгә син бир
күз—яшь түгәр савыт:
тутырырбыз аны
җан газабын савып...

Савыт чыңлап торсын,
әрнү тавышын йотып...
Тыңламасын өчен
дөнья, йөзен чытып...

## Үтмәс сагыш

Бик сәер сүз: вакыт уздыру!
Тотып калып булса икән аны!
Куркытмыймы сезне мизгел үтүе,
ни сөйли соң мизгелләрнең саны?..

Көн үзенең чигенә якынлаша,
акрын гына кичлеккә авышып.
Бөтен нәрсә ага төнгә таба,
үзәннәргә җәелә төн тавышы...

Таулар йоклый, ә йолдызлар—сакта...
Тик алар да саный вакыт агышын.
Аһ, тик минем йөрәк сыендырган
Мәңгелекнең үтми торган сагышын...

* * *

Мин максат та түгел, юл да түгел,
камалышта калган кальгә дә...
Сүз көченең кыю җиңүе мин,
ирешкәндә бөек мәгънәгә...

Син—чәчәксең, ә мин—тын өрүче,
җил—яңгыр мин, җирне сөюче...
Яки кинәт, irекле бер мәлдә—
үзем туп һәм тупны чөюче...

* * *

Йолдыз нуры җиткезгәнне
төн төбеннән
Җитди кабул итә бел син,
ул—тегеннән...

Күрсен төн бәһаләвеңне
хәзинәсен...
Аның иркен дөньясына
хәзерлән син...

## Илаһилык бизмәне

Могҗизалы Иҗат көненнән соң
йоклый Алла, күреп төшендә
безне—үзе чәчкән йолдызларның
чит-ят җемелдәве төсендә...

Безнең бөтен кылганнарыбызны
төйнәгән ул йодрык-учына.
Чигәсендә—тәүге каһарманнар
каны ут күк тибә-очына...

Ара-тирә селтәп атар сыман
шул газапны—тоеп изгәнен.
Әмма һаман үз ягына баса
Галәм нуры—Илаһ бизмәне...

* * *

Дөнья бала булып кала бирә,
болын, урман—өнсез сабыйлык.
Очсыз-чиксез киңлекләр дә дәшми—
алар безне күреп таныймы?..

Лалә дибез, роза гөле дибез,
Һәр нәрсәгә исем кушабыз.
Аларның тик бездә бер гаме юк,
исемсез бер җисем—кошка без...

Шагыйрь өчен—Ай да ялгыз буйдак...
Һәр күренеш, әйбер-атама.
Алар түзә безнең тыкшынуга—
монысы ни-нәрсә дип атала?..

## Алхимик

*(Сонет)*

Ачы көлеп, читкә атып бәрде
Сыекчасын... Савыты ватылды.
Хәзер белде ни җитмәвен, әрнеп,
хасил итәр өчен алтынны...

Әйе, меңәр еллык Вакыт зарур
шашкын теләк чынга ашсынга,
Җаның тулсын—океан ирке белән,
Уең тусын—йолдыз астында...

Көтеп көтек иткән могҗизасы
ычкынды да төнлә, атылды
тын бушлыкка—Ходай катына...

Суфый исә, җен күк, үкенеп, ярсып,
учына кысып хыял–алтынны,
елап калды сере артыннан...

* * *

Кыямәт җитеп, бар әрвахлар кубарылгач,
алардан соң кинәт бушап калган Шарның
эреп юкка чыгачагы кебек Күктә—
тереләр дә бүген убыла җир астына.
Һәм шулардан авыраеп калган Җир–шар
бата бара сыман галәм төбенә –
меңәр еллык ләмгә, кайда ки язмышлар
телсез балыклар шикелле тонык күзле
салкын гына очлашалар әлегә сүзсез...
Менә шунда инде йомык җәрәхәтләр
төнбоеклар сыман ачыла һәм Үзагым
коточкыч зур әкәм–төкәмнең
котсыз кармавычларына илтеп тыга
җебегән корбаннарын су төбенең...
Шулар сөягеннән хасил акбур–ташлар
төссез мәрҗәннәр мисләндә чәчәк ата
Һәм терелә́й катып калган курку хисе
тармак җәя тавыш–тынсыз гына...

## Сонет

Ах, дусларым, яңа машиналар
ул яңалык түгел һич гаҗәеп,
Күзгә күренеп торган үзгәрешкә
җырлама дан, кочагыңны җәеп.

Биек йортлар, токлы чыбыклардан
Галәм үзе күпкә, бел, яңарак.
Яңа утлар—кабызганны көтә,
ә йолдызлар күктә гел яналар...

Санама син, илтәр поездлар, дип
Бөек чорга ерак еллар аша...
Эон белән эон аралаша...

Күп нәрсәгә әле юл караңгы...
Киләчәк һәм Кеше... Илаһ асылың
якынайтса иде шул араны...

*Лена Шагыйрьҗан*
*тәрҗемәләре. 2008 ел.*

# ҺӘР НӘРСӘНЕҢ ИЯСЕ БАР...



Шагыйрь **Разил ВӘЛИЕВнең**
рәссам **Әхсән ФӘТХЕТДИНОВ** белән әңгәмәсе.

**Р. ВӘЛИЕВ:** *Татарстан халкы, татар халкы синең олуг рәссам икәнеңне күптән таныды. Дәүләт тә, хөкүмәт җитәкчеләре дә талантыңа югары бәя биреп, республиканың иң олы бүләген—Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясен тапшырды. Хөкүмәт тануы, халык тануы зур нәрсә. Әмма син бит ана каләр дә шундый ук рәссам булгансың. Бу—бүген генә иҗат белән шөгыльләнеп, бүген генә алган бәя түгел, ул синең гомерлек иҗат юлыңа бирелгән бәя. Син инде 40 елдан артык шундый актив иҗат тормышы белән яшисең. Әмма без сине моннан егерме ел чамасы элек кенә, ә кайберәүләр исә әле күптән түгел генә таный башлады. Ә син үзеңнең рәссам икәнеңне үзең кайчан тоя, таный башладың?*

**Ә. ФӘТХЕТДИНОВ:** Мин аны балачакта ук сизә идем. Ләкин рәссам дип саналгач та, үземне әле рәссам дип әйтергә кыенсына идем. Мин Мәскәүдә укып кайтучыларга, югары сәнгать мәктәбен тәмамлаучыларга табына идем, алар инде чын рәссамнар дип уйлый идем. Соңыннан күрәм—үзем дә шул ук иҗат белән шөгыльләнәм, аларның ничек шөгыльләнгәннәре—күз алдымда. Димәк, мин дә алар кебек эшли алам. Вакыт-вакыт үземнең уемның кайберәүләрнекенә караганда алгарак та киткәнен сизә башладым. «Мин дә рәссам була алам бит» дип, моннан чирек гасыр элек, менә кырык яшьләр тирәсендә әйткәнмендер. Хәзер уйласам, мин балачактан ук рәссам булганмын икән... Рәссам булып китмәсәм дә йә шагыйрь, йә язучы булыр идем.

**Р. В.** *Әхсән агай, без синең белән бик еш очрашабыз. Син бик кызык әңгәмәдәш. Син һәрвакытта онытылып китеп, күңелеңне ачып сөйләшәсең. Шушы сөйләшүләр вакытында без гел сәнгать турында гына сөйләшеп утырмыйбыз бит. Син бик еш кына әти-әниеңне искә төшерәсең. Мин кайвакытта: "Сиңа кемнән нинди сыйфат күчкән?"- дип сорап куям. Син инде: «Тырышлыгым, үҗәтлегем Мәгъмүрә исемле әниемнән күчкәндер»,—дисең. Әниегез бик иртә вафат булган—биш бала калдырып*

*кырык яшьтә фани дөньядан киткән. «Ә инде рәсем ясау сәләте әтием Саримнан күчкән»,—дисең. Әтиең бакчачы да, умартачы да, балта остасы да булган, эшләмәгән эше калмаган. Чыннан да, һөнәрманлык әти-әнидән күчә торгандыр, кан белән күп нәрсә биреләдер, генетика дигән нәрсә бар бит. Болары бер нәрсә. Әмма ләкин олуг рәссам булып җитүеңдә синең үзеңнең дә бик зур өлешең бар. Кеше Аллаһы Тәгалә биргән сәләткә генә куанып утыра икән, аның бик күп эшләре барып чыкмый. Язмышыңа, иҗатыңа үзең генә керткән өлешең зур дип саныйсыңмы? Һәм бу өлеш нидән гыйбарәт?*

**Ә. Ф.** Бу чынлап та шулай. Әти-әни биргән рухи мирас булмаса, эшкә маһирлык фундамент, нигез, геннар белән бирелмәсә, үзеңнән генә әллә ни өстәп тә булмый торгандыр. Ләкин һәрбер язмыш шул биргәннәргә нәрсәдер өсти ала. Минем әти-әниемә укырга туры килмәгән, укый-яза белсәләр дә, зур мәктәп үтмәгәннәр. Миңа ул өстәлде—мин күп укыдым. Бөтендөнья сәнгатен дә өйрәнергә туры килде. Татар авылыннан чыккан малайга бөтендөнья сәнгате белән танышуның бәясен мин хәзер дә әйтеп бетерә алмыйм. Шушылар әти белән әни биргәннәргә өстәлә, күрәмсең. Мин бөтен нәрсәне укырга, кешеләр белән аралашырга, танышырга ярата идем. Шулар да өстәлгәндер инде. Монысын инде үземнең өлеш тә дип әйтергә ярый. Чөнки кеше укырга, алга омтылырга, кызыксынырга тиеш.

**Р. В.** *Син Чирмешән районының Урманасты Үтәмеше дигән авылда туып-үскәнсең. Анда балачагың үткән, Камышлыда, Югары Осланда яшәп алгансың. Урал якларына барып чыгып, Түбән Тагилда педагогика институтында сәнгать-графика факультетында укып, анда эшләп тә калгансың—өлкән укытучы булгансың. Шуннан соң дөньяны урап, чын мәгънәсендә акыл утыртып, шәхес булып җитлеккәч кенә Татарстанга әйләнеп кайткансың. Син кайчакта шаяртып кына әйтәсең: «Минем язмыш шундый булды инде—Урманасты Үтәмешеннән китеп, Казанга Владивосток аша килдем»,—дисең. Нинди җилләр сине дөнья буйлап куып йөртте? Нигә турыдан-туры Түбән Камага яисә Казанга килеп урнашмадың?*

**Ә. Ф.** Чынлап та, күпләрнең язмышы бик гади була—мәктәптә укый, югары уку йортын тәмамлый һәм 20 яшендә гомер буе шөгыльләнә торган эшен таба. Минем алай булмады. Язмыш шулай кушты. Читкә чыгып китүем—рус телен белергә, аннан соң югары уку йортларына барырга кирәк иде. Авылдан чыгып кына теләсә кайсы уку йортына кереп булмый иде, русча белмәсәң, бигрәк тә. Минем яшьтә кайда укырга мөмкин, мин шул җиргә бардым. Бәлки башка уку йортына керергә дә җай булгандыр. Әмма мин пединститутта укуымны кызганмыйм. Ул миңа бик зур тәҗрибә, рухи байлык бирде. Институтта өлкән укытучы булып эшләгәч, анда калырга да мөмкин иде, ләкин минем иҗат белән шөгыльләнәсем килде. Шуннан инде туп-туры иҗат эшенә кереп киттем. Рәссамнарның сәнгать фондына эшкә кердем. Бу инде минем беренче иҗади пристанем, тукталышым булды. Шушы фонд иҗат белән шөгыльләнергә мөмкинчелек бирде. Миңа күбрәк бизәкләү белән шөгыльләнергә туры килде. Үткән чорым шактый төссез иде, аны да бизәкләү белән мәшгуль булдым. Дөрес, бөтен нәрсәне берьюлы колачлап булмый. Тормышның, иҗат юлының кайсыбер мөһим нокталары бар, шушы нокталар тирәсендә генә кайнашырга кирәк икән. Мин теге өлкәгә, бу өлкәгә ташланмадым, үзебезнең татар халкының фольклорына, тарихына, күңеленә ныклап таянырга тырыштым.

**Р. В.** *Әхсән агай, мин сине рәссам буларак шактый яхшы беләм. Остаханәңдә дә кат-кат булдым. Бер нәрсәгә игътибар иткәнем бар: син иҗат эше белән шөгыльләнгәндә авыз эченнән моңланырга яратасың, гел җырлап, көйләп йөрисең. Сине әле җырчы буларак белми торганнардыр. Синең күңелең тулы моң. Син бер тапкыр әйткән идең: «Мине туган якларыма шул татар җыры тартып кайтарды, «Карурман»нар, «Каз канатлары, «Тәфтиләү»ләр тартып кайтарды»,—дип. Җыр турында синең шактый гына кызыклы фикерләрең дә бар. Ничек уйлыйсың, татар җырына, татар моңына каян килә икән шундый илаһи көч? Халык хәтле халыкны*

*саклап калган көч. Милләтне бит без җыр-моң, иман саклап калган дип әйтәбез. Җыр гына сакламагандыр инде, әдәбият та саклагандыр, мәдәният та, рәсем сәнгате дә, дин дә саклагандыр. Әмма шулар арасында, синенчә, үзәк урынны җыр алып тора. Ә татар җырына шундый илаһи көч каян килә икән?*

**Ә. Ф.** Җыр турында дулкынланмыйча гына сөйләп булмый. Бигрәк тә, татар җыры турында. Мин аны, бәлки, балачак елларында аңлап та бетермәгәнмендер. Миңа җырның сүзләрен башыннан ахырына кадәр белү бик мөһим дә түгелдер. Әмма мине җыр, көй, моңниндидер бер халәткә кертә. Шуңа күрә, минемчә, әдәбиятка, мәдәниятка, рәсем сәнгатенә караганда татар кешесен җыр күбрәк саклап калгандыр. Әйтик, мәсәлән, китапны яндырырга була, театрга бина төземәскә, рәсемгә күргәзмә заллары ясамаска була. Ә менә җырны берничек тә тыеп булмый. Аны авыл эчендә җырламасаң, урманга барып, кырга чыгып җырлап була. Җыр беркайчан да туктый торган әйбер түгел. Тагын шунысы да бар: башка төр сәнгатьләрдә ялганлап та, фальш ясап та була, ә менә чын җырга ялган керә алмый. Кеше үзенең күңеленә моң килгәч кенә җырлый. Мин кайвакыт «Гөлҗамал» кебек борынгы җырлар хәтта мәҗүсилек чорларында җырлангандыр дип уйлап куям, һәм менә шушы җыр бүгенгә кадәр сакланган бит. Әгәр дә хәзерге заман җырларында «Гөлҗамал»да сакланган кечкенә генә өзекләрне, ноталарны очратсам, шул җырлар да миндә ләззәтле хисләр уята. Шуңа күрә, тарихчы-археологларга иске корылмалар кадерле булган кебек, җыр да татар халкының күңеленә керү өчен мөһим әйбердер. Хәзерге көндә дә җырчылар, җыр язучылар җырның нәрсә икәнен, аның кадерен белсеннәр иде дип әйтәсем килә. «Кара урман», «Каз канаты», «Тәфтиләү» һәм башка шундый җырлар тыңлаганда, кеше үз максатына, үз хыялына якынлаша дип уйлыйм. Җыр кешегә юнәлеш, көч бирә.

**Р. В.** *Әхсән агай, син бу дөньяны рәсемнәр, буяулар, төсләр аша ачарга, гомумән, дөньяны үзеңчә аңларга тырышып яшисең. Бу һәр рәссамның, һәр шагыйрьнең, һәр язучының, гомумән, һәр сәнгать кешесенең төп максатыдыр. Әмма, ни кызганыч, бөтен кеше дә бу максатка ирешә алмый. Менә син рәссамнар арасында табигатьнең бәгыренә үтеп кергән, табигатьнең серен аңлаган сирәк шәхесләрнең берседер. Кайсы гына әсәреңне карасак та, аларның барысында да—табигать. Син табигатьнең матурлыгын гына күреп калмыйсың, ә аның эчке мәгънәсен, төрле халәтен: трагик, сөенечле, куанычлы, сагышлы чагын да тирәнтен аңлыйсың. Шуңа күрә мин сине чын мәгънәсендә табигать баласы дип уйлыйм. Минемчә, табигатьне аңлаган, аны яраткан кеше табигатьнең иң гүзәл җирендә яшәргә тиеш шикелле. Урманасты Үтәмештәме ул, урман уртасында чишмә буендамы, йә башка җирдәме—тик гүзәл бер урында. Ә менә син 1969 елдан бирле Түбән Кама шәһәрендә гомер итәсең. Ул минем дә яраткан туган шәһәрем. Әмма Түбән Кама бит, ни әйтсәң дә, нефтехимия башкаласы. Андагы төтен ургыган завод торбалары, нефтехимия мәшхәрләре, җирнең кара туфрагын кызыл балчыкка кадәр ашап бара торган замана афәтләре... Ә син шунда яшисең. Бәлки рәссам өчен шулар кирәктер дә. Шушы трагедия, афәт күңелеңне тырнап, ярана тоз сибеп, сиңа иҗат дәрте биреп тора торгандыр, син шулар белән көрәшергә теләп торгансыңдыр. Әллә Түбән Камада яшәүнең башка сәбәпләре дә бармы?*

**Ә. Ф.** Кызганыч, без еш кына бу тормышта яшәр җиребезне үзебез сайлап ала алмыйбыз. Мин, дөнья урап кайткач, Казанда да кала алган булыр идем. Монда егерме елдан соң гына фатир алырсың, дигәч, Түбән Камага киттем. Мин бәхет эзләп йөрмәдем. Кешегә, бигрәк тә иҗат кешесенә баш өстендә кояш, ай, күк булса, җил иссә, торырга йорты, ә миңа, рәссам буларак, остаханәм булса—шул җиткән. Түбән Камада кояш та, ай да бар, йортлары да матур. Минем монда остаханәм, анда иҗат итәргә мөмкинлегем бар. Бәлки, Казанда калсам, бәхетлерәк тә булган булыр идем. Әмма мин бу урынымны да үземчә кызыклы итәсем килә.

Түбән Кама ул үзенчәлекле, яңа, матур шәһәр. Казан белән чагыштырганда монда традицияләр әллә ни күп, бай түгел. Дөньяда һәр нәрсәнең башлангыч чоры була.

Менә шул башлангыч чорның рухын сизсән, бар дөньяны да, олылыкны да аңларга була. Шуңа күрә мин шушы яшь шәһәрдә яшәп тә, бай традицияле шәһәрләрне сизеп, аларны читтән күзәтеп яшим.

Миңа күп кеше: «Нишләп Түбән Камада яшисең, рәтле кеше периферияда калмый»,—дип сорау бирә. Бәлки бу шулайдыр да. Шуңа күрә күп кеше Казанга китәдер дә инде...

**Р. В.** *Кемнәрдер шикелле, Казан кебек зур шәһәрнең кечкенә генә бер рәссамы булганчы, Түбән Каманың олы рәссамы булуы зуррак бәхеттер. Ә син бит Түбән Каманың олы рәссамы булып кына калмадың, бөтен республиканың, бөтен татар халкының олы рәссамы дәрәҗәсенә ирештең. Аннары, үзең әйткәнчә, монда сиңа шартлар тудырдылар, монда синең кадерең бар. Ә кеше кайда кадере бар—шунда яшәргә тиеш. Бу дөньяда безгә иң җитмәгән нәрсәләрнең берсе—ул кеше кадере. Сиңа бу кадерне Түбән Камада күрсәтә башладылар. Иҗат итәр өчен сиңа остаханә дә, фатир да бирделәр. Шәһәр үзәгендә нинди матур галереяң бар. Казанда кайсы рәссамның шундый бәхете бар әле?! Бөтен Татарстанга сез андыйлар 2-3 кенә кешедер.*

*Бүген менә без синең Түбән Камадагы галереяңда утырабыз. Синең персонажларыңа карап торам да, исемә төшә: элек син башка геройлар белән яши идең. Син табигатьне дә, шәһәр пейзажларын да тасвирлап сурәткә төшерә идең. Соңгы дистә елда персонажларың үзгәрде: син убырлар, албастылар, пәриләр белән хыялланып яши башладың. Әкренләп кенә реаль дөньядан читләшә барасың кебек. Үзеңә яңа бер дөнья тудырдың. Шуның сәбәбен үзеңнән ишетәсем килә. Син әллә хәзерге фани дөньядан арыдыңмы, туйдыңмы, һәм үзеңә яңа дөнья уйлап табып шунда яши башладыңмы? Моның сәбәбе нидә?*

**Ә. Ф.** Узган гасырның 70-90нчы елларында, минем ныклап торып иҗат итә торган чорымда, әхлак мәсьәләсенең бик түбән төшүен сиздем. Мине кайчакта рәсем ясау да бик кызыксындырмый, ә әхлаксызлыкка каршы нинди сюжетлар, нинди темалар белән чыгарга, нинди мәсьәләне рәссам буларак ничегрәк күтәрергә икән дип уйлана идем. Шулай итеп, рәсем ясау минем фикер йөртүнең бер формасы гына иде.

Хәзерге заманда мин тормыштан үземә тәм таба алмыйм. Ислам дине чорына килгәндә, атеистик пропаганда аша үткән кеше буларак, мин анда күп нәрсәләр белмәгәнемне сиздем. Белмәгән нәрсә белән эш итеп булмый. Мин тарихта арткы якка таба барам һәм хәзер мәҗүсилек чорына килеп җиттем. Мәҗүсилек чоры ни өчен кызыксындырды? Мин бит, диннәр янадан күтәрелгән чорда, мәҗүсилеккә китеп бардым. Яхшы чормы, начармы—бу тарихның бер чоры. Мине монда кызыксындырган нәрсә—кешеләрнең бу чорда табигатькә якын булулары. Алар агачларга, күккә табынганнар, табигать кочагында күбрәк яшәгәннәр. Ә табигать эчендә яшәгән кеше чистарак була. Мәҗүси чорны хайванлык чоры дип әйтсәләр дә, минем уйлавымча, хәзерге заман чорының хайванлыгы мәҗүси чор хайванлыгыннан мең мәртәбә артыграктыр.

Бу чорларда матур-матур легендалар, риваятьләр туган. Ислам диненә каршы килерлек нәрсә дә юк кебек аларда. Ипине идәнгә ташлама, суны пычратма, тегеләй итмә, болай итмә кебек кешелекне саклый торган тәрбияви тыюлар булган. Минемчә, «Кара урман», «Гөлҗамал» кебек татарның матур моңлы җырлары мәҗүсилек чорында тугандыр. Шул чорда һәр нәрсәнең иясе булуы мине бик кызыксындырды. Хәзерге заманда иясезлек сизелә, хәтта кайбер халыкның да иясе юк, вакытның да иясе юк.

**Р. В.** *Әхсән агай, синең белән сөйләшкәндә, мин фикерләү юнәлешеңә, фикерләү мөмкинлекләреңә шаккатам. Син рәссамнар арасында фикер белән яши торган сирәк затларның берсе. Рәссамнарның күбесе матурлыкны, гүзәллекне күрсә дә, аңа фикер салырга тырышмый. Әмма син иң беренче итеп фикерне алга куясың. Кешене хайваннан аера торган нәрсә ул—фикер йөртү, уйлый белү. Син менә шуны алга*

*куясың, ижатында ачык чагылдырасың. Әмма Европадагы бер бөек кеше: «Рәссам чын мәгънәсендә рәссам булсын өчен, анын телен кисәргә кирәк»,—дигән. Ягъни, ул сөйләшмәсен һәм бөтен фикерен, талантын төсләр аша, буяулар аша гына бирсен, дигән. Ә син үзеннен ижат талантынны сүз аша да, жыр аша да бирә беләсен. Шуна күрә мин әллә теге кешенен сүзләре сина кагылмый микән дип уйлап куям...*

**Ә. Ф.** Анын сүзләре белән килешәм. Мин бит эшләгән вакытта сөйләшмим. Остаханәдә торганда айлар буена, хәтта өйгә кайткач та күп сөйләшмим. Әмма кайчакта кешеләрнен күнеле тулган була. Аны моңлы жыр, мәгънәле сүз белән генә бушатып була. Күнеле тулган чакларында шагыйрь шигырьләр язып аны бушата, мин сөйләп бушатам. Сөйләшеп, фикер әйтеп син үзеннен позициянне белгертеп, жәмгыятькә чыгарып тикшерәсен. Анын өчен сине йә мактыйлар, йә башына сугалар. Кайвакытта бөтенләй сөйлисе килми, кайвакыт, киресенчә, сөйлисе килә, бигрәк тә сине анлаучы, тынлаучы булганда.

**Р. В.** *Минем анлавымча, синен уй-фикерләрен шулкадәр күп, алар рәсем сәнгатенә генә сыеп бетә алмый. Пушкин да бит шигырь язган, шигырьгә сыймаганын прозага салган, прозага сыймаган фикерләрен көндәлекләргә төшергән. Ә аларга да сыймаганнарын кәгазь читенә рәсемнәр итеп ясаган. Анын эчендә уй-фикерләр шулкадәр кайнап торган, алар бер генә төрле формага сыя алмаган.*

*Без бәләкәй чакта Шүрәлене Тукай буенча гына белә идек, ә хәзер без аны Әхсән Фәтхетдинов рәсемнәре аша да өйрәнәбез. Тукайның шүрәлесе бер генә иде: бармаклары бүрәнәгә кыстырылган, хәйләкәр генә урман сарыгы. Әхсән Фәтхетдинов шүрәлеләрнен бөтен төрләрен барлыкка китерде: монсу, шатлыклы, усал—барлыгы 50-60 шүрәлең бар синен. Хәтта синен шүрәлеләрен яши-яши үсеп житеп, гаилә корып та жибәрделәр, аларның балалары да туа башлады. Шулай берзаман Түбән Камада депутатлыкка кандидат булып йөргән чакта син галереяңда шаяртып әйтеп тә куйган иден: «Менә без депутатлыкка әллә кемнәрне тәкъдим итәбез, ул депутатлар сайланганнан соң сессияләрдә гәжит укып, йоклап утыралар. Татар халкы мәнфәгатьләре аларның уйларына да кереп карамый. Әллә соң, Разил туган, татар халкы мәнфәгатьләрен яклар өчен депутатлыкка шүрәлене тәкъдим итикме? Ул бит татар жанлы шүрәле». Мин соңыннан бу сүзләрдә шактый тирән фикер ята бит дип, уйланып та йөрдем. Чынлап та, татар халкы өчен шүрәле кем ул, синең өчен шүрәле нинди зат ул?*

**Ә. Ф.** Мин шүрәле белән Тукай аша балачактан ук таныш. Элек ана ничектер исем китми иде. Ә тора-бара ул мине шулкадәр эләктереп, күнелемне биләп алды, шүрәле аша татар халкынын символик образына чыгасым килде. Башка бер халыкта да андый образ сакланмаган. Шүрәле татар халкы белән бергә барган, бергә яшәгән. Ул кимсетелү чорын да үткән: аңа мөгез такканнар. Аны житди булмаган бер образга да әйләндергәннәре бар. Шүрәлене кайчакта, бер ахмат зат, дип әйтүчеләр дә бар. Әмма бу алай түгел. Менә без барыбыз да үләчәкбез, ә шүрәле калачак. Анын турында киләчәк буыннар кат-кат язачак. Тукай бит анын бер фрагментын гына алган. Анын шүрәле турында язарга вакыты гына житмәгәндер, чөнки гомере кыска булган, бәлки әле әллә нәрсәләр язган булыр иде. Татар халкы шундый мәнге яши торган образ тудыра алган икән, димәк, монда нәрсәдер бар. Безгә моны анларга гына кирәк. Ана халык үзенең бөтен эчке хисен салган. Көләсе килгән икән—шүрәлегә бәйләнгән, ачуланасы килсә дә—шүрәлене эзләп тапкан. Ул халыкның эчен бушата торган ниндидер бер образга әйләнгән. Янәшәдә шундый образ булганда, халык үлмәячәк. Менә шүрәле үлсә, халык та үлгән була инде...

**Р. В.** *Әхсән агай, син шүрәлене урман иясе дип әйттен. Мин монын белән килешәм. Урман—безнен табигатебез, без—табигать балалары. Без бәләкәй чакта әби-бабаларыбыз урман иясе—Шүрәле турында, абзар иясе, йорт иясе, су иясе—Су анасы, тагын берничә ия хакында сөйлиләр иде дә, шунын белән бетә иде. Менә мин синең әсәрләренне карыйм да, синдә нинди генә ия юк!? Синен әсәрләрен*

*аша мин тора-бара һәр нәрсәнең иясе бар дигән фикергә килдем. Ә сина андый фикер кайчан килгән иде?*

**Ә. Ф.** Мин моны беркаян да укымадым. Әллә берәрсеннән ишеттемме, әллә ул минем үземдә тудымы, тик бу минем өчен алтын фикер: «Дөньяда һәрбер нәрсәнең иясе бар». Ничек инде урман кебек урманның, тау кебек тауның ияләре булмасын!? Без йорт, абзар ияләрен ишетеп үскән кешеләргә, ни өчен урам, тыкрык ияләре булмасын!? Алар һәрберсе үзенчәдер, аерымрактыр, һәр агачның, һәр ботакның, һәрбер яфракның да беркемгә дә охшамаган иясе бардыр. Чөнки һәр яфракның—үз язмышы. Аларның кайсы кышка агачта эленеп кала, кайсы җил белән очып китә, кайсы агач астында калып чери. Аларның язмышлары бер-берсенә охшамаган, үзенчәлекле, һәрбер үзенчәлекле нәрсәнең иясе бар. Мин башта кырык ия ясыйм, дип әйттем, ник алай башка килгәндер. Аннары ул күбрәк булды. Соныннан шатланып куйдым: картаеп беткән "ия" сүзен бераз яшәрттем кебек, хәзер "ия" сүзе газета-журналларда да күбрәк кулланыла башлады.

**Р. В.** *Әхсән агай, синең Түбән Камада да, Казанда да, башка җирдә дә дусларың бар. Әмма дусларың арасында шагыйрьләр аерата күп. Чөнки үзен дә шагыйрь җанлы кеше бит. Син кайвакыт, илаһи дулкынга кучеп, шигырь белән дә сөйләшә башлыйсың. Шагыйрьләр дә синең белән очрашканда битараф калмыйлар, рәсемнәренә, үзенә сокланып шигырьләр дә язалар. Әсәрләренә исемнәр куйганда да син шагыйрьләребезнең шигъри юлларына мөрәҗәгать итәсең. Әйтик, синең байтак әсәрләреңдә шагыйрь Равил Фәйзуллин иҗатыннан алынган шигъри юллар файдаланылган. Күптән түгел арабыздан киткән шагыйрь Зөлфәтнең сина багышланган шигыреннән берничә юл искә төшереп китим әле:*

*«...Остаханәңдә мин, Әхсән,*
*Өнсез булдым—*
*Кешене син бакый иткән бит...*
*Син—җан табигате генә түгел,*
*Табигатьнең җаны икән бит!*

*Җирләр куккә күтәрелгән чакта,*
*Йолдызлы күк җиргә төшкәндә -*
*Уйларымны меңгә тапкырлап гел*
*Йөрим, Әхсән, остаханәңдә!*

*Сөйләшергә мин табармын сине*
*Кара яңгыр, тоташ кар аша!—*
*Кардәштән дә кадерлерәк кешем—*
*Тамырдашым ла син, ләбаса...*

*Зөлфәт тә синең остаханәңдә булган, минем дә булганым, хәтта кунып та чыкканым бар. Мина ул шулкадәр ошады, әсәрләренне бөтенесен бергә күргәч шаккаттым, аерыла алмыйча алар белән төне буе сөйләшеп чыктым. Чөнки анда шүрәлеләр, албастылар, карачкылар—нәрсә генә, кемнәр генә юк?! Әле үзенең чиратын көтеп яткан агач ботаклары да җитәрлек. Карыйм-карыйм, күзгә йокы керми. Алар мине куркыта, шомландыра да, алар шактый ук килбәтсез, ямьсез дә күренәләр. Таң атып, йөзләренә кояш нурлары төшә башлагач, алар шулкадәр матураеп киттеләр ки... Мин шунда аңлый башлаган кебек булдым—әлеге шүрәлеләр, албастылар, өрәкләр үзләре аерым, башка дөнья түгел, алар бит без үзебез икән ләбаса...*

**Ә. Ф.** Кеше үзенең бу дөньяда кем икәнлеген аңларга тиеш. Менә киләчәктә кешенең үзен дә бик каты гына ремонтлыйсы, төзәтәсе бар. Чөнки аның баш миләре бераз бозылган, күңеле буталган кебек тоела, кеше тормыш карурманында адашкан кебек күренә. Ләкин һәрчак алай була алмас, табигать яңа кешеләрне тудырып торыр, начарлыклар әкренләп онытыла барыр. Мин уйлыйм, кеше барыбер терелер, моңа бары вакыт һәм тырышлык кына кирәк. Ул, һичшиксез, шулай булачак...

Дания
Заһидуллина

# ИЛ ЙӨРӘГЕНӘ ЯЗА УЛ

Исемеңне ташка язма, ил йөрәгенә яз, ди халык. Үз фидакарьләренең тырышлыгы ярдәмендә генә исән калган татар милләте өчен исемен ил йөрәгенә уя алучылар бигрәк кирәк, үтә кадерле. Көч-куәтен, акыл-гыйлемен, җегәрлек-сәләтен халыкка хезмәт итүгә багышлаган тынгысыз һәм зыялы зат, милләт өчен күп хезмәтләр һәм игелекләр кылган шәхес Тәлгат Нәби улы Галиуллин нәкъ шулай, фидакарьлеге белән исемен ил йөрәгенә язганнардан. Әдәбият белеме фәнендә абруй казанган талантлы галим, Казан дәүләт университетының профессоры, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы, татар укучысына яхшы мәгълүм, инде ярты гасыр буе яңа исемнәр, яшь талантлар хакында хәбәр итеп, әдәбиятның үсеш тенденцияләрен аналитик билгеләп барган эзләнүчән тәнкыйтьче, мәгариф һәм фән өлкәсендә зур эшләр башкарган: республика күләмендә әһәмиятле Алабуга педагогия институтын яңа биеклеккә күтәргән, өр-яңа вуз—Чаллы дәүләт педагогика институтын—оештырган, шаулы 1989 елны Казан дәүләт университетында татар филологиясе буенча махсус факультет ачкан оста оештыручы һәм гыйлемле укытучы, лектор, татар әдәбиятына яңа сулыш өргән, заман героен биргән язучы, милләт мәнфәгатьләрен кайгыртуны үзенең намус эше санаган җәмәгать эшлеклесе ул.

Тәлгат Нәби улы 1938 елның 20 июлендә Татарстанның Норлат районы Кычытканлы авылында туа. «Гомер тәлгәшләре» дигән автобиографик повестенда ул авылның бер үзенчәлеге итеп халкының эшчән һәм батыр булуын билгели, икенче үзенчәлекне анга-белемгә омтылу дип күрсәтә. Авылдашларының шушы ике сыйфатын үзендә бергә куша алу аңа, күрәсең, төрле өлкәләрдә зур уңышларга ирешергә ярдәм иткән.

Урта мәктәпне тәмамлаган яшь егет бер ел Свердловск өлкәсенең Краснотурьинск шәһәрендә алюминий заводында эшли. Белемгә омтылу аны Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына алып килә. Сәләтле, тырыш, кызыксынучан һәм акыллы егетне шушы факультетның татар теле кафедрасына ассистент итеп калдыралар (1962 ел), аннары аны Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына аспирантурага тәкъдим итәләр. Шушы елларда ук Тәлгат Нәби улы татар әдәбияты тарихы өчен мөһим мәсьәләләргә багышланган фәнни мәкаләләр белән чыгыш ясый, татар әдәбият белеменә үзфикерле һәм төрле характердагы материалны колачлап-инләп алырга сәләтле яшь белгеч килгәнне «хәбәр итә». Аның татар шигъриятендә баллада жанрының үсеш-үзгәреш юлын күзәткән, алтмышынчы еллар шигъриятендә элгәргеләр традицияләрен барлаган, милли әдәбият һәм халык авыз иҗаты арасындагы күпкырлы, күпъяклы бәйләнешләрне тикшергән гыйльми язмалары масштаблылыгы белән аерылып тора. Бер үк вакытта булачак галим әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә каләм сыный: Ш. Галиев, С. Хәким, И. Юзеев һ. б. шагыйрьләрнең китапларына, аерым әсәрләргә кагылышлы тәнкыйди язмалары дөнья күрә. Кискен тәнкыйди фикерләр әйтү яки кеше ышанмаслык чагыштырулар белән мавыкмыйча, тәнкыйтьче Т. Галиуллин шигъриятнең үз материалында тирән күзәтүләр ясауга, аерым әдипләр әсәрләрен татар поэзиясе тарихы фонында карауга өстенлек бирә. Киләчәктә, зур галим булып җитешкәч тә, шушы сайлаган сукмагына тугры кала ул.

Тагын бер кызыклы факт: 1968 елны, XX гасыр уртасы татар шигърияте һәм халык авыз иҗаты арасындагы бәйләнешләрне тикшерүгә багышланган кандидатлык диссертациясен яклаганда, яшь галимнең инде ике дистә язмасы дөнья күргән була. Хәзер, басмалар саны чиктән тыш күбәйгән заманда да, мондый «багаж» белән диссертация яклаучылар юк дәрәҗәсендә. Әлеге факт Т. Галиуллинның язу куәсе хакында да, үзенә таләпчәнлеге турында да сөйли, әйтер сүзе-фикере булганнарның һәр заманда аны халыкка җиткерү өчен мәйдан таба алуына дәлил булып та килә.



*Тәлгат Галиуллин китапларының берничәсе.*

1965 елны Алабуга дәүләт педагогия институтына эшкә китеп, яшь-яшь килеш анда дәрәҗәле һәм җаваплы вазифалар башкарганда да (1967-71 елларда институтның укыту һәм фәнни эшләр буенча проректоры, 1971-86 елларда ректор), Тәлгат Нәби улы фәнне һәм әдәби тәнкыйтьне ташламый. Киресенчә, аның яңадан-яңа тикшерү объектлары билгеләнә. Тәнкыйтьче буларак, шигърият белән чикләнмичә, ул прозага да мөрәҗәгать итә башлый. Әйтик, Э. Касыймовның «Томан аша» романына (1969), М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар» романына (1972) әтрафлы рецензияләре басылып чыга. 1960-70 еллар чигендә Т. Галиуллинның даими игътибар үзәгендә торачак «үз» авторлары пәйда була: Ш. Галиев (1963 елдан башлап), С. Хәким (1964 елдан башлап), Р. Харис (1969 елдан башлап), Г. Латыйп (1968 елдан башлап), Х. Туфан (1970 елдан башлап) И. Юзеев (1973 елдан башлап) һ. б. Алар иҗатына һәм галим, һәм тәнкыйтьче буларак бәя биргән язмалар даими рәвештә республика матбугатында дөньяга чыга. Гомумән, әдәби процесс белән кызыксынып, шигърият пульсын тоеп тору— аның бөтен иҗат гомеренә хас сыйфат. Яшь шагыйрьләр иҗатын тикшерү, алар әсәрләрен туплаган җыентыкларны күзәтү, язучыларның әдәби ел йомгакларында чыгышлар ясау, әдәбият тарихына кагылышлы аналитик, күзәтү характерындагы материаллар әзерләү—болар барысы да күп укуны, эзләнүне таләп итә, эрудиция һәм әдәбиятны ярату хакында сөйли. Яшь галим фәнни язмаларында шигърияттә, аерым шагыйрьләр иҗатында, конкрет әсәрләрдә яңалыкларны, әдәби алымнар кулланылышын, традицияләрнең дәвам ителешен, образлылыкны игътибар үзәгенә куя. Татар әдәбият белемендәге яңалыклар, вакыйгалар да һәрчак аның күз уңында: әйтик, замандашы, әдәбиятчы Н. Юзиевнең «Традицияләр яңарганда» (1967) һәм «Сәнгатьчә матурлык һәм осталык» (1969) китапларына рецензияләр, танылган рус язучысы М. Горькийның тууына 100 ел тулуга карата язма (1968), тууына 70 яшь тулуга багышлап Н. Исәнбәтнең гыйльми эшчәнлеген бәяләү (1970) һ. б. шундыйлардан.

1970-80 еллар чигендә галимне кызыксындырган, борчыган мәкаләләр монографик тема булып формалаша: совет чоры шигъриятендә реализм традицияләренең нигезе, үсеше, үзгәреше. Бу тема берничә китапта: «Социалистик реализм юлыннан» (1977), «Дыхание времени (вопросы становления и развития социалистического реализма в татарской советской поэзии до 1941 года)» (1979) хезмәтләрендә һәм докторлык диссертациясендә ачыла-ачыклана. Аларда әдәбият белеменең иң катлаулы мәсьәләләреннән булган иҗат методы хакында күзәтүләр дә, 20-30 елларда татар әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйтьнең торышын тикшерү дә, татар шигъриятендә язу ысулына караган методологик фикерләр дә, 20-30 еллар шигъриятенә җентекле анализ да урын таба. Аерым алганда, сайланган материалда 20-30 еллар татар әдәбиятының Көнбатыш һәм Көнчыгыш поэзиясе үзенчәлекләрен яңа методологик нигездә синтезлавы хакындагы фикер дәлилләнә. Бу нәтиҗә алга таба татар әдәбияты тарихын өйрәнү өчен гаять зур әһәмияткә ия була: ул кайбер фән эшлекләреренең бу чор татар шигъриятендә рус әдәбияты,

революцион идеяләр йогынтысын өстенлекле санавына чик куя. Аннары, чор шигъриятен тикшерү вакытында берничә: кеше һәм җәмгыять, шәхес һәм төркем, кеше һәм хәл-әхвәлләрнең катлаулы мөнәсәбәтләре барышын күз унында тоту кирәклеге хакындагы методик характердагы кагыйдә ассызыклана. Чор лирик героен күпъяклы тикшереп, автор аның үз вакыты кешесе, тормышка инкыйлаби мөнәсәбәтле көрәшче генә булмыйча, табигать баласы икәнлеген дә дәлилли. Т. Галиуллин 1920-30 еллар шигъриятендәге жанрлык ягыннан үзгәрешләргә карата чыгарган нәтиҗәләр дә, XX гасыр буе татар әдәбият белеме тарафыннан үстерелеп килеп, XXI гасыр фәнендә дә әйдәп бара. Галим бу чор татар поэзиясенең нәкъ менә жанрлар өлкәсендә «революция» ясавын билгели. Жанрлык хасиятләре эзлекле һәм әтрафлы өйрәнелгән дип булмаган бу вакытта тарихи поэтика юнәлешендә мөһим һәм дөреслеге алга таба расланган закончалыкларның асылын күрсәтә.

Хезмәтләрдәге аерым бер гомумиләштерүләр үз чоры өчен кыю һәм көтелмәгәнчә яңгырый. Әйтик, галим чор сулышын чагылдыручы байтак әсәрләрнең, революцион лозунглар күтәргән шигырьләрнең уртакул шагыйрьләр тарафыннан иҗат ителүен исбатлый. «Модага ияреп» язылган иҗат җимешләренең татар шигърияте йөзен билгеләмәвен талантлы авторлар иҗаты мисалында күрсәтә.

Галимнең докторлык диссертациясе татар әдәбият белемендә XX гасыр татар шигъриятен тулысынча инләп алып өйрәнерлек әзерлекле шәхес бар икәнлекне тагын бер кат искәртә. 1981 елны филология фәннәре докторы дигән олы дәрәҗәгә ирешкәннән соң да Т. Галиуллин, бер-бер артлы фәнни һәм тәнкыйди характердагы күләмле монографияләр, китаплар чыгарып, үзе хакында формалашкан әлеге күзаллауның дөреслеген раслый.

Т. Галиуллин—әдәбият гыйлемендә тәнкыйть һәм фән тарихы мөмкинлекләрен бергә файдаланып, тоташтырып, әдәби-иҗат портретлары тудыруга нигез салучыларның берсе. «Еллар юлга чакыра» (1975), «Безнең заман—үзе җыр» (1982), «Шагыйрьләр һәм шигырьләр» (1985), «Дәвамлылык» (1987), «Илһам чишмәләре» (1988), "Гомер учагы" (1991) китаплары нәкъ менә шушы яктан кызыклы, фәнни һәм әдәби кыйммәткә ия. Алар XX гасыр әдәбияты хакында гомумән татар әдәбияты тарихы фонында уйланып, шушы әдәбиятны тулы әдәби процесс күзлегеннән өйрәнү юлларын күрсәтеп язылган. Исемнәре янында «әдәби тәнкыйть мәкаләләре» дигән аңлатма бирелсә дә, китаплар әдәбият тарихының актуаль мәсьәләләрен көн тәртибенә куйган фәнни монография дәрәҗәсенә ия. Хезмәтләр шартлы рәвештә аерылган ике өлешне: әдәбиятны өйрәнү мөмкинлекләрен билгеләгән теорияне һәм шуны гамәлгә ашырган тарихи язмаларны берләштерә.

Язмаларның исеменә үк язучы, шагыйрь иҗатындагы төп сыйфат чыгарылган, ул инде, тәкъдим ителәчәк материалны гомумиләштереп бәяләү буларак, укуга «көйли». Әйтик, «Шагыйрьләр һәм шигырьләр» китабында (1985) шушы чорда актив иҗат иткән шагыйрьләр иҗаты тикшерелә. С. Хәкимгә багышланган бүлек «Зур бу илем, гаҗәп киң бу дөнья» дип атала, автор анда татар шагыйре иҗатындагы лейтмотив буларак гомумән дөнья хакында уйлану урын тапканлыкны ассызыклый. Яки Нури Арсланов шигъриятен барлаган бүлек «Үз илем, үз республикам бар» дигән исем йөртә, бу татар шагыйренең гражданлык лирикасы, патриотик мотивлар белән эретелгән шигырьләр аша дан казануы үзәккә алына. И. Юзеевне автор «Яшьлек һәм батырлык җырчысы» дип исемли.

Аннары шагыйрьләрнең иҗат үзенчәлеген тәшкил итә торган берничә сыйфат аерып чыгарыла. Әйтик, С. Хәким иҗаты болай бәяләнә: 1) «С. Хәким каләме тудырган әсәрләрнең шөһрәте, барыннан да элек, халык язмышының үзәк вакыйгаларын, борылыш моментларын кеше характеры, шәхес кичерешләре аша һәм шул ук вакытта фәлсәфи тирәнлек белән калкытып куя алу осталыгы белән аңлатыла»; 2) «шагыйрь һәр очракта да чор рухы таләп иткән, үз эчке кичерешләренә, уйлануларына якын тематиканы һәм жанрны алга чыгара»; 3) төп темалар буларак Бөек Ватан сугышы, туган ил-җир, туган җирдә барлыкка килгән үзгәрешләр, туктаусыз эзләнү һәм йөрәк-хис тыйгысызлыгы күрсәтелә.

Шунда ук шагыйрьләр иҗаты чорларга бүленеп, бәяләнеп уза. Мәсәлән,

Р. Фәйзуллин шигъриятендә тәнкыйтьче «берсен-берсе тулыландырып, вакыты белән бәхәсләшеп, тартышып үскән өч юнәлеш, елларын тәгаен генә билгеләве кыен булган өч чор, өч этап» билгели: беренчесендә «ул укучыны тормышны гадәти булмаганча күрүе һәм тасвирлавы, чәчрәп торган метафорасы, ассоциациясе һәм гармония, көйле аһәң белән санашмаган ижеге белән үзенә каратты», бу чорда ул—тәҗрибәләр ясаучы, традицияләрне җимерүче бунтарь; кыска шигырьләр чоры—«экспрессив тыгызлык, мәгънәви һәм стилистик куелык, образлы киеренкелек ярдәмендә тар мәйданда фикер, идея әйтеп салу, хисне ачу», философ шагыйрь; өченче чор—«сугыш һәм иминлек, үткән һәм киләчәк, батырлык һәм куркаклык турында язылган шигырьләрендә Маяковский, Такташ, Җәлил традицияләрендә тәрбияләнгән трибун шагыйрь буларак ачыла». Р. Фәйзуллин иҗатын яратучы һәм белүчеләр өчен дә, тикшерүчеләр өчен дә бу бүленеш—аксиома, кире кагу мөмкин булмаган бәя.

Тагын бер мисал. Т. Галиуллин, 60-80 елларда мәйданга чыккан бик күп талантлы шагыйрьләр белән беррәттән, Ренат Харис өчен дә «үз» тәнкыйтьчесенә, иҗатын даими күзәтеп баручы укучыга әйләнә. Яшь шагыйрь үзен таныткан, үзе хакында хәбәр иткән бер вакытта ук тәнкыйтьче аның иҗатындагы түбәндәге үзенчәлекләрне аерып чыгара: 1) бу иҗатта кешенең фикерләү рәвешенә, интеллектына үтеп керергә, тормыш диалектикасын аңларга омтылыш көчле; 2) аның лирик герое—көчле, нык ихтыярлы шәхес, рухи дөньяны да шагыйрь элегик моң, сагыш аша түгел, бәлки «ихтыярлы» ритмнар, «мускуллы» сынландырулар, экспрессия һәм катлаулы ситуацияләр аша сурәтләргә ярата; 3) аналитик фикер, эзләнүчән хис шагыйрьгә көнитешнең төрле күренешләренә үтеп керергә юл ача: сурәтләнгән вакыйгаларга, эчке дөнья чагылышларына үзенең мөнәсәбәтен төгәл һәм ачык итеп рәсемләп бирү мөмкинлекләрен арттыра; 4) ул—"шартлаулы", көтелмәгән алымнар, кыю метафоралар шагыйре, сүзгә саран һәм экономияле шагыйрь. Бүген, шагыйрь татар шигъриятендәге нигез баганаларның берсенә әверелгәч тә, әлеге иҗатта шушы үзенчәлекләрнең «ярылып ятуын» күрми мөмкин түгел. Шуңа күрә XX гасыр поэзиясе, аның аерым сүз осталары хакында яңа хезмәтләрдә, диссертацияләр һәм монографияләрдә без Т. Галиуллин карашларын үстерү белән очрашабыз. Галим чын мәгънәсендә тулы бер гасыр шигърияттен өйрәнүгә сукмак салды, киләчәк тикшеренү юлларын билгеләде.

1986 елны Казанга әйләнеп кайтып, Тәлгат Нәбиевич башта Казан дәүләт педагогия университетының әдәбият кафедрасында, аннары Казан дәүләт университетында профессор булып эшли башлый. 1989 елны аңа татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетын оештыруны тапшыралар. Татар милли күтәрелешенең иң матур казанышларыннан берсе булып, факультет 20 эчендә татар дөньясы өчен бик күп гыйлемле һәм талантлы яшьләр үстерде, белгечләр әзерләде.

Шушы мәшәкатьле, җаваплы эшләр белән беррәттән, Тәлгат Нәбиевич фәнни тикшеренүләрне дә ташламый. 90нчы еллар—хәбәрдарлык чоры әдәбият белеме фәненә дә гаҗәеп көчле тәэсир ясый. Билгесез исемнәр һәм әсәрләр кайта, озак вакытлар яшәп килгән концепцияләрнең идеологик заказга барып тоташа торган «йомшак» яклары ачыктан-ачык күрсәтелә. Инде әдәбият тарихын бөтен тулылыгында аңлау мөмкинлеге ачылган кебек тоела. Ләкин... бу эш алай бик ансат кына булып чыкмый, иске концепцияләрне кире кагу, яки социалистик реализм белән көрәшүнең үзмаксат булмаганлыгын аңлау килә. Чөнки янача эшләү юллары табылмаган, ә менә ярты гасырдан артык вакыт дәвамында тупланган гыйльми тәҗрибә тиз генә фәнни аренадан китәргә теләми икән бит! Инде тагын бер кат яңа концепция кирәклеге, ләкин аның иске мирастан тулысынча баш тартып түгел, бәлки элгәргеләрнең эзләнүләрендәге уңышлы якларны файдаланып гамәлгә куелырга тиешлеге аңланыла...

Филология фәннәре докторы, галим Т. Галиуллинның «Шигърият баскычлары» (2002) һәм «Шәхесне гасырлар тудыра» (2003) китаплары әдәбият турындагы фәнгә шундый концепция алып килә. Әдәбият белемендәге XX гасыр ахырында

тәнкыйтькә дучар булган концепцияләр әдәби барышка иҗтимагый-сәяси яктан якын килүне таләп итәләр. Хәзер инде әдәбиятның идеологик яки сәяси заказ белән генә барлыкка килә алмавын, аның үз эчке закончалыкларына буйсынып, чорның әдәби аң үзенчәлекләренә таянып үсүен бераү дә кире какмый. «Ләкин аны кайсы яктан тикшерү дөресрәк соң?»—бу сорау исә ачык кала килә. Т. Галиуллин әлеге мәсьәләгә үз карашын белдерә, ул әдәбиятны милли тамырлар һәм шартларга бәйле рәвештә яшәешне танып-белү өлкәсе, милли үзаң һәм характерны сүз-сурәт ярдәмендә тергезеп күрсәтү сферасы дип саный. Мәдәният тарихындагы күренешләрне менталь үзенчәлекләргә мөнәсәбәтле тикшерү методологик яктан Л. Н. Гумилев хезмәтләренең дә «умыртка баганасын» тәшкил итә. Татар галиме исә халык тарихындагы үзгәрешләрне әдәби парадигма алышыну нокталары буларак карый. Аның «Милли үзаң һәм шигърият» язмасы әлеге концепциянең асылын укучыга җиткерүе белән әһәмиятле.

«Татар поэзиясе тарихын яңача өйрәнү мәсьәләләре» дигән тикшеренү беренчесен дәвам итә һәм төгәлләштерә. Татар шигъриятенең аерым бер дәверләрен өйрәнү эшендә кабул ителгән кайбер карашларга бәя биреп, автор үз концепциясенең төп кануннарын формалаштыра.

Беренчедән, галим озак еллар дәвам иткән һәм XX йөз башы белән 1917 елдан соңгы әдәбият арасында бернинди уртаклык юк, дигән караш белән килешмәвен белдерә, «ике дәвер әдәбиятларын чагыштырып караганда, тирәннән, астан агып яткан чишмәләрне, ерганакларны барлаганда, сурәтле фикерләүнең бернинди сәясәткә, өстән индерелгән хакимияткә бирешми торган үз эчке кануннары, уртаклыклары барын сиземләве кыен түгел». Димәк, милли әдәбиятның шушы эчке уртаклыкларын, күчемлелек-дәвамлылыгын күздә тотып өйрәнү кирәк.

Икенчедән, сәясәт басымы әдәбиятны «заманның шәүләсе, колы» дәрәҗәсенә төшерә. Аның күтәрелеше исә теге яки бу халык әдәбиятында талантлар, олы әдипләр булу белән бәйле. Шуңа да әдәбият тарихын өйрәнү бәя бирүдән башка була алмый, юкса төрле дәрәҗәдәге, төрле мөмкинлекләргә ия язучылар бер калыпка салыначак.

Өченчедән, Т. Галиуллин мона кадәр әдәбият белемендә тискәре бәяләнеп килгән, ләкин күп кенә әдипләр иҗатына зур йогынты ясаган дини-мифологик катламның, модернистик һәм шәкли эзләнүләрнең махсус тикшеренүләр объекты булырга тиешлеген дәлилли. Шуның белән бергә, автор «социалистик реализм» кебек зур күренешне соңгы вакытта уйдырма дип атауга да каршы чыга. Шулай итеп әдәбиятны бөтенлектә, төрлелектә, тулылыкта өйрәнү кирәклеге көн тәртибенә куела.

1995 елны язылган бу мәкаләдә мондый юллар бар: «Күнегелгән, күп тапкырлар тәкърарланган яссылыкларга ябышып яту, шигъриятне бик тар сәяси-җәмгыяви күзлектән чыгып кына бәяләү, карашлар төрлелеген кабул итмәү, бер фикерне канунлаштыру—әдәбият фәнен, тәнкыйтьне торгынлыкның җылы, тыныч, иплe ярларыннан ерак алып китә алмас. Үткәнгә тәнкыйди карашны «авантюра», «карьера артыннан куу» кебек текә сүзләр белән өркетү, мирасның абруен төшерү дип бәяләү чоры иртәме-соңмы үтәчәк. Безнең буынга насыйп булган өермәле вакыт туктаусыз алга хәрәкәтне, эзләнүне, уйлануны таләп итә. Үзгәрмичә мөмкин түгел». Бу сүзләрнең дөреслеген вакыт инде раслады. Галим үзгәрү юлларын, әдәбиятны яңача өйрәнү юнәлешләрен билгеләүдә дә хаклы булып чыкты.

Хезмәтләрнең «йөзек кашы»—егерменче һәм утызынчы еллар шигъриятен, бу чорлардагы олы шагыйрьләр иҗатын күзәтү-анализлау өлеше—галимнең нәзари фикерләрен гамәлдә сынау да булып тора. Бу эзләнүләр мона кадәр укучыга аз билгеле мисалларга таянуы һәм, шуның белән бергә, билгеләнгән вакыт аралыгындагы шигъриятне тулысынча колачлап алуы белән сокландыра. Т. Галиуллин гыйльми өйрәнүләр объекты итеп сайланган дәвер әдәбиятына бербөтен милли-әдәби аң җимеше дип карый. Үзе тәкъдим иткән нәзари кагыйдәләрдән чыгып, автор татар әдәбиятындагы күчемлелекнең 1917 ел вакыйгалары белән өзелмәвен дәлилли. Мәсәлән, ул елларда М. Гафури, Г. Камал, Ш. Бабич кебек шагыйрьләр мирасында

халык авыз иҗаты традицияләре чагылу игътибарга лаек. Хәтта мона кадәр татар әдәбият белеме дәшми үтә торган өлкә: егерменче еллар әдәбиятында дини-мифологик мотивларның саклануы С. Сүнчәләй, Т. Ченәкәй, Ә. Сәгыйди, Г. Харис һ. б. шигырьләре мисалында күрсәтелә. Шулай итеп, галим—үзе фәнгә аяк баскан бер вакытта—мөрәҗәгать иткән классиклар иҗатына XX гасыр ахырында янадан әйләнеп кайта, аларны яңа күзлектән тикшерүгә һәм бәяләүгә алына.

Егерменче еллар татар шигъриятенә кагылышлы тикшеренүләр әдәбият белемендә ачык кала килгән берничә сорауга җавап бирә: Дәрдемәнд һәм Сәгыйт Рәмиев кебек, XX йөз башында иҗатларының "алтын чорын" кичергән зур фигуралар инкыйлабка нинди карашта булдылар? Ни өчен татар шагыйрьләренең бөтенесе диярлек 1917 елгы революцияне шатланып каршы алды? Дәвер әдәбиятына кайсы шәхесләр нинди өлеш кертте? Бу чорда татар шагыйрьләре нинди иҗат юнәлешләрен үз күрде, нинди алымнарга мөрәҗәгать итте? Заман җилләре татар сәнгатенә нинди яңалыклар алып килде? Үз фикерен беркемгә дә көчләп такмыйча, ләкин ышандырырлык язып, галим татар укучысын шушылар хакында уйланырга чакыра, татар әдәбиятындагы бер этап хакында гына түгел, милли сәнгатьнең бүгенге хәленә сәбәп булган факторлар, мәдәният тарихыбыз турындагы нәтиҗәләре белән уртаклаша. Авторның үзе язганнарга битараф булмавы, аерым бер вакыйгалар хакында сүз алып барганда үкенүле-ачынулы интонациягә мөрәҗәгать итүе укучының да күңел кылларына кагыла. Борчылырга мәҗбүр итәрлек фактлар да күп язмада. Мәсәлән, шушы чор әдәбиятына мөнәсәбәтле К. Әмири, Ә. Сәгыйди кебек аз билгеле шагыйрьләр иҗатына бәя биреп барган автор әдәбиятта беренче адымнарын ясауга ук, гражданнар сугышы вакытында башларын салган яшьләрнең исемлеген китерә: В. Җәлал, К. Кәрипов, Ш. Бабич, Ш. Фидаи, И. Йосфи, Д. Гобәйди, Бамин (Бәдретдин Әминев) һәм башкалар алар. Иң яхшы әсәрләрен язарга өлгермәгән талантлы яшьләрнең сәясәт корбанына әверелүе башка бүлекчәләрдә дә игътибарга алына, татар әдәбиятының аерым бер дәверләрдәге торыш-үзгәрешләренә бүгенге караш, еш кына артык таләпчән якын килү дә искәртелә. Галимнең үз халкы мәдәниятенә, әдәби мирасына, фаҗигале язмышларга дучар булган улларына хөрмәте, каләм тибрәткәндә үзенең татар булуын һәрчак истә тотуы хезмәтнең буеннан-буена кызыл җеп булып бара.

Шунысы кызык: әдәбият белеме фәнендә 20-30 еллар әдәбияты бергәрәк каралып, уртак тенденцияләрне үстерүче кебек кабул ителә иде. Ә биредә Т. Галиуллинның ике чорны аеруы алар арасындагы дәвамчанлыкны да, һәр этапның үз хасиятләрен дә бик төгәл күрергә ярдәм итә. Шагыйрьләрнең шәхси иҗат дөньяларын ачу аша, чорның гомуми әдәби панорамасы, дәвер әдәбиятының уртак сулышы калкытып куела. Егерменче еллар шигъриятен эзләнүләр чоры дип бәяләгән автор утызынчы еллар әдәбиятында да, «күзгә бәрелеп торган сыйфат сикереше» ясалмаган хәлдә, бик күп унай яңалыклар әдәбият сәхнәсенә менде дип белдерә. «Утызынчы еллар татар шигърияте» бүлекчәсе шушы чор татар әдәбияты каршында баш ию, аны реабилитацияләү булып аңлашыла. Галим поэзиянең үткән тәҗрибәгә таянуын да, «кылычын чүкечкә, мылтыгын сукага, уракка, соңрак штурвалга алыштырган» лирик каһарман тудыруын да, заман алып килгән яңалыкларга шунда ук шигъри сүз ярдәмендә мөнәсәбәт белдерүен дә уңыш дип карый, бер үк вакытта чор шигъриятенең буш сафсата, коры хәбәр, риторика белән мавыгу кебек кимчелекләрен дә ачып сала.

Хезмәтләрдә «татар әдәбияты поэзиядән башлана» дигән фикер берничә тапкыр кабатлана, алай гына да түгел, шушы гыйбарәнең дөреслеге исбатлана. Шигърият феномены бөтен тулылыгында һәм тирәнлегендә Т. Галиуллинның фәнни фикерләү предметы булып торса да, поэзия хакында сөйләү гомумән әдәбиятка бәя бирү кебек яңгырый. Автор шигырь ярдәмендә сүз сәнгате кануннарын ачыклый һәм тәкъдим итә, шул кануннарга таянып аерым энҗе бөртекләрен—әсәрләрне анализлау эше башкара, шулар аша чор әдәбиятына ачкыч таба.

Т. Галиуллин үз нәзари концепциясен тарихи материалда да «сынап карый». Ике китапта да Г. Тукай шигъриятен өйрәнү мәсьәләләренә игътибар ителә. Аларда

Тукай мирасын өйрәнүнең киләчәк юллары барлана, Тукай фигурасын үзәккә куеп, гасыр әдәбиятына тәнкыйди-уйланучан караш ташлана, гасыр башында үз «шигъри мәктәбен тудырган» татар шагыйренең 12 шигыре янача «укып бирелә», заманча шәрехләнә. Шәрехләүләр Тукай шигырьләрен янадан бер кат укып чыгарга, бөек татар шагыйре мирасының үлемсезлек сәбәпләре, төрле заман укучылары өчен ачыла торган яна мәгънә төсмерләре хакында уйлануларга этәрә.

Китапларда Тәлгат Нәбиевичның үз холык-фигыле, тормыш позициясе дә көзгедәге кебек ярылып ята. Автор яна фикер әйтү өчен мона кадәр билгеле булганнарын кире кагу юлына басмый, һәр кешегә, үзе телгә алган шагыйрь, язучы яки галимгә аның хәерхаһлы, хөрмәтле мөнәсәбәте аермачык. Әдәбият белемендәге бер генә табышны да кире какмыйча, галим киләчәккә гыйльми тикшеренү юлларын барлый, юнәлешләр билгели алган, үз концепциясенә нигезләнеп, татар шигъриятенең аерым чорларына янача, заманча, җентекле бәя биргән. Чын галимлек этикасы шундый була.

Ә язучы буларак, Т. Галиуллин прозага кыю исталекләре («Замана балалары», «Дәгъва» китаплары), тормышның бер мизгеленә сатирик-тәнкыйди күзлектән карап уйланырга мәҗбүр иткән хикәяләре белән килеп керде. Ярым публицистик, ярым әдәби повестьлар авторның үзе күргәннәрне-кичергәннәрне бәян итүе рәвешендә язылып, совет чорына, халык белән идарә итүчеләрнең эш алымнарына, кешеләр арасында урнашкан гайре табигый мөнәсәбәтләргә сатирик бәя бирүе ягыннан үзенчәлекле. Сак һәм эзоп телен яратып кулланучы татар язучылары арасында бу өлкәгә аяк басучылар күп түгел иде. Ләкин мондый әсәрләр китмәскә урнашкан төсле тоелган совет тәртипләренә карашны үзгәртүгә хезмәт итте.

Хикәяләүче образы ярдәмендә бер төенгә җыела торган кече жанрдагы әсәрләрендә автор татар әдәбиятына яна, үзенчәлекле геройлар алып килде. Әйтергә кирәк, Т. Галиуллинның образ тудыруда үз «сере», үз алымы бар. Башта геройның портретын бик җентекләп, чагыштыруларны мул кулланып «ясап» күрсәтә, вакыйгалар барышында да табигатенең үзенчәлекле якларын барлый: һәр хәрәкәт, сүз, эш-гамәл шушы максатка хезмәт итә. «Тимерче-терминатор»дагы Ярулла картны гына алсак та, әлеге батыр кыяфәтен укучы күз алдына китереп бастыргач, автор аның сыйфатларын берәм-берәм билгели башлый: көрәш вакыйгасында «Сабан туенда көнне уздыру—вакытны заяга сарыф итү» дип санаган Ярулланың гаделсезлеккә түзә алмавы (көрәшкә шуның өчен генә чыга), олы күнеллелеге (алпарлыны чәй эчереп җибәрүе генә ни тора!) ачылса, әкренләп, без аның төгәл, тынгысыз, таләпчән, ярдәмчел, бала җанлы, тәртип яратучы, пөхтә-җыйнак, үз кадерен белеп яшәүче икәнлеген күрәбез, образ бөтен төс ала. «Терминатор» дип атауның сәбәбен тимерченең алачыкта тимер чүкегән мәлдә «гүләп» сулавы белән анлатса да, машина кебек төгәл, җитез Ярулла үзенең бөтен барлыгы белән утянар икән!

Шул рәвешле үзәк, гомумиләштерүче сыйфатны хикәянең исеменә үк чыгарырга ярата автор. «Нуретдинов жизни»дәге фамилия әйтеп танышучы, фамилиясе белән «дер селкетеп» яшәүче партия әгъзасы, якты киләчәккә ихлас ышанып, иртәннән төнгә кадәр эшләгән, тормыш мәгънәсен партия эшенә хезмәт итүдә күргән кеше тибы да искиткеч тормышчан бит! Кичәге көн җитәкчесе тибы, фамилия "йозагына" бикләнеп, үзен якын кешеләреннән дә аерып, киртәләп куйган, шәхси тормышын да партия мәнфәгатьләренә буйсындырган «фамилияле кеше» тибы. Шундый ук «йозаклы», «Урман хуҗасы» хикәясендәге бернәрсә дә белми-күрми яши торган Урал—хезмәтче тибы. Яки «Колючник» сатирик хикәясендәге Нәҗип—үзен аклау өчен теләсә нинди ялганга әзер, башкаларны, хәтта якыннарын чүп урынына да күрми торган шома кеше тибы. «Җир алмасы»ндагы топинамбур үстерү хыялы артыннан китеп, аллау һәм талау юлына баскан, матур фантазиясе тайгак юлга алып чыккан Габделгазиз—үз ялганына ышанып яшәүче булдыксыз бер тип...

Т. Галиуллинның һәр хикәясе характер тудыруга юнәлтелгән. Бигрәк тә ирония белән сурәтләнгән геройлары психологик яктан бөтен һәм тип дәрәҗәсендә килеп чыга. Хикәяләрдә автор фикере, әдәби концепциясе беренчел, алгы планда тора.

Шуна да анда күпмедер публицистик пафос та урын таба.

1999 елны Тәлгат Галиуллин үзен тагын бер жанрда сынап карый—«Гомер тәлгәшләре» дип аталган автобиографик повесть яза: әйтерсен, укучыны «истәлекләр урамына» чакыра, хатирәләр, язмыш тыгыз аралаштырган шәхесләр хакында сөйләп, үз дөньясын—үз рух сандыгын ачарга тели.

Повесть авторнын туган авылы—Кычытканлы хакындагы бүлек белән башланып китә. Авылнын исеме дә, урыны-табигате дә, тарихы-тамырлары да, күренекле шәхесләре дә бары тик Кычытканлыныкы булып күз алдына баса. Алай гына да түгел. Автор Кычытканлыны яраттырырга өлгерә: авылнын үткәне хакында горурланып укыйсын, умырзая аланынын сөрелүе, урманнарнын киселүе җанны тырнап, үкендереп куя. Ләкин укучы шушы ноктада тукталып калмый: автор аны үз төбәге—үз авылы, әлеге матур урыннарнын икенчесе хакында уйланырга мәжбүр итә.

Повестьнын башка бүлекләре дә шундый көчкә ия. Бабай—зур гаиләне туендырып торучы булдыклы, ярдәмчел һәм киләчәк-дәвам хакында кайгырта белгән акыллы, үз нәселенә телгә осталык, язу-сызуга хирыслык калдырган «писарь» Галиулла; дөнья көтеп, сигез бала үстергән, кызык тудырырга яратучы, яшәеш хакында уйланып яшәгән философ, көндәлекләр алып бара алган, хыялый-шигъри җанлы әти—Нәбиулла; акыллы һәм сабыр, эшчән һәм «дипломат» әни; апалар, энесенелләр турында язып, автор һәрберсен әдәби образ итеп сурәтли алган. Шунын белән бергә Т. Галиуллин әти-әни, якыннарнын кеше тормышы-язмышындагы урыны-роле турында уйлана һәм уйландыра. Әлеге «тәлгәшләр»дә—бала вакыттан янәшәдә булган кешеләрнен мөнәсәбәте, күнелдә шулар хакындагы хатирәләр; алар һәр шәхесне, һәр характерны, һәр кешене бар итә, үзенчәлекле ясый. Безнен гомер буе кылган эш-гамәлләребез дә, җәмгыятьтә һәм гаиләдәгеләргә мөнәсәбәтебез дә, кайгы-шатлыкларны, сынау-сыналуларны ничек үтеп чыгуыбыз да, башкалар каршында нинди сыйфатларыбыз, холык-фигылебез белән гәүдәләнүебез дә шушы «тәлгәшләргә» бәйле икән ләбаса! Шулай итеп повесть туган җир, әти-әни, янәшәдәге кешеләр һәм алар хакындагы безнен күнелдәге хатирәләр тәлгәшләренен Кеше өчен ин якын, ин газиз һәм ин әһәмиятле нәрсәләр булуын искәртә. Тел язмышына бәйләп милләт язмышы хакында уйландырырлык өлешләр дә игътибарга лаек. Үткәндәге мирас—авыл укытучыларынын тискәре «үрнәге», зыялыларнын, хәтта татар теле укытучыларынын үз балаларын рус мәктәбенә бирүе, бүгенге көннеке булган—яшьләрнен китап укымавы, шаблон фикерләрне кабатлаудан котыла алмавы һ. б. шундый проблемалар турында укучы белән житди, борчылулы сөйләшү алып барыла.

Шушы әсәрләрдән килгән интеллектуаль һәм тәнкыйди тенденцияләр, маҗаралы сурәт тудырырга омтылу язучынын бүгенге яшәешебезне сурәтләгән, заманыбызнын төп чирләрен, халыкны яшәткән ышаныч-өметләрен тасвирлаган «Сәет Сакманов» дип исемләнгән трилогиясе тупланган романнары: «Тәүбә» белән «Элмәк» һәм «Төнге юллар»да бергә килеп төенләнә.

Романнар беренче карашка маҗаралы әсәр кебек уйланылган дигән тәэсир калдыра. Маҗаралы әсәрләргә хас җинаятьләр, үтерешләр үзәккә куела. Ләкин традицион маҗаралы жанрда җинаять эшләнү һәм шуны ачу, дөреслекнен тантана итүе сюжет барлыкка китерә, детектив геройлары арасында җинаятьче, корбан һәм үтерүчене фаш итүче булу мәҗбүри. Һәм шуларнын берсе: йә үтерүчене табучы, йә шик төшкән кешеләрдән берәү, йә корбан—унай герой итеп сурәтләнергә мөмкин. Бу романнарда без бөтенләй башка күренеш белән очрашабыз. Җинаятьләр эшләнә, кан коела—ләкин җинаятьчеләрне фаш итү омтылышы юк. Аларнын кем булуы да яшерелмәгән. Чөнки язучы мондый максат куймый. Ул туктаусыз үтереш, акча өчен көрәш, кан коеш, үч алу, куркыту, дустынны сату кебек хәлләрнен җәмгыятьтә нормага әверелүен күрсәтә.

Җәмгыятьтәге явызлык трилогиянен үзәк мотивы. Советтан сонгы тарихи чынбарлыкнын гариплеген язучы абсурд чигенә житкереп ачарга омтыла. Мондый тормышка көрәшчеләр һәм геройлар әлеге явызлыкны тудыручыларга,

кубәйтүчеләргә; гөнаһсызлар корбанга әвереләләр. Биредә унай як—авторның шушы җәмгыятькә мөнәсәбәте, тәнкыйте, укучыны шушы хәлләрне акыл аша уздырып, уйланырга чакыруы, гөнаһсыз корбаннар өчен сызлануы.

Трилогиянең һәр романы бер-берсенә якын структурада иҗат ителгән. Сюжет-композициясе, кулланылган алымнар җәһәтеннән дә охшашлыклар җитәрлек.

«Тәүбә»нең сюжет-композиция бирелеше традицион роман калыбын саклый. Ике төп сюжет сызыгы да язучының җәмгыятькә сатирик-ирониялe мөнәсәбәтен алга чыгарырлык итеп уйланылган. Беренчесе Сәет һәм тирәлек каршылыгына корылган. Романның буеннан-буена Сәетнең тирәлек белән катлаулы мөнәсәбәтләрдә узган тормышы сөйләнелә. Каршылыкның бер ягында җәмгыять түгел, бәлки тирәлек булу әсәрнең үзендә берничә тапкыр искәртелә. Язучы кешеләрнең катламсыйныфларга аерылуын даими ассызыклый (мәсәлән, Әхмәдиша карт Сәет егетләренә сыйныфташлар дип эндәшә), шушындый катламнарның берсе—күпләп акча эшләү юлына аяк басучылар дөньясы игътибар үзәгенә куела.

Икенче төп сюжет сызыгы—Сәет белән Зөлфия мәхәббәте тарихы. Ул Зөлфиянең үлеме белән тәгәлләнә, романның үзендә гөнаһсыз бала үтерелүе кебек шәрехләнә. Һәм әсәр башында ретроспекция алымы ярдәмендә сөйләнелгән, Сәетнең милициядән китүенә сәбәпче булган коедан табылган бала үлеме белән ассоциацияләнә. Фәридә баласына карата Сәет мондый сүзләр әйтә: «Нарасый баласының җанын алган анадан да явыз, җаһил кеше була алмый. Теләсә нинди ерткыч хайван, гомерен фида кылу исәбенә булса да, нәселен саклап кала...». Ә инде Зөлфия—«гөнаһсыз бала» үлеменнән соң мондый бәя урын ала: «Зөлфия өчен ул бары үзен битәрләде. Яраткан хатынына базны үзе казыды, упкынга үзе сикертте. Күндәм генә, баш иеп, берни булмагандай, тук тормыш белән, табигать ямена, ризык тәменә сокланып кына яшисе иде дә бит, Сәет булдыра алмады. Нәфесе җиңде». Димәк, гөнаһсызлар үлеменә гөнаһлыларның нәфесе, чикне узып китүе сәбәп, дигән нәтиҗә соралып тора. Әлеге сүзләр романның исеме белән чагыша. Кешеләрнең тәүбә чигенә җитүе, гөнаһсызларның каны коелу, кешенең ерткыч хайваннан да түбән хәлгә төшүе советтан соңгы чорга, җәмгыятькә бәя, иң олы тәнкыйть булып яңгырый. Романдагы бертуктаусыз үтереш, кан коешлар шушы фикергә иллюстрация булып килә. Аның сәбәбе—нәфес мәсьәләсе әсәр барышында берничә тапкыр калкып чыга. Мәсәлән, Әхмәдиша карт түбәндәге сүзләрне әйтә: «Нәфесне тыя белү—адәм баласының ихтыярын, башка җан ияләреннән үзгәлеген күрсәтүче төп ызан ул».

Романның үз эчендә җәмгыятькә тәнкыйди бәя берничә юнәлештә берьюлы алып барыла. Вакыйгалар катламы Сәетнең, Зөлфия белән танышканнан соң, элеккеге тормышын искә төшерүе кебек урнашкан. Милициядә эшләүче ирнең хакыйкать эзләүдә ныклык күрсәткән өчен эшеннән куылуы, ресторанда ишек төбе саклавы, мебель цехы ачып җибәрүе, ул тар-мар ителгәч, машиналар сату-алу, аннары корал, гашиш белән сәүдә, шушы җылы урынны учта тотар өчен, берниндн киртәләрдән дә тайчанмау—бу чылбырның буыннары. Язучы героеның нык ихтыярлы, көчле кеше булуына басым ясый, хәтта яшьлегенә кайтып, хәрби хезмәттә дә дөреслекне турыдан ярып әйткәне өчен җәза алуын искәрә. Ләкин бу хатирәләр ирнең башкисәр, кан коючы булуын аклый алмый. Әсәр шәхес хакындагы гуманистик, бигрәк тә совет әдәбиятында күпертелгән мифны җимерә, юкка чыгара, кеше күңелендә, аңында явызлыкның бик тирәндә ятуын билгели. Герой ярдәмендә совет әдәбияты белән "уйнау" чаткылары бар: Сәетнең хәрби хезмәттә, милициядә хакыйкать сакчысы кебек бирелеше татар совет әдәбиятындагы унай геройга охшаш. Шушы «сакчы»ның постсовет җәмгыятендәге әхлакый монстр белән бер үк кеше икәнлеген аңлау, ике төп сюжет сызыгында аларның капма-каршы: эстет һәм үтерүче буларак тасвирлануы кешенең аң төпкелендә ятучы кара көчләр турындагы—берниндн идеологик лозунглар ярдәмендә кешенең асылын битлек белән алыштырып булмау хакындагы—язучы фәлсәфәсен тирәнәйтеп килә.

Сәет образында унай һәм тискәре яклар бер-берсен дәвам итеп, тоташып китә. Үзендәге үзгәрешне язучы геройның авызыннан, хәрби училищеда булган хәлләргә

бәйле аңлата: «Шунда безнең илдә дөресен сөйләгән, хакыйкатьне ярып салган кешегә яшәү юклыгын, сәясәтнең пычрак нәрсә, көчленең кулында курчак фәхеш икәнлеген аңладым. Политикадан читкә киттем. Митингларның, урамда азатлык, бәйсезлек дип кычкырып йөрүләрнең файдасыз, киләчәксез нәрсә икәнен күптәннән аңладым. Көчленеке замана». Ләкин бу сүзләр бер сорауны ачык калдыра: Сәетнең хакыйкатькә төшенүе аның, идеология тарафыннан кидерелгән битлеген салып, асылына кайтуы булганмы, әллә киресенчә, үз асылын яшереп, заманча битлек сайлавымы? Җәүдәт белән сөйләшүдә язучы Сәеттән «кыйблам—йөгәнсез җил, җилнең төсе юк» дип әйттерә. Бу да—сорауның һавада эленеп калуына бер дәлил. Күрәсең, җавапны һәр укучы үзе табарга тиеш.

Тәнкыйди караш язучы—укучы сөйләшүендә дә урын ала. Укучының игътибарын махсус юнәлтергә теләгәндәй, язучы турыдан-туры «гаделсез хәятны, тәртипсез яшәешне, нурсыз җәмгыятьне каһәрләп...» кебегрәк гыйбарәләргә мөрәҗәгать итә. Илдәге иҗтимагый-сәяси үзгәрешләргә аналитик, әсәр тукымасына публицистик «ямау» кебек килеп кергән бәяләр дә романның буеннан-буена сызылып бара. Ләкин иң әһәмиятлесе: җәмгыятьтәге гарип кануннар аерым бер геройлар төшенгән хакыйкать төсендә билгеләнә, күрсәтелә.

Ә ирония әсәрдә сурәтләнгән тормыш кыйммәтләренең үзгәрүен ачуга хезмәт итә. Ул, бигрәк тә, геройлар монолог-диалогларының автор мөнәсәбәте белән каршылыкка керүендә аермачык күренә, әсәрнең укучы белән «гәпләшеп», укучыга ниндидер «тарихлар» сөйләп тулылануында чагылыш таба. Автор еш кына соңрак булачак хәлләрне хәбәр итеп, ә «хәзерге»дән нәтиҗә ясап бара. Мәсәлән, ресторанда эшләгәндәге вакыйгалар хакындагы икенче бүлекчәдә Мансур—Сәет («Соңрак Мансур олы даирәләр белән аралаша, ресторанны сатып ала, хөкүмәт малына чыгу юлларын таба. Мәгәр ике тәкә, барыбер, тар басмада очрашырга тиеш булалар киләчәктә») һәм Салих—Сәет («Киләчәктә бу адәм белән юллары гел орынып, кисешеп, мәнфәгатьләре якынаеп барасын, дуслар ук булмасалар да, бер-берсенә кирәкле кишер яфраклары булып китәселәрен белмиләр иде әле алар. Кеше әүлия дә, күрәзәче дә түгел») мөнәсәбәтләренең алга таба ничек үсәчәге ачыклап кителә. Җиденче бүлекчәдә Сәет—Җәүдәт мөнәсәбәтләренең дәвамы искәртелә: «Беренче очрашуда туа алмаган җылылык Казанда күрә алмауга, ачыктан-ачык дошманлыкка күчте». Хәтта әсәрдә үзәк урыннарның берсен алып торган мәхәббәт тарихының ахыры да алдан ук укучыга белдерелә: «Мәгәр Сәет тә, Зөлфия дә үзләрен ни-нәрсә көтәсен, гомергә бер бирелә торган сәгадәт мизгелләренең озакка бармасыннан хәбәрдар түгел иделәр. Үзе үк хезмәт иткән кара шайтан, явыз мәкер аны хәятта иң якын, иң газиз кешесеннән аерып алырга, канлы сугыш юлына чыгарырга тиеш иде. Тәкъдир китабына шулай язылган».

Әсәрдә, аерым бер гыйбарәләр белән уйнау да ирония хасил итә. Шундыйларның берсе—игелек сүзе. Ул—Сәет җитәкләгән ширкәт исеме. Әхмәдиша карт күршесендәге әбине күчереп утырту хакында сөйләгәндә, язучы аны текстка болай кертә: «Үҗәт карчыкны кысрыклап чыгару максатын да яшермәделәр игелекле күршеләре». Һәм алар эшләгән «игелекләр» тасвирлана: этне ату, тавыкларны ату, әбигә көпшә юнәлтү һ. б. Нәтиҗәдә, "яхшылык" һәм "явызлык" төшенчәләренең бер-берсенә тоташу, керешү, бер-берсен алыштыру мөмкинлеге туа.

Романда интертекстуальлек көчле булып, еш кына язучы шуның ярдәмендә әдәби сурәтне тирәнәйтүгә ирешә. Мәсәлән, Сәет белән Зөлфия шигырьләр аша сөйләшәләр. Дәрдмәнд һәм Тукай иҗатына алып киткән цитаталар бу мәхәббәтнең шагыйрьләр җырларлык булуын күрсәтә. Идеал дәрәҗәсендә сурәтләгән героинясын автор «Лолита кебек яшь, Наташа Ростова кебек саф, Нәфисәдәй тыгыз тәнле иде» дип белдерә... Нәтиҗәдә, Сәет һәм Зөлфия мәхәббәте, гомумән, тормышта һәм әдәбиятта булырга мөмкин иң югары хисләр үрнәге, шигырьләр исә шушы мәхәббәтнең хәзерге җәмгыятьтә нинди каршылыкларга очравын күрсәтү өчен кулланылган алым кебек кабул ителә. Матурлык, сафлык бары тик шушы сөюдә генә табыла дип раслый әсәр һәм шушы фикер җәмгыятьтәге, кешеләр арасындагы начар мөнәсәбәтләргә, җылы урын өчен көрәштәге хыянәт, үтереш, пычраклыкка каршы

куела. Бу антиномия тел чаралары ярдәмендә көчәйтелә. Сәет-Зөлфия хисләре, тормышы хакында сөйли башладымы, язучының теле матур-нәфис, зәвыклы; ә инде башка барлык хәл-күренешләр тупас, кайчак натуралистик элементлар белән баетылган сөйләм аша тасвирлана. Үз чиратында, язучы тарафыннан идеал дәрәҗәсенә житкерелгән мәхәббәт ярдәмче геройларның берсе—Сәнгать күзлегеннән бөтенләй бүтәнчә күренә. «Кара син аны, паханны, нинди яшь кызны, гүзәл сынны кулга төшергән бит. Кеше өчен ясак түләп, төрмәләрдә черемәгән шул ул. Баеп яткан! Акча, байлык һәр нәрсәне хәл итә. Кара «Волга»ны күрүгә, кызларның күзе-башы агуланган балыкныкы төсле мингерәүләнә».

Беренче романда табылган үзенчәлекле сыйфатлар икенче, өченче әсәрләрдә дә калку билгеләнә. «Элмәк»—Сәетнең яралардан дәваланып ятуыннан алып Ваһапов оештырган һөҗүмгә кадәр араны колачлый, шулай ук ретроспекция ярдәмендә ир тормышындагы ике-өч ел вакытны күздән кичерә. Монда да бала—корбан мотивы әйдәп бара. Ул—Фәриданең Сәеттән табарга җыенган баласы.

Соңгы роман исә «Төнге юллар» дип атала һәм язучы үз героен үлемгә китереп житкерә. Сәетнең нәни баласы—яңа туган улы Искәндәр—ятим кала.

Һәр романда да исем үзенчәлекле символ булып килә. Соңгы романда уңышлы файдаланылган аллегорик образлар—җил, ай, көзге яфраклар вакыйгаларны матур бәяли. Романнан-романга фикер үсеше, мәгънә тирәнәю, иҗтимагый яссылыктан гомумкешелек кыйммәтләре хакында уйлануга күчә бару да олыгая һәм үзгәрә баручы Сәетнең халәтенә аваздаш. Язучы әкренләп укучыны Сәеткә теләктәшлек ноктасына алып бара. Әйе, тирәлекне, заманны, җәмгыятьне һәм кешенең үзен гаепләүче, тәнкыйтьләүче авторның Сәеткә каршы куярлык идеаль герое юк. Мондый мохиттә ул була да алмый. Автор киресен расласа, укучысын ышандыра алмас иде. Шушы факт өч романны берләштерүче борчылуның төп сәбәбе булып тора.

Әсәрдә мажаралы жанрның күп кенә шартлары үтәлә. Сюжеттагы үтерешләр, серләр, аларның кинәт ачылып китүе, беренче-икенче китапларның серле-билгесез ноктада тәгәлләнүе, кеше ышанмаслык очраклылыклар мажара ятратучы укучыны үз чаралары белән жәлеп итә. Ләкин ике төрле укучыны күздә тотып иҗат итү, сатирик-ироник концепциянең беренчеллеге, күнегелгән кыйммәтләрнең җимерелүен сурәтләү, янәшә тора алмаган күренеш-сыйфатларны тоташтыру һ. б. үзенчәлекләр Т. Н. Галиуллин трилогиясен гади мажаралылыктан алып китә, татар әдәбияты өчен яңа, ят алымнар күпләп кулланылган иҗат буларак бәяләү юлларын эзләргә мәжбүр итә. Әлеге алымнар әдәби әсәрдә тудырылган тормыш моделен бозмый, язучы концепциясен тулы килеш укучыга житкерергә ярдәм итә. Укучы исә бу әсәрләрне мажаралы планда да, интеллектуаль уен, язучы белән сөйләшү кебек тә кабул итә ала. Иң мөһиме шул: XX гасыр татар әдәбияты хакында сүз алып барганда, бу романнарны читләп үтү мөмкин түгел—алар чор сәнгатенең үзенчәлеген билгеләүче, милли әдәбияттагы үзгәрешләрне әйдәп баручы әсәрләр булды.

Хикәя һәм роман жанрларында каләм сынаганнан соң 2004 елны Т. Галиуллин «Мәкер» повестен бастырып, традицион юнәлешнең дә үзе өчен чит түгеллеген раслады. Олыгайган, тормыш юлын кичкән кешенең, беренче мәхәббәтен кабат очратып, яшьлегенә «әйләнеп кайтуы», егет һәм кыз язмышын, чынлап торып туарга өлгермәгән гаиләне җимергән хәлләргә кабат күз ташлау һ. б. вакыйгалар аша уйланылган әсәр сентименталь рухлы. Әмирнең, гашыйк булып, инде бәхеткә ирештем дигәндә генә, кеше сүзенә, әсәр исеменә чыгарылганча, көнчеләр мәкеренә юлыгып, хата эшләве хакында сөйләп, автор әхлакый нәтиҗәләр чыгара һәм милли әдәбият өчен табигый булган әхлак проблемалары хакында сөйләшүгә укучыны да тарта. Вакыйгаларның Әмир исеменнән, аның искә төшерүе кебек хикәяләнүе аларны үкенеч ноктасыннан, инде хата кылганлыгын аңлаган кеше позициясеннән шәрехли, шуңа да повесть якты сагыш, үкенеч хисләре белән сугарылган. Мәхәббәтнең матурлыгы, ышаныч-өметләр җимерелүнең ачысы укучыны да тетрәндерә. Сәвия һәм Әмир образларының тулы характерлар буларак ачылуы аларны аклау, ә мәкер кылган—ялган гайбәт сөйләгән—Ленарны гаепләү ноктасына алып килә. Ленарның

да, мәхәббәтне җимереп, үз бәхетен кора алмавы, тормышын фаҗигале төгәлләве әхлакый бәяне тирәнәйтә. Шуның белән бергә язучы фәлсәфи гомумиләштерү ясый—Сәвия исеменнән әсәр ахырында болай дип әйттерә: «Җир йөзендә бит әле үз мәхәббәтен бөтенләй тапмаган кешеләр дә була. Без алардан бәхетлерәк». Бу сүзләр мәхәббәт кичерә алуның, аны югалткан очракта да, кеше өчен иң кадерле һәм мөһим хасият, кыйммәт булуын ассызыклый.

Талантлы кеше һәр өлкәдә талантлы була, ди безнең халкыбыз. Чыннан да, галим, тәнкыйтьче, педагог һәм җитәкчелек осталыгына ия Тәлгат Нәби улы Галиуллинның гасыр ахырында күпме бәхәсләр һәм кызыксыну уяткан романнар язарга керешүе, прозаның барлык жанрларын иңләп алуы үзе үк аның шәхес буларак күзәтүчән һәм кызыклы, рухи яктан бай, нечкә психолог икәнлеге хакында сөйли. Т. Галиуллинның әдәбият белеме өлкәсенә караган гыйльми хезмәтләре заман ихтыяҗларына җавап биреп, фәннең бүгенге торышын исәпкә алып язылган булса, әдәби иҗаты да милли әдәбиятка заман сулышын алып килде, XX гасыр ахыры китереп чыгарган психологик һәм иҗтимагый катаклизмнарны, кеше турындагы күзаллауларның үзгәрүен хәбәр итте.

Т. Галиуллин—тормышта да, фәндә дә киң карашлы, вакланмый, алдан, еракны күреп эш йөртә торган кеше. Үз укучылары гыйльми хезмәтләренең нигезен, концепциясен билгеләгәндә дә, яклау советында башка җитәкчелектә язылган хезмәтләр якланганда да, аның шушы үзенчәлегенә—эшнең үзәгенә күз ташлау, ахыргы максатын бик төгәл билгели алу, булачак нәтиҗәләрне алдан ук ачыклау сәләтенә сокланмый мөмкин түгел.

XX гасыр башында да, XX-XX1 гасыр чигендә дә татар янарышын, милли фикер күтәрелешен аерым шәхесләр,үзенең яшәү мәгънәсен милләткә хезмәт итүдә күргән татар зыялылары әзерләде. Тәлгат Нәбиевич шуларның берсе: халкыбызның уллары һәм кызлары мәйданнарда «Азатлык!» сүзен яңгыратканда студентлары белән мәйданнарга чыккан профессор милләт өчен, татар телен саклап калу, татар әдәбиятын һәм сәнгатен үстерү өчен бүген дә әллә никадәр эшләр башкара. Тынгысыз, эзләнүчән, кыю шәхес буларак, татар матбугаты битләрендә һәрчак саллы, проблемалар күтәргән язмалары белән чыгышлар ясый, Татарстаннан читтә яшәгән милләттәшләре белән аралаша, сөйли, борчыла, тыңлаучыларны матур тавышы, аһәңе, гадәти булмаган фикере белән сихерли. Ул һәрчак алга омтыла, һәрчак тирә-юньдәгеләр өчен яңа юллар сыза, киләчәккә—ераккa карап эш йөртә.

Гомерен татар халкына хезмәткә багышлаган, Татарстандагы югары белем бирү һәм фән, әдәбият тарихына исеме алтын хәрефләр белән уелган Тәлгат Нәбиевич шушы көннәрдә үзенең матур юбилеен билгеләп үтә. Күпсанлы укучылары, ул юл күрсәткән шәкертләр исеменнән аны олы бәйрәме белән котлап, уйлаганнары тормышка ашуын, сәламәтлек һәм күңел көрлеге, яңа үрләр, яңа сөенечләр, яңа китаплар телим!

Рашат
Низами

# АУЧЫ. ШАГЫЙРЬ. ГУМАНИСТ.

*Иркен Төмән!*
*Моңсу Төмән!*
*Юмарт Төмән!*
Шәүкәт Галелша.

Мин Себерне үземчә яртысы гына беләм дип саный идем. Чөнки, сәфәрем төшеп, бу якларда өч-дүрт тапкыр булганым бар. Енисей, Тобол елгаларында колач салып йөзгән чаклар да булды. Тайга уртасында—яна оешып килгән Туртас поселогы. Заманында бирердә без, шабашкага чыккан студентлар, агачтан фин йортлары салдык. Сазлыклар, әкияти-серле тайга, бармак башы тикле эре черкиләр әле дә булса хәтердә. Безгә арзан гына бәягә, ау мылтыгы һәм идәнгә җәешле аю тиресе тәкъдим итүчеләр дә булды. Ни кызганыч: студентның кесә ягы такыр иде шул...



Ниһаять, мин Себерне үзем өчен өр-яңадан ачтым!

Бу хәл Себер татары, Төмән өлкәсендә туып-үскән шагыйрь Шәүкәт Гаделшаның "Аучы жыры" дигән китабы белән танышканнан соң булды. *(Казан. Татарстан китап нәшрияты. 2004 ел.)* Китап саллы, күләмле, ул сайланма әсәрләр рәвешендә тәкъдим ителгән.

Кем соң ул Шәүкәт? Аның шигъриятенең төп үзенчәлекләре нәрсәдә? Мин шушы сорауларга жавап табарга телим...

Сүзне китапның исеменә үк бирелгән "Аучы жыры" шигыреннән башлап китәсе килә. Күңелнең эчке кичерешләренә, шуның нигезендәге конфликтка корылган бу шигырь нәни бер поэма кебегрәк укыла. Сюжеты бик гади: сунарчы егет сөйгәненең туган көненә сусар (куница) мехыннан "көмеш бүрек" бүләк итмәкче була. Әгәр шуны эшләми икән, кыз аның мәхәббәтеннән баш тартачак... Сөюеннән исергән егет төнгә чаклы эзли сусарны, уйлана-газаплана торгач, ахыр чиктә ул аны карурманга "бүләк" итеп калдыра һәм вәгъдә бирә:

*Озатып бар*
*Син алдымнан.*
*Сиңа бер дә*
*Мин кагылмам.*

Урман сусары белән әнә шулай дусларча, кешелекле саубуллаша егет. Аның бу сыйфатына ничек инде сокланмыйсың ди!

Гомумән, аучы образы шигырьдән шигырьгә үстерелә, яңа бизәкләр белән баетыла. Икенче бер шигырьдә без аучының "йөз яшьлек" (!) икәнлеген дә беләбез...

Әкиятләргә кергән болан образы да китапның буеннан-буена диярлек укучыны "озата" бара. Ул- моңсу да, гамьле дә, горур да, ачулы да. Ә нигә, без—кешеләр—үзебез дә әнә шундый кавемнән түгелмени?

Ярык мөгезле ата болан, ана боланның чакыру авазын куып тоталмыйча, арып егыла... Чып-чын фажига лабаса! Автор, әнә шушы "үгез хәлендә" мин дип, тирән гомумиләштерү ясый.

Шунысы гажәп: Шәүкәт һәр вакыйгага һәм күренешләрнең уртасына, ягъни асылына өермәдәй үтәли узып керә, аны үзенә генә хас телбизәкләр белән сурәтләп, үзенең янача шигъри дөньясын тудыра. Ул берәүгә дә охшамаган. Аның дөньясы

кин, колачлы: бөҗәкләрдән алып йолдызларга кадәр...

Образлы фикер йөртү, метафоралар һәм чынбарлыктагы детальләр белән оста эш итү аның һәр шигырен диярлек бизәп тора. Шулай әйтергә яраса, ул үзенең остаханәсендә, фанатик бер галим сыман, янадан-яна ачышлар ясый. Фикеребезне ныгыту өчен, кайбер мисалларга мөрәҗәгать итик:

*И зәңгәр күк,*
*Чәчәк булып коел әле!*

*...Үрләр артында*
*Тук боланнар күкне сөздер.*

*Тал очында уйный йодрык—*
*Кош калдырган кара оя.*

*Үле тынлык. Кар ыңгыраша.*
*Шундый куркыныч!*

*Кара карга күкрәге*
*Күзге булып ялтырый.*

*Кояш та, ай да бит*
*Тез кебек түгәрәк. һ. б.*

*Кояш әле бик түбәндә—*
*Кашы гына күренә.*

Житеп торыр булмаса. Күтелмәгән тәэссоратларның муллыгын исбатлап торасы юк бу очракта. Тагын да мөһиме—алар кырыс яисә акварель сурәт булып шундук истә калалар.

Шәүкәтнең дөньясы (шигъри генә микән?) кин, колачлы. Аның иҗаты белән танышканда кемнәрне, ни-нәрсәләрне генә очратмыйсың: тукран, карчыга, кыр үрдәге, торна, аккош, саескан, сыерчык, чуртан, поши, аю, селәүсен, төлке, елан, нарат, карагай һәм башкалар. Алар гади бер рәсем генә түгел, фәлсәфә нуры белән өретелгән әдәби образ-сурәтләр.

Менә гап-гади бер кош—тукран. Ул әле бер, әле икенче агачны бик тырышып-дәртләнеп чукый. Лирик герой сөйгәнен көтеп тилмерә, аның хәле мөшкел:

*Нигә соң килми ул,*
*Нигә һаман*
*Ялгыз утырам?*
*Агачларны түгел,*
*Йөрәгемне*
*Чукый тукран.*

Шәүкәт Гаделша—чын табигать баласы. Аның бу сыйфаты иҗатында тулаем чагыла, һәр шигыреннән диярлек саркылып тора. Табигатьне ул җаны-тәне белән кабул итә, шигъри күзләр белән ярата. Моны ул үзе дә таный һәм курыкмыйча әйтеп тә бирә:

*Эт шикелле өрә белөм,*
*Карчыга күк күрә беләм...*

Тагын шунысын да әйтик, табигать җырчысы Пришвин сыман, коеп куйган натуралист кына түгел шагыйребез. Табигатьнең гап-гади күренешләреннән ул тормыш-яшәешебездәге актуаль проблемаларына кадәр күтәрелә, зур гомумиләштерүләр ясый. Аның яшәү формуласы шактый кырыс һәм усал:

*Чак кына аңлый алсам мин*
*Үлән, агачлар телен,*
*Миңа ары яшәр өчен*
*Кешеләр кирәк түгел.*

Табигатьне ярату гына җитми, кирәксә аны төрле рәнҗетүләрдән яклый белергә дә кирәк. Бу җәһәттән "Поши ите" дигән шигырь аеруча характерлы. Авылдашлары поши аткан: "табада да, өстәлдә дә поши ите"... Олысы да, кечесе дә малайны сыйланырга кыстыйлар. Ул ашарга кыенсына, тискәре сүзләр белән үзенчә бунт күтәрә! Шигырьнең азагы исә гыйбрәтле гуманизм белән тәмамлана:

*Поши ауган урыннарда*
*Үсеп чыга сары чәчәк.*
*Шул чәчәкне таптаганны*
*Яшен сугып үтерәчәк...*

Ш. Галелша иҗатындагы тагын бер үзенчәлеккә игътибар итик: әсәрләрендә ике агым кушылып китә, синтезлаша—реаль чынбарлык һәм автор фантазиясе. Менә шушынардан еш кына төрле балкыштагы гаҗәеп фантасмагория барлыкка килә! Моны шулай ук күп кенә мисаллар белән ныгытырга, расларга мөмкин.

"Таңын ауда азан ишеттем" шигыре кӧтелмәгән яклары белән сискәндерә. Бу исәр сунарчының гамендә ау кайгысы түгел, дөнья кайгысы! Төз чыршыларны ул мәчет манарасы итеп күрә. Өстәвенә, беркем дә тоймастай кичерешләр дулкынында йөзә:

*Серле эңгерлеккә чумган*
*Куакларны, ботакларны*
*Коръәндәге хәрефләргә,*
*Сүрәләргә охшатамын.*

Юк, эш моның белән генә бетми әле. Лирик герой шушы күзәтүләреннән тагын да югарырак баскычка күтәрелә: тумышыннан надан, денсез иканлегенә нәфрәте кузгала, мылтыгын җиргә сугып ватмак була. Ә үзе, бүре баласыдай, һаман әле караңгылыкка карый...

Чыннан да, кеше күнеле—карурман!

Шәүкәтнең дүрт-биш иҗекле калыпка көйләнгән шигырьләре чичәннәр сөйләменә охшаш. Сюжетлы шигырьләре барлыгын да билгеләп үтик. Аның байтак кына шигырьләре балладага тартым. Әмма автор тыйнаклык күрсәткәнме, китапта "баллада" дигән сүзне бер дә очратмадым.

Шагыйрь бик күп шигырьләренә истә калырдай кабатланмас исемнәр куша белгән. Әйтик, шундыйлардан: "Каен—яшел шар", "Көнем—упкын", "Балыкчы хатын", "Черкине сагынам", "Аю хәлендә калам", "Чалдун теле"...

Чалдун димәктән, бу сүз җирле сөйләштә "Себер татары" дигәнне аңлата. Гомумән, үзенең шигырьләрендә Шәүкәт Себер татарлары теленә генә хас диалект сүзләрне бик иркен һәм кыю куллана: чәрәгәй, марта, серәнкә, хорей, кучкер, яртыясак, агун, чәпче һәм башкалар. Контекста алар ансат аңлашыла.

Язганнарымнан, Шәүкәт Галелша гел табигать турында гына яза икән, дип аңлашылмасын. Ул тарихи темаларга да еш мөрәҗәгать итә һәм безне Күчем хан, Ермак яшәгән дәверләргә йолкып алып кер. Бүгенге көннең "мескенлеге" хакында чаң кага:

*Атларны чүктерел атланыр*
*Берәр ир Себердә калдымы?*

Мин бу темага сүзне озайтырга җыенмыйм. Чөнки китапка кереш сүз язган күренекле шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов әлеге буразнаны тирәннән ерып чыккан. Кабатланасым килми. Р. Әхмәтҗанов үзенең әдәби мәкаләсен болай дип тәмамлый:

"Шәүкәт Галелшаның шигърияте легендалар вә дастаннар иле—Себернең җир-суына, урман-кулләренә, киек-җәнлек дөньясына, ырулары рухына Шигъри Дога булып ишетелә!"

Бу мәкаләмдә мин дә нәкъ менә шул хакта сөйләргә тырыштым түгелме? Шөкер, безнең фикерләр тәңгәл, авазлаш икән.

Әйе, шагыйрь Себер киңлекләрен, аның күпкырлы хәятын киң полотналы манзара рәвешендә укучыга ачып бирә. Барысын күздә тоткан хәлдә, мин моны бер дә икеләнмичә Шәүкәт Галелша феномены дип атар идем. Шуна да бу каләм әһеленең үзен "Мин—хан!" дип игълан итүен "аңларга" да мөмкин. Юк, Шәүкәт, "Мин Себеремне яратам!" дип шау килми, сөрән салмый. Купшы сүзләрдән ерак ул. Ләкин аның туган ягына булган хөрмәте-мәхәббәте-горурлыгы иҗатыннан саф чишмә суыдай һәрдаим челтерәп, саркылып тора.

Заманында Салисә Гәрәева "Уралым" дигән шигырьләр җыентыгын бастырып чыгарган иде. Ул да әнә шулай үзенчәлекле итеп безгә Урал-тау образын ачып биргән иде...

Укучы: "Нәрсә Ш. Галелшаның шигырьләрендә кимчелекләр бер дә юкмени?"—

дип сорарга мөмкин. Бар барын, ләкин болар, минем уйлавымча, вак-төяк кенә. Мәсәлән, кайбер шигырьләрендә "караштыргала-каршыларга" кебек кытыршы, уңышсыз рифмалар да очрап куя. Аерым шигырьләрендә ритм ягы аксаган урыннар да юк түгел. Шикмәнмим, киләчәктә ул боларга игътибар итәчәктер.

Шагыйрь Шәүкәт Гаделшаның төп үзенчәлеге нәрсәдә? дигән сорауга мин үземчә җавап таптым шикелле.

Көтелмәгән шигъри ачышлар. Драматизм. Каршылыклы, киеренке хисләр гармониясе. Кырыс матурлык, чынбарлык. Фәлсәфи-лирик агым. Авыр чакларда да рухын төшермәгән бунтар шәхес...

Бер сүз белән әйткәндә, Ш. Гаделша шигъриятенең төп үзенчәлеге—аның кабатланмас шагыйрь булуында икән.

Моңлы сазын кулыңнан төшмәсен, шагыйрь дустыбыз!

Язмамны Ш. Гаделшаның иҗатына хас бер шигыре белән тәгәллим.

## Чалдун теле

*Юк. Көлкеле, мескен түгел*
*Чалдун анамның теле.*
*Ул бит татар телебезнең*
*Иң серле, моңлы куле.*

*Ничек аны сай дип әйтим—*
*Төбенә җиткәнем юк.*
*Ничек аны тар дип әйтим, -*
*Ярыннан үткәнем юк.*

*Кайтсам—аның бәпкәсе мин, -*
*Туп-туры чумам, йөзәм.*
*Табигатькә, борынгылыкка*
*Якынаюны сизәм.*

*Эчәм, эчәм—эчкән саен*
*Сусавым арта бара.*
*Күзләр, йөзем, күкрәкләрем*
*Монда купчеп кабара.*

*Тыңлап телнең яңгырашын*
*Тәмләп елап аламын.*
*Фәрештәләр монда гына*
*Чайкыйлардыр тамагын.*

*...Ничек мескен булсын*
*Теле чалдун анамның.*
*Кул корыса Себеремдә,*
*Сүнәр теле татарның.*

Фәридә
Гаффарова

# САДРИ МАКСУДИ АРСАЛ

Садри Максуди (Садретдин Низаметдин улы Максудов) 1878 елның 23 июлендә (иске стиль белән) Казан өязе Ташсу авылында (хәзерге Биектау районына керә) Низаметдин мулла гаиләсендә дөньяга килә.



Бу гаиләдә белемгә омтылыш көчле була, чөнки үз заманының шактый укымышлы кешесе буларак, Низаметдин мулла Төркиядән төрле газета-журналлар, китаплар кайтарткалап торган. Шуннан кайткан төрек әлифбасыннан Садри укырга өйрәнә. Ул башта үз авыллары мәдрәсәсендә—әтисендә укый, аннан Казанда абыйсы Әхмәтһади мөгаллимлек иткән "Галләмия" мәдрәсәсендә белем ала. Биредә ул сигез ел буена төрек, гарәп, фарсы телләрен, ислам фәлсәфәсен, дин белемнәрен өйрәнә.

Садриның аннан ун яшькә өлкәнрәк абыйсы Әхмәдһади Максуди төрки дөньяда танылган "Тәрҗеман" газетасын чыгара башлап, үз газетасы битләрендә төрки халыкларда миллият хисләрен уятучы беренче орлыкларны чәчәргә керешкән атаклы Исмәгыйль бәк Гаспринский белән дустанә мөнәсәбәттә була. 1893 елны И. Гаспринский аны Бакчасарайга Зынҗырлы мәдрәсәсенә укытучы итеп чакыргач, Һади Максуди шатланып риза була һәм үзенә ияртеп энесе Садретдинне дә Кырымга алып китә. Биредә Садри төрек телен, тарих, география, табигать белемен өйрәнә. Садретдиннең Кырымга килүе һәм анда Исмәгыйль бәк Гаспринский белән танышуы—яшь егетнең киләчәгенә төп юлны билгеләгән һәм аның тормышында иң зур әһәмияткә ия вакыйга.

Яшүсмер Садри үзенең яшьтәшләренә караганда укымышлырак була. Нәкъ менә шушы ягы белән ул Исмәгыйль бәкнең игътибарын җәлеп итә. Ә яшь Садрига аның бер фикере ошый: төрки халыкларның берлеге, бердәмлеге турындагы фикер. И. Гаспринский, һәр форсаттан файдаланып, бөтен төрки халыкларның бер гаилә, ягъни Кырым һәм Казан татарларының, башкорт, кыргызларның бертуган булуы, христиан динендәге чуашларның да, шаман якутларның да бер төрки гаилә әгъзалары икәнлекләрен Садрига җентекләп аңлата. Шул ук вакытта ул Казан татарларының иң мәдәниятле халык буларак үзләрен башкалардан югары тотуларын, өстен куюларын тәнкыйть итеп, ачынып сөйли, яшь Садрига бөтен төрки халыклар бергәләп кенә тәрәккыять юлында уңышларга ирешә алачагын аңлатырга тырыша.

Бер елга якын аралашып яшәүнең файдасы тия: яшь Садри Максуди төрки бердәмлек, халык язмышы турында уйлана башлый. Анарда бөек төркиче Исмәгыйль бәк Гаспринскийга карата тирән ихтирам һәм аркадашлык хисләре уяна. һәм, еллар узгач, ул тормышының һәр хәлиткеч борылышында аның милләт хисе һәм төрки бердәмлек турындагы сүзләрен исенә төшерә, кызы Гадилә Айда әйтүенчә, "Минем рухи атам—Исмәгыйль, бәк Гаспринский" дия торган була.

Ләкин Зынҗырлы мәдрәсәсендә белем эстәп яткан вакытта, 1894 елны

Фәридә ГАФФАРОВА (1951)—*галимә, тарих фәннәре кандидаты. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институтында (институт бүленгәч, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында) эшләде. Г. Исхакый, Һ. Максуди, С. Максуди һ.б. турында йөзгә якын фәнни мәкалә, 5 китап авторы. 2006 елны вафат.*

Ташсудан көнелсез хәбәр килә: аталары Низаметдин мулла авырып киткән. Агалы-энеле Максудилар Казанга кайтып китәргә мәҗбүр булалар.

Казанга кайткач, Садри "Галләмия" мәдрәсәсен тәмамлый һәм Укытучылар мәктәбенә (Учительская школага) укырга керә. Бирედә укыганда Садри тулысынча рус әдәбияты һәм рус теленә тәрҗемә ителгән фәнни әдәбият дөньясына чума. Үзе укыган рус романнары тәэсирендә чын татарча "Мәгыйшәт" исемле роман да яза. Ә бит С. Максудига бу вакытта бары тик 19 яшь кенә була.

Укытучылар мәктәбендә укыган елларда Садрида француз телен өйрәнү теләге туа. Үзе әсәрләнеп, мавыгып укыган әсәрләр, серле Париж Садри Максудида Франциягә барып уку теләген уята. Әмма ул бу уй-хисләрен хәтта абыйсы Һадидан да яшерә, чөнки аңа үзенең бу теләге тормышка ашмас хыял гына булып тоела. 1901 елны Укытучылар мәктәбен тәмамлагач, С. Максуди университетка кермәкче булып, Петербургка бара. Тик рус университетының ишекләре татар баласы өчен ябык була. Шуннан соң ул Ясная Полянага барып үзе һәр әсәрен яратып укыган һәм бик хөрмәт иткән Л. Н. Толстой белән очраша, анда бер көн була. С. Максуди үзенең Л. Н. Толстой белән очрашып-сөйләшеп уздырган вакытын "гомеренең иң гүзәл мизгеле"ннән саный. Аннан ул Кырымга китә, анда Исмәгыйль бәк Гаспринский белән күрешә, үзенең белемен дәвам итәр өчен Төркиягә китәргә теләвен әйтә. Әмма И. Гаспринский аңа ул вакытта Европа мәдәниятенең мәркәзе булган Парижга китәргә, укуын шунда дәвам итәргә киңәш бирә. Аның бу киңәшеннән соң күңеленең иң тирән җиренә яшерелгән Парижга барып уку теләге Садрида яңадан кабынып китә.

Французча бик начар белгән, акчасы, таныш-белешләре булмаган С. Максуди үзенең зирәклеге, тырышлыгы, чыдамлыгы аркасында бөтен авырлыкларны җиңеп, һәммәсенә түзеп, бер ел эчендә француз телен өйрәнеп, Парижның Сорбонна университетының хокук факультетына укырга керә һәм дүрт елда аны бетереп тә чыга. Франциядә узган еллар романтик рухлы С. Максуди күңелендә матур хатирәләр калдыра, чөнки ул анда үзенә гомерлек дуслар, фикердәшләр таба: Сорбонна университетының сәясәт мәктәбендә укучы Йосыф Акчура, Яхья Кемал (булачак төрек язучысы) һәм башкалар белән дуслаша, алар белән төрки халыкларның үткәне, киләчәге турында кайнар бәхәсләр алып бара.

Шушы 1902 елны, инде Парижга барып, урнашып, университетта укый башлагач, С. Максуди И. Гаспринскийдан хат ала, ул аңа тиздән "Тәрҗеман"ның чыга башлавына 20 ел булачагы турында яза.

Әлеге хаттан соң Садри бик уйланып йөри, аны бу уңай белән төрки халыклар арасында беренчеле хәзерлек эшләре дә алып барылмавына борчыла. "Әгәр бу хәл башка алдынгы милләтләрдә булса, бер юбилей үткәрерләр иде, ул милләт үзенең милләтпәрвәрләренә олы хөрмәт, ихтирам күрсәтер иде", дип көенә. Дусты Йосыф Акчура белән киңәшкәч, алар бу юбилей мөнәсәбәте белән Төркиядә һәм Россиядә яшәүче танылган зыялыларның И. Гаспринскийга хатлары рәвешендә бер китап чыгарырга уйлыйлар һәм, үзләренең теләк-киңәшләрен әйтеп, барлыгы йөздән артык кешегә хат язалар. Бу китапчык Россия төркиләре арасында И. Гаспринскийның "Тәрҗеман" газетасының 20 еллык юбилеен уздыру өчен нигез, бер этәргеч була. 1903 елда Бакчасарайда милләтсөярләрнең җыелышуы "бер милли конгресс рәвешен ала, төрле өлкәләрдән килгән төркиләр һәм Россия төркиләре өчен милли мәдәниятләрен үстерүдә, диннәрен, телләрен саклауда русларга каршы тору өчен бер киңәш мәҗлесе булды", дип яза С. Максуди үзе бу турыда соңыннан. Бу бәйрәмгә үзе кайта алмаса да, ул үзләренең әлеге юбилейны уздыруда этәргеч булулары белән бик горурлана.

1906 елны С. Максуди Сорбоннаны тәмамлап, юрист дипломы алып, милли хисләр белән тулып, үзен милләт тәрәккыятенә хезмәт итәргә хәзерләп, Россиягә кайта. Шушы елдан алып аның татар милләтенә фидакарьләрчә хезмәткә багышланган эшчәнлеге башлана.

1906 елның 16-20 августында Түбән Новгородта "Иттифак әл-мөслимин" партиясенең III съезды уздырыла һәм аның эшендә И. Гаспринский, Й. Акчураларның чакыруы буенча С. Максуди да катнаша, аның сәясәт комиссиясендә эшли, әлеге партиянең үзәк комитетына сайлана, партия тарафыннан аның кандидатурасы II Дәүләт думасына депутатлыкка тәкъдим ителә.

С. Максудиның, шулай итеп, 1907 елдан 1912 елга кадәр II-III Дәүләт думаларындагы депутат буларак эшчәнлеге, ягъни ил күләмендәге рәсми сәясәттәге эшчәнлеге башлана. II Думада ул президиум әгъзасы итеп, III Думада исә мөселман фракциясенең сәркәтибе итеп сайлана.

1907—1912 еллар—татар вакытлы матбугатында өзлексез кыйналуга,

тәнкыйтьләнүгә дә карамастан, III Думадагы сигез кешедән торган мөселман фракциясе һәм аның иң эшчән депутатларыннан булган С. Максудиның сәяси, милли эшчәнлегенең иң актив еллары. Ул II һәм III Дәүләт думалары утырышларында төрле закон проектлары каралганда татар һәм мөселман халыкларының хокукларын яклап барлыгы 15ләп, ә төрле комиссияләрдә исә 100дән артык чыгыш ясый. Бу чыгышларның барысы да диярлек рус газеталарында басылып бара һәм җәмәгатьчелектә киң яңгыраш ала. Аның Дума утырышларында ясаган һәр чыгышы вакыйгага әйләнә.

1912 елны IV Думага сайлауда күчемсез милке юк дигән сылтау белән С. Максуди кандидатурасы уздырылмый һәм шулай итеп III Думаның иң эшчән депутаты булган С. Максуди кандидатлар исемлегенә кертелми. Депутат булып сайланмаса да, ул Россия хөкүмәтенең милли сәясәтен татар милләтенә аңлату, житкерү буенча зур эш алып бара. Думада закон проектлары каралганда әлеге законның татар халкына, мөселман халыкларына файдасы барлыгын яки юклыгын җентекләп аңлаткан мәкаләләре "Йолдыз" газетасында һәрдаим басылып бара.

Утыз яшенә кадәр буйдак булып яшәгән С. Максудиның шәхси тормышында 1910 елда зур үзгәреш була: ул миллионер Шакир Рәмиевнең кызы Камиләгә өйләнә. Туйга татар дөньясының барлык танылган байлары, зыялылары чакырыла, бу вакыйга турында барлык татар газеталары да диярлек язып чыга.

Ул, туйдан соң, хатыны белән Петербургка китә, анда үзенең депутат буларак эшчәнлеген дәвам итә. 1912 елны аларның беренче кызлары Гадилә туа, ә 1914 елны икенче кызлары Наилә дөньяга килә. С. Максуди өчен бу еллар шәп еллар була: беренчедән, ул гаилә тормышы белән бик бәхетле булса, икенчедән, үзен бөтен көчен, сәләтен биреп милләтенә хезмәт итә алуы белән бәхетле саный.

Татар милләтенең иң бай промышленникларыннан булган Ш. Рәмиевнең кызына өйләнү С. Максудиның матди хәленә генә уңай тәэсир итеп калмый, аңа җәмгыятьтә берничә баскычка югарырак күтәрелергә дә ярдәм итә. Петербургта яшәгәндә алар шәһәрнең затлы нәселдән чыккан аксөякләре белән аралашып яшиләр.

С. Максуди белән Камилә ханым кырык җиде ел бергә тату, матур гомер итәләр, ике кыз үстерәләр. Гадилә исемле кызы—Төркиянең беренче хатын-кыз дипломаты, ул шактый еллар Голландия, Италия, Испания һ.б. илләрдә Төркиянең тулы вәкаләтле илчесе була. Соңыннан фән белән шөгыльләнә, әтисенең язылып бетмичә калган хезмәтләрен төгәлли, "Садри Максуди Арсал" дигән китабын яза.

С. Максудиның иң актив сәяси һәм милли эшчәнлеге 1917 елның Февраль революциясеннән соңгы чорга туры килә. Эчке Русия һәм Себер төрки-татарларының аның проекты буенча 1917 елның 22 июлендә игълан ителгән милли-мәдәни мохтарият, 1918 елның 13 апреленә кадәр генә яшәп калуына да карамастан, бәйсезлеген кабат торгызу теләген югалтмаган татар халкы өчен бу көннәр тарихка шанлы көннәр булып кереп кала. Милли-мәдәни мохтариятнең Уфада уздырылган Милли Мәҗлесендә С.Максуди Милли Идарә рәисе итеп сайлана. Милли-мәдәни мохтарият совет хакимияте декреты белән таратыла, С. Максуди чит илгә качарга мәҗбүр була.

1918—1923 елларда шушы милли-мәдәни мохтариятнең Милли Идарәсе рәисе буларак, ул Парижда уздырылган Тынычлык (Версаль) конференциясендә катнаша, төрле мәсьәләләргә багышланган җыелышларда чыгышлар ясый, белдерүләр белән чыга, ягъни Россиядән эмиграциягә китәргә мәҗбүр булган милләтләрнең милли оешмалары җитәкчеләре белән берлектә татар халкы исеменнән эш алып бара. С. Максуди 1923 елларга кадәр Россиядәге сәяси хәлләр үзгәрер дә илгә кире кайту мөмкинлеге туар дигән өмет, ышаныч белән яши.

Аңа Сорбонна университетында яңа ачылган төрки халыклар тарихы кафедрасында профессор урыны тәкъдим ителә һәм ул төрки халыклар, тарихы буенча лекцияләр курсы укый башлый. Бирелә С. Максуди француз телендә үзенең "Төрек расасының үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге" исемле хезмәтен яза. Төркиядә Республика игълан ителгәч, С. Максуди зур шатлык хисләре кичерә. 1924 елның җәендә "андагы үзгәрешләрне үз күзләре белән күрер өчен" Франциядән Төркиягә китә. Монда ул дусты Йосыф Акчура белән очраша. Әнкара һәм Истанбул университетларында төрки халыклар тарихы буенча берничә лекция укый.

Әнкарада ул Төркиянең хөкүмәт җитәкчесе Мостафа Кемал Ататөрек белән таныша, ә ул исә аны Төркиягә чакыра. Төркия хөкүмәтенең мәгариф министры Хәмдуллаһ Сәхби 1924 елның ахырларында яшь республикага хезмәт итәргә чакырып аңа рәсми хат җибәрә. С. Максуди 1925 елның башларында: "Анда мине тарихи хезмәтләр көтә" дип, Парижда инде көйләнеп барган тормышын,

Сорбонна университетындагы төрки халыклар тарихы кафедрасындагы мөдирлек һәм профессорлык эшен калдырып, бөтенләйгә Төркиягә күчеп китә һәм шул елдан башлап гомеренең соңгы көннәренә кадәр Төркия бу талантлы галимнең, сәясәтченең икенче Ватанына әйләнә.

Бик күп татар мөһаҗирләрен үзенә сыендырган, татар халкының Й. Акчура, Г. Баттал, Ф. Туктаров, Г. Исхакый, М. Бигиев, З. Вәлиди кебек асыл улларын кабул иткән төрек халкы С. Максудины да үз улы итеп таный.

С. Максуди Төркиягә килү белән Х. Сәхби житәкләгән милли мәгариф министрлыгына эшкә урнаша. Бераздан М. Кемал кушуы буенча яна гына төзелгән яшь республика өчен бик кирәкле кадрлар әзерләргә тиеш булачак Хокук мәктәбен оештыра һәм шунда ук моңарчы әле беркем тарафыннан да укытылмаган яңа фән—"Төрки хокук тарихы" фәнен укыта башлый. С. Максуди төрки хокук тарихы өлкәсендә ислам дине кабул ителгәнгә кадәр чордагы төрки җәмгыятьтәге хокук тәртибен өйрәнә һәм ике ел эчендә яңа фән—"Төрки хокук тарихы" фәненә нигез сала. 1928 елда аның беренче фундаменталь хезмәте—"Төрки хокук тарихы" басылып чыга һәм озак еллар буена студентлар өчен дәреслек булып хезмәт итә.

Биредә ул хокук бүлеге профессоры вазифасында 18 ел эшли, ә 1943 елдан Истанбул университетына күчә һәм озак еллар буе анда хокук тарихы укыта.

1928 елда Мостафа Кемал кушуы буенча Тел комиссиясе төзелә. Комиссия алдына төрек әлифбасын латин графикасына күчерү һәм төрек телен гарәп, фарсы сүзләреннән чистарту, алар урынына яңа төрек сүзләре ясау мәсьәләсен хәл итү бурычы куела. С. Максуди үзенең остазы итеп санаган И. Гаспринскийның төрки халыкларның бердәмлеге, берлеге идеясен яклый һәм барлык төрки халыклар өчен госманлы төрекләрнең телен уртак тел буларак күрә. Ул гарәп һәм фарсы сүзләре урынына төрек теленең үз эчендә яңа сүзләр ясау мөмкинлегеннән файдалану кирәклеге мәсьәләсен яклый һәм төрек халкының югары үскән фәнни теле булырга тиеш дип язып чыга ("Төрек юрду", 1928 ел). Тел комиссиясе тәкъдим иткән яңа әлифба белән килешмәгән С. Максуди "Миллият" газетасында (сентябрь, 1928 ел) "Телне реформалаштыру проблемасы" дигән озын мәкаләсен бастыра. Берничә ел эчендә ул тел реформасына багышланган 30лап мәкалә яза.

Ул әлеге мәкаләләре белән төрек теленең үсеше, аны гадиләштерү, чит сүзләрдән чистарту, яңа сүзләр ясау һәм яңа әлифбаны гамәлгә кую өчен гаять зур эш башкарган тел галиме буларак та танылa. С. Максуди үзенең шул мәкаләләрен җыеп 1930 елда "Төрек теле өчен" дигән китабын чыгара, китапка сүз башын Мостафа Кемал Ататөрек яза: "Милли хис белән тел арасындагы бәйләнеш бик көчле. Телнең милли һәм бай булуы аркасында милли хис тә бөек була. Төрек теле телләр арасында иң бае. Үз илен һәм аның киләчәген саклап кала алган төрек милләте, билгеле, үз телен чит телләрнең басып алуыннан да саклаячак. 2 сентябрь, 1930 ел. Гази М. Кемал." С. Максудиның төрек мәдәниятендә, фәнендә тоткан урынының зурлыгын, әһәмиятлелеген күрсәткән һәм хезмәтенә бирелгән бу бәя җәмәгатьчелек алдында аның абруе тагын да күтәрелүенә сәбәп була.

С. Максуди, үзенең бар гомерен, төрки халыкларның тарихын өйрәнүгә багышлаган З. Вәлидидән кала, төрек тарих фәнен үстерүгә дә иң зур өлеш керткән галим булып санала. Төркиягә күчеп килгәч тә үк аны "Төрек учаклары" җәмгыятенә әгъза итеп кабул итәләр һәм ул 1927 елда әлеге җәмгыятьнең мәдәният һәм фән буенча комиссиясенә сайлана. Җәмгыятьнен 1930 елның 27 апрелендә уздырылган съездында ул Тарих академиясе төзергә кирәклеге мәсьәләсен күтәреп чыга. М. Кемалга аның бу тәкъдиме ошый һәм, озак та үтми, махсус комиссия төзелә. Комиссия төзелү белән төрки халыклар һәм алар эчендә төрек халкының яңа тарихын язу буенча М. Кемал җитәкчелегендә кызу эш башлана.

"С. Максуди төрек тарихын яңадан язып, тарих хакында милли аңны, карашны үстерүгә зур өлеш кертте, милләтчелекне төркичелек дип аңлатты һәм тарихта үзенең эзен калдырды" (С. Максудиның тууына 115 ел уңае белән уздырылган конференциядә Г. Пултар ясаган докладтан). Төркиядә хәзер яши һәм эшли торган "Тарих җәмгыяте" исә аның әнә шул тырышлыгы нәтиҗәсе булып тора. (Әлеге "Тарих җәмгыяте"н төзүгә Й. Акчура да зур көч куйган, ул әлеге җәмгыятьнең беренче рәисе булган һәм 1932 елда уздырылган Беренче Төрек тарих конгрессында да рәислек иткән).

Төркиядә С. Максуди сәясәт белән дә шөгыльләнә, ул 3 мәртәбә Төркия парламентына депутат булып сайлана. Бер мәртәбә Й. Акчура белән бергә эшли. Гомере буе Й. Акчураны хөрмәт иткән һәм аны үзенең дусты санаган С. Максуди аның үлемен (1935 ел) авыр кичерә. Аңа багышлап язган "Дустым Йосыф Акчура" дигән мәкаләсендә ул аның сәяси эшчәнлегенә зур бәя бирә. Барлык төрки халыклар өчен дә бәйсезлек, милли үсеш чоры киләчәк һәм Й. Акчура

кебек милләтебез өчен яшәгән шәхесләрнең үлмәс исемнәре онытылмаячак ди. Й. Акчураны ул төркилек идеалына бертуктаусыз хезмәт иткән үз милләтенең бөек улы дип атый.

1946 елда Төркиядә Демократлар партиясе төзелә. Бу партиянең оешуында С. Максудиның да өлеше зур, чөнки аның дәүләтнең демократик киләчәгенә якты өметләр баглап, кичке "Сон сәгатьтә" газетасы битләрендә һәр атна саен диярлек демократия, күппартиялелек, гражданлык хокуклары турында гади халыкка аңлаешлы телдә язылган күп санлы мәкаләләре чыга. Ул 1950-55 елларда Бөек Милләт Мәҗлесенә Милләт вәкиле булып инде демократлар партиясенең Әнкара бүлегеннән сайлана. Милләт Мәҗлесендә тел мәсьәләләре каралганда, хокук буенча кануннар тикшерелгәндә дә Төркиянең иң абруйлы сәясәтчесе, олы галиме булган С. Максуди Арсалның салмак, әмма көчле, вәкарьле тавышы янгырый. Ул 50нче елларның урталарына кадәр Төркия һәм Европа сәясәтендә күренекле урын били. Төркия делегациясе составында Милләтләр лигасы эшендә катнаша, Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң төзелгән Европа Советында да Төркия парламенты делегациясе җитәкчесе буларак бик актив эшли. Европа Советында ул Европа федерациясе конституциясен язу өчен төзелгән һәм Европа илләренең иң күренекле юристлары кергән комиссиягә сайлана, үз фикерләрен дәлилләп кайнар чыгышлар ясый һәм комиссия әгъзалары ул язган Конституциянең төрки дәүләтләргә кагылышлы параграфлары белән килешергә мәҗбүр булалар.

С. Максудиның Төркия республикасының иң абруйлы, танылган сәясәтчеләреннән булуын күрсәткән бер факт: 1955 елда президент сайлаулары вакытында президентлыкка күрсәтелгән 5 кандидатураның берсе —Садри Максуди Арсал. Олы яшьтә булуын сәбәп итеп, ул кандидатурасын ала.

С. Максуди 1955 елда гына сәясәттән китә һәм үзенең калган гомерен бары тик фәнгә генә багышлый. Аның соңгы гыйльми хезмәтләренең берсе "Миллият тойгысының социологик әсаслары" дип атала. "Анда милләт һәм милли мөнәсәбәтләр проблемасына тирән теоретик анализ ясала. С. Максудиның бу китапта төрле дәлилләр белән нигезләнеп бәян ителгән фикерләре милли мәсьәләләрне тикшергәндә, милли идеологиянең ориентирларын билгеләгәндә, методологик таяныч ролен үти алалар"—бу хезмәт турында Я. Абдуллин әнә шулай дип язды.

С. Максуди 1957 елның 20 февралендә Истанбулда вафат була. Ул көннәрдә Төркиянең барлык газеталары кайгы сүзләре белән чыга, аның гаиләсенә Европаның төрле илләреннән, Төркия дәүләт җитәкчеләреннән кайгы телеграммалары килә. Газеталар: "Төркия үзенең зур галимен, дәүләт эшлеклесен һәм сөекле улын югалтты", дип язалар. Дөньяның киң җәмәгатьчелеге аны олы дәүләт эшлеклесе, төрек халкы исә аны үзенең улы дип таный.

С. Максуди 21 февральдә Истанбулда җирләнә, табуты куелган мәчет янына, аның белән хушлашырга дип, дистәләрчә мең кеше җыела. Аның җәсәде салынган табутны хастаханәдән Баязит мәчетенә, аннан ул эшләгән университетка кадәр кулга күтәреп алып киләләр. Ә табут исә Төркия флагына төрелгән була. Бу—төрек хөкүмәтенең Төркия республикасы сәясәтендә мөһим роль уйнаган, мәдәниятендә, фәнендә зур эшләр эшләгән танылган сәясәтчегә, олы галимгә күрсәткән ихтирамы, олы хөрмәте була. Аның кабере бүген дә кадерләп саклана, зиярәт кылына. Истанбулда С. Максуди исемендәге урам да бар.

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Иске Ашыт авылы

Менә без Казан артындагы борынгы торак пунктларның берсе—Иске Ашыт авылына килдек. Исеме язма чыганакларда әледән-әле очраган бу авылның оешу тарихы борынгы чорларга китә. Иске Ашыт авылы район үзәге Арчадан 43 чакрымда утырган.

Иске Ашыт, Яңа Ашыт һәм Ашытбаш авыллары Ашыт суы буена урнашкан. Бу авылларның исемнәре Ашыт елгасы атамасыннан алынган.

Иске Ашыт авылы Казан ханлыгы заманыннан ук билгеле. Бу авыл зиратында болгар чорларына мөнәсәбәтле (XIV гасыр) кабер ташлары табылган. Археологлар Иске Ашыт янындагы Йорт өсте дип йөртелгән зиратта болгар—Алтын Урда—татар чорларына караган кабер ташлары, соңгы болгар (Алтын Урда) чорына нисбәтле керамика кыйпылчыклары теркәгәннәр.

Марсель Әхмәтҗанов бер мәкаләсендә болай яза: Болгар дәүләте 1236 елдан соң Алтын Урда дәүләтенең бер үзәк өлешенә әверелеп, «Болгар олысы» дип йөртелә башлый. Олыс башына җирле аксөякләр һәм татар ханнарының кардәшләре булган бикләр (бәкләр), солтаннар куела.

XIII гасырда Болгар олысында Бураш бик, ә XIV гасырда Булат-Тимер бик, Хәсән солтан, Мөхәммәт солтан, Габдулла хан кебек шәхесләрнең идарә иткәнлекләре мәгълүм.

Болгар дәүләте Алтын Урдага корал көче белән кертелгән булса да, әлеге вакыйганың нәтиҗәсе соңыннан шактый уңай якка үзгәрә. XIII гасырның 70-80 елларында Болгарның икътисады аякка баса. Урта Идел буйларында шәһәрләр күтәрелә, акча, ювелир хәзинәләре туплана, чын сәнгать үрнәкләре булган каберташлар куела башлый.

Бату хан гаскәре белән Болгар җирен яулап алса да, андагы болгарлар кырылып бетмәгән, монголлар да килеп утырмаган. Болгар җирендә куелган каберташлар чама белән 1360 нчы елларга кадәр болгар телендә язылганнар. Зөя елгасы буйларыннан Уфа шәһәренә һәм Вятка (Нократ) шәһәреннән Самара өлкәсенә кадәрге җирләрдә болгар телендә ташлар куелган. Борынгы болгар теле үзенчәлекләренең югала бару процессы бөтен Алтын Урдада дәүләт теленең татар теле булуы белән бәйләнгән.

Шушы дәверләрдән Арча төбәгенә кергән Иске Ашыт авылы кырында да болгарлардан ике каберташ сакланган. Алар галим Һарун Йосыпов тарафыннан табылып укылганнар.

**1 нче таш**

Борынгы текст: «...бакый ахирәт йатуы тарих җийати җүр эл сикир жал, зөлкагъдә айых ун сикир кун әти, җийати кун әти...»

Тәрҗемәсе: «...бакый ахирәттә ятуы тарих җиде йөз илле сигезенче ел, зөлкагъдә аеның унсигезенче көне иде, жиденче көн иде...»

Әлеге язулы каберташ һиҗри 757 ел, милади хисап белән 1357 елның 3 ноябрендә вафат булган болгар кешесе кабере өстенә куелган.

**2 нче таш**

Борынгы текст: «Болгар Тотай улы Салих зийарти, Рәхмәтуллаһи галәйһи рәхмәтән васигатән. Фани дөнйа ран бакый ахирәти йатуы... тарих җийати җүр... үч жал... билех кун әти».

Тәрҗемәсе: «Болгар Тутай улы Салих зияраты. Анын өстендә Аллаһы тәгаләнең киң рәхмәте торсын. Фани дөньядан бакый ахирәткә ятуы тарих җиде йөз... өч

---

*Дәвамы. Башы журналның 2006 елгы 6 санында.*

жыл... бишенче көн иде».

Бу таш һижри 7... 3 ел, милади 13... 3 елда^вафат булган кеше кабере өстенә куелган».

Әхмәтжанов фикеренә күрә, Казан ханлыгы дәвереннән калган борынгы зиратларның берсе Иске Ашыт авылы янында сакланган. Бу типтагы борынгы зиратлар Арча төбәгендәге күп кенә авылларда мәгълүм. Аерым алганда, Иске Ашыт авылы кырында Казан ханлыгы дәвереннән калган зиратта өч каберташ сакланган. Ул ташларны 1927-1928 елларда атаклы татар галиме Гали Рәхим табып, язуларын күчереп алган. Ташъязмаларның сакланышы начар булып, берсенен генә куелган елы таныла. Анда татар телендә «Тарих тукыз йөз кырыкда...», «Тикән», «Күрермен дөньяны вәйран (бары)», «бакый ирмәс юк (карары)» дигән сүзләр генә сакланган. Бу таш милади ел исәбе белән 1533 елда үлгән кеше кабере өстенә куелган. Анда Казан ханлыгы дәверендәге каберташ язмаларында еш очрый торган «бу дөньяда бар да бетә, бернәрсә дә мәңгелек түгел» мәгънәсендәге шигырь юлы китерелә. Язмадагы: «Бикәж» исеме—кабернең татар югары катлавыннан булган дәрәҗәле хатын-кызга нисбәтлелегенә дәлил. Казан ханлыгы дәвереннән Иске Ашыт авылында сакланган башка ике ташның язулары танылмый".

Ашыт атамасы 1602-03 еллардагы Казан өязе теркәү кенәгәсендә бик еш очрый, һәм башка тарихи чыганакларда да искә алына. Бу елга атамасы В. П. Семенов редакцияләгән тарихи хезмәттә дә кабатлана. XVIII гасыр тарихи чыганагында Ашыт авылында (ул икенче төрле «пустошь Шатуловка» дип аталган) 203 йомышлы татар яшәгәнлеге искәртелә.

А. Артемьев җыентыгында Ашыт авылының 118 хуҗалыгында 655 ир-ат һәм 552 хатын-кыз яшәгәнлеге әйтелә. Авылда мәчет эшләгән, кече атна көннәрендә базар үткәрелгән.

Н. Н. Вечеслав хезмәтендә Иске Ашыт искә алына. Авылдагы 198 хуҗалыкта ислам дине тота торган 655 ир-ат һәм 622 хатын-кыз яши. Авылда бер мәчет, бер мәдрәсә, вак-төяк сата торган 15 кибет, әйбер мана торган бер кярханә, тимерче алачыгы, тунмай эретү кярханәсе, ике су тегермәне, бер кабак, җиде ашханә булган. Кече атна көнне базар үткәрелгән. Печән Пакуслары яисә Ашытбаш дип йөртелгән авыл да телгә алына. Андагы 118 йортта 428 ир-ат һәм 393 хатын-кыз яшәгән. Авылда бер агач мәчет, су тегермәне, вак-төяк сата торган ике кибет эшләгән.

Ашыт суының сул ягына, Уржум сәүдә юлының уң ягына утырган Ашыт авылын И. А. Износков түбәндәгечә сурәтли. Иске Ашыт авылының бер өлеш халкы 1780 елда аерылып чыгып Яңа Ашыт авылын нигезли. Иске Ашытның җирләре «Мәмәдәли бушлыгы» (Мамадалеев пустошь) булып саналган. Авылдагы 192 хуҗалыкта 672 ир-ат һәм 649 хатын-кыз яшәгән. Алар ислам дине тотканнар һәм Иске Ашыт авыл җәмгыятенә кергәннәр. Тормыш-көнкүрешләре әйбәт, кәсепләре: иген игү, тимерчелек, балта эше, он тарту булган. 1898 елгы бүлешмәдә күрсәтелгәнчә, Иске Ашыт авылында татарлар яшәгән. К. П. Берстель бүлешмәсендәге мәгълүматлар күрсәтүенә күрә, Иске Ашыт авылында 1138 татар кешесе гомер иткән.

Ашыт исемендәге җыен бәйрәме дә үткәрелгән, Н. Б. Борһанова язуына караганда, бу җыенны тагын Катык җыены яки Ашыт каршы дип тә йөрткәннәр. Әлеге җыенны Ашыт һәм аның кушылдыклары ярына урнашкан Иске Ашыт, Иске Кенәр, Печмәнтау, Ташкичү, Мәмсә һәм Иске Тазлар авыллары халкы бәйрәм иткән. Иске Ашыт авылы элек Ашыт Иле дип тә йөртелгән. Ашыт җыенын бергәләшеп үткәрә торган авыллар арасында «иле» формасын алган авыл атамасы—Ашыт иле берәү генә. Кама алды җирлегендә «иле» сүзе катнашкан авыл атамалары түбәндәгеләр: Чура Иле, Чуаш Иле, Аяз Иле, Кариле, Казиле, Чүрчиле, Дүртиле, Өчиле, Ялаг Иле, Бүл Иле, Кодаш Иле, Олан Иле, Тау Иле һ. б. «Ил» сүзе борынгы заманнарда барлык төрки халыкларда да ыру-кабилә һәм кабиләләр берлеген белдергән. «Эл»—рун язмаларында кабиләләр союзы, ил мәгънәсендә кулланылган. Авыл атамаларында «ил» ыру һәм кабилә төшенчәсен аңлата булса кирәк. Ә соңыннанрак ул «туган авыл», «ватан» дигән территориаль мәгънәгә ия була башлаган.

Ашытбаш халкы Кырлай, Яңа Иябаш, Кысна авыллары белән бергә «Кырлай җыены» үткәргән.

Ашыт авылы тарихының бер өлешен халкыбызның күренекле шәхесе Шиһабетдин Мәрҗани язып калдыра. Аның «Мөстәфадел-әхбәр фи әхвали Казан вә Болгар» (Казан, 1989) дип аталган китабында без мондый юллар укыйбыз: «Ашыт авылы—Ашыт елгасы буенда иң борынгы авыл. Хәтта ислам хөкүмәтләре (Казан ханлыгы) көннәрендә дә яшәгән һәм төзек биналардан торган. Әмма заман агышы белән бер урыннан икенче урынга күчеп йөргән. Шул тирәдә дә дүрт урында утырганлыгы мәгълүм. Әүвәл—Шаһкол елгасында; аннан күчеп, хәзер «Күчмә» дип танылган елгада; каберлеге хәзер дә «Күчмә каберлеге» дип мәшһүр. Аннан соң, хәзерге

урынына күчкәч тә, өч каберлеге булып, «иске каберлек», «яна каберлек», «йорт өсте каберлеге» дип йөртелгәннәр. «Ашыт каберлекләрендә әүлия кабере бар»,—дип халык телендә сөйләнсә дә, ачык бер хәбәр яки берәр китапта булмаганлыктан, ана ягыннан бабабыз мелла Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек вафат булгач, мәрхүм атабыз: «Инде Ашыт зиратында әүлияләр күмелгәнлеге мәгълүм булды»,—диде.

Ашыт кешеләреннән Мәкәләй бине Ак Суфи исемле гаять көчле һәм бик батыр кеше булган. Хәзер дә Ашытта искедән калган бик калын, хәтсез юан, ике ат көчкә тартырлык имән баганалар бар. «Мәкәләй шул баганаларны үзе ялгыз күтәреп утырткан»,—дип сөйлиләр. Берәр жирдә туй яки зур жыен булса да, башка мәжлесләргә чакырылып, мәшһүр байлар белән аралашып яшәгән. Туйларга барганда, атын калын чи имән агачыннан кисеп бөккән дуга белән жигеп, башкалар тугарып ала алмагач: «Без фәкыйрь кешене игътибарга алмыйлар, атыбызны тугармыйлар, китәм»,—дип, мәжлес иясенә үпкә белдергәч хужалар ялынып, гозер итеп, үзеннән тугарта торган булганнар. Эчке мәжлесләрдә сугыш чыгарып, кешеләрне кыйнап, күп вакытларда аларны киртә аркылы ташлый торган булган. Ахырда Кышкар байлары—Габдеррәшид бине Госман бине Габделкадыйр һәм туганнары Сәгыйдләр—Мәмсә авылында бер мәжлес ясап, аны явыз ният белән чакырып, бал эчертеп исерткәннәр дә сәндерәгә асып үтергәннәр һәм Ашыт суына чыгарып ташлаганнар. Берничә көннән соң мәете калкып чыккач, Ашыт кешеләре аны Ашыт суы буенда, «авыл асты тегермәне» дип йөртелә торган тегермәннән югарырак, елганың көньягында күмгәннәр. Хәзергә чаклы кабере мәгълүм, агачтан чардуган корылган. Бу вакыйга 1170 (1756) ел азагында булган.

1220 (1805) ел азагында Ашытта базар ачылган һәм кибетләр төзелгән».

Ашыт атамасы Казан ханлыгы чоры документларында, шулай ук Казан өязенен теркәү кенәгәләрендә, рус елъязмаларында, тарихи-статистик, тарихи-географик, тарихи-этнографик һәм башка чыганакларда искә алына. Археограф Һарун Йосыпов язуына караганда, Ашыт сүзе кабер ташларында кеше исеме янында, тумышы белән шул урыннан, ягъни Ашыт елгасы ярындагы берәр авылдан икәнлеген күрсәтү өчен кушамат буларак кулланыла (мәсәлән, Ашыт Сибгат һ. б.). 1834 елда Казан губернасы буенча үткәрелгән ревизская сказка материалларында Ашыт Тарзимин исем-фамилиясе теркәлгән.

Ашыт мәчетен Шиһабетдин Мәржани болай сыйфатлый. «Иң элек мәгълүм булганын Ашыт авылының үз әһалисеннән Ишморад бине Мортаза бине Исмәгыйль бине Юныс бине Идрис 1796 елда төзеткән. Балаларыннан хәзер Ашытта Солтангали бине Тимергали бине Корбангали бине Ишморад һәм аның балаларыннан Гали, Йосыф һәм Хажимөхәммәтжан исәннәр. Шушы авылдан чыккан Шимай сәүдәгәре Хәсән бине Мөсәгыйд бине Ибтәкеш бине Туктамыш бине Тактар 1859 елда бу мәчетне яңадан төзетте. Үзе 136... елда вафат булды. Мәчетнең манарасы ике тапкыр авып төшеп, аны 1876 елда әлеге кешенең углы Хөсәен бине Хәсән төзәттерде. Аның олы баласы Идрис Ашыт карьясендәге Шаһкол елгасы янында вафат булган һәм шунын каберлегендә жирләнгән, диләр.

«Тумышы белән Ашыт авылыннан булган мулла Мөхәммәдрәхим бине Йосыф бине Габделкәрим бине Арыслан әл-Ашыти атасыннан һәм башка галимнәрдән белем алып Ашыт карьясендә имам һәм хатыйб булган. Ун елдан соң Мәчкәрәдә имам, хатыйб һәм мөдәррис итеп куелган. 1818 елда Мәчкәрәдә вафат булган һәм шундагы каберлектә жирләнгән».

Ашыт атамасы алган су республиканың төньяк-көнбатыш өлешендә ага. Аның озынлыгы 130 чакрым. Ул—Мари иле жирендәге Илләт елгасының сул кушылдыгы. Уң ягыннан Ашытка Оры, Шашы, Өлә, Күәм һәм меридиан юнәлешендә ага торган, озынлыклары 15 чакрым чамасы булган вак инешләр килеп кушыла. Сул ягыннан аңа Симет суы коя.

Кызганыч, хәзер Ашытның суы елдан-ел саега. «Элек, без үскәндә Ашыт суы шау балык иде. Вак ташбашлар гына түгел, буйлары берәр метрдан артык бәртәс, чуртаннар, берничә килограммлы алабуга, сазаннар күп иде. Бер елны тегермәнче Ярәфи безне чарык астында үрләгән зур-зур балыкларны тирес сәнәге белән чәнчеп алып хәйранга калдырган иде. Ашыт суы менә шундый балыклы иде ул без бала чакта»,—дип сөйли авыл аксакаллары.

Хәзерге көндә Иске Ашыт авылындагы 138 хужалыкта 205 ир-ат һәм 269 хатын-кыз яши.

Авылда урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, балалар бакчасы һәм кибет эшли. Авыл тарихына багышланган музей бар. Халык үзәкләштерелгән газ яга, йортларга су кергән. Асфальт юл хәзер авылга кадәр килеп житкән.

Авылда мәчет бар. Халык зиратны тәртиптә тота.

Авыл халкы өлкән буынга карата мәрхәмәтле һәм игътибарлы. Картлар йортына

бирелгән карт-карчыклар юк. Ялгыз торучы Мәйшәкәр апаның картлар йортына китәсе килмәгән. Халык аны карау һәм тәрбияләүне үз өстенә алган.

Ашыт сүзенең килеп чыгышы белән кызыксынучылар байтак. Гарәп телендә «ашыт»—«сазлык», «сазлыклы урын» дигән сүз. Ашыт суының киң үзәнендә сазлы җирләр, юеш һәм баткак урыннар күп очрый. Мондый урыннар элек тагын да күбрәк булган. Ләкин шуна да карамастан, «ашыт» сүзе ахырындагы төрки-монгол телләренә хас булган күплек кушымчасы—т аны гарәп телендәге «сазлы урын» мәгънәсендәге ашыт берәмлеге белән бәйләргә урын калдырмый. Ашытның кушылдыклары Симет һәм Кишет атамаларында да нәкъ шундый ук—т кушымчасы бар.

Ашыт атамасының килеп чыгышы турында түбәндәге фикерләр яши. 1971 елда басылып чыккан бер мәкаләсендә Һарун Йосыпов Ашлы һәм Ашытның бер этнонимның төрдәшләре булуын дәлилли. Археолог Альфред Халиков борынгы төрки ашина ыруы башка төрки кабилә-кавемнәр арасында безнең эра башларында Алтайдан Көнчыгыш Европага үтеп кергән дип уйлый. Шушы карашны нигез итеп алып, Гомәр Саттаров Ашытны борынгы төрки ашина (бүре) ыругы атамасының—т кушымчасы алган күплек формасы дип карый. Ашина (бүре) кабиләләренең бер өлеше хәзерге Татарстан төбәгенә килеп чыккан һәм андагы Ашыт елгасына үз исемен биреп мәңгеләштергән. Археолог А. П. Смирнов һәм С. А. Плетнева мәгълүматларына таянып, Нажия Борһанова Ашыт атамасын борынгы төрки-хәзәр ашин кабиләләре белән мөнәсәбәтле дип уйлый һәм үзәкләре Ашлы шәһәре булган болгар кабиләләре дә шушы ашиннарга барып тоташа булса кирәк, дигән фикер әйтә.

Кама аръягы җирлегенең Зәй районында урнашкан Кушъелга авылы да элек Ашыт исемен йөрткән. Ашытның төрки халыкларга мөнәсәбәтле атама икәнлеге шик тудырмый. Ашыт сүзенең төрле төбәкләрдә таралуы безне һич аптыраашта калдырмаска тиеш, чөнки төрки кабилә-кавемнәр үзләре күчеп йөргән киң җирлектә халык булып оешканнар һәм таныш атамаларны төрле төбәкләргә алып барып кушканнар. Шулай булгач, ул төрки халык яши торган башка төбәкләрдә дә очрый. Әйтик, Башкортстанның Белокатай районында—Ашин, Калтасы районында Ашыт авыллары, Иглин районында марилар яши торган Ашин исемле бистә бар. «Ашыт» берәмлеге һәм «аш» тамыры белән ясалган атамалар Мари, Удмурт, Мордва җөмһүриятләре, Ока, Цна елгасы бассейннарында, Чиләбе өлкәсендә, Байкал аръягы җирләрендә, Кытай чигендә, Тажикстан, Молдова җирләрендә һәм башка урыннарда очрый.

Авыллар утырган урын күркәм, су-инешләр, урман-әрәмәләр, чишмә-кизләүләр күп.

Иске Ашыт авылында Ашыт суына коя торган Күчмә, Шаһкол, Озын алан, Мулла, Тирән, Муса елгалары, Салават, Сәйфи чишмәләре, Пумыр, Көбәк сазы күле, Чеми сазы, Саескол болыны, Күчмә асты зираты һ. б. топонимнар бар. Татарстандагы күп авылларда Иске Йорт исеме алган топонимнар очрый дидек инде. Мондый топоним Иске Ашыт авылында да бар. Эпиграфист Һарун Йосыпов язганча, Иске Йорт яисә Йорт өсте урыннары, Иске яисә Борынгы зиратлар авыл беренче урнашкан урыннар белән бәйләнешле. «Шуның өстенә,—дип дәвам итә галим,—бу атама борынгы төркиләрдә иҗтимагый-ыру билгесе хезмәтен үтәп, хәзер исә борынгы чорлардан алып шушы җирләрдә яши торган халыкның хуҗалык-иҗтимагый термины буларак кулланылган булса кирәк».

Авыл уртасыннан Тимерче инеше ага. Аның тирә-ягын бөдрә таллар уратып алган. Инеш ярында элек тимерче алачыгы булган, шуңа күрә аңа Тимерче инеше дигән исем биргәннәр.

Арчадан Иске Ашытка кайтканда төньяк-көнбатыш якта Пумыр (Поморье) күле булган. Аны кечкенә диңгезгә охшатып «море» (диңгез) дип атаганнар. Элек күл тирән, саф сулы булган, суында сөлекләр йөзгән. Хәзер бу күл юк инде, ул кипкән.

Ашыт елгасы авылга житәрәк борылыш ясый. Бу урынны Ат дугае (тугай) дип атыйлар. Авыл халкы: «...Безнең сулар тугай-тугай, ат сугарырга унай,»—дип җырлый.

Ашыт суында Муса биясе (ягъни буа—Ф. Г.) дип атала торган урын бар. Бу урында Муса бай буа буыдырткан һәм тегермән тоткан.

Чишмәләр—авылның бизәге. Салават чишмәсенең сулары саф, тешләренне камаштыра, бик салкын. Атамасы кеше исеменә нисбәтле рәвештә барлыкка килгән. Салават дигән кеше аны караган, тәрбияләп торган. Сәйпи чишмәсен Сәйфетдин исемле кеше чистартып тоткан.

Иске Ашыт авылы янында нарат, зирек һ. б. агачлардан торган калын урманнар шаулап үскән. Ләкин елга ярларындагы һәм авыл тирә-юньнәрендәге урманнар

киселеп беткән. Халык яратып йөри торган печәнлекләр—Күчмә һәм Шаһкол. Бу урыннарда печән котырып уңа, авыз суларын китереп каен һәм жир җиләкләре өлгерә, хуш ис аңкытып чәчәкләр тирбәлә.

Күчмә атамасы ничек барлыкка килгән? 1929-30 елларда, ягъни колхозлашу елларында өч-дүрт кеше ризасызлык белдереп, авылдан чыгып китә. Алар хәзер Күчмә дип аталган җиргә килеп урнашалар, күченеп киләләр. Күчмә коесы дигән атама да шуннан калган.

Хәзер сабантуе үткәрелә торган жир Яшелчә дип атала. Элек монда колхозның яшелчә бакчасы булган. Анда кәбестә, кыяр, помидор, кишер, суган, хәтта карбыз да үскән.

Яз көннәрендә Ашыт елгасы ярларына сыеша алмый, ташып чыга. Буаны язгы ташу алып китә һәм күрше авыллардан йөрүчеләргә юл бетә. Шул сәбәпле 1985 елда күпер төзелә. Ул Арча районында иң зур һәм озын күперләрнең берсе.

Хәзерге карьер янында (анда известьташ чыгарыла) Мари зираты булган. Жир казыганда ул урыннан кеше сөякләре чыга. Җәйләүдән ерак түгел генә Иске зират бар. Анда борынгы кабер ташлары исән әле.

Авылда тарихи музей бар. Анда борынгы эш кораллары, татар халкының милли киемнәре һәм борынгы акчалар саклана. Иске Ашыт базарлы авыл булган. Базар бай булган. Кабак урамының исеме шул көннәргә барып тоташа. Чөнки бу урам буенча мәйханәләр, ягъни кабаклар сузылып киткән була. Утын урамы да шул вакытларның истәлеге. Базар 1955 елга кадәр эшләгән, ә аннан соң ул Яна Кенәргә күчерелә.

Арча яклары талантларга бай. Бу төбәктән Г. Тукай, Ш. Мәрҗани, Г. Бәширов, Г. Ахунов, М. Мәһдиев h. б. шагыйрьләр, галимнәр һәм язучылар чыккан.

Авыл укытучылары һәм мәдәният хезмәткәрләре бик тырышып эшлиләр. Укытучы Хафизова Силүзәгә Татарстанның атказанган укытучысы исеме бирелгән. Гомере буе мәдәният өлкәсендә хезмәт иткән Фәттерәхманова Саяра Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемгә ия булган.

Һәр авылда хәзер нык үзгәрешләр бара. Халык үз асылына, үз диненә кире кайта. Бу хәл Иске Ашыт авылында да нәкъ шулай. Элек авылда 4 мәхәллә булган һәм мәдрәсә дә эшләгән. 1950 елларда мәчет манарасы киселгән. Бай үткәне булган, хәзерге вакытта 131 хуҗалыктан торган, 205 ир-ат һәм 269 хатын-кыз яшәгән Иске Ашыт авылында мәчет ачылу күңелгә канәгатьлек хисе бирә.

Авылда унбер еллык урта мәктәп, балалар бакчасы, китапханә, ашханә, мәдәният йорты, элемтә үзәге, медпункт халыкка хезмәт күрсәтә. Авыл халкы газ яга. Күп йортларга су кертелгән. Юллар да игътибар үзәгенә менде. Арча белән Яна Кенәр арасына асфальт салынган. Авыл араларындагы юллар күтәртелеп таш түшәлгән, хәзер аларга асфальт җәйгәннәр.

Иске Ашыт авылында яшеллек тә күп. Мәктәп балалары ел саен агач утырту белән шөгыльләнәләр. Җиңүнең 45 еллыгына авылның һәрбер ветераны чыршы агачы утырткан. Шул чыршылар хәзер бик матур булып үсеп киләләр. Мәдәният йорты каршына утыртылган үсентеләр дә хәзер бик матур булып югарыга үрлиләр.

Табигатькә, әйләнә-тирә мохиткә урманнар китергән файданы һәрберебез белә. Элек авыл янында калын урманнар шаулап торган. Ләкин елга яры буйларындагы, авыл тирә-юнендәге урманнар киселеп беткәннәр.

Авыл зираты тирәли таш баганалар утыртып, тимер рәшәткә белән тотып алганнар, һәр елны ирләр бер көнне җыелышып зиратны чистарталар, тәртипкә китерәләр. Бу хәл хәзер гадәткә кереп китте.

Авылда өлкән буынга карата игътибар зур. Ел саен олылар көне билгеләп үтелә, аларга бүләкләр һәм күчтәнәчләр бирелә. Матур яши Иске Ашыт авылы халкы!

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# Е

**ЕВГЕНЬЕВ** Павел Кузьмич (20.6.1909, хәзерге Чуашстан Респ. Цивильск ш.—9.2.1972, Казан), язучы. Казанда Чуаш пед. техникумын тәмамлый (1927). 1930 елга кадәр балалар укыта, 1941 гә кадәр «Колхозник Татарии», «Красная Татария» г-таларында эшли. Бөек Ватан сугышында «Вперед, к победе!» дивизия г-тасында эшли, сугышларда катнаша. Казан губернасы Спас өязе Рус Бизнәсе (хәзерге ТРның Спас р-ны Антоновка а.) авылында 1861елгы крәстиян чыгышларын тасвирлаган «Бездна» (1951) тарихи повесте; балалар өчен «Урман табышмаклары» («Лесные загадки», 1958) хикәяләр җыентыгы; Сталинград сугышы турындагы «Ерзока» (1966) истәлекләр китабы; «Раифадагы обелиск» («Обелиск в Раифе», 1969) документаль повесте, очерклар авторы. 2 нче дәрәҗәдәге Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әдәб.: Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**ЕВТУШЕНКО** Евгений Александрович (18.7.1933, Иркутск өлкәсе, Зима ст.), язучы, публицист, тәрҗемәче. «Киләчәк разведчиклары» («Разведчики грядущего», 1952), «Энтузиастлар шоссесы» («Шоссе Энтузиастов», 1956), «Наз» («Нежность», 1962), «Ак карлар ява» («Идут белые снеги», 1969), «Ике пар чаңгы» («Две пары лыж», 1982), «Гражданнар, тыңлагыз мине...» («Граждане, послушайте меня...», 1989), «Минем үземнеке генә» («Моё самое-самое», 1995); «Җиләкле урыннар» («Ягодные места», 1982), «Үлемнән алда үлмә» («Не умирай прежде смерти», 1993) һ.б. романнар һ.б. китаплар авторы; «Балалар бакчасы» («Детский сад», 1982), «Сталинны күмгәндә» («Похороны Сталина», 1993) кинофильмнарның режиссеры һәм сценарийлары авторы. Е.—«алтмышынчылар» буыны вәкиле. В.В.Маяковский юлыннан китеп, риторикага, югары пафоска ия, публицистик, үзенә генә хас булган стиль тудырды. Шагыйрьнең күп кенә әсәрләрендә көн үзәгенә куелган заман мәсьәләләренә битараф түгеллеге чагылыш таба. 1969-70 елларда Е. Казанда була, «Казан университеты» поэмасын язу максаты б-н архив материалларын өйрәнә. Поэмада кин тарихи фонда Россиядә мәгариф системасының туүын, үсүен күрсәтү б-н берәттән күп кенә әхлак мәсьәләләренә дә тукталып үтә: разночинецлар феномены, укуга мөнәсәбәт, милләтара каршылыклар һәм, киресенчә, рус һәм татар мәдәнияты диалогы: «Казан, Казан, татар башкаласы, / күз алдына китерә алмадың / кайнап торган казаныңда синең / Россиянең куәт алганын». Казан шагыйре Н.М.Ибраһимовка багышланган: «Ни кызганыч: аз билгеле факт. / Һәйкәлләргә лаек асылда: / «Во поле березонька...» җырын да / татар чыгарганы ачылды. / Моның өчен сиңа, җан дустым, / Ибраһимов Нигъмәт, дан булсын!»,—дигән юллар киң яңгыраш ала. 1970 тә поэма Казан ун-тында укыла. Е. әсәрләре Казан матбугат битләрендә еш басылды. 1993тән бирле шагыйрь АКШта яши. СССРның Дәүләт премиясе лауреаты (1984). 3 нче дәрәҗәдәге «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен» ордены б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Собр. соч.: В 3 т. М., 1983.

Әд.: Михайлов А. Поэты и портреты: портреты, проблемы, тенденции военного поколения // Новый мир. 1974. № 4; Сидоров Е. Евгений Евтушенко: Личность и творчество. М., 1987; Агеносов В., Анкудинов К. Современные русские поэты: Справ.-антология. М., 1998.

*А.Э.Скворцов.*

**ЕМЕЛЬЯНОВ** Яков Емельянович (16.8 (?). 1848, Казан губ. Лаеш өязе Алан-Полян а.—3.2.1893, ш.у. өяз Үри а.), шагыйрь. Чыгышы б-н керәшен татарлардан, дәүләт крәстияннәреннән. 1864 елдан Казанда яңа ачылган Үзәк керәшен татарлар мәктәбендә укый. 1867 дән Е. Үри авылында изге Гурий борадәрлеге мәктәбендә, 1873 тән Казанда Үзәк керәшен татарлар мәктәбендә, 1874 тән Әрнәш авылында Дини борадәрлек мәктәбендә укыта (соңгысында дьякон да булып тора). 1880 нән—Юкәче авылында, 1882 дән—Югары Чура, 1888—Танькино, 1891 дән—Үри авылларында рухани вазифаларын (священник) башкара.

Беренче шигырьләрен мәктәптә укыган елларда яза башлый. Бер үк «Стихи на крещёно-татарском языке. Дьякон Я.Емельянов стихлары» (1879; 2 нче басма, 1888) дигән исемдә кириллицада басылган ике шигъри җыентык авторы. Һәр җыентыкта 12 шәр шигырь, шуның 7 се кабатлана. Арада иң уңышлысы булган «Ярлы тормыш» шигырендә крәстияннәрнең авыр тормышы тасвирлана. Шигырьләренең күбесендә крәстиян тормышы чагылыш таба. Социаль тигезсезлек, шөһрәт ярату, карунлык, икейөзлелек һ.б. кимчелекләр шагыйрьне рәнҗетә

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 санынан басылып килә.*

(«Олысыманлык», «Әләк», «Саран бай» һ.б.). Е. күңел сыкравы б-н наданлык турында яза, кряшеннәр арасында киң таралган им-том итүдән көлә («Күремчене хөрмәтләү»). Ләкин бернигә карамастан Е.ның лирик герое тормышка оптимистик караштa, авырлыкларга түзем, якты киләчәккә өмет б-н яши. Шагыйрь укучыны яхшылыкка, ярдәмчел булырга өнди. Аерым шигырьләрендә православие динен мактый («Ходай сине илдән алган», «Саташканны уяту»). Моның сәбәбе—рухи остазы Н.И.Ильминскийның көчле йогынтысы. Кайбер шигырьләре—рус шагыйрьләре, ш.и. И.С.Никитин шигырьләренең тәрҗемәсе. Е.ның шигъри теле сөйләм теленә якын, шигырь төзелеше фольклор традицияләренә нигезләнә. Мәс., шагыйрь еш кына «ялгау» алымын файдалана (шигъри юлның яки строфаның соңгы сүзен киләсе шигъри юлның яки строфаның башында кабатлана). Шигырьләрдә сюжет өстенлек итә. Әсәрләренең аһәнлеге һәм көйлелеге өчен Е.ны халык арасында «җырчы Җәкәү» дип йөрткәннәр.

Әсәр.: Татар мәгърифәтчелек әдәбияты. К., 1979; Татар поэзиясе антологиясе. К., 1992. 1 кит.

Әд.: Гайнуллин М.Х. Татарская литература XIX в. К., 1979; Сафин С. Гражданским духом осиянный // Аргамак. 1998. № 5/6; Глухов М. «Егылмас иде сыналган жан...» // Казан утлары. 1973. №3; Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 том; Фәйзуллин Р. Шагыйрь, поп һәм якташ // Казан утлары. 1998. № 10.

Авторлар: Х.Й.Миңнегулов, Е.В.Липаков.

**ЕНИКИ** (Еникиев) Әмирхан Нигъмәтҗан улы (17.2.1909, Уфа губ. Бәләбәй өязе Яңа Каргалы а.—16.2.2000, Казан), язучы, ТАССРның халык язучысы (1989). Морзалар нәселеннән. 1911 елда гаиләләре б-н Дәүләкән авылына күчеп киләләр; Е. авыл мәдрәсәсендә укый. 1925 тән Е. Казанда яши. 1926 да Казан. ун-ты рабфагына укырга керә. 1927 дә Донбасска китә, татар шахтёрларын ликбез курсларында укыта. 1941 гә кадәр Казанда һәм Бакуда төрле оешмаларда һәм пр-тиеләрдә эшли, Маргелан шәһәрендә (Үзбәкстан ССР) балалар укыта, 1931-33 тә Казанда Хезмәтне фәнни оештыру ин-тында читтән торып укый. Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыштан соң «Совет әдәбияты» ж-лында, ТАССР МС каршындагы радиофикация комитетында эшли, Казан авиация техникумында укыта.

Е.нең беренче «Озын көй тыңлаганда» исемле хикәясе 1926 да «Безнең юл» ж-лында басыла. Соңрак башка хикәяләре, «Дус кеше» (1929) повесте языла. Әдәби тәнкыйть яшь язучы иҗатының уңай (геройларның эчке дөньясына игътибар) һәм тискәре (китапчылык йогынтысы, артык хиссилек) якларына да игътибар итә. Зур әдәбиятка Е. үзенең сугыш елларында язылган хикәяләре б-н килеп керә. Аның «Бала» (1941), «Ана һәм кыз» (1942), «Мәк чәчәге» (1944), «Бер генә сәгатькә» (1944), «Тауларга карап» (1948), «Кем җырлады?» (1956), «Әйтелмәгән васыять» (1965) һ.б. хикәяләренә тирән психологизм, лирик һәм фәлсәфи әһәмиятлелек хас. Авторның фәлсәфәсе тормышка, халкының киләчәгенә оптимистик карашка нигезләнә. Е. әсәрләрендә аталар һәм балалар мөнәсәбәте анык һәм принципиаль идея-эстетик концепциягә нигезләнә. Язучының традицион милли сыйфатларга ия булган өлкән яшьтәге кешеләр образлары аеруча уңышлы тудырыла. Милли характерлы олы буын кешеләр образы—Е. казанышларының берсе булып тора. Алар арасында Галимҗан абзый б-н Мәрьям абыстай («Бер генә сәгатькә»), Хәмидә («Тауларга карап»), Акъәби, Минлебай карт («Әйтелмәгән васыять»). Бу геройларга чын мәгънәсендә кешенең иң яхшы сыйфатлары тупланган. Шуңа күрә Е. буыннар арасындагы өзелмәс чылбыр идеясен алар б-н бәйли.

Мәхәббәткә багышланган әсәрләрендә кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр җентекләп, уйчан караш б-н тикшерелә. Язучы мәхәббәткә карата җавапсызлык көтелмәгән авыр кичерешләргә китереп чыгарырга мөмкин дип кисәтә. «Ялгызлык» (1957), «Төнге тамчылар» (1964) хикәяләрендә, «Саз чәчәге» (1955), «Йөрәк сере» (1957), «Рәшә» (1962), «Вөҗдан» (1968) повестьларында катлаулы кеше язмышлары аеруча тормышчан сыйфат б-н тасвирлана.

Язучыны, беренче чиратта, кешенең эчке дөньясын, аның хисси, әхлакый сфераларын өйрәнү кызыксындыра. Е. әсәрләрендә ачык чагылган «эш-хезмәт сферасында конфликтлар», ясалма актуальлек артыннан куу, әзер чишелешләр, тормышны катгый әдәби схемага буйсындыру юк. Язучы үз идеясен турыдан-туры белдерми, үзенең мөнәсәбәтен персонажларына такмый. Теге яки бу күренешләрне объектив рәвештә тасвирлап, ул нәтиҗәне укучының үзенә ясарга калдыра. «Рәхмәт, иптәшләр» (1952), «Саз чәчәге», «Рәшә», «Вөҗдан» повестьларында әхлакый мәсьәләләрне яктырту укучыга көчле эмоциональ тәэсир итүгә буйсынган; психологик ситуацияләр зәргәрчелек осталыгы б-н анализланган; барлык дәлилләр төгәл һәм җентекләп эшләнгән. Е. әсәрләре тирән психологизм б-н сугарылган. Аның повестьларында мещанлыкны, байлык җыюны, икейөзлелекне һәм эгоизмны фаш итү заманында төрлечә бәяләүләр, заманында каты бәхәсләр һәм дискуссияләр тудырды. Ләкин тормыш һәрвакыт автор карашларының дөреслеген раслап килде.

Е. геройларының кичерешләре музыка, җыр б-н кушылып бара. Бу авторның эзлекле рәвештә традицион романтик нигезләмәсенә (концепциясенә) тугры булып калуы турында сөйли. Сәнгати стиль үзенчәлекләрен чагылдырган ирония, сатира һәм юмор язучы иҗатында зур урын алып тора. Тасвирлы, мәгънәле теле, кайвакыт сарказмга тин юморы, хикәяләренә кабатланмас тәэсир көче өсти («Чәнечкеле хикәяләр», 1962; «Салават күпере», 1966, «Шило в мешке», 1967 җыентыклары). Композитор С.Сәйдәшев тормышындагы бер мәхәббәт тарихына «Гөләндәм туташ хатирәсе» (1978) романы багышланган.

Гомеренең соңгы елларында язылган «Хәтердәге төеннәр» (1983), «Соңгы китап» (1986), «Кояш баер алдыннан» (1996) әсәрләрендә автор үзенә генә хас булган җентеклелек б-н гомеренә һәм иҗатына нәтиҗә ясый, үтеп барган гасырның сәяси, иҗтимагый һәм әдәби вакыйгаларын анализлый, аларга үзенең объектив бәясен бирә, татар халкының, бөтен илнең тарихы һәм киләчәге турында уйлана. Аларны киләчәк буын укучыларына мөрәҗәгать, алар б-н сөйләшү дип тә, бер үк вакытта өлкән буынның хаталарын кабатламас өчен ясаган кисәтү дип тә кабул итәргә мөмкин.

Е. актив рәвештә тәрҗемә өлкәсендә дә эшләп килде. Татар теленә Н.В.Гоголь, А.Н.Островский, М.С.Бубеннов, О.Гончар, К.Г.Паустовский, Э.Г.Казакевич, Ч.Айтматов әсәрләрен тәрҗемә итте. Ул—ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (1984), 2 нче дәрәҗәдәге Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары һәм медальләре б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Әсәрләр: 5 томда. К., 2000-2004; Юлчы. К., 1979; Глядя на горы. М., 1974; Страницы прошлого. К., 1998.

Әд.: Мустафин Р. Целебное озеро // Образ времени. К., 1981; Халит Г. С любовью к человеку // Портреты и проблемы. К., 1985; Сверигин Р., Хатипов Ф. Рәшәле дөнья // Мирас. 1999. № 3—4.

*Р.Х.Сверигин.*

**ЕРИКӘЙ** (Ерикеев) Әхмәт Фазыл улы (16.12.1902, Уфа губернясы Златоуст өязе Илкенде ав. – 15.9.1967, Мәскәү), шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе. 1920 елдан Уфа губернясы оешмаларында эшли. 1927 дә Мәскәүгә килә. Журналистика ин-тында укый, бер үк вакытта "Эшче", "Игенчеләр" газетасы, "Ударниклар" ж-лы редакцияләрендә эшли; СССР халыклары иҗат секторын һәм 1932 елдан Гослитиздат каршында милли сектор оештыра. Мәскәү консерваториясе каршында эшләп килгән татар опера студиясе эшендә катнаша: җыр, опералар өчен либретто текстлары яза, рус һәм башка чит ил опера әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. 1942 дән "За честь Родины" дигән фронт газетасында редактор урынбасары. 1945-50 дә ТАССР Язучылар берлеге рәисе. "Ташлы дулкыннар" исемле беренче китабы 1930 елда Мәскәүдә басыла. Е. – татар җыр поэзиясен башлап җибәрүчеләрнең берсе, зур популярлык казанган 300 дән артык лирик җырлар, романслар текстлары (С.Сәйдәшев, Р.Яхин, Ж.Фәйзи, А.Ключарёв, М.Мозаффаров, З.Хабибуллин, Н.Җиһанов көйләренә) авторы. Үзенең әсәрләрендә Е. мәхәббәткә, иркле хезмәт романтикасына, туган як матурлыгына дан җырлый. Табигый яңгырашлы, эчкерсезлек, ягымлы аһәңле шигырьләр аның поэзиясен характерлаучы билгеләр. Бөек Ватан сугышы елларында Е. вакытлы матбугатта фашист илбасарларына каршы көрәшкә өндәүче, дошманны җиңәргә рухландырган шигырьләр яза. Сугыш темасына багышланган "Сугыш җырлары" (1941) шигырьләр җыентыгы, сугыш геройлары турында "Салават Кәримов" (1943) һәм "Геннадий Гобәйдуллин" (1943) очерклары бар. "Лирика" (1934), "Язгы җырлар" (1941), "Мәхәббәт җырлары" (1949), рус теленә тәрҗемәдә "О дружбе, о любви" (М., 1955), "Судьбы и люди" (М., 1974), "Энҗе чәчәк" (1959: русча тәрҗ. "Жемчужина", 1961), "Ике йөз җыр" (1982), «Җырланмаган әле безнең җыр» (2002) исемле шигъри җыентыклары укучыларга яхшы таныш. "Кечкенәләр өчен әкиятләр" (1938), "Нәниләргә шигырьләр" (1938), "Весенний гром" (1948; татарчага тәрҗ. "Язгы күкрәү", 1950) китаплары балаларга адресланган. А.Твардовскийның "Василий Тёркин" (1946) поэмасын татарчага тәрҗемә итә. Рус композиторлары, шагыйрьләре, тәрҗемәчеләре белән тирән элемтәдә була. Композиторлар А.Шапорин, Н.Мясковский, С.Кац белән берлектә Е. сүзләренә романслар иҗат итеlә. Е.нең шигырь һәм поэмалары П.Васильев, П.Антокольский, С.Васильев, Д.Бедный, М.Исаковский, Б.Ахмадуллина, В.Рождественский, В.Тушнова, А.Жаров, В.Державин, С.Липкин, Е.Евтушенко, В.Ганиев тәрҗемәләрендә рус укучыларына да билгеле. 1946-54 елларда СССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, ике тапкыр "Почёт билгесе" орденнары, медальләр белән бүләкләнгән.

Әсәр.: Әсәрләр: Шигырьләр, җырлар. К., 1950; Сайланма әсәрләр: Поэмалар, шигырьләр, җырлар. К., 1971; Избранное: Стихи. М., 1982.

Әд.: Хусаин М. Песенный взлёт // Советская Татария. 1982. 19 дек.; Хәйри Х. Әхмәт Ерикәй шигырьләре //Язучы һәм тормыш. К., 1979; Сафин Ф. Җырчы шагыйрь // Казан утлары. 1982. №12; Миннуллин К. Ах, җырларым...// Ватаным Татарстан. 1993. 5 гыйн.

*В.Х.Ганиев.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# УЛ—ЯРУЛЛИННАР ЙОЛДЫЗЛЫГЫННАН

МИРСӘЕТ ЯРУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Болай дип әйтү һич тә арттыру түгелдер. Чөнки татар музыка дөньясында бу мәгълүм фамилиядән танылган вә исем алган шәхесләр, музыкантлар чыккан. Һәм, Ходайның рәхмәте белән, аларның һәркайсына да "беренчелек пальмасы" насыйп булган.



Бу фикеребезне мисаллар белән раслап китик. Заһидулла Яруллин (1988–1964) татар профессиональ музыкасына нигез салуда катнашкан талантларның берсе. Анын өлкән улы Фәрит Яруллин (1914–1943) беренче татар балеты "Шүрәле"не иҗат иткән композитор буларак билгеле. Мирсәет Яруллин исә "КЕШЕ" дип аталган беренче татар ораториясе (шагыйрь Ренат Харис сүзләренә) белән үзенең талантын күрсәтеп бирде.

Мирсәет Яруллин 1938 елның 12 июнендә Мамадыш районы Кече Сон авылында туа. Анын беренче укытучысы, остазы–халык музыканты, данлыклы "Тукай маршы"ның авторы, этисе Заһидулла агай була, билгеле. Композиция остасы А. Леман житәкчелегендә Казан музыка училищесын (1955-58), консерваторияне (1958-63) һәм аспирантураны (1964-67) тәмамлый.

Укыган елларында ук, скрипка белән окестр өчен концерт язып (1962), ул инде үзенен житди композитор икәнлеген белгертә. Диплом эше сыйфатында Муса Җәлилнең "Сандугач һәм чишмә" шигыренә Вокаль-симфоник поэма иҗат итә. Консерватория студенты буларак, республика жыр конкурсларында берничә тапкыр дәрәҗәле урыннарны яулый.

М. Яруллинның күп кенә әсәрләренә татар музыка фольклоры белән заманча композицион техник алымнарны кушу, берләштерү хас. Анын музыкасы халыкчан да, шул ук вакытта үзенә генә хас бизәкләр белән дә аерылып тора.

Композиторнын жырлары халыкта бик популяр. Аларнын күбесе татар жыр сәнгатендә үзенең урынын тапты һәм инде дистәләрчә еллардан сон да радио, телевидение, аудиокассеталарда үзләренең янгырашын табалар.

Мирсәет Яруллин композитор буларак абруй казанды һәм 1977–1989 елларда Татарстан композиторлар союзынын рәисе буларак җәмәгать эшләрен үз жилкәсендә тартып барды. Ул- бүгенгә көндә дә композиторлар союзынын идарә әгъзасы, Идел буе һәм Урал композиторларынын берләштерелгән төбәк рәисе.

1967 елдан бирле композитор Казан дәүләт консерваториясендә полифония һәм аранжировка дәресләре алып бара. Педагог булу өстенә, инде менә ун ел буе татар музыка сәнгате факультетынын декан вазифаларын да үти.

Ул–Татарстанның (1970), Каракалпак АССРнын (1980), Россия Федерациясенен (1985) атказанган сәнгать эшлеклесе. Муса Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты.

# ҮЗЕБЕЗНЕҢ РӘССАМ

ЭРОТ ЗАРИПОВКА 70 ЯШЬ

Күренекле рәссам, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Эрот Якуб улы Зарипов 1938 елның 20 июлендә Пермь өлкәсенең Уинск районы Иштирәк авылында туа, Башкортстанның Янавыл районына караган Ямады авылында үсә. Урта мәктәпне бередә тәмамлаганнан соң, Пермь шәһәрендәге сәнгать студиясендә укый, аннары исә совет армиясендә хезмәт итә. 1965 елда ул Львов каласындагы И. В. Федоров исемендәге Украина дәүләт полиграфия институтын тәмамлый һәм Казанга эшкә кайта. Рәссамның шуннан соңгы гомере Татарстан китап нәшрияты белән тыгыз бәйләнә. Ул нәшриятның техник редакциясен житәкли, бизәлеш мөхәррире һәм китап бизәлеше редакциясенең баш рәссамы вазифаларын башкара.



Житмешенче еллар уртасында Эрот Зарипов Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты аспирантурасында укый һәм шушы институтта берничә ел дәвамында өлкән фәнни хезмәткәр булып эшли. Шул елларның вакытлы матбугатына күз салсаң, еш кына аның мәкаләләренә тап буласың. Болар—замандаш рәссамнарның ижат портретлары, күргәзмәләр хакында язмалар, татар рәсем сәнгате тарихына кагылышлы тәфсилле мәкаләләр. Рәссамның тарихи портрет жанрына кереп китүе дә шушы елларга туры килә. Ул XIX гасыр ахыры һәм XV йөз башында яшәгән татар мәгърифәтчеләренең портретлар сериясен ижат итә башлый. Рәссамга иске фотосурәтләр, тарихи китаплар, сүз тасвирламалары ярдәмгә килә. Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәржани, Гали Чокрый портретлары әнә шулай туа. Ул чакта Татарстанның Милли китапханәсен житәкләгән Разил Вәлиев рәссамга күренекле татар мәгърифәтчеләренең тулы сериясен эшләргә тәкъдим итә. Бүгенге көндә Эрот Зариповның ике йөздән артык портретны берләштергән "Татар мәгърифәтчеләре һәм әдипләре" сериясе мәктәпләр һәм башка уку йортлары өчен дә чын мәгънәсендә хәзинәгә әверелде.

Соңгы унбиш ел дәвамында Эрот Якуб улы "Багышлаулар" сериясен ижат итә. Шәүкәт Галиев, Гариф Ахунов, Иллар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Роберт Миннуллин кебек әдипләргә "багышлау"лар зыялы жәмәгатьчелектә зур кызыксыну уятты.

Эрот Зариповның пейзаж жанрындагы әсәрләре дә байтак күргәзмәләрдә катнашып, лаеклы бәя алды. Заманында рәссам "Авыл" ижат төркемен оештыручыларның берсе булды.

2006 елда Татарстан китап нәшриятында рәссамның тулаем ижатын чагылдырган "Заман көзгесе" исемле альбом-китап (кереш сүз авторы—М. Закир) дөнья күрде.

Журналыбызның, татар әдипләренең якын дусты рәссам Эрот Якуб улы Зариповны юбилее белән котлыйбыз, аңа яңа ижат уңышлары телибез!

Кадим
Җәмитев

# КАЙТТЫМ ГЕРМАН ҖИРЕННӘН

СКУЛЬПТОР ЯЗМАЛАРЫ

## "Кызлар исе" керде

Үз-үзенә игътибар итә башлау, кызларга гына түгел, малайларга да килә икән ул. Дөрес, "ярыйсы гына" аерма белән. Аерма безнең файдага түгел: кызлар иртәрәк өлгерүчән була бит.

Язгы хисләр, шуның нәтиҗәсендә килеп чыга торган гашыйк булулар—үсмерлек чорында табигый нәрсә. Хисләр тулып, үз-үземә игътибар итә башлау менә шушы чорга туры килде дә. Хисләр генәме—"кызлар исен" тоя башлыйсың бит! Кайчандыр, "тышкы дөнья" тынгылык бирмәгән булса, хәзер инде "кызлар дөньясы". Үзләре магнит сыман тарталар, үзләре читкә этәрәләр—менә бит нинди хикмәт! Әлбәттә, бу нәрсә мине дә әйләнеп үтмәде. Яшүсмер көннәренең берендә бер кызга гашыйк булдым мин... Үзе генә белмәде... Сонрак кына сизенде ул аны. Авыл тынганнан соң өйләре каршыннан үтә идем мин аның. Тәрәзәләрендә әле ут булса да, карамаска тырыштым. Хисләр, хисләр... Кайнап-ташып тора. Ничек кенә илтеп җиткерергә аларны үзенә? Нинди юллар белән?

Ысулы табылды.

Алда Яңа ел бәйрәме тора иде. Котларга булдым мин аны. Үзем ясаган БҮЛӘК белән. Калын китап кадәрле бизәкле "сандык" булырга тиеш иде ул. Катыргыдан ясап ак кәгазь белән тышлап чыктым мин аны. Төсле буяулар белән бизәкләдем. Фанерадан челтәрләп рам кистем дә эченә "күренеш" ясап беркеттем. Шушы "менә дигән кәртинкәне" сандык өстенә авыштырып утырттым. Булачак бүләкне камилләштерү моның белән генә чикләнмәде әле: кибеттән кечтеки генә ислемай алып кайтып "сандык" эченә урнаштырдым. Нәтиҗәдә кызыклы да, матур да бер нәрсә килеп чыкты кебек...

Күрмәсеннәр дип, мин аны күбрәк төннәрен эшләдем. Ә ислемайны... үз акчама алдым. (Язгы-көзге чорда авыл кешеләре китергән резин итекләр ямап акча эшли идем инде мин.)

Аның тагын да кыенрагы—тапшыру иде әле. Үз кулына тапшыру турында сүз дә булу мөмкин түгел. Болай да кызлардан читләшү гадәте булып, гашыйк булганнан соң мин аңа якын да килә алмадым. Үзе чыгып алыр дип капка төбенә куеп китә алмыйм бит инде мин аны. Җае чыкты: шул очта яшәүче бер малайны ялладым. Үзе өйдә вакытны туры китердем дә төргәгемне тоттырып кертеп җибәрдем мин ул малайны! "Бирдем" дигән сүзеннән башка берни дә белә алмадым.

Шушы бүләк-әсәрем аша җиткергән беренче яшьлек хисләремне аңлый алдыңмы икән син, башымны әйләндергән зур күзле, зифа буйлы Гөлзифа?!.

## Кавый абый мәктәбе!

Җидене бетергәндә укуымны дәвам итү өчен Икшермә урта мәктәбенә барасымны белгәч, "Сине анда көтәләр инде"—диде укытучы Равил абый. Әллә чынлап,

*Ахыры. Башы 5, 6нчы саннарда.*

әллә шаяртып. Мин килгәндә, андагы укучылар саны әйтеп бетергесез—меннән артык иде. Унбишләп, авылдан килеп укыйлар булып чыкты. Дөрестән дә мәктәп директоры Кавый абый Байкиев беренче күрүдә үк мине танып алды: "Синең кебекләр монда бик кирәк",—диде ул, күпмәгънәле итеп...

## Кавый абыйның олы хуҗалыгы

Дәрес әзерләүләр безнең кичен, сыйныф бүлмәләрендә бара иде. Мин—аерым бүлмәдә... Моннан икеләтә файда булды—чыкы-чыкы килүче кызлардан кача алуым үзем өчен булса, шау-шу, ыгы-зыгыдан кача алуым—мәктәп өчен: рәссам эшләрен башкару өчен тыныч урын да кирәк бит.

Авыл җирендә олы мәктәп үзе бер хуҗалык бит ул. Тәҗрибә бакчасы, мул җирле биләмәләр... Кавый абыйның мәктәп дип исәпләнгән хуҗалыгы гадәттән тыш хуҗалык иде. Мин "сигезгә" килгәндә әлеге "гадәттән тыш хуҗалыкта" бер көтү хайваннар бар иде. "Күп кенә атлар, хәтта дуңгызлар да. Болардан тыш, "тимер ат" лар белән үзйөрешле арбалар тупланмасы... Тагын әле күпме эшче-хезмәткәрләр...

Казанышларының берсе буларак, Кавый абый эшләтә белде. Балаларны да, олыларны да. Эшләтә алуының сере—тәмле тел, кайнар азык—шушы ике нәрсәдә... Кавый абый, һәрбер эшне үзе җитәкләп, мәсьәләне ышандырырлык итеп аңлатып бирә алды. Аның бөтен эшчәнлеге, омтылы-шы, хыялы мәктәп хуҗалыгын туктаусыз үстерепянартып торып, аңа әлегәчә беркемдә булмаган яңалыклар кертеп, "күренекле", "алдынгы", "беренче" булу иде.

Аның хуҗалыгын туктаусыз үстерүгә юнәлдерелгән уй-фикерләр ташкыны кайнап торган казанны хәтерләтә иде. Шуның нәтиҗәсендә үзен-үзе җәлләмәде, үз-үзенә рәхимсез булды, тынгылык күрмәде, башкаларга да тынычлык бирмәде.



*Сак-Сок. 1992 ел. Шамот. К. Җәмитев эше.*

## Чын егетләр эше—Кавый абыйча...

Кавый абыйның үз җитәкчелегендә башкарыла торган "чын егетләр эше" бар иде әле ("чын егетләр эше"—аның үзе әйткән сүзләр). Урман кисү дип атала ул. Әлеге эштә дөрестән дә чын егетләр—"тугыз", "ун", "унбер"ләр генә катнаша алды. Урман кисүләр утынга тураклау өчен генә түгел, бүрәнә-баганалар хәстәрләү өчен дә була иде.

Бу эш күбрәк кышкы чорга туры килер. Урманда... Тирән кар ерып... Агачны еккач, тураклар га да кирәк бит әле. 3-4әр метр озынлыкта итеп. Аннары трактор арбасына төяргә кирәк. Кайда тәгәрәтеп, кайда өстерәп, кайда күтәреп дигәндәй...

Укучыларны үгетләп торуның кирәге юк. Әйт кенә—үзләре үк торып йөгерәчәкләр. Аларга, ни өчендер, дәрестән азат ителү кыйммәт. Аның каравы, Кавый абый аларның мөмкинлекләрен чамалый алды. Белде ул шулай ук нәрсә "ярый", нәрсә "ярамый". Әйтик, сентябрь аенда балалар хезмәтен бәрәңге-чөгендер алуда куллану—хәтта ай буе да—ярый. Шул ук балаларны трактор арбасына утыртып, дөресрәге, дыңгычлап төяп (баскан килеш!) чокырлы-авыш юллардан нинди дә булса эшкә алып йөрүләр, яисә шул ук урман кисүләр (олы-олы агачлар була дигән сүз бит) балалар өчен катгый тыелган—шуңа күрә ярамый булып чыга. Шунда берәр хәл килеп чыкса? Аның, дөресен әйткәндә,

ул турыда уйларга вакыты да булмагандыр. Хуҗалыгын туктаусыз үстереп-яңартып торып, яңа үрләр яуларга кирәк иде ана. Алла саклады үзен: җинаять итеп карый алырлык хәвеф-хәтәрләр килеп чыкмады—бәхете булды.

...Тирән кар ерып, агач егып утын әзерләгән чакларда, эшләп ярыйсы гына арыгач... пилмән ашарга утырта иде ул безне. Кышкы урманда кайнар пилмән! Пилмән дигән нәрсә миңа елына бер мәртәбә эләксә эләккәндер. Ә монда... Югыйсәм, бәйрәм дә түгел бит—затлы ризык, аша туйганчы! Шундый сыйдан соң, ничек инде "чын егетләр эшенә" бармыйсың...

## Рәсемнән... "2"ле?

Мәктәпне тәмамлагач, Казан сәнгать училищесына барасымны укытучылар белә иде инде. "Шулкадәр оста ясап, сине бернинди имтихансыз алачаклар—менә күр дә тор!"—диләр иде алар миңа еш кына...

Ә мин керә алмадым.

Укытучыларның артык хуплавы мин-минлекне шулкадәр көчәйткән, аның ише уку йортына барып укырга керә алуымда бернинди шик тә калмаган иде. Бу хәл мине үтереп ташлады. "Тегеләр" ялгышканнардыр, бәлки? "Ялгышканнарын" белгәч, гауга куптардым. Имтиханда ясаган эшләремне күрсәтүләрен сорадым. "Ярамый" диделәр. Ректорга киттем. Каршы килмәде, ярдәм итте... Рәсемемдә баш хәтле "2"ле (!) тора иде. Укытучыларыма мин кайгымны әйтә алмадым. Ләкин без капчыкта ятмый. Бу хәл озакламый билгеле булды. Үземә генә түгел, укытучыларым өчен дә кайгылы нәрсә булды бу...

Казан училищесына имтихан бирергә Кави абый белән барырга туры килде. Иртәгә чыгарылыш кичәсе дигән төндә утырып чыгып киттек без.

Мин капчык-капчык бәрәңгеләр өстендә, йөк машинасында. Җил ыжгыра, рәхәт. Ярый әле җәйге чорның җылы төне. Юлда ике каен үсентесен егып салдылар. Миңа түшәк булсын өчен түгел, кемгәдер мунча себеркесе итеп алып бару өчен. Таң атканда Казанга килеп җиттек: Бер апага урнаштырды мине Кави абый. Түләтмәде дә—рәхмәт.

Озак вакытлардан соң шушы нәрсәне искә төшереп уйлап алдым: шул кадәр булдыклы-башлы Кавый абыйның башына бер нәрсә барып җитмәгән. Анда керү өчен махсус әзерлек үтәргә кирәк булган бит! Ярар, гади укытучылар "бернинди имтихансыз керә" алуыма ышансыннар да. Ә күпләрне күргән-ишеткән Кавый абый "сурәт җене кагылган" егетнең язмышын бик ансат хәл итәргә уйлады микәнни?

## Клуб мөдире

Кайтып керүгә, әбием әйтмешли, тынгысыз эшкә—клуб мөдире итеп куйдылар. Уйлап чыгарулар минем өчен "көндәлек" нәрсә иде. Төрле лозунг—күрсәткечләр: плакатлар ясау-язу белән беррәттән, мин кайбер нәрсәләрдә яңалык та керттем. Моңача булмаган декорация дигән нәрсәне ясап, сәхнә артына элдем. Хәзер инде, тамаша вакытларында тамаша куючылар "каеннар эченнән" килеп чыга торган булды. Аннан тыш, сәхнә пәрдәсен берүк вакытта ике якка да ачыла торган иттем.

Моның ише яңалыкларны халык та хуплады, җитәкчеләр дә күрде. Үземә дә ошап, күңелемә хуш килә иде: мин бит боларны кемнең дә булса кушуы буенча түгел, күңел кушуы буенча эшли идем. Яратып. Шуңа күрәдерме, минем ул чорда кызлардан читләшү булмады да. Уеннар оештырып, гармунда уйнап, җырлатып-биетеп кенә калмадым, гармунымны куеп торып, пластинка җибәреп үзем дә уенга кушылып китә идем.

Көчебездән килгәнчә пьесалар өйрәнеп, театр да куйгалый идек. Атна ахырында кино булса, икенче атна ахырында тамаша кылу була иде. Кышларын күрше авылларга да баргаладык.

## Язмыш җибәргән фәрештә

Әйе, "рәссам булам" дип, биш яшемдә үк белдергән идем мин. Шуна омтылуда, язмыш кушуы нәтиҗәсендәдерме, бер көтелмәгән хәл булып куйды. Клубта эшләгән вакыт иде... Көзге пычрак төннәрнең берсендә язмыш миңа Югары Көч аша Фәрештә җибәрде. Бер юлаучы иттереп. Авыллар арасында бизәкче эше буенча көн күрүче бер агай булып чыкты ул. Күрше авылдан—мин аны белә идем инде. Ул заманда һәрбер клуб, кибет, оешма аталышын калайга бизәкләп-язып түбәгә элү бар иде. Менә шушылар буенча оста иде ул, Вакыйф абый.

Тәрәзәдә ут яктысы булгач, кереп кунып чыгарга булган ул. Ә мин Ленин портретын ясап маташа идем. (Еш кына төннәр буе да утырган чаклар булды.) Рәсем белән "җенләнгәнемне" белә иде инде ул.

—Син Шәмәрдәнгә барып Вил Гарипов дигән рәссамны тап әле...—диде ул миңа менә-менә ясалып бетәргә тиешле соңгы "әсәремне" җентекләп карап алганнан соң.—Сиңа аның белән танышырга кирәк. Ул кайдадыр укый...

Икенче көнне үк Шәмәрдәнгә сәфәр кылдым.

Минем кинәт кенә китеп баруымны эштә генә түгел, өйдә дә белми калдылар. Илле чакрым аз ара түгел. Яртысын утырып, яртысын җәяүләп үтәргә туры килде миңа ул араны.

## Рәссам белән танышу

...Мәктәп ишек алдында физкультура дәресендә таптым мин аны. Дәрес беткәч, читкәрәк китеп утырдык. Таныштык. Омтылышым турында әйттем. Өйдә эшләгән бер төргәк кәгазьләремне җәеп салдым. Ә ул, тиз генә күз йөртеп чыкты да, нәрсәләрдер әйтергә тотынды. Үземә карата мактау сүзләре чыкмагач, мин юньләп тыңламадым. Укытучыларымнан, күп кенә авылдаш-күршеләремнән ишетә торган: "Менә булдыргансың!", "Шәп тә соң, ә!..", "Шушы кадәр оста ясарсың икән!..—ише сүзләр көткән идем мин аннан. Ә андый сүзләр ишетелмәде.

Юкка гына килеп йөргәнмен, дип уйлап алдым да таралып яткан төргәгемне җыярга тотындым.

—Шөгыльләнеп карарбыз, берәр нәрсә килеп чыкмый калмас,—дип, шулай да өметләндерде ул мине.

Без икенче көнне үк эшкә керештек. Дәресләр баштан ук бик мавыктыргыч башланды: иртәнге сәгатьләрдә өендә—карандаш белән ни дә булса карап ясау, кичен табигатьтә—төсле буяулар белән күренеш ясау. Башта, аңлашыла ки, ул "ясый". Мине хәйран калдырганы—аның үзе белән йөртә торган этюдник—буяулар тартмасы һәм күренеш ясау җайланмасы.

...Кечкенә генә ике төрле пумаланың алмашлап эшләп торуы нәтиҗәсендә җайланмага беркетелгән кәгазьдә, акрынлап, күренеш ачыла башлады. Ул күренеш торган саен тулырак-ачыграк була барды. Мин моңа сихерләнеп карап тордым. Үзебезнең Мишә буйларын миңа да шушындый ук осталык белән чагылдырасы иде! Беркемгә бер нәрсә белдермичә бер атна буе яттым мин анда. Шөкер, тикмәгә булмады. Карандашны дөрес тоту, акварельне дөрес куллану кагыйдәләрен өйрәндем мин шул чакта.

## Даһи образы—минемчә

Даһи Ленинның "сүнмәс образын тудыру" дигән нәрсә бик нык борчый иде мине. Мәктәпне тәмамлаганда булды бу.

Мәсәлән, Томский (совет чорының атаклы сынчысы) ул нәрсәне искитәрлек итеп тудыра алган. Шуның белән бөтен Совет халкын шаккатырган. Кавый ага үзенең тарих дәресе ахырына кайтып төшеп сөйләгән иде аны.

Әбиемнең искергән өстәл җәймәсен алдым да шуңа Ленинны ясарга керештем. Укытучым Кавый абыйның кызыктыргыч сөйләменнән чыгып, Ленинның аеруча акыллы булуына басым ясарга кирәк иде миңа. Ленин сурәте белгечләреннән Томский гына түгел, Андреев кебекләр дә аның шушы ягын исәпкә алып, маңгаен

кирәгеннән артык биек итә торган булганнар бит.

Әгәр дә акыл дигән нәрсә чиксез икән инде, дип уйлап алдым мин шунда—ул бер яклы гына үсеш ала алмый. Томскийларныкындагы кебек, өскә генә "ыргылырга" тиеш түгел, ягъни мәсәлән. Шушы төгәл фикерләүне күз алдында тотып, "артык" акылны мин башының арткы өлешенә юнәлтмәкче булдым. Шулай иттереп, сурәтем нәтиҗәдә ике сарылы йомырка рәвешен алды.

Чамадан тыш акыл индерелгән әлеге баш... җилфердәп торган кызыл байрак каршында сурәтләнде. Әле анда дүрт хәрефтән торган дәһшәтле "КПСС" бар иде. Даһиның йөзен-карашын Андреев рәсеменнән алдым. Мин аны төннәрен, кеше йоклап беткәч кенә башкардым. Шуңа күрә аны беркем белмәде. Чамадан тыш сизгер әбиемнен: "Карап аны кем дә ясый",—дип әйтүен теләмәдем мин. "Тач Лилин инде, койган да куйган!", йә булмаса: "Бу кадәр охшаса охшар икән, ә!.."—дия иде һәр күргән кеше аны. Шулай да, берәү—ә ул Ленинны бигүк яратып бетерми торган көтүче булып чыкты—сурәткә карап торды-торды да әйтеп куйды: "Ни өчен син аның башын менеке шикелле иттең? Артка бүселдерден? Шулай куштылармы, әллә ул дөрестән дә шулай булып, халыкка гына белдермәгәннәрме?"

Кирәгеннән артык акыллы итсәм дә, районның һәвәскәрләр күргәзмәсендә аңа икенче урынны гына бирделәр. Беренче урынны әләктерүче... Вил Гарипов үзе булып чыкты. "Мин ул Ленин башын ярты сәгать эчендә эшләп ташлыйм, ипидер!"—дип мактанганы булды. "Акылына берничек басым ясалмаган шушындый гади портретка беренче урын?!! Өстәвенә, ярты сәгать кенә ясап?.." дип гаҗәпләнеп алган идем мин шунда.

## Мин—шәкерт

Иҗауда укырга кергәндә имтихан бирү үзе бер тамаша булды. Башлангыч сыйныфларда укыганда үз телем ничек авыр булса, монда урыс теле... (Удмурт җирендә минем татар мәктәбен бетерүем исәпкә алынмый бит.) Урыс теле чын мәгънәсендә минем өчен чит тел булды. Язмача гына да түгел бит... Тагын физикасы, тарихы бар. Ярый әле һөнәрем буенча телдән булмады... Язмачаны яздым. Күчереп булса да. Тарихын да бирә алдым. Ә физиканы... Имтихан алучы үзе дә аптыраштa. Бер миңа карый, бер—өстәлендәге кенәгәсенә.

—Миңа син кызганыч, Замитов. Менә бит: һөнәрең буенча гел "5"леләр. Болай эшләп карыйк. Күрше аудиториядә "физиклар" бирә. Шунда кер дә әйт: Петр Петровичтан диген. Ул сиңа билет бирер...

Белмим, әллә сораунын җиңелрәге әләкте, әллә соңгы көчем-кыюлыгымны җыепмы—пупаладым. Әлбәттә, минем максат—һөнәрем буенча укып, биргәнне мөмкин кадәр күбрәк үзләштереп рәссам булу. Тик, шунысы гына... урысча укыйсы бар! Беренче ел—беренче курс минем өчен аеруча авыр ел булды. "Чит" тел миңа озак вакытлар киртә булып торды. Рәхмәт мөгаллим-педагогларга—тырышканны күреп хәлемә керәләр иде. Ә Барковская... сәнгать тарихыннан... Урыс телен су урынына эчкәннәрне дә борып чыгара иде ул. Белмим, кайдан андый явызлык—үзен егетләр яратмауданмы?.. Яше инде барса да, ялгыз гомер итүен белә идек без аның.

Кызлар дигән нәрсә монда да бар бит. Бар гына түгел, шыгрым тулы. Ниндиләре генә юк... Авылныкылардан тыш... шәһәрнекеләр күпме бит!

Беренче курс минем "чит тел" үзләштерү белән үтте.

## Пычаксыз операция

Белмим, ничек килеп чыккандыр, көннәрнең берендә үзәк урамдагы стоматологиягә килеп әләктем. Бөтен кыюлыгымны җыеп барын да ачып салдым. Мине карадылар... Берәрләп тә, берничәләп тә. Ахырдан "доктор Айболит"ка охшашлы бер агай килеп чыкты. Карады, яңак сөяген капшады, эттe-тартты, каергалады... Авыртты—түздем. Бер генә дә капшап карамаган җире калмагач, болай диде:

—Иртәрәк килергә иде, егет, иртәрәк... Җиде яшьләрдә. Һич югы—ун-унике яшьләрдә. Хәзер инде соң. Беләсеңме ни өчен? Сөякләрең каткан инде. Бөгеп булмый, аңлыйсыңмы?..

Юк, мин аны аңларлык түгел идем. Доктор булып, ул да ярдәм итмәсә, кем ярдәм итә алыр миңа?

Текәлеп аңа карыйм. Сүз белән берни әйтә алмыйм. Яшьле күз карашым аша укый алгандыр ахрысы ул үтенү, ялвару сүзләремне... Зур бәлагә килеп эләккәндә генә була торган бәгырь сыкрануын тоймый калмагандыр...

—Ярый, ярый... Аңлыйм,—диде ул беразга уйга калып.—Мин консилиум җыеп карыйм. Ягъни, үзебездәге барлык белгечләрне... Кинәшү өчен. Нинди килешүгә килсәк, шулай булыр. Мона... ризамы син, егет?

Ничек инде риза булмыйм ди—ни дә булса эшләсеннәр генә!

Өч-дүрт сәгать вакыт үткәннән соң ап-ак халат-калфаклардан килеп керделәр... Санап чыктым: җидәү иде алар. Икесе—хатын-кыз. Мине махсус урынга яткырып көчле яктырткычлар кабыздылар. Җидесе җиде яктан чорнап алдылар. Миңа төбәлгән игътибар шулкадәр көчле иде ки, миллионнарча ел элек яшәгән ниндидер "төрнең" сакланып калган берданбер табылдыгы итеп хис иттем үземне. Вакыт-вакыт нәрсәдер әйтеп, минем тирәли әле бер, әле икенче якка күченеп йөрделәр. Башымны капшадылар, авызымны туктаусыз ачтырып тордылар. Арып, ачып тота алмас хәлгә җиткәч, берсе каерып ачып тотты.

Байтак кына азаплаганнан соң әүвәлге доктор, барысының игътибарын үзенә юнәлтеп, нидер сөйләп алды. Калганнары да берәм-берәм нәрсәдер әйтте. Мин тыңларлык түгел идем. Тыңлаган булсам да аңламас идем: алар, аңлашылса кирәк, латин сүзләрен кулланып сөйләштеләр. Иң ахырдан нәтиҗә ясау максаты беләндер инде, шул ук күзлекле доктор... озаклап кына үз фикерен әйтте. Консилиум дигән нәрсә ике сәгатьтән артык барды...

Икенче көнне "балалар бүлеге"ндә кабул иттеләр. Яшь-яшь кенә практикант кызлар иде алар. Аңлавым буенча, алар теш тезмәсенең калыбын салдыру өчен үлчәм алырга тиешләр иде. Алар алдында авызымны ачып зәгыйфь тешләремне күрсәтү тагын да кыенрак булды. Кызарындым-бүртендем. Ә аларның йөзләре шатлык белән тулы: үзара сөйләшәләр-көлешәләр. "Моннан соң алар мине беркайчан да күрмәсләр бит, әйдә көлсеннәр..."—дип үз-үземне тынычландырырга тырыштым.

Ниһаять, озак ясалган җайланма әзер... бер яктан куанычлы, икенче яктан... аны туктаусыз киеп йөртәсе була... Кеше күз алдында. Икенчесе (әле анысы да бар) ярый күренми, авыз эчендә...

Кешегә күренмәскә тырышып, әйләнгеч-аулак юллар белән кайтып киттем. Кача-поса... Кайтып җиткәндә башым үтереп сызлый иде. Богаулап куйганнармени...

Ә ул дөрестән дә богауланган иде. Кыяфәтемне мин торакка кайткач кына күрә алдым... Ияктән баш түбәсенә тарттырылган көчле путалар... Тоюым буенча, һәрбер пута эчендә күпсанлы бударгычлар булырга тиеш. Иякта һәм баш түбәсендә шуларны беркетеп торучы "чокырлар". "Богау"ның төсе дә очкычларда гына була торган алюмин төсендә. Көзгедән күргәч, үземнән куркып куйдым: икенче дөньядан очып төшкән җан иясен хәтерләтә идем мин. Тешләр дә "богаулап" куелгач, авыз эчендә әйтерсең кадак катыш ком. Бударгычларны тарттырып торучы ыргаклар иде ул. Кайтып керүгә, мондый хәлдә күреп, дустым куркып һушсыз кала язды.

—Кем сине болай итте, дус!?—диде ул, мине кочып алып.

Авызымны ачып әйтергә җыенган идем, ботка килеп чыкты... Өстәвенә, авызым тулы кан икән. Тырпаеп торган ике баштагы ыргаклары авыз эчен ерткан булган.

Атналар, айлар үтә торды. Баштарак, авырту-сызлавына түзә алмыйча ул нәрсәне салып ыргыткан вакытлар булды. Икесен дә. Әллә ничек иттереп баш авыртты. Кайвакытларны, башымны тимер богау эченә кыстырып куйган кебек була иде. Каты тартылудан алгы тешләр сызлады-сыкранды.

Атна-ун көнгә бер юынуны исәпкә алмаганда, бер дә салмадым мин аларны... Ашаганда-утырганда, көндез-төнлә дә. Баштарак, сөйләшү генә түгел, сүз әйтү дә мөмкин түгел иде. Бу хакта бернәрсә белмәгән курсташларым миңа башта саклык белән, аннары шикләнеп карый башладылар. Әллә ниләр уйлап чыгардылар...

Докторның кушуы буенча баштарак атнага бер мәртәбә, сонрак айга бер күренеп тордым.

Ярты ел үткәндә нәтиҗәсе күренә башлады. Аскы тешләр бик авырлык белән булса да эчкә авыша башладылар. Чыгып торган ияк тә каты тарттыру нәтиҗәсендә урынына "угыра" башлады. Ярты елдан ул богаулар янага алышынды. Болары инде тагын да катырак булып чыктылар. Нәкъ бер ел да бер айдан соң богауларның кирәге булмады инде—салып ташладым... бөтенләйгә.

Моның белән генә әле эш бетмәде.

Аскы-өске тешләр арасында бармак сыярлык аралык кала бирде. Шунлыктан, сүзләр элеккегечә үк булмаса да "азапланып" чыгалар иде әле. Бу нәрсә докторның үзен дә уйландырган. Аралыкны ябу өчен тешләрне үстереп булмый. Моны мин үзем дә аңлый идем. Моның өчен доктор үзенең нииндидер авырттырмый торган ысулын кулланды: мин моны соңрак аңладым. Гади генә булса да, бу нәрсә атна буена барды. Әйе, ияк сизелерлек артка чигенде. Тешләр ярыйсы гына турыланды, ике арада булган аралык бетте дияргә була. Әлбәттә, болар белән генә "коеп куйган" егет кыяфәте була алмады. Шулай да...

Иң куанычлысы—сөйләшкәндә телем элеккечә бүселеп чыкмас булды. Бу миңа кызлар янында үземне кыюрак тотарга мөмкинлек бирде. "Миннән көләләр" дигән уй да кими төште. Ә оялу дигән нәрсә, гадәт буенча дәвам итте... Үземне егетләрчә ышанычлы итеп тота алу өчен тагын күпмедер вакытлар кирәк булды. Шуннан соң гына кызлар дигән көйдергеч тә, сөйдергеч тә токымга курыкмыйча якыная башладым...

## Мин—тәҗрибә кроликы?..

Богауларны салып ташлап иркен сулыш алгач, коньяк кыстырып докторга килдем. Алмады. Эшли башлагыз әле, аннары килерсез, диде.

Мин аны башкача күрмәдем. Эшли башлагач, ә ул өч елдан соң иде—килдем.... Инфаркт белән китеп барды, диделәр. Тагын берничә елдан шул якларга килеп чыккач, дустым белән очрашып бер ашханәгә кердек. Күрше өстәл артында ике ханым утыра. Иптәшем аларга игътибар итеп өлгергән икән инде. Матурлык ияләре булганга түгел, үзләрен сәер тотканга...

—Кара әле, кара, тегеләр гел сиңа карап-карап алалар,—ди бу миңа.

—Кит әле, булмаганны,—дим.—Ни өчен алар син барында миңа карасыннар.

—Ышанмасаң, әнә үзең кара.

Игътибар иттем. Дөрестән дә... Нәрсә булыр бу, дип гаҗәпсенеп яннарына ук киләм.

—Сез минем дустыма карап-карап аласыз, танышырга телисезме әллә,—дигән булам.

—Юк, без Сезгә карап-карап куйдык.

—Ярар, минем белән дә танышырга була...

—Ә без Сезнең белән таныш инде...—дип серле генә елмаеп та куйдылар.

Аларның шаяртуларына бернинди дә шик юк иде миндә.

—Хәтерлисезме...—дип сөйләп китте шунда берсе.

Теге вакытта көлешә-сөйләшә мине калыплаган шат күңелле практикант кызлар булып чыкты алар. Вакыт агышы аларны олыгайта төшкән, тулыландырган, өлкән ханымнар кыяфәте керткән үзләренә... Миңа уңайсыз булып куйды. Кызарынып та киттем. Менә сиңа, мә! Уйламаганда... Аларның хәрәкәтчән кечтеки генә куллары астында утырганда, "алар мине башка беркайчан да күрми бит", дип үземне тынычландырып утырган идем бит. "Тау белән тау гына очрашмый", дип тикмәгә генә әйтмәгән икән борынгылар. Тора-бара төсмерләдем мин аларны. Әйе, менә бар иде берсенең...

Беренче эш иттереп докторны сорашмый булдыра алмадым.

—Ул чын мәгънәсендә доктор иде. Табиб булган өчен генә түгел... Галим... Туктаусыз экспериментлар алып барды,—дип сөйләп китте алар бер-бер артлы.—Аның өчен сез күпмедер дәрәҗәдә кролик булдыгыз... анысын беләсезме? Ул бит

медицина тарихына мәгълүм булмаган яңа ысул белән эш итте. Сез... йә "кеше" булырга тиеш идегез, йә...

—Йә, кем?!—дидем мин шундук, кабынып.

—Тәҗрибәсе барып чыкмаган кролик... Үзегез аңлыйсыз инде... Сезгә ул вакытта унсигез яшьләр бар иде бугай...

—Егерме бер ярым,—дип "өстәп" куйдым, ачыклык кертеп.

Мина эсселе-суыклы булып куйды.

—Анысын беләсездер, елдан артык диссертация язды бит ул. Шулар нигезендә... Аннары... Башыгызга кидерелгән тасмаларның нәрсә икәнен чамалагансыздыр? Аның эчендә, будыргычтан тыш, "каткан" сөяккә тәэсир итә ала торган ниндидер нәрсә булырга тиеш иде... Әйе, каткан сөякне "бөгә" алуны исбатлау иде аның максаты. Шуның нигезендә докторлыкны яклау өчен керешкән иде дә... Якларга өлгергәндерме—анысын без белмибез...

## Нәгълә́т төшкән Кремль...

Авылыма каникулга кайтуга, кышынмы, җәенме, кая да булса алып китәләр иде мине. Бизәкләү эшенә...

Бер җәйге кайтуымда күрше авыл мәктәбендә зур гына бер сурәт ясарга туры килде. Мәскәү Кремле сурәте иде ул. Урам якка эленергә тиешле, юк-бар буяу белән генә ярамый... Гадәттә, мондый нәрсәләр киндер тарттырып, яисә фанерага ясала. Эзләделәр-эзләделәр, аның ише нәрсәне тапмадылар. "Мә, яса шушына—чыдамлырак булыр", дип кара яшел тукыма (сукно) китереп бирә мина хуҗа. Ярар, дим. Әле мондыйга ясап караганым юк үзе.

Яшел төсне юк итү өчен ак буяу яздырып алдым. (Аның нигезе ак булырга тиеш иде.) "Буяу шушы гына... буйыйсы нәрсәләр әле күп, яртысын калдырырсың",—дип, мина бер чиләк иттереп бирделәр. Ясыйсы сурәт тә кечкенәдән түгел: буе—ике, ине—бер метр чамасы.

Эшкә керештем. Яшелне капларга дип әйтүем. Нәрсә бу? Буяп барам, буяу юкка чыга бара. Калынрак иттереп сылыйм—шундый ук хәл. Гел сеңеп бара... Бәлки, кипкәндә ачылыр, дим. Сылый торгач бер чиләк буявым юкка чыкты... Үзем дә шаккаттым. Ә хуҗа белсә... шаккатып кына калмас әле. Булса булыр инде, дидем дә киттем кибеткә. Кая ул андый нәрсә булу—булганы да юк, диләр. Рәхмәт кибетчегә, бөтенләй буш чыгарып җибәрмәде, кинәшен булса да бирде. Теге бер чиләк буяуны биргән мөдиргә барырга... Бер ярты кыстырып.

"Кара аны, беркемгә дә әйтәсе булма, белсә хуҗа мине асып куячак",—дип яртыны алды да өч килолы буявын биреп җибәрде. Киләм... Бер чиләк буяуны йоткан тукымам соң көзгә уҗымны хәтерләтә иде. Әйтерсең, ул "уҗым"га беренче кар бөртекләре төшкән... Кыймылдатып карыйм—балчык белән сылап куйган мени: күтәрерлек булмаган! Кипсен әле бу ике-өч көн тирәсе, дип китеп бардым. Өлгертү өчен әле вакыт бар. Берничә көннән соң киләм дә капшарга керешәм: кипкән! Ничек кипмәсен ди, җәйнең коры вакыты бит. Икенче кат буярга керештем. Күңел күтәренке... Буяу да табылды бит. Үлчәп биргәнмени мөдир—таман гына булды.

Үзем белән алып килгән кысып чыгара торган нәфис буяуларым белән тиешле сурәтне ясарга керештем. Вакытны әрәм итмим, дип кичкә кадәр ясадым да ясадым... Ясалган төшкә игътибар итеп карасам... тагын "уҗым" бәреп чыккан. Берәр әфсенләгән-каргаган нәрсә булып чыктымы соң әллә бу, дип уйлап алдым. Нишләргә?.. Киттем кабат буяу эзләргә... Берәр атна эчендә җитәрлек кадәр ничек тә буявын да табармын, "уҗым" бәреп чыга алмаслык таш булып сурәт да катар... Рәхмәт Кавый абыйга (авыр туфрагы җинел булсын), ул коткарды. Дөрес, бер атна эчендә ана үзем дә ярдәм иттем. Ниндидер альбом бизәкләргә кирәк иде ана.

Кабат килгәндә полотнам дөрестән дә шакыраеп каткан иде. Өч көн эчендә дүртмә-бишме йолдызы балкып торган Кремль сурәтен ясап ташладым. Директор канәгать иде. Ә буяуның артыгын кайтарып бирмәвем өчен сүкми булдыра алмады. Чакыртып "гонорар" бирделәр. Артык тоткан буяу бәясен исәпкә алып, әлбәттә. Акчаны яхшылап төреп эчкә үк тыгып куеп, кайтырга чыктым. Коеп яңгыр яварга

тотынды... Ара—җиде чакрым... Өстә күлмәк-ыштан да, чүпрәк халат. Яңгыр орды да орды! Кайтып җиткәнче. Ул яңгыр әллә кай җирләремә үтеп керде. Куен кесәсенә тыгып куйган кечкенә кәгазь төргәге генә дәрт өстәп, юл буе мине җылытып кайтты. Үзем эшләп тапкан акча бит!

Тик, шунысы... Кайтып кергәндә танымаслык булып буялып беткән иде ул акчалар... Кесәмдә... бакыр купоросы булган икән (буяуга кушу өчен куллана идем мин аны).

Икенче вакыт кайтуымда—ә ул кышкы каникулда иде—беренче булып шул ук мәктәпкә чакыру алдым. Алайсам, ошатканнардыр, нигә бармаска: бераз булса да акча эшләп алу зыян итмәс!

Килсәм—ясаган Кремлем тагын "яшәреп" чыккан бит! Бу юлы инде язгы чирәм кыяфәте иде анда. "Нәгъләт төшкән Кремль" дип уйлап алдым да, киттем авылыма. Киндер булмаса, фанер табарга да, янабаштан керешергә... Башкача булмый. Бәлки, эш анда гына да түгелдер?.. Гыйлем иясе Җомабикә әби янына кереп бу хикмәтне сөйләп бирим дидем.

"Керәмәл дисеңме? Теге... патшалар утыра торган җирме әле ул? Ә-ә, элекке заманда Явыз Иван явызлыклар уйлап утырган анда, безнең чорда—Ысталин... Явызлык оясы ул, карале. Шуна күрә дә синең Керәмәл сурәтең барып чыкмаган. Әле тагын йөз ел утырсаң да чыкмас. Әйтимме? Мине кайсыдыр сиезгә дәлихәт иттереп җибәрмәкчеләр ие... Кәмунис булмасам да. Бармадым. Ул сиезләре нәкъ шул керәмәл эчендә булганга күрә... Баш тарт син аннан. Як-ягына каранып өч мәртәбә төкер дә икенче сурәт яса да куй",—дип тынычландырды ул мине.

Җома әбинең әйткәненә колак салмый булдыра алмадым, ни булса булыр дидем дә... Казан Кремлен ясап куйдым. Беркемгә әйтмичә генә... Барыбер Кремль бит... Йолдызы гына бер. Аның каравы, азаплану булмады—бер көн эчендә ясап куйдым.

Дистәләрчә еллар үтте. Кабат чакыручы булмады. Димәк, кабул ителгән диган сүз.

## Язмыш мине сын сәнгатенә китерде...

Сын сәнгате белән мин икенче курста укыганда гына таныштым. Аңынчы бу өлкәне бөтенләй белмәдем дип әйтергә дә була. Бала чакны исәпкә алмаганда... Учак янып торганда әбиемнең камырын чеметеп алып, төрле "казлар" әвәләп кызган кирпечкә ябыштыра идем. Кызарып пешә дә алып ашыйм. Тәмле була иде ул...

Өченче курс ахырында укытучыбыз яртыеллык дәверендә башкарылган эшләребезгә нәтиҗә ясап чыкты. Ахырдан миңа килде дә:

—Бирә алганын бирдем. Алга таба сиңа монда вакыт үткәрү генә булачак. Худфондта Мәскәүдән килеп эшләүче бер сынчы бар. Шуның белән танышырга кирәк сиңа,—диде.

Икенче көнне юк инде мин анда. Үземне белдергәннән соң, әйтәм: "Сынчы булырга телим",—дим. "Әгәр дә син монда акчаны күп бирәләр дип уйлап кына сынчы булырга уйласаң, ялгышасың. Сынчы һөнәре мавыктыргыч булса да, гадәттән тыш авыр һөнәр. Талантка ия булудан тыш, бик нык тырышуны, аны яратуны, вакытың-көчең белән дә санашмауны гына түгел, бөтен тормышыңны багышлауны таләп итә",—дип кисәтте ул мине.

Икенче очрашуга бер күтәрәм эшләремне алып килдем. Алар өч-дүрт ел дәверендә тупланган нәрсәләрем иде. "Менә хәзер сынчы булырга кирәклеген күрәм...—диде ул, игътибар белән карап чыкканнан соң.—Белеп тор, алмаска да мөмкиннәр... Ни өчен дисеңме?—Яшең унҗиде түгел..."

Көннәрнең берендә имтихан бирергә дип мин Мәскәү каласына юл тоттым. Мин керәсе уку йортында минем кебекләр уйлаганымнан да күбрәк иде. Шулардан җидәү (!) генә алынырга тиеш. Аңлашыла: сынчы һөнәре табиб-мөгаллим һөнәре түгел—күп була алмый. Аларның да өчесе-дүртесе конкурска кагылышсыз керә. Дуслык-туганлык аша—без моны белә идек инде.

Владимир Табахмахер (соңрак Табах), мин танышкан сынчының аты шулай

иде—үзе дә авырлык белән генә керә алган. "Коммунист булуым гына коткарды",—дигәне булды аның ахырдан. Менә нәрсә котә иде мине алда...

Документларны тапшырып, имтиханнарга үтә алдым. Әлеге уку йортының (Московское высшее художественное училище) никадәрлегә дәрәҗәле икәнлеге күренеп тора: Союзның төрле почмагыннан килгәннәр анда...

Имтиханнарны бирдем... Тиешле балл җыелмады. Һөнәр буенча "өч"ледән артык куймадылар. Диктант (милли мәктәп бетергәнне исәпкә алып) буенча "5"ле иде. Тарихтан "4"ле... Икенче елга тагын бардым—шундый ук нәрсә. Өченчесендә инде укуны ташлап киттем... Керә алмасам, шунда ук урам себерүче булып урнашам да, ныклап ел буе хәзерләнеп, икенче елга керәм... дидем. Әзерләндем... Кереп карадым: тагын керә алмадым. Урам себерүче булып урнашу дигән нәрсә дә, милициягә урнашу нияте дә барып чыкмады—Мәскәүдә калып мондый эшләргә урнашу өчен... армиядә хезмәт итеп кайту кирәк икән. Дүртенче мәртәбә дә талпынып карадым. Һәр очрактагыча бер балл җитми кала.

Ижауга җибәрелгән Володя Табах.. кабат Мәскәүенә китеп барды... Фатир бирмәделәр... Ә мин хезмәткә—армиягә алындым. Көннәрнең берендә телеграмма алам. Володядан. "Манежда бөтенсоюз рәссамнар Күргәзмәсе ачылды. Аңа син дә "эләктең". Котлыйм... Алга табан да иҗади уңышлар телап, В. Табах"... Берни аңыша алмый аптырашта калдым. Манеж кадәр манежга—ә ул Бөтенрәсәй рәссамнары Берлегенең Үзәк күргәзмә залы—мин нәрсәм белән эләгергә мөмкинмен?.. Дипломсыз... Союзда да булмаган килеш..

Бу нәрсә ярты елдан соң кунакка кайткач ачыкланды. Туп-туры Мәскәүгә, Володяга... Килеп керүгә үк ул миңа калын гына альбом-китап тоттырды: "Мә, актарып кара, бәлки үзеңне дә табарсың..." Актара торгач, дөрестән дә таптым бит: ташта утырып курайда уйнаучы "Бабай "сурәте...

—Сынчы булырлык синдә төп нәрсәләр бар: пластика, фантазия, композиция... Синдә натураны ныклы белү генә җитми.—Бераз тынып торды, аннары дәвам итте:—Беләсеңме, анысын мин үзем дә бирә алам. Дөрес, дипломсыз... Әйдә, бергәләп әзерләнеп карыйк. Дипломсыз художниклар союзына керү тарихта әле булмаган хәл. Белеп тор: моның күпчелеге үзеңнән торачак. Мин бүлдыра алганын бирермен. Ә кирәк булганда син миңа булышырсың. Моны җиңеп чыга алсаң, сиңа Олы Сәнгатькә юл ачык дигән сүз. Беләсеңме, "Берлеккә" эләгү—кандидатлыкка минимумны яклаган белән бер—дипломнан югарырак. Биш ел чамасы тырышу кирәк булачак..."

Хезмәтемне бетергәч, сөйләшкән буенча Мәскәүгә кайтырга тиеш булдым мин. Эшкә урнашырга да әзерләнергә, әзерләнергә... Эштән соң. Кичләрен, төннәрен.

## Мәскәүгә килүләрем...

Шулай итеп, армия хезмәтен тәмамлауга, ныклы уй-хыяллар белән Мәскәүгә юл тоттым. 1973 елның август ахыры иде ул...

Башкала. Серле дә, шомлы да. Тарта да, өркетә дә... Володя Табахның энесе Валера тәкъдиме белән эшкә урнаштым. Кара эшкә—башкача юл юк иде. Анысы да лимит белән. Вакытлыча урнашу дигән сүз. Әгәр биш ел буе үзеңне үрнәк тотсаң, сине Мәскәү кешесе дә итәргә мөмкиннәр, бүлмәле дә була аласың... Валера үзе лимит белән килеп кергән кеше. Ул мине үзе эшли торган оешмага—"Мослифт"ка урнаштырды. Мин килгәнче үк ул анда оетка салып куйган булган инде.

Безнең төзү-төзекләндерү идарәсе иске йортларга тышкы яктан йөри торган кабиналы лифтлар урнаштыру белән шөгыльләнә иде. Астан алып өскә кадәр гел пыяла шахта... Андый шахталарны унике катлы йортларга да куярга туры килде. Менә шул шахталарны пыялалау иде минем алдагы вазыйфам. Аннары "балта остасы" да булырга туры килде әле, эретеп ябыштыручы да...

Ничек итеп булса да миңа үземне рәссам буларак күрсәтергә кирәк иде. Шул уй белән ниндидер бәйрәм алдыннан идарәнең бөтен коридорын бизәкләп чыктым. Дәһшәтле 1917 елгы революциядән алып беренче космонавт Гагаринга кадәр булган вакыйгаларны чагылдыра торган "кәртинкә"ләр булды ул. Ошады—мине рәссам

итеп билгеләделәр. Шунда ук үз почмагым да оешты.

Үз почмагым дигәч тә... Кем дә булса идарәдән килеп шакый икән, кертми хәлең юк. Еш кына төркем булып керәләр иде. Аулакта утырып "салу" өчен. Андый салып утырулар сәгатьләр буена сузыла... Түзсәң—аларга кушыласың, түзмәсәң читкәрәк посып, эшләгән булып кыланасың, яисә чыгып торасың. Аларны кертми дә ярамый, куып чыгарып та булмый: чөнки алдагы көнем—алар кулында... Ярый инде аракыга йөгермәс өчен горурлык дигән көч таптым үземдә.

Гомуми торак... Мин аның нәрсә икәнен белсәм дә... мондагысы тамырдан аерылып тора иде шул. Монда инде эшче сыйныфы вәкилләре: эчүгә әвәс, тавыш-орышка батыр халык.

Остазым, иҗат өлкәсендә зур уңышларга ирешә алмаса да, яхшы мөгаллим була алды. Ул үзе күпкырлы гыйлем иясе. Сәнгать тирәсендәге күп нәрсәләрне тирәнтен аңлап-белеп эш итте. Симфоник, орган әсәрләрен тыңлый белде ул: һәрбер әсәрнең аталышын, аның авторын ялгышсыз атый алды. Поэзия, проза кебек нәрсәләрне яхшы белде. Театрда куела торган әсәрләрнең үзенчәлекле ягына игътибар итте. Совет чорындагы тыелган нәрсәләрне бик бирелеп укып-өйрәнеп барды. Аеруча ошаган урыннарын кычкырып укып та ала иде. Күпме шигырь-поэмаларны яттан белде!.. Сәясәт өлкәсендә көчле бәхәсләр алып барыр иде...

Аның белән аралашып, үзем дә җитди музыкаль әсәрләрне тыңларга-үзләштерергә керештем. Болары да, сын-һәйкәл әсәрләре кебек үк, катлаулы нәрсәләр булып чыкты. Шуңа күрә, аларны үзләштерү дә җиңел генә бармады...

Остазыма рәхмәт йөзеннән мин үзем өчен Андрей Платонов, Леонид Андреев, Михаил Зощенко, Валентин Катаев, Илья Эренбург кебек каләм осталарын ачтым. Болар бары да—музыка-театр да, проза-поэзия дә аның "өйрәтү программасына" керә иде. Сын сәнгате, гомумән, Олы Сәнгать болардан тыш аерым яши алмый икән дигән фикергә килдем мин.

Орган...

Нинди куәтле серле көч анда! Күктән килә торган көчле галәм янгырашы... Гаҗәеп тә тылсымлы авазлар тупланмасы...

"Имтиханнар"ны уңышлы биреп, 1978 елда СССР Рәссамнар Берлегенә кандидат итеп алындым. (Ә ул, остазым билгеләгәнчә—нәкъ биш елдан соң булды.) Олы Сәнгатькә юл ачылды... Лимит белән саубуллашырга вакыт җитте. (Бу вакытта өйләнеп, мәскәүле булган идем инде.) Ул саубуллашуны мин үзенә күрә бер истәлек иттереп, идарәдә мәҗлес оештырдым.

Минем барасы юлларым, максатым шактый нык ачыкланган иде инде.

Ким Шакиров

# КУРКУ

*Бу язмаларым фәнни трактат яисә монография түгел. Үз башымнан үткән вакыйгалар һәм шуларга бәйле кичерешләр мин фәкыйрегезнең игътибарын кеше психикасында була торган мөһим халәткә—төп эмоцияләрнең берсенә—курку тойгысына җәлеп иткән иде.*

Әтиебезнең туганнан туган энесе—Рәүф абый—миннән бер-ике яшькә генә олырак. Шуңа күрәдерме, ә бәлки үзе мавыгып сөйләгән бихисап әкиятләрен яратып тыңлаганыбыз өчендер, ул безгә еш килә һәм кайчагында кунып та кала. Шундый төннәрдә без «ташбаш»лар өчен әдәби кичә, ягъни әкият бәйрәме була. Картәниебез сукыр лампаны сүндереп йокларга ятканда (эштән арып кайткан әниебез күптән изрәп йоклый, әтиебез фронтта, фашистларга каршы сугыша) без малайлар сәндерәдә урнашып—төнәп беткән булабыз, кунагыбызның сүз башлап җибәрүен түземсезләнеп көтәбез. Шыпырт кына сөйләсә дә, Рәүф абый һәр сүзен диктор кебек аерымачык әйтә. Аның ике ягындагы энеләрем дә, аларның берсе аша тыңлаучы мин дә колакларны тырпайтабыз. Кыскасы, абыебыз сөйләгән бихисап әкиятләр хәзер телевидение аша карый торган озын сериалларны алыштыра иде. Хәтеремдә калган әкиятләр һәм риваятьләрнең кайсысын Рәүф абыйдан, кайсыларын башка сүз осталарыннан ишеткәнмендер яисә китаплардан укыганмындыр, төгәл әйтә алмыйм. Әмма асылында сүзем әкиятләр һәм аларның эчтәлеге турында түгел. Иң мөһиме—Рәүф абыйның әкияттәге кульминация дип атала торган киеренке җирендә, куркыныч персонажга охшарга тырышып, яман дәһшәтле пышылдап, без малайларны куркытып алуы иде. Ә без, бу алымга күнегеп, шундый мизгелләрне алдан сизеп, көтеп алабыз, рәхәтләнеп куркабыз...

Гади генә процессны алып карыйк—таган атынуны. Бер мизгелдә иң югары ноктага күтәрелеп, хәрәкәт юнәлеше капма-каршыга—түбәнгә таба алышынган чакта, гәүдә авырлыгы юкка чыга (бу—орбитадагы космонавтларның даими халәте), бөтен тән чымырдап китә, нindидер рәхәт һәм ләззәтле курку хисе кайдадыр янбашлар арасындагы импульс белән бергәләп югала. Текә таудан чаңгыда шуганда да шундый ук кичерешләр була, әмма бу очракта авырлык көче бөтенләй үк юкка чыкмый, чаңгының карга ышкылуы һәм һава каршылыгы авырлык көченең реаль көч икәнлеген искәртә. Барыбер рәхәтләнеп куркасың, бигрәк тә тау битендә агачлар үсеп торса.

Пермь краендагы Ишем авылының бик күркәм урыны ул Чәкрә тавы. Туган якларны сагынып кайтканда исләрем китеп шул тауга карыйм: ничек, курыксак та, шул таудан шуып төшәргә тәвәккәлләгәнбез икән, ваемсызлыкмы ул, әллә шул курку хисен кичерү теләге булганмы, әллә дус-ишләр һәм яшьтәшләр арасында куркак түгел икәнлегеннe исбатлыйсы килүме? Мөгаен, барысы бергә булгандыр.

Җәй көннәрендә дә шул курку ләззәтен тояр өчен чарасын таба идек. Авылыбыз зур, Ирин исемле елгабыз шактый кин. Елга аша бер-беренә барып йөрер өчен күпер кирәк. Ишем өчен бер генә күпер һәм хәтта ике күпер дә аз булган. Ирин суы башта, Ишемгә килеп кергән җирендә, иң тәбәнәк Кичү күпере астыннан агып үтә. Авыл уртасында иң биек күпер—Урта күпер калкып тора.

Аерым авыл кебек читтә торган Түбән Аръякны авылның калган өлеше белән тоташтыручы Түбән күпер бераз гына тәбәнәгрәк. Аның каравы, күпер астындагы

су искиткеч тирән, күпер рәшәткәсенә басып баштүбән ыргылсаң да төпкә житеп су үләннәре арасыннан ләм тырнап алу жиңел булмый. Урта күпердән чумган кешеләрне күргәнем булды булуын, әмма үзем, турысын әйтим, андый батырлык кылмадым. Күпернең биеклеге өркетми, андагы суның бик тирән булмавы шөбһәләндерә иде. Алла сакласын, су төбендә яткан ташларның берсенә бәрелеп муеныңны сындырсаң яисә ахмак башыңны ярсаң... Шуңа күрә, Кичү күперда баштүбән чумарга өйрәнгәч, Түбән күпердән чумып батырлыгыңны раслау һәм шул уңайдан бераз гына булса да авырлык көченнән котылып ирекле очу халәтендә булырга омтылу бик табигый иде. Чумарга җыенган чакта көтү кайтканын көтеп күпер башына килгән халык арасында син күз аткалап йөргән кыз да күренсә, чуммый булдыра алмыйсың. Архимед ачыклаган көчне җиңеп, су төбенә җитә алсаң, бөке кебек су өстенә атылып чыкканда бер кулыңны күтәреп учыңны ачып җибәрәсең. Беләзегең буйлап кара ләм агып төшсә, хыялыңда йөргән кызыкай үзеңне игътибарсыз калдырмас дип өметләнә аласың.

Менә шундый ләззәтле куркулар өчен таудан шуганда "Чаңгы" дисәң "Әү!" диярлек чаңгы шәләмәтен аягыбызга мунчала бау белән бәйләп ныгыта идек. Ә суга күпердән чумганда резин башлык юк, анысы турында ишеткәнебез дә булмады. Тиешле җиһазсыз гына таудан шуу һәм суга чумулар, әлбәттә, бик хәвефле гамәл. Дустым Мидхәт Сәлимхановның әнә Түбән күпердән чумганда колак пәрдәсенә зыян килде. Озак интекте, колагыннан эренсыман сыекча агып йөрде, ахырда ул ярым чукрак булып калды, хәтта хәрби хезмәттән дә азат иттеләр үзен. Әмма шундый гыйбрәтле вакыйга да малай-шалай өчен сабак булмады, күпердән чумучылар саны кимемәде.

Безгә психика мохиткә яраклашу өчен бирелгән. Әгәр кеше курку сәләте белән «җиһазландырылган» икән, димәк, бу сәләтнең яшәү өчен әһәмияте зур булгандыр. Чыннан да, курку белмәгән җан иясе күп очракларда хәвефле хәлләрдән исән-имин чыга алмаган булыр иде. Шуңа күрә курку хисе психиканың тәрәккый итүендә бик көчле этәргеч булган дип исәпләргә җирлек бар. Димәк, бу сыйфат безгә ата-бабалардан мирас булып калган кадерле бүләк дип кабул ителергә тиештер. Аларны куркыта алырлык күренешләр—яшен яшьнәп күк күкрәү һәм җир тетрәү, сәбәбе билгеле булмаган җил-давыллар һәм башка шундый хәвеф-хәтәрле вакыйгалар һәрдаим булып тормаганмени? Шуның өчен курку хисе без адәм балаларына тумыштан ук, дөресрәге, ана карынында тәрәккый итә башлаганда ук ярым кыргый бабаларыбыздан мирас булып генетик хәтер аша сеңдерелгән сәләт дип бәяләнергә тиештер, мөгаен.

Бу уңайдан олы улыбызга ике яшь чагында булган бер вакыйга исемә төште. Обсерваториядә эшли идем ул заманда. Җәйнең бер эссе көнендә аны су коенырга дип Идел буена алып бардым. Чишенеп суга керергә җыенган гына идек, каяндыр чирәм арасыннан тузбаш елан шуышып чыкты. Шуны күргән улыбыз күз ачып йомганчы җилкәмә менеп тә утырды, юкса елан затын моңарчы күргәне булмады. Ата-аналарның курку тойгылары аларның балаларына да бик тиз күчкәне билгеле, әмма бу очракта мин, тузбашның зарарсыз, юаш зат икәнен белеп, үз-үземне бик тыныч тоткан идем. Кыскасы, улымның еланнан куркуында минем бернинди катышым юк. Аның психикасы нәүрәбендә бу курку генетик хәтер мирасы буларак саклангандыр дип уйларга җирлек бар.

Әмма курку сәләте аерым бер кешедә ул туган чакта көчәя, тагын да тирәнрәк тамыр җибәрә булса кирәк. Чыннан да, якты дөньяга ана карыныннан чыккандагы иң беренче кичереш—көчле курку булмыймени? Җылы һәм авырлык көче булмаган караңгы дөньяда, ана организмы белән кендек аша өзлексез элемтәдә рәхәт кенә яшәгәннән соң күз чагылдырырлык якты, әмма салкын дөньяга чыгу тетрәндергеч бер хәл. Шулай итеп, ата-бабаларыбыздан калган курку хисен хәтеребез безгә мирас рәвешендә житкерсә, дөнья күрү михнәте курку сыйфатын тагын да көчәйтеп һәм ныгытып куя шикелле. Кыскасы, курку сәләте җан иясенең яшәү программасындагы бик мөһим элементы булып тора, күрәсең.

Курку кичерешенең аерым бер шәхескә генә хас булганы да билгеле. Ә мин үзем, мәсәлән, ата казлардан курка идем. Шунысы гаҗәп: ата каз тарафыннан кыйналганымны хәтерләмим, ә менә күкәй басып утыручы ана казыбыз мин аны оясыннан, кухня шкафының аскы ишеген ачып, һава суларга чыгарып җибәргәндә

дә, кире кереп урынына урнашканда да ботымны шактый авырттырып чукып үтә иде (чукып кынамы әле, чукыганда башын кинәт борып, тиремне шактый күгәртә иде). Ә мин барыбер шул ана каздан курыкмадым. Ата каздан нигә курыкканымны әнием аңлатып бирде: ике яшем тулгач, мине ата каз яхшы гына дөмбәсләгән булган, хәтта аркама басып авыр томшыгы белән башыма да бәргәләгән. Шунысы да гаҗәп, әнием бу турыда сөйләгәч, мин ата казлардан курыкмас булдым, ысылдап яныма килсәләр, имән һәм урта бармакларымны аерып кулымны гына суза идем. Гаилә башлыгы шунда ук кирегә борыла, балалары янына кайтып, гайрәтләнеп канат кагып ала иде (янәсе, дошманны куган, аларны яклаган).

Бу җәһәттән ике ир-ат исемә төште. Берсе типсә тимер өзәрлек яшь егет, аучы, чит илләрдән килгән һәвәскәр аучыларны озатып йөри, аюдан да, бүредән дә курыкмый, буе, ачуым килмәгәе, ике метрга җитәдер. Туган якларга ялга кайтканда очрашабыз үзе белән. Бервакыт ул безнең капкабыз янында тукталды, ниндидер йомышы бар иде. Исәнләшеп кенә өлгергән иде танышым, кинәт чүгәләде дә, шулай чүгәләгән килеш, украин егетләре гопак биегән шикелле, верандабызга чабып кереп тә китте. Хәйран калып, мин дә тиз генә аның артыннан кердем. Бал корты безнең тирәдә очып йөри башлаган икән, шуннан курыккан имеш. Хәтта йомышын да исенә төшерә алмый аптырады (балык кармакларга чакырам дип килгән булган). Ни хәл итәсең инде, ул да берәр нәрсәдән куркырга хаклыдыр бит. Икенче ир-ат күптән инде гүр иясе, ул әтиемнән дә олырак иде. Колхозда печән әзерләү вакытында берничә җәй аның белән бергә эшләү насыйп булды. Шул абзыйның, фронттан күкрәк тутырып орден-медальләр тагып кайткан каһарман разведчикның, тычкан яисә бака күрсә коты алына иде; ул, кулындагы эш коралын (балтамы анда, яисә чалгымы) ташлап, кая туры килсә шунда чабып китә иде. Аның шундый галәтен яхшы белгән малай-шалай шаярырга ярата иде. Беркөнне, аштан соң корсак шиндереп аз-маз ял иткәндә бер яшьтәшем, тычкан тотып алган да, койрыгыннан күтәреп ана якынлаша башлады. Кибән астында яткан абзыебыз сикереп торды, кулына сәнәк тотты. Имансыз малай, тычканны бераз чайкалдырып торганнан соң, Галләм абзыйга таба ташлаган иде, ул, үзенә таба очып килгән тычканны читкә бору теләге беләндерме, сәнәген алга этәрде. «Уеннан—уймак» дигәнне раслап, сәнәк очы малайның корсагына төртелде. Ярый әле җәрәхәте тирән булмады, тиресеннән генә кан катыш сүл агып тора иде. Кемгә ничектер, минем өчен бу вакыйга бик гыйбрәтле булды. Кешенең ниндидер житешсезлеген файдаланып шаяру бик начар һәм хәтта куркыныч гамәл икәнлегенә шул чакта инандым.

Хәтеремдә яхшы сакланып калган тәүге куркуларым бер җәйдә, мина өч яшь ярым чакта булды (мина ул чакта ничә яшь булганын әнием әйтте). Беренчесен табигый күренештән, калган икесен техникадан курку дип атарга була. Өйдә үзем генә чакта соры җанварлар һөҗүм итте. Яфраклары коелып беткән себерке шәләмәтен ничек кулыма эләктергәнмен дә, ничек сандык өстенә менеп өлгергәнмен, анысы хәтеремдә калмаган, мөгаен, бик каты курыкканнандыр инде. Ә менә бу серле җан ияләренең (күсе дип аталулары мина соңыннан мәгълүм булды), яныма килеп һәм алгы тәпиләрен сандыкка терәп, мина таба очлы борыннарын сузуларын, үземнең, сандык өстендә чаба-чаба, шәрә себерке белән бар көчемә аларның танауларына сугуымны һич онытасым юк. Шулай «бөтен яклап оборона» тоткач, ишек алдыннан кергән әниемдерме, әтиемдерме коткарган иде, тәгаен кемлеген хәтерләмим. Шунысы гаҗәпләндерә: бу вакыйгадан соң күседән курку күңелемә сеңеп калмады, ниндидер җирәнү генә туа аларны күрсәм. Бәлки беренче очрашуда ук агрессиягә актив каршы торуым нәтиҗәсе булгандыр.

Техникадан беренче куркуым урамда күрше балалары белән уйнаган чакта булды. Кинәт малай-шалай, шау-гөр килеп, төрлесе төрле якка таралып-сибелеп бетте, берүзем торып калдым. Иң якын капка безнеке булгач, тиз генә ишегалдыбызга кереп качтым. Йортыбыз каршысына автомобиль килеп тукталды. Кабинасыннан бер абзый чыкты, брезент (хәзер аңлавымча) чиләген күтәреп инешкә чапты. Аннан кирегә килеп, мина ифрат зур булып күренгән бөкесен алып, радиаторына су салды. Бу абый ни өчендер машинасының тәгәрмәчләренә типкәләп алды (мин аны ачулана дип уйладым), янә кабинасына кереп утырды. Машина кузгалып авылыбыздан чыгып киткәч кенә тынычландым. Шулай атсыз йөри торган зур әрҗәле арбаны беренче күрүем мин сабыйны тетрәндергән иде.

Икенче куркуым тагын да көчлерәк булды. Ишек алдында үзем генә идем. Чирәм арасындагы төрле бөҗәкләрнең тормышын күзәтәм, тирә-якка күз салу да юк, бөтенләй дөньямны онытканмын. Чалт аяз көн уртасында кинәт карангы сыман булып китте. Башымны күтәреп караган идем, котым алынды: нур чәчеп торган кояшны нииндидер килбәтсез зур, озынча кара җисем каплаган. Ярый әле адәм баласына курку хисләреннән тыш башка эмоцияләр дә бирелгән. Шуларның берсе—кызыксыну. Мине билгән ике кичереш (курку белән кызыксыну) арасында барган көрәш мине урынымнан кузгалмый гына бу сәер күренешне күзәтергә мәҗбүр итте. Җисемнең авылыбыз өстендә хәрәкәт итүе ачыкланды. Үзе бик югары да түгел. Мин аны авылдан китеп офык кырыенда юк булганчы карап калдым. Күктә самолетлар очып йөргәнен күргәли идем, ә мондый зур, дирижабль дип аталган очкычны якыннан күрү минем өчен куркыныч та, кызыклы да һәм сокландыргыч та булды. Бу вакыйгадан соң үскәч очучы булу теләге туган иде, әниемә, зур үсеп очучы булгач, сине мунчага самолетта гына алып йөртермен, дия идем (мунчабыз өйдән еракта, утарыбызның инешкә якын очында иде). Очучы булып булмады, чөнки, сукыр лампа яктысында китап уку белән бик мавыгып, күзгә зыян китергәнмен.

Хәер, сүзем курку кичерешләре турында бит әле. Курку белмәгән кеше бар микән ул? Шундый кичерештән мәхрүм шәхес мохиткә ничек яраклашкан булыр иде икән? Курку белми торган кеше чынбарлыкта куркуын җинә торган кеше түгелмени? Мәсәлән, мин үземне һич кенә дә батырлар затыннан дип исәпләмим. Күп мәртәбә бик куркыныч хәлләрдә булдым, сабый чаклардагы кебек машинадан яисә ата каздан курку гына түгел иде болары. Шуларның берничәсен сөйләсәм, укучыларым өчен гыйбрәтле дә, файдалы да булыр дип уйлыйм.

1956 елның көзе бу. Обсерваториягә яңа килгән чагыбыз, әлегә фатирыбыз да юк. Чираттагы ялга чыккан бер фәнни хезмәткәребез шул бер айдан үз фатирында яшәргә тәкъдим итте. Без, әлбәттә, рәхмәтләр укып ризалаштык. Иң башта җыештыру-чистарту белән мәшгуль булдык, чөнки бер ялгызы яшәгән хуҗабикә өендәге тәртипкә бөтенләй игътибар итмәгән иде шикелле. Һаҗәр зур кухняны чистартты, андагы тау кебек өелгән иске газеталарны яндырганда күптән ягылмаган зур мич тотен чыгарды. Шуңа күрә, салкын булса да ишекләрне ачып, һаваны сафландыру кирәк булды. Үзем зур бүлмәдә тәртип урнаштырып чуалдым, борынгы пианино янында өелеп яткан шундый ук борынгы нота альбомнарын тәртипкә керттем, кайбер әсәрләрне уйнап та карадым әле. Кыскасы, йокларга ятканда соң да, бик арылган да иде. Башым мендәргә тию белән изрәп киткәмен. Күпме йоклау насыйп булгандыр, тәгаен генә әйтә алмыйм, әмма Һаҗәрнең бик каты кычкыруы котымны алып уятты. Ул нәрсәдән курыкканын ничек тә шәйлидер, ә мин моның сәбәбен белмим, шуңа күрә катырак та куркам. Өстәвенә ут кабыза алмый интегәм, Һаҗәр исә кычкыруыннан туктамый. Ниһаять, ут янды, паникерым бераз тынычланды, сүзсез генә мендәренә ишарәли. Якынрак иелеп караган идем, исләрем китте—мендәрләр һәм җәймә өстендә ап-ак кортлар шуышып йөри, чебен кортына охшаганнар, тик нечкәрәк һәм озынраклар. Аларның кайдан килеп чыгуын ачыклау кыен булмады. Караватт астында такта чәй ята икән, зурлыгы белән өстәл тактасының яртысыннан ким булмас, әлеге ноталар шикеле үк борынгы чәйдер инде. Һава дымлылыгы һәм температура унай булгандыр да, чәйдәге файдалы матдәләр тәэсирендә чебен кортының яңа токымы тугандыр, бәлки. Әмма ул чакта моны ачыклау кайгысы түгел иде, кортлардан арыну белән мәшгуль идек. Ниһаять, бераз тынычланып, янә йокларга яттык. Әмма бер булмаса булмый икән, тагын да нииндидер аңлашылмый торган куркыныч нәрсә йокыбызны бүлде. Теге борынгы пианино үзлегеннән уйный башлады. Юньле музыка булса бер хәер әле, юк бит, имәндергеч, котны ала торган музыка иде бу. Башта бик көчле итеп субконтроктава өлкәсендә, аккорд дисәң, аккорд түгел, тавыш боткасы янгырап китте, аннан соң кварта һәм квинталар аралашып барган иблис арпеджиосы башкарылды, иң ахырда югары регистрдагы тавыш боткасы ишетелде. Ниһаять, шул ук тавышлар кире юнәлештә, нечкә тавышлардан иң калыннарына чаклы, акрын гына, салмак кына яңгырап үттеләр. Иң ахырда кемнеңдер идәнгә типкән тавышы ишетелде. Чәчләрем үрә торганын, ә чәч тамырлары боз кристаллары кебек катып калганын яхшы хәтерлим. Үземнең шулай да бу галәмәтне Һаҗәр дә ишетте микән, әллә үземдә генә шундый саташу башланды микән дип уйларлык рухым калган имеш.

Шулай нишләргә белми ятканда Һәҗәр мина:

—Ишеттенме?—дип пышылдады.

—Ишеттем,—дип, шыпырт кына җавап бирәм. Димәк, шайтан музыкасы чыннан да яңгыраган булып чыга, психикамда гаеп юк икән, шөкер.

—Тор, ут кабыз,—диде Һәҗәр.

Нишлисең бит, сер бирергә ярамый иде. Яңа гына бергә яши башладык бит әле. Тәвәккәлләп урынымнан тордым да бу юлы утны тиз генә кабыздым, беренче курыкканда кнопканың кайда икәнен хәтеремә яхшы сеңдергәнмен икән. Әлбәттә инде, башта ук пианино янына бактым. Чукынган җан, пианинонын клавиатурасы астында, педальләренә таба борынын сузып, зур гына бер мәче утыра иде. Пианино корпусы эчендә чабып йөргән тычкан затын ауларга тырышып клавиатура өстендә ул биегән икән. Ана нинди «ягымлы сүзләр» әйтүемне чамалау кыен түгелдер. Хәер, үзем дә инде, клавиатура капкачын ябып куярга онытканмын. Ә песи төтен чыккач бүлмәләрне җилләтәбез дип ишек ачканда кереп калган икән.

Пианино яңгыравыннан куркуны күзгә күренми торган һәм серле, табигате билгеле булмаган нәрсәдән курку дип атарга буладыр. Нәрсә куркытканны белмичә курку ай-йай куркыныч була икән! Бу вакыйгалардан соң унөч ел үткәч тагын шулай билгесез нәрсәдән курыккан идем. Бу очракта шул мине куркыткан нәрсәне күрдем дә, тавышын да ишеттем, ул минем артымнан куып бик зур тизлек белән килә дә иде. Шул нәрсәдән котылам дип бик нык чабып та, ераклыкка һәм биеклеккә сикереп тә берьюлы өч рекорд куйганмындыр, билләһи.

Бер башлагач, тәртибе белән сөйлим инде. Татарстаннан читтә, бер институтта эшләгән чагым. Ректорыбызның шундый гадәте бар иде: җәй җитү белән укытучыларның барысын да чираттагы ялга чыгара да, вакыты җиткәч, кабул итү имтиханнарына алдан билгеләнгән укытучылар төркемен ялдан чакыртып ала. Имтиханнар тәмамлангач, ялы бүленгән укытучылар төркеме ике атнага ял йортына җибәрелә. Шул елда мин фәкыйрегез дә алдан билгеләнгән укытучылар арасында идем. Кыскасы, калабыздан ерак булмаган бик матур урында ял итү насыйп булды. Ял йорты санаторий түгел, анда дәвалау процедураларына йөрисе юк. Тиешле вакытта ашка килергә онытма да тәртип бозып йөрмә, калган вакытыңны теләсән ничек сарыф итә аласың. Көннәрнең берсендә әнә шул вакыт сарыф иткәндә ярдәм өчен ялланган, культмассовик дип атала торган яшь ир-ат мина, сер итеп кенә, бер җирдә кара бөрлегән күп, дигән иде. Бик шәрехләп юлын да аңлатып бирде. Мин эзли торган җиргә, Агыйделнең су кырыена барып җитәр өчен аның чәнечкеле куе куаклар белән капланган, Чәкрә тавыннан да биек һәм текә ярыннан төшәргә кирәк. Уңайлырак сукмак булмас микән дип шактый барганнан соң бер ерганакка килеп чыктым. Шул ерганак төбеннән түбәнгә сукмак дисәң сукмак түгел (киң), юл дисәң юл түгел (тар) бер нәрсә суга таба алып бара иде. Шул ком белән капланган текә ярлы ерганак буйлап түбәнгә таба атлыйм. Ничә минут баргамындыр, анысын әйтә алмыйм, кинәт артымда бик көчле үкергән тавыш ишетелде. Борылып карагач, котым очты: нинидер куе тузан өере мина таба тәгәрәп төшеп килә, тизлеге шактый зур. Мине куып җитәр өчен күп вакыт та кирәкмәс ул пәригә. Уңга янсә сулга, ерганакның текә ярына күтәрелеп качарга маташып караган идем, барып чыкмады, ком белән кирегә ишелеп кенә төшәм. Бердәнбер котылу чарасы—бар көчемә алга чабу. Ничек чапканымны күрсәгез иде, дөнья чемпионнары да болай чаба алмыйлардыр. Әмма барыбер теге нәрсәнең тавышы көчәя бит, димәк, арабыз кыскара дигән сүз бу. Борылып карыйм дип вакыт сарыф итә алмыйм, бар көчемә чабам, бәлки су кырыена, иркен җиргә элегрәк барып җитәрмен дигән өмет көч бирә. Ләкин энергиям дә чиксез түгел бит әле, җитәр микән. Уф, шөкер, алда күземә куак күренде. Ерганак ярында үскән шул куакка чаклы сикереп, тотына алсам... Хәзер исемә төшкәндә шул гамәлләремә реконструкция ясап карыйм да, ул чакта башымда бернинди аңлы уй да булмагандыр сыман. Хәер, котыла алмасам, өч улым ятим, ә Һәҗәрем тол калачак бит, дигәнгә охшаш уй чагылып үтте бугай аңсы. Кылган гамәлләрем үзеннән-үзе, механик рәвештә булды. Шунысы хәтеремдә уелып калган: әлеге куакка якынлаша башлагач, тизлегемне тагын да арттырдым, горизонт яссылыгына 45 градус чамасындагы почмак тәшкил иткән юнәлештә ераклыкка да, биеклеккә дә берьюлы сикердем һәм әлеге куакка тотынып калдым. Ә теге бүки мин торган җирдән аста, ерганак төбендәге тар юл буйлап түбәнгә

үкереп узып китте. Эсседән алҗыган һәм кигәвен һөҗүменнән ярсыган сыер көтүе Агыйдел ярына чабып төшә икән ләбаса!

Шундый, сәбәбе күренеп тормаган куркулар гадәттә кыска вакыт эчендә булып үтәләр. Ә менә аңлы курку кичерешләренең, вазгыятенә карап, төрле вакыт биләп торуы мөмкин. 1969 елның июль аенда Севастопольдә кунакта булган идек. Поезд төн уртасында килде дә, гүзәл диңгез манзарасын иртән торып урамга чыккач кына күрдем. Кара диңгез дип юкка әйтәләр икән, күм-күк икән ул, кабарынкы гөмбәз кебек өслегендәге суы шәһәр өстенә агып төшәрдәй булып күренә иде. Аңлашыладыр ки, утыз дүрт яшен узып кына диңгезне беренче кат күргән ир-атка иң яхшы кәефләнү су коенудан гыйбарәт иде. Әмма пляжда шыгрым тулы халык, комда ятып кызыныр өчен дә урын эзлисең, суы да быкырдап беткән. Уралның кыргый табигатендә туып-үскән кешегә шундый хәл ничек ошасын ди инде? Минем күңелсез йөргәнемне сиземләгән хуҗа, дустым Рәмиз Гыймаев—ул чакта капитан-лейтенант, хәрби табиб, госпиталь башлыгы урынбасары—пароход белән Инкерман аша чыгарга һәм Софья Перовская исемендәге совхозга барып кайтырга киңәш бирде:

—Андагы пляжларда кеше дә юк, совхоз белән дә танышырсыз, бәлки әле киләсе җәйгә студентларыгызны стройотрядка да җибәрерсез. Виноград җыйганда эшче күп кирәк була.

Икенче көнне иртүк торып шул совхозга киттек. Менә кайда икән ул хозурлык! Озакка сузмадым, чишенеп, тәбәнәк кенә текә ярдан суга чумдым. Һаҗәр ашыкмады, яр кырыена утырып, кояшта кызынган арада груша ашап калды. Ә мин чиста җылы суда йөзеп тә, чумып та, мәтәлчек атып та сабыйлар кебек уйнадым, аруымны сизә башлаганчы рәхәтләндем. Кояшта кызынып алу да зыян итмәс дип ярга чыгарга уйлаган идем, ни хикмәт, диңгез мине җибәрергә теләми иде—ярдан килүче дулкыннар (мин ярдан чумганда кайларда булганнардыр, күзгә чалынмаганнар иде), бер-бер артлы бәреп, мине диңгез уртасына таба өстери башладылар. Яхшы йөзгәнемне белгән Һаҗәр апагыз мине көлемсерәп күзәтә, шаяра дип уйлый. Бу вазгыять мине бик куркытты. Үзем өчен курку түгел иде бу. Хәлгә төшенә калса, Һаҗәр бер генә мизгел дә икеләнеп тормас, ярдәмгә ташланыр, сәер тозакка минем шикелле эләгер дә, икәүләп юкка чыгарбыз, балалар бөтенләй ятим калырлар дип курыктым. Курку хисе фикерләүгә ярдәм итми, әлбәттә. Көчле куркудан паникага биреләсең, акыл параличына дучар буласың. Бик тиз берәр төрле ният кылырга кирәк иде. Баш эшләмәгәч, иң гади ният—берүзем генә һәлак булу. Балаларыбыз хет әнисез калмас дидем. Шуннан ничектер тынычландым һәм көтмәгәндә кыен хәлдән чыгу ысулы да башыма килде. Ярдан кайтарылып диңгезгә баручы мәкерле дулкыннарның астына чума, ярга баручы дулкыннарның исә өстенә күтәрелә башладым. Бу маневр нәтиҗәсен бик тиз бирде, ярга баручы шаян дулкыннарның чираттагы берсе мине чуерташ белән капланган текә һәм тәбәнәк ярга чыгарып атты. Һаҗәр апагызга якын гына җиргә дүрт аякланып барып төштем.

Кич белән дустым Рәмиз аңлатмаларын бирде:

—Гамәлләрең бик дөрес булган, андый күренеш «тягун» дип атала,—диде ул.— Аны аңламаган кешеләрнең күбесе, бик оста һәм көчле йөзүче булсалар да, паникага бирелә, мәгънәсез хәрәкәтләр кыла. Нәтиҗәдә маҗара фаҗига белән тәмамлана.

(Муса Җәлил дә нәкъ шундый маҗарага юлыккан булган икән бит. Әмма ул дулкыннар белән хәлдән тайганчы тартышкан. Иптәшләре коткармаса, бөек каһарманыбыз гыйбрәтле язмыш сынаулары аша үткәнче үк дөнья куясы булган икән. Шунысы да кызык: Җәлил дә, мин дә—15 февраль көнне туганбыз, димәк, Сукоярлар, икебезне дә су дөньясының үзенә тартып алырга тырышуы очраклы хәл микән?).

Бу вакыйгадан соң суга атлап керә башлаганда беркайчан да курку кичерешләренә юлыкмадым, һәрчак тыныч булдым. Сәбәбен хәтәр һәм гыйбрәтле сынауны үтә алу нәтиҗәседер дип аңлыйм.

Диңгездә булган курку кичерешен уртача тизлектәге курку дип атар идем. Чагыштырып карар өчен үз башымнан узган тагын ике маҗараны искә алырга туры килә. Аларның икесе дә бала чакта ук йоккан «чир»—балык кармаклау һәвәслеге аркасында булган иде. Шул шөгылем үз гаиләмдә чатаклыкларга сәбәпче дә булгалады, чөнки Һаҗәр апагызның кәефе кулыма кармак очраклы рәвештә генә

эләксә дә бозыла торган иде. Үзгәртеп кору давыллары һәм лаеклы дип атала торган ялга чыгуыбыз һәм пенсиямнен ташка үлчим генә булуы анын әлеге һәвәслегемә мөнәсәбәтен дә капма-каршы якка үзгәртте дә куйды. Апагыз мине елга буйларына үзе үк юллый башлады. Сылтавы да табылып кына тора бит әле: йә кызыбыз Яна ел бәйрәменә, йә студент оныгыбыз кышкы каникулга киләм дип хәбәр итәләр. Барысына да ин яхшы сый—елга балыгы. Тирә-юньдәге сулыкларны яхшы белгән балыкчылар белән дуслаштым. Алар арасында Чулпанда яшәгән Александр Афонин белән Рафаэль Зарипов бигрәк осталар. Елганың кайсы урынында, ярдан ничә метр ераклыкта нинди балык кабасын төгәл әйтеп бирәләр. Алар белән барсаң, балыксыз кайтмыйсың инде. Әмма алар гел бара алмыйлар шул, хужалыклары да бар бит. Кайчагында берүземә генә дә чыгып китәргә туры килә.

Шундый очракларның берсендә, Пермьдә яшәп яткан кызыбыздан телеграмма килгәч, 1998 елның 28 декабрендә, электр поезды белән ярты сәгать барып һәм илле минут җәяү атлап, кайчандыр Пустошь авылы булган җирдә кичке энгер-менгергә чаклы балык кармакладым. Карангы төшкәнче станциягә барып житим дип кармакларымны җыйдым да кайтырга чыктым. Шактый озак атлагач кына ялгыш сукмактан киткәнемә төшендем. Капма-каршы юнәлештә барганмын икән, монысын урманчыкка житкәч агач кәүсәләрендәге мүкне капшап белдем, болыт арасында күренеп алган ай да шуны раслады. Бик үк карангы да түгел, тулы ай вакыты. Әмма сәгатькә карап вакытны билгеләп булмый, яктылык житми. Иң аянычы—кирегә кайтасы юл агач араларында юкка чыкты. Берданбер ориентир—электр линиясе, юлы булмаса да, шуннан тайпылмый гына атларга кирәк. Юеш кар ерып, тирән чокырлар аша тимер юл ягына ничек өстерәлеп килеп чыгуым турында шәрехләп сөйләүнең кирәге юктыр. Юл буена миемне өзлексез курку, бер заман хәлдән таярмын да кар өстендә туңып калырмын дигән уй бораулый иде. Өстәвенә агач төпләре дә кайбер юнәлешләрдән караганда нәкъ бүре булып күренәләр. Монысы инде төп куркуны бераз басып, киметеп куя. Әйтәсе дә юк, курку парчалары белән бизәкләнгән сәяхәт булып чыкты бу. Авылга житкәндә төнге сәгать бер тулган иде. Поездлар йөрми, сирәк-мирәк машинада узучылар туктарга уйламый да—кыяфәтем карачкыныкы кебек булгач, кем туктасын ди. Шөкер, ялт итеп үтеп киткән бер машина кинәт кылт туктады да тиз генә мина таба чигенеп килде. Шунда ук машинадан милиция подполковнигы пистолетын тотып сикереп чыкты, мине машинасына төрткәләп кертә башлады (үзе әйтүенчә, мине исерек дип уйлаган, ә соңыннан, гәпләшә башлагач, ачыкланды: кибет ярдәм иткән, аны басканнар икән, шуна күрә мине дә шул юлбасарларның берсе дип уйлаган инде подполковник, рәхмәт яугыры). Юл уңаенда аңлаштык, иртәнгә тиклем Коркачыкта милиция бүлегендә киемемне киптереп, участковыйлар кабинетында бик кайнар һәм бик татлы чәй эчеп ял иттем (кизү торган егетләр сыйлады). Өйгә кайтуым, ничек каршы алулары турында сөйләп тормыйм, болай да аңлашыладыр, өйдән чыгып киткәннән соң бер тәүлектән артык вакыт үткән иде бит инде.

2002 елның гыйнвар ахырында Кировтан, каникулга киләм дип студент оныгыбыз телеграмма суккан иде. Аны сыйларга иң яхшы нәрсә һаман да шул балык инде, чөнки ул бәләкәй чагында, әтисе хәрби табиб булып хезмәт иткәндә Курилдагы Итуруп утравында, тәэминат начар булгач, күбесенчә балык ашап үсте (бәлки шуңа албасты кебек зур, Тарзан кебек көчледер дә әле). Сөекле оныгын сыйларга теләгән әбисе, аңлашыладыр инде, янә мине балык тотарга җибәрде. Бу юлы үзебезгә якын җиргә генә юнәлдем. Боз өстендәге балыкчылар сукмагы буйлап ашыкмыйча гына барганда кинәт боз ишелеп китте дә, боз кисәкләренең бер-берсенә бәрелешүе ксилофон тавышлары чыгарды. Шул мизгелдә боз боравын һәм фанер тартмамны сулга, үзем чыгасы ярга таба ташлап өлгердем, сул терсәгем белән бозның ярылмый калган калынрак җиренә асылынып калдым. Аяк белән капшап караган идем дә, яхшы таныш киртләч кырыенда икәнемне аңладым. Көч-кодрәт кайдан килгәндер, хәзер дә исем китә, бозны җимерә-вата ярга ыргылдым, сай урынга җитеп, боз өстенә күтәрелдем. Гер кебек авырайган ботинкаларымны салып суын агызып тормадым, тиз генә өйгә элдердем. Очып кайткан кебек булдым. Барысы да шулкадәрле тиз баштан кичте, курку-фәлән әллә булмаган, әллә булып та бөтенләй онытылган. Әмма онытылмый икән шул. Кич белән йокымсырый башлаганда ксилофон тавышы берничә кабат уятты. Курку хисе күңел төбенә турыдан-туры ингән, аң сферасы

аша рикошет биреп кенә үткәндер. Ашыкмыйча, аңлы рәвештә вакыйганы кино кебек яңадан карап үткәч кенә тынычлап йокыга киттем.

Курку тизлеге турында сүз кузгалган икән, куркуның башка төрләрен дә карап үтү урынлы булыр. Аларның берсен өзлексез, даими яисә тизлеге булмаган курку дип атарга була. Аның кайчан башланганын да, кайчан тәмамланачагын да күп очракларда билгеләү мөмкин түгелдер. Кайберәүләр андый курку кичерешен кадерләп саклыйлар, гомере буена рәхәтләнеп куркалар. Психотерапевт яисә психиатр ярдәме кирәк була.

Күрәбез ки, курку өчен сәбәпләре чыгып кына тора. Әмма без аннан башка да куркырга җаен табабыз.Ниләрдән генә курыкмый адәм баласы? Караңгы урамнарда йөрүдән, картаюдан, үлемнән, имтихан бирүдән, йогышлы чирләрдән, зур залда халык күп җыелганда чыгыш ясаудан, җитәкче белән бәхәсләшүдән, кирәк чагында турысын әйтүдән, һич югында үзең уйлап чыгарган мифик заттан (бүкидән) куркабыз. Калада сирәк була торган кешегә тротуарда очраган һәркем шикле күренә, авылда сирәк булган шәһәр баласын басуда җан иясе булмавы шөбһәләндерә. АКШның 1801—1809 еллардагы президенты Т. Джеферсон әйтмешли, безне беркайчан да булмый торган күңелсез вакыйгалар күбрәк борчый. Бу уңайдан күптән ишеткән мәзәк исемә төште. Бер хатын басмада кер чайкый, ә янында нәни кызы елап утыра икән. Әнисе:

—Ник елыйсың, кызым, ни булды сиңа?—дип сорагач, бала:

—Аһ, әнием, менә мин үсәрмен дә кияүгә чыгармын, балам булыр, менә шулай кер чайкаганда ул суга батып үлсә, нишләрмен дип уйладым да, йөрәгем җу итеп китте, шуңа елыйм,—дип җавап биргән имеш. Менә шулай ул, куркасың килсә, сәбәбе булмаса да, сылтавы табыла.

Ә менә реаль куркынычлар арасында моңарчы искә алынмаган тагын бер төре бар, ул да булса—шәхесара бәйләнешләрдә була торган кискен каршылык, дошманнарча бәрелешләр. Бер заман электр поездында кердем, буш урыннар күп иде. Вахитов тукталышында бер хатын-кыз керде, минем белән рәттән сул якта, кырыйдагы буш урынга утырды, ниндидер әйберләрен сул аягы янында идәнгә куйды. »Компрессор заводы» тукталышында шыгрым тулып халык керде, басып баручылар да күбәеп китте. Ничә тукталыш үткәнбездер, игътибар итмәдем, бу хатын, миннән әйберләренә күз-колак булуымны үтенеп, ниндидер танышларын эзләп бугай, алгы вагоннарның берсенә китеп барды. Нинди әйбер икәнлеген карап-нитеп тормыйча, ваемсыз гына каравылчы булырга ризалык биреп калдым. Бик озак күренми торды бу очраклы юлдашым. «Чыпчык» тукталышына җиткәндә тамбурга чыгып баручы бер егет мин каравыллаган әйберләр арасыннан бер сумка күтәреп китте. Шулчак каршымда утырган бер карт пассажир, теге егеткә ымлап, миңа күз кысты. Мин, тиз генә сикереп тордым да, егетне тамбурда куып җиттем, әлеге сумкага чытырдатып ябыштым:

—Миңа бу әйберләрне сакларга кушылган, кая өстерисең әле бу сумканы?—дидем. Егет шашкандай акыра башлады:

—Бу минем сумкам, ал кулыңны, миңа »Чыпчык»та төшеп калырга кирәк!—ди. Ә мин, тыныч булырга тырышып:

—Менә минем белән рәттән утырган хатын килер, кем сумкасы икәнен шунда ачыкларбыз,—дип җавап бирәм. Егет бар көченә чинап кычкыра башлады:

—Мин ул хатынны көтә алмыйм, миңа төшәргә вакыт, җибәр сумкамны!

Вагонның бу очындагы пассажирлар өчен тамаша булды. Егет чын күңелдән акыра кебек, ярый әле сугышмый-нитми. Үз-үземнән шикләнеп, аның күзенә карыйм, бер дә карак күзенә охшамаган төсле, ихлас күңелдән ярсый кебек. Нишләргә? Ярый, дим эчемнән генә, Чыпчык зур авыл түгел, алдаласа, барыбер табармын мин аны, күзем талганчы, фотога төшергән кебек, чыраен хәтеремә сеңдерим әле. Шактый күп пассажирлар да шаһит булырлар дип уйлыйм. Шулай күзгә-күз карашканда егет ничектер ошый башлады, бер генә дә карак заты димәссең. Поезд туктый башлагач, тәвәккәлләп, кулымны сумкадан алдым. Егет, бераз тынычланып, платформага чыкты. Мин урыныма кире килгәндә әлеге хатын да килеп җиткән иде. Бераз гына элгәрәк әйләнеп кайткан булса ни булыр иде соң ул юньсезгә? Аңа пассажирлар мәҗараны тасвирлап та өлгергән. Ә сумка чыннан да аныкы булмаган, теге егет үз сумкасын аның әйберләре белән янәшә куйган

икән. Пассажирлар рәхәтләнеп көлештеләр. Минә көлке түгел иде шул. Ни дисәң дә егет базык бәдәнле һәм бик тыгыз йодрыклы иде, сумкага тотыну батырлыгым сугыш-җәнҗалдан курку кичереше белән сугарылган иде. Сугышып гарип булып калсаң, пенсиягә чыккан олы кешене бу хәл һич кенә дә бизәмәячәк иде.

Ә моннан утыз елдан артык элек булып узган бер вакыйга мине бик нык тетрәндергән иде. Ул заманда әлеге институтта проректор булып эшли идем. Кичләрнең берсендә сонарып кайтып киләм. Фатирыбызга якын бер урында, микрорайонның басу кебек иркен, аулак җирендә табиблар карары нигезендә химия кафедрасының мөдире вазифаларыннан азат ителгән иптәшем туктатты:

—Мин сине күптәннән бирле сагалап йөрим, менә, ниһаять, бергә-бер очраштык. Беркем юк, мин сине хәзер үтерермен, гәүдәңне бик яхшылап юк итәрмен, эт белән эзләсәләр дә таба алмаслар,—диде.

Яшермим, бик курыктым, анарчы булган куркуларым чүп кенә булып калды. Шулай да үземне мөмкин кадәр тыныч тотарга тырыштым:

—Ярый, үтерерсең дә ди, гәүдәмне дә яшерерсең, вакыты да, урыны да бик уңайлы. Башта, ниятеңне тормышка ашыра башлаганчы, шәхсән миңа булган дәгъваларыңны әйтсәң, миңа да, үзеңә дә җинелрәк булыр,—дидем.

—Башыңны юләргә салма әле, синең аркада хәерчелектә яшим бит, ректорның иҗади ялда булуыннан файдаланып, мине эшемнән азат итәргә ашыктың.

Без Гасыйм белән Казан университетында бер елларда укыдык. Төрле факультетларда булсак та, бер тулай торакта яшәгәч, көн саен диярлек очраша, волейбол уйнаганда йә бер, йә көндәш командаларда була идек. Арабызда дуслык мөнәсәбәтләре туып тернәкләнмәде анысы. Шулай да, университетны тәмамлап төрле төбәкләрдә эшләгәннән соң бормалы юлларыбыз безне янә бер институтта очраштыргач, ничектер үзара урталык хисләре туды. Дуслашып ук китмәсәк тә, еш кына очрашып гәпләшә торган булдык. Ахири дуслар булып китә алмауның, аңлавымча, сәбәбе бер генә иде бугай: мин дүрт бала атасы (өч малай һәм котеп алынган кыз-төпчегебез бар), ә ул, минем шикелле дүртенче дистәсен ваклап килүче ир-ат, һаман әле буйдак сыйфатында йөри. Дөрес, ул берьялгызы түгел, аның янына колхозда эшләп пенсиягә чыккан әнисе күчеп килде. Бәлки бу фактор да егетнең гаилә корып яшәмәвенә сәбәпче булгандыр, әмма Гасыймның бер кыз белән ике мәртәбә никахлашуы һәм туй үткәрүе, туйдан соң киленнең затының әти-әнисенә кайтып китүе барыбызны да аптырашта калдырган иде. Тыштан күренми торган көчле кичерешләр аркасындадыр, бәлки, егетнең үз-үзен тотуында сәер нәрсәләр чагыла башлады. Тора-бара процесс көчәйде, ул психиатрия белгечләре өчен пациент булды. Хастаханәдә берничә ай дәвалануының нәтиҗәсе—инвалид таныклыгы. Икенче группа билгеләгәннәр. Аерым конвертта ректор исеменә табиблардан махсус хат та килгән, докторлык диссертациясен язар өчен ярты еллык иҗади ялга киткәндә бихисап күрсәтмәләре белән бергә ул миңа шунысын да әйтеп куйды:

—Гасыйм Латыйповичны, озакка сузмыйча, эшеннән азат итегез, не дай бог, ул-бу килеп чыкса, мәсәлән, имтиханда начар җавап бирүче студентка ачуланып аны кыйнап ташласа яисә берәрсенең күзенә кислота-фәлән сипсә, без—администрация гаепле булачакбыз.

Бу четерекле эшен үзе хәл итмичә миңа калдыруына ризасызлыгымны белдереп:

—Аның больницадан чыгуына ике ай үтте бит инде, нигә бу кыен мәсьәләне күптән бергәләп хәл итмәдек?—дидем.

—Табиблардан рәсми хат әле күптән түгел генә килгән иде шул, тиз генә хәл ителә торган эш түгел бит, үпкәләмәгез инде.

—Ярар инде, алайса, тик ул хатны калдырыгыз, кирәк булачак.

—Яхшы, яхшы, мин обязательно калдырырмын, тик бүген аны кәгазьләр арасыннан эзләп утырырга вакытым юк. Сез, бу кабинетка кереп ректор вазифаларын үти башлагач, барлык кирәкле документлар белән бергә, шушы эш өстәленең уң тумбасында, өске тартмада әлеге хатны да табарсыз,—диде ректорыбыз.

Сүзендә торды да ул үзе, өстәл тартмасында теге хат бар иде. Әмма ул инде күптән килгән икән. Димәк, четерекле мәсьәләне хәл итүне минем карамакка калдыру алдан ук планлаштырылган булып чыкты. Монысы да куркуның бер төре инде—җаваплы карар кылудан курку. Менә шулай итеп мин, бергә укыган иптәшемне эшеннән азат

итү турында приказ язып, үземә кул куярга да туры киләчәк. Мондый кыен хәлдә калганым юк иде әле. Әлбәттә, моны берүземә генә хәл итәргә ярамаганын аңлый идем. Партком секретаре, профком рәисе белән киңәшләштем, институтның кече шурасын (факультет һәм кафедра житәкчеләрен) Гасыймның үзенә белдермичә генә утырышка җыйдым. Кыскасы, бу кыен карарның күмәк карар икәнен раслар өчен мөмкин кадәр күбрәк документ тупларга тырыштым. Бик кыен булды. Фажига бит: эш хакы 384 сум булган кешене 40 сумлык пенсиягә күчереп карагыз әле, өстәвенә әнисенең пенсиясе дә 12 сум гына (ул заманда бичара колхозчылар шундый гына пенсия алалар иде). Авыруы башка төрле булса, икенче группадагы инвалидларга эшләргә дә ярый, әмма психика чире булган очракта бу һич мөмкин түгел иде шул. Приказны иптәшемә укыту, аның белән күзгә-күз карап сөйләшүнең нинди кыен булганын аңлыйсыздыр. Гасыйм табиблар күрсәтүе буенча кылынган күмәк карарны һәм аның нигезендә дөнья күргән приказны тыныч кабул иткән иде. Ә менә бит, бераз вакыт үткәч мөнәсәбәте үзгәргән, мине генә гаепли. Берәрсе котырткандыр, мөгаен.

Үземне мөмкин кадәр тыныч тотарга тырышып, сүземне дәвам итәм.

—Тыңла әле, Гасыйм, барлык протоколларны, табибларның хатын үзең карап чыккан идең бит, ә приказ соңгы штрих кына, мин булмасам, аны минем урында утырган башка берәү язган булыр иде. Бу вазгыятьтә бердәнбер юл—сиңа дәваланырга һәм табиблар комиссиясе аша реабилитация үтәргә кирәк. Шуннан соң сине мин булсам мин, мин булмасам минем урында кем булса шул, эшкә ике куллап кабул итәчәкбез. Әгәр инде мине чыннан да бу фажигадә гаепле дип исәплисең икән, минем берни эшләр хәлем юк, үтерерсең, мин үлемнән курыкмыйм, үлем күзенә караган чакларым да булды. Шактый эшләр дә башкарып өлгердем инде, диссертация дә якладым, фәнни ачышларым да бар, зур тикшеренүләрдә дә катнашу насыйп булды, китаплар да яздым, берсен үзең дә укыдың. Кыскасы, бер уйлаганда, тормыш программамның күп өлеше чынбарлыкка ашты да бугай. Шунысы гына жәл: дүрт балам тернәкләнеп аякка басмаган әле. Әгәр дә мине, үзең әйткәнчә, үтереп гәүдәмне яшерсәң, минем кая олакканымны белә алмый аптыраган кешеләр мине шыпырт кына чит илгә кыяклаган дип уйлаячаклар. «Ватанын ташлап качкән» кешенең балаларына алар үскәнче пенсия бирерләрме-юкмы, шикле. Мөгаен, Һажәргә тиң ир дә табылыр әле ул, үзең дә әйтәсең бит, яшь чагындагы чибәрлеген җуймаган. Әмма балалар өчен әти булыр микән ул кеше, анысын кем белә? Ләкин бу гамәлеңнең үзең өчен бер файдасы да булмаячак: мин үтерелгәннән соң минем урынга килгән башка кеше дә сине реабилитациясез эшенә кире кабул итә алмас. Мине үтерүеңнең мәгънәсе булмас диюем монысы. Мин әйтәсемне әйттем. Калганы—синең ихтыярыңда.

Шундый озын монологымны бүлдерми тыңлавы Гасыймның бераз тынычлануын, ничектер акылы сафланып китүен раслый иде бугай. Жәл, күзләрен күреп булмый, караңгы. Шулай да вазгыятьнең уңай якка үзгәрүен сиземлим. Үзем дә тәмам тынычландым. Башта булган көчле куркуым да гаиләм ятим кала дип курку иде бит.

Гасыймны ашыктыру, сүз башларга кыстауның ярамаганын аңлый идем. Аның күңел төбендәге өермәләр, көчле кичерешләр ничек һәм кая борылачагын кем белгән... Ниһаять, ул сүз башлады:

—Гафу ит, туган, мин бөтенләй башымны җуйганмын бугай, нинди җинаятьчел уйлар белән килгәнмен бит. Минем бүгенге хәлемдә гаебең булмаганны элек яхшы аңлаган идем бит югыйсә. Соңгы көннәрдә, бик күп уйлана торгач, акылым караңгыланып китте кебек.

—Аңлаша алуыбыз өчен мин бик шатмын, әйдә, керик, чәй эчеп утырырбыз...

—Юу-ук, рәхмәт, хатының һәм балаларың күзенә ничек карый алырмын? Үпкәләмә миңа, зинһар. Ә мин тизрәк әнием янына кайтыйм инде, аңлыйсыңдыр, мин кая барганымны аңа әйтми генә чыгып киткән идем, югалткандыр, бик борчыладыр, бәлки эзләп тә чыккандыр әле, хуш, сау бул, ачу саклама миңа, зинһар,—дип, иптәшем октябрь аеның кичке караңгысында юкка чыкты.

Бу хатирәләремне ашыкмыйча гына, берничә ай буена яздым мин. Тикмәгә түгел икән. Кайчан да булса курку темасына кагылышлы китаплар дөнья күрәчәген күңелем сизгән диярсең. Казанга бер барганда үземә кирәкле өч китап сатып алдым. Курку

турында үзлегемнән язган нәрсәләрем фән күрсәтмәләренә каршы килми микән, дигән сорау борчый иде. Шуңа күрә бу китапларны җентекләп өйрәнә башладым. Икесе кирпеч калынлык, форматлары да шактый зур. Аларны тикшергән арада китап кибетләрендә дүртенчесе дә пәйда булды. Анысын да өйрәнү зарур иде. Шөкер, бу китапларда фикерләремне инкяр итә торган берни күренмәде. Бердәнбер борчыган нәрсә—улымның еланнан куркуын аңлавымның галимнәр фикеренә тәңгәл килмәве иде. Алар маймыл халкын зоопаркларда өйрәнәләр икән. Андый зоопарк шартларында туып-үскән маймыллар еланнан курыкмыйлар имеш. Ә табигый шартларда яшәгән маймылларның еланга юлыкканда котлары алына икән. Зоопарк маймыллары, шул маймылларның елан күргәч паникага бирелүләрен күзәтеп, шулай ук курка башлыйлар имеш. Шундый күзәтүләр нигезендә тикшеренүчеләр, кеше дөньяга курка торган булып килми, тормыш тәҗрибәсе ана шартлы рефлекс сыйфатындагы курку сәләте бирә, дип расларга тырышалар. Бу фикергә таянып кына улыбызның беренче күрүдә үк тузбаш еланнан бик каты куркуын аңлату мөмкин түгел. Шактый озак уйланып йөргәннән соң шундыйрак фикергә килдем: кеше маймыл түгел бит әле, геномнарыбыз арасында да бер процент чамасында аерма бар. Шулай булгач, курку механизмнары туу кешедә дә, маймылда да бертөрле үк булырга тиешмени? Ул гынамы әле. Бәлки бу аерма кешенең маймылдан килеп чыкмаганлыгына, аның эволюция юлларында үзенең аерым траекториясе булганына да ишарәлидер.

Ярый, монысы галимнәр карамагында калсын. Әлеге китапларны уку бик күңелле булды. Күп кенә очракларда «Американы яңадан ачу» белән дә шөгыльләнгәнмен. Анысы да яхшы бит, фикерләү сәләтен җуймаганыңны аңлау күңелне күтәрә икән. Кыскасы, барысы бергә ике мең бит тәшкил иткән дүрт китапны җентекләп өйрәнү өчен шактый күп вакыт кирәк булса да, һич җәлләмим. Бу китапларда үз башымнан узган хәвефле хәлләр һәм шулар нәтиҗәсендә булган кичерешләргә тиешле аңлатмалар да таптым. Аларның барысы турында сөйләп торуның хаҗәте юктыр. Китапларның берсендә минем сабый чакта дирижабльдән куркуымның кызыксыну хисе белән сугарылуын аңлатырлык язмага да юлыктым. Кинәт була торган кискен вакыйгада аңлы рәвештә куркырга өлгерми калып, сонарып курку очраклары да галимнәр тарафыннан тикшерелгән, андый куркуны кичектерелгән курку дип атаганнар. Хәер, андый атама белән тулысынча килешмәс идем, уйлавымча, бу терминның ялгыш фикерләүгә юнәлтүе ихтимал. Курку һич кенә дә кичектерелми, курку кичереше булып үтә, әмма ул аң сферасында эз калдырып өлгерми, нәтиҗәсе күңел төбенә сеңә. Соныннан, ретроспектив анализ нигезендә генә, курку хәлендә булып өлгергәнеңне аңлыйсың. Бу очракта кичектерелгән курку түгел, ә бәлки куркуыңны кичегеп аңлау дисәк, хакыйкатькә якынрак булыр кебек.

Курку кичерешләрен төрләргә бүлеп тикшерүдә исә төрле юнәлешләр бар икән. Куркыткан күренеш буенча тикшерә башласаң, курку төрләре ифрат күп була: ябык урыннардан, мәсәлән, лифт кабинасыннан, яисә, киресенчә, бик иркен, басу кебек ачык урыннардан курку; беренчесе клаустрофобия, икенчесе агорафобия дип аталган. Үрмәкүчтән куркуның да үз исеме бар имеш (арахнофобия). Йөрәк авыруыннан курку кардиофобия дип атала. Әмма куркуны шундый нигездә классларга бүлеп карау уңышлы юнәлеш түгел дип уйлыйм. Чыннан да, кешене куркыта алырлык күренешләр бихисап түгелмени? Алай булгач, курку төрләре дә бихисап булып чыга бит. Нәрсәдән куркасың, шуның атамасын куллан да, вәссәлам! Бакадан куркуны фрогофобия, күседәен куркуны ратофобия (инглиз телендә бака—frog, ә күсе—rat) дип атарга була, судан куркуга рус телендә водобоязнь дип исем бирелгән, аквафобия дип атасаң да ярый.

Шәхсән үземне кәефләндергән нәрсә дә бар: курку кичерешләрен тизлекләре буенча бүлеп карау мин фәкыйрегезнең казанышы булды, бу китапларны укыганда андый фикерләргә юлыкмадым. Шуңа күрә галимнәргә курку кичерешләрен классларга бүлеп карау өчен яңа критерий да тәкъдим итәргә булдым. Кичереш тизлеге буенча түбәндәге классларны аерып карарга була:

кинәт курку (боз ишелеп, салкын суга чумгандагы шикелле);

тиз курку (ашыктыргыч вазгыятьтә, сыер көтүеннән чабып качкандагы кебек);

уртача тизлектә курку (уйланырга бераз вакыт була, дингездәге вакыйга кебек);

акрын курку (вакыт запасы зур, адашып йөргәндәге шикелле);

даими курку (куркуга салган күренеш яисә уйлар өзлексез дәвам итә, андый курку фобия дип атала);

вакытлыча даими курку (курку чыганагы тәэсиренең яисә шул тәэсир булган мохиттә тору вакытына бәйле).

Соңгы, алтынчы төр курку турында аңлатма бирү кирәктер. Мәсәлән, кемдер биек урыннардан курка, түбәнгә караса, аның башы әйләнә, күнеле болгана. Андый урыннан ераклашкач, курку хисе юкка чыга. Кайбер очракларда мондый вакытлыча куркуның сәбәбе дә билгеле булмый. Бәлки укучыларым арасында шундый тойгыларга юлыкканнары да бардыр. Мәсәлән, текә тау битендәге зур кыя, шарлавык, урманның кискен тар почмак тәшкил иткән чигендә үзен дә аңлап житкерми торган шомлану борчый. Андый шомлы урыннар кала шартларында да еш очрый: тәртипсез өелеп яткан металл җиһазлар, тимер юл өстендәге җәяүлеләр күпере, тоннельгә керү урыннары һ.б. Шундый урыннарда нигә шомлануымны аңламый идем. Ниһаять, бер лаборатория яныннан үткәндә, шулай ук шомлана башлавымны тоеп, анда ни эшләгәннәрен белештем. Инфратавыш белән тәҗрибә үткәрәләр икән. Лаборатория ишеге яныннан мөмкин кадәр еракка кителә китәсе килә. Пермь өлкәсенең Молёбка авылы янындагы аномаль зонасының кайбер урыннарында да шундый кичерешләр булганын яхшы хәтерлим. Бермуд өчпочмагында кораблар һәм очкычларның һәлакәткә юлыгуын да кайбер галимнәр экипажның һәм пассажирларның паникага бирелүе белән, ә паниканың сәбәбен Атлантик океан төбенең физик һәм геометрик үзенчәлекләре аркасында туа торган инфратавыш тәэсире дип аңлаталар. Шуна күрә югарыда аталган шомлы урыннарда да тереклек иясен куркытырлык инфратавыш чыганаклары пәйда буладыр диярга җирлек бар. Көчле булмаган аз ешлыклы (7—15 герц) дулкыннар, эчке органнарның үз ешлыкларына тәңгәл килеп, резонанс күренешен тудыралар. Ә җир тетрәвеннән алдарак туа торган инфрадулкыннар бик зәгыйфь була, кеше организмы аны сиземләми, югыйсә шундый катастрофага кадәр үк паника башланыр иде. Кайбер җанварлар андый дулкыннарны сизәләр. Ашхабадта 1948 елда җир тетри башлар алдыннан бер этнең бишектә яткан баланы алып чабып чыгуы һәм баланы эттән коткарабыз дип аның артыннан чабып чыккан олыларны да коткаруы билгеле. Мин фәкыйрегезгә 1956 елда Уралда һәм 1968 елда Кавказда андый дәһшәтле күренештә «катнашу» насыйп булган иде. Янадан туры килмәсен дип кенә әйтер идем. Заманча әйтсәк, стресс дип атарга була моны. Югарыда аталган «шомлы» урыннарда тибрәнү амплитудалары зуррак һәм шуна күрә дулкын энергиясе дә зуррак була. Нәтиҗәдә, организмга резонанслы тәэсир сизелерлек дәрәҗәдә булып, бу хәлне без субъектив яктан борчылу, шомлану һәм хәтта курку кичереше дип кабул итәбез. Болардан чыгып, кала һәм сала кешеләренең психикасында була торган аерманы да аңлау кыен түгелдер. Шәһәр халкының авыл халкына караганда тәшвишләнүчәнрәк икәне күптән билгеле. Бу аермага сәбәпче факторлар (шул исәптән социаль факторлар) арасында колак ишетми торган, әмма организмга тискәре тәэсир ясаучы инфратавышлар да зур роль уйный. Чыннан да, инфратавыш тудырырлык корылмалар калада бик күп бит: лифтлар, балкон яисә лоджия рәшәткәләре, трамвай һәм троллейбусларга энергия бирүче җайланмалар, чүп чыгару торбалары, начар ябылган яисә бөтенләй ачык калган канализация люклары... Матбугатта инфратавышны кайбер илләрдә демонстрантларны куркытып таратыр өчен кулланалар дип тә язганнар иде. Булмас димә. Яшелчә базыннан күсетычканнарны куып чыгарыр өчен дә кулланалар бит андый чыганакларны...

Әгәр бу язмаларым укучыларда кызыксыну уятса һәм алар, кибернетиклар әйтмешли, уңай кире элемтә рәвешендә миңа бу турыда житкерсәләр, бу темага янадан мөрәҗәгать итәргә дә мөмкин булыр. Куркуның асылына төшенү, аны җиңәргә өйрәнү тормышыбызның сыйфатын күтәрәчәк дигән өметтә калам. Укучыларыма изге теләкләр юллыйм. Яшәүдән курыкмыйк, акыл безгә шуңа дип, куркуны җиңәр һәм яшәр өчен бирелгән.

## Әхәт Хәбибуллин

Хәбибуллин Габделәхәт Габделхәй улы (Әхәт Хәбибуллин) 1952 елны Түбән Кама районының Түбән Чаллы авылында колхозчы гаиләсендә уникенче бала булып дөньяга килә. Авыл мәктәбен тәмамлаганнан соң, Бөгелмә шәһәрендә нефтьчеләр училищесын тәмамлый. 1970-72 елларда Кавказда хәрби хезмәттә була. Армиядән



соңгы өч ел Әлмәт физкультура техникумында уза. 1976 елда язмыш аны Ерак Көнчыгыштагы Находка шәһәренә китерә. Ә. Хәбибуллинның 1976-82 еллардагы гомере дингез-океаннар белән бәйле. Балык тотучы "Лотос" дигән корабта Әхәт Хәбибуллинга күп портларда туктап, байтак илләрдә булырга, халыкларның тормыш-көнкүрешен күрергә туры килә. Дингезчеләр тормышына хас байтак сынаулар һәм сыналулар үткәч, 1982 елны ул янәдән Әлмәткә әйләнеп кайта. Яшьлегендә сайлаган һөнәре буенча 8 еллар гади нефтьче булып эшли. 90 нчы еллар башында төзелеш эшләре белән бәйле үзенең шәхси оешмасын ача. Шул ук елларда Әлмәт һәм Түбән Кама газеталарында аның очерклары, хикәяләре күренә башлый. Кайбер язмалары Казан басмаларында да дөнья күрә. Кечкенәдән язу эшенә битараф булмаган егет көннән-көн иҗат эшенә тартыла. Язучы дуслары Ш. Бикчурин, Ә. Галиев, Ф. Садриев, И. Әхмәдиев һәм тагын бүтән каләмдәшләренең киңәшләрен тотып, ул дингез тормышы турында, көндәлекләренә нигезләнеп, күләмле әсәр яза башлый. Байтак еллар иҗат газаплары кичергәч, ниһаять ул роман рәвешен алып, "Ялгыш язмышлар" исеме белән 2001 елны "Матбугат йорты" нәшриятында басылып чыга. Бу әсәр аны чыннан да язучы итеп таныта да. Каләмдәшләре әсәрне унай бәялиләр. Мәсәлән, Ф. Садриев болай дип яза: "Әсәр тормышның үзе, берни арттырылмаган. Бернинди фальш юк... Иң мөһиме – автор Булат Гәрәев персонажы аша кыю йөрәкле, туры сүзле, үзенең иманына, милләтенә тугры, максатчан чын татар егете образын тудыра алган".

2008 елның гыйнварында Г. Афзал, Н. Әхмәдиев, Ф. Садриев тәкъдимнамәләре нигезендә Кабул итү коллегиясе һәм Идарә Әхәт Хәбибуллинны Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алу турында карар чыгарды.

# ФӘЛСӘФИ РУХЛЫ ӘДИП

## Диас Вәлиевкә 70 яшь

1970 еллар драматургиясендә Диас Вәлиев исеме аерым бер урын алып тора. Әдәби эшчәнлеген чәчмә әсәрләр язудан башласа да, бераздан драматургия жанрына күчә һәм бу өлкә аңа танылу алып килә.

1938 елда Арча районы Казанбаш авылында туып, урта мәктәпне Казанда тәмамлаган егет университетның геология факультетына укырга керә, университеттан соң Себердә өч ел геолог булып эшләгәч, 1965 елда Казанга кайта. Бераз вакыт геологик оешмаларда эшләгәннән соң ул үзенең хезмәт биографиясенең яңа сәхифәсен башлый— "Комсомолец Татарии" газетасында әдәби хезмәткәр вазифасын башкара, бер үк вакытта иҗат эше белән дә шөгыльләнә, тумыштан килгән сәләт, тормышны танып белүе аны тиз арада әдәбият дөньясына алып керә. Билгеле, әдәбият өлкәсендәге хезмәт әдәби белем таләп итә, 1973-1975 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларда укый.



Диас Вәлиев матбугатта тәүге тапкыр 1959 елда "Карта старика" исемле хикәясе белән күренә, Казан, Мәскәү журналларында төрле хикәяләре, пьесалары басыла башлый. Беренче китабы исә 1970 еллар башында дөнья күрә, Казанда, Мәскәүнең "Современник" нәшриятында "Картлар, ирләр, малайлар" («Старики, мужчины, мальчики») исемле повестен һәм хикәяләрен туплаган китабы чыга.

Ул елларда Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында "Намус хөкеме" әсәре зур уңыш белән барса, Мәскәүнең Ермолова театрында "Дәвам" ("Сиңа тормыш бүләк итәм"), "Диалоглар" исемле спектакльләре куела, пьесалары буенча эшләнгән радиоспектакльләр Бөтенсоюз радиосыннан тапшырыла, үзәк телевидениедән телевизион фильмнар күрсәтелә, "Казанның елга аръягы күрәзәчесе" ("Пророк из Казанского заречья"), "Казан университеты" пьесалары илебезнең төрле театрларында сәхнәләштерелә. "Дәвам" ("Сиңа тормыш бүләк итәм") пьесасы өчен 1976 елда Д. Вәлиев республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Диас Вәлиевнең әсәрләре фәлсәфи тирәнлеге, тормыштагы мөһим проблемаларны күрә, аларны сәнгати югарылыкта яктырта белүе белән аерылып тора. Драматургны бигрәк тә тормышның язылмаган кануннары, кешеләр арасындагы дини—әхлакый кагыйдәләрнең бозылуы борчый.

Шул ук Камал театры Д. Вәлиевнең "Үзеңә хыянәт итсәң" (1975) һәм "Диалоглар" (1976) драмаларын да сәхнәләштерә, әлеге әсәрләр 1982 елда аерым китап булып та басылып чыга. Драматургның Җәлил һәм аның көрәштәшләренә багышланган "Билгесез көн" ("День икс") исемле әсәрен дә укучылар яратып кабул итә.

Д. Вәлиев рус телендә иҗат итсә дә, татар әдәбиятын рус укучыларына җиткерү буенча да актив эш алып бара, көндәлек матбугатта әдәбият-сәнгатькә караган язмалары белән еш катнаша. 1984 елда аның тәрҗемәсендә Г. Коләхметовның "Ике фикер" һәм "Яшь гомер" исемле пьесалары рус телендә дөнья күрә. Соңгы елларда Д. Вәлиевнең ("Три похода в вечность", 1990) исемле эсселәр җыентыгы, "Өченче кеше яки Фәрештә" ("Третий человек, или Небожитель, 1994), "Мин" ("Я", 1999) романнары укучыларга барып иреште.

Д. Вәлиев—1973 елдан СССР Язучылар союзы члены.

# ҮҖӘТ МӨХӘРРИР

*Юк.*
*Артыгын бер дә сорамыйм мин—*
*Бары күңелемә тимәгез.*
*Мин шигырьдә эшче.*
*Эш хакымны*
*Тик ярату белән түләгез.*

"Җыр тәме"

Әлеге шигъри юлларны бик еракта яшәүче берәр гыйлем иясенә бирсәң, Марс Шабаевны монарчы күреп тә, укып та белмәгән килеш, ул шагыйрьнең иҗади һәм шәхси портретын бик җинел генә сурәтләп әйтә алыр иде... Сүзен: "Юк!"—дип башладымы—димәк ул үз заманы, чордашлары белән һәрдаим бәхәстә. "Күңелемә тимәгез" дигәне—аның каты куллы, әмма тиз үпкәләүчән икәнлегенә ишарә. Шигырьдә эшче булуы—профессиональ каләм иясе дип аңлашыла. Ярату белән түләү өметләнгән шагыйрь үзе дә тормышка гашыйк кеше булыр...



Шагыйрь йә акылы, йә таланты белән яраттыра. Иплелеге, кыюлыгы, эшчәнлеге, ягымлылыгы өчен дә яратып була аларны. Шагыйрьнең холкын аның иҗатыннан эзлибез.

Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Марс Шабаев—үзе бер планета. Аның тирәсендә иярченнәре булып авторлар йөреп торыр иде. Ул күзәтүчәнлеге белән фикерле, кирелеге белән хаклы, усаллыгы белән якын, кем әйтмешли, ямьсезлеге белән сөйкемле кеше иде. Бүгенге татар поэзиясен әйдәп баручы исәннәр, заманында Марс Шабаевны үзләренең остазлары итеп, җае тигәндә трибуналардан әйтергә яраталар иде. Ә инде Татарстан радиокомитетында әдәби-драматик тапшырулар редакторы, "Яшь ленинчы" газетасының әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире, "Азат хатын" журналының җаваплы секретаре, "Чаян"ның тәржемәчесе, Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире, "Казан утлары"ның бүлек мөхәррире булып эшләгән шагыйрь Марс Шабаевның иҗади сиземләвен хөрмәт итеп шунысын да әйтергә кирәк, ул: "шигырьләрең әйбәт!"—дигән яшьләр күптән инде Халык шагыйрьләре булды. "Юк синдә, вакыт әрәм итеп, бушка кәгазь туздырып йөрмә!"—дигәннәре әле бүген дә булса яшь язучылар исемлегендә.

Табигать үзенең хозурлыгын-гүзәллеген: урман-тауларны, елга-күлләрне авылларга тигезләп өләшмәгән. Иҗат кешеләрен дә шулай ук...

Күрше Актаныш төбәгендә сабыйлар, тәпи йөреп киткәнче, әвәл биергә өйрәнә дибез һәм ни хикмәттер, анда һәр ике хыялыйның берсе шигырь яза. Ә Марс Шабаев туып-үскән театраль Минзәлә каласында шагыйрь һәм язучылар биш мең кешегә берәү генә туры килә. Шулай булгач Марс Шабаев та туган як мохитен меңнәр

күзе белән күзәтергә, сокланырга, нәүмизләр өчен язып калдырырга тиеш. Әгәр шагыйрьнең иҗатын шартлыча икегә аерып үлчәү тәлинкәсенә салсан—туган як табигатенә багышланган шигырьләре белән мәхәббәт лирикасы тигезләшер кебек. Марс Шабаев зәңгәр Ыкны күрше районнар белән бүлешми, ул аны шигырь саен бөтенләйгә һәм бары тик Минзәләнеке генә итәргә омтыла, ахыр чиктә "Салда сәяхәт" дигән повесть белән укучылар күнеленә беркетеп куя, җырга сала. Шагыйрьнең дистәгә якын җыры бар, тик ул җырлар әле үзенең җырчыларын тапмаган, киләчәктә тыңлаучыга килеп ирешәсе сөенеч булып калсыннар. Шунысы нык сизелә: көй сорап туган ул шигырьләр нәкъ менә салда язылганнардыр кебек. Марс Шабаев җыр текстларын тиражлау белән мавыкмый, ул чаманы белә—әйбәт шагыйрьнең җырлары күп булмас...

Әдәбият кырына шау-шуларсыз, ыгы-зыгы тудырмыйча гына килеп кергән һәм егерме биш ел буе иҗади алмаш тәрбияләгән Марс Шабаев тынгысыз поэзия мәйданын калдырып, тыныч кына китеп бара—үзе исән чагында ук канатлырак, өметлерәк, бәдәнлерәк көрәшчеләргә юл бирә.

*Кыска төннәреңә алмаш булып*
*Йокысызлар килер,*
*Озыннар...*
*Язмышыңны куркып көтеп ятма,*
*Язмышыңа каршы үзең бар.*
"Кеше булып"

90 еллар башында тотрыклы яшәешебезгә ашкынып килеп кергән "Дөнья базары" күп кенә иҗат шәхесләренең өметен өзде, күңел төшенкелегенә дучар итте. Үткен карашлы, кыю каләмле Марс Шабаев тулысынча тәрҗемә эшенә кереште. Америка шагыйре Уолт Уитменның шигырьләрен татарча яңгыратучы ул. Казакъ һәм каракалпак шагыйрьләрен дә тәрҗемә итте. Мәскәүдә яшәп рус телендә иҗат итүче Рауль Мирхәйдәровның романнары Казанда күпләп татарча басыла икән—монда да Марс Шабаевның тырышлыгы бәхәссез.

Аның архивы өйрәнелмәгән әле, аларны актарганда бик күп каләмдәш дусларның рәхмәтле хатлары өскә чыгар. Кырыс, әмма мәрхәмәтле остазны олылау хатлары булыр алар. Җитмеш дүрт яшькәчә яшәп тә үз гомерендә түрәләргә баш имәгән, ялагайланмаган, акны—ак, караны—кара дип дус-дошманына әйтә алган, хакыйкать хакына бик күп авыр сүз ишеткән үҗәт шагыйрьне дә яратып һәм сагынып була икән ул.

**Камил КӘРИМОВ**

## Бәян Гыйззәтнең тууына 90 ел

Танылган әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Бәян Гыйззәт (Фәтхелбәян Нургаян улы Гыйззәтуллин) 1918 елның 16 июлендә Башкортстанның Кушнаренко районы Талбазы авылында туган. Авыл мәктәбенең алтынчы классын һәм Уфада медицина рабфагын тәмамлагач, ул Казан дәүләт педагогия институтының филология бүлегенә укырга керә. 1941 елда укуын уңышлы тәмамлый һәм аны аспирантурада калдыралар. Ләкин Бөек Ватан сугышы башланып китә һәм ул шул елның декабрь аенда армиягә алынып, сугыш елларында Көнбатыш, Белоруссия фронтларында барган сугышларда катнаша.

Сугыштан соң, Б. Гыйззәт Татар дәүләт академия театрына әдәби бүлек мөдире булып эшкә керә. Шул ук елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан Тел, әдәбият һәм тарих институты аспирантурасында да укый һәм 1951 елда «Гафур Коләхметовның иҗаты» дигән темага диссертация яклап, филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала. 1953 елдан башлап ул—Тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән гыйльми хезмәткәре, ә 1968-81 елларда сәнгать бүлеге мөдире булып эшли.

Бәян Гыйззәтнең әдәби-фәнни эшчәнлеге тулысынча диярлек татар драматургиясе һәм татар театр сәнгате белән бәйле. Аның драматургия һәм театрга кагылышлы тикшеренүләре «Егерменче йөз башында татар әдәбияты» (1954), «Татар совет әдәбияты тарихы» (1960), «Заман сулышын тоеп» (1967), «Татар совет театры» (1975), Мәскәүдә рус телендә чыккан «История татарской советской литературы» (1965), «История многонациональной советской литературы» (1972) исемле китапларда урын алган. Таҗи Гыйззәт иҗатын яктырткан монографиясе 1957 елда аерым китап булып басылып чыга. Мәскәүдә Сәнгатьләр тарихы институтында әзерләнгән «История советского драматического театра» исемле алты томлык коллектив хезмәттә дә ул, авторларның берсе һәм редколлегия члены буларак, татар театрының үсеш этапларын яктырткан фәнни очерклары белән катнаша.

Болардан тыш, Б. Гыйззәтнең драматургия һәм театр сәнгате турындагы мәкалә һәм очерклары төрле җыентыкларда, әдәбият һәм театрга бәйле белешмә-энциклопедияләрдә, көндәлек матбугат битләрендә күпләп басылган. Г. Камал, Г. Коләхметов, Г. Кариев, К. Тинчурин, М. Фәйзи, Х. Әбҗәлилов, Г. Кутуй, Һ. Такташ, Г. Насрый һ. б. бик күпләргә багышланган иҗади портретлар, аерым әсәр яки спектакльләр турында рецензияләр, тәнкыйть мәкаләләре—болар һәммәсе дә Бәян Гыйззәтнең, галим һәм тәнкыйтьче буларак, иҗади активлыгы һәм колачы турында сөйлиләр.

Б. Гыйззәт 1957 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

Ул 1991 елның 26 маенда Казанда вафат булды.



Татар генераллары бергә җыелгач (араларында безнең язучылар һәм журналистлар да бар). Мәскәү. 1993 ел.



Чыңгыз Айтматов Казанда еш була иде... Моннан 36 ел элек, 1972 елда алынган рәсем. Сулдан уңга: Чыңгыз Айтматов, Рәшит Гарипов, Гариф Ахунов.



*Марс Шабаев һәм Габделхәй Сабитов Ык елгасында. 1967 ел.*



*Җиргә басып йөрүләргә ни җитә! Илдар Юзеев (сулда) һәм Шаһинур Мостафин. 1998 ел.*



*Кемнәр бар да, кемнәр юк...*
*Әлмәттә яшәп иҗат иткән язучылардан бер төркем. Уңнан сулга: Әхәт Гаффар, Гамил Афзал, Рафаил Төхфәтуллин, Әдип Маликов, Роберт Рәкыйпов. 1985 ел.*

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## БЕЗ ҖИҢДЕК!

***

Казан биш елдан үзендә җәйге Бөтендөнья студентлар уеннарын кабул итү хокукын яулады. Универсиада өчен көрәшкән Испаниянең Виго һәм Кореяның Гван-Джу шәһәрләрен артта калдырып, Казан 27 мөмкинлектән 20 тавыш җыя алды. 31 май. Кичке сәгать 10. Дулкынландыргыч мизгелләр: FISU президенты Джордж Киллиан конвертны ачты һәм 2013 елгы җәйге Универсиаданың башкаласы итеп Казанны игълан итте. Брюссельгә Россия һәм Татарстан делегациясе булып ТР Премьер-министры Рөстәм Миннеханов, Казан мэры Илсур Метшин, ТР Яшьләр һәм спорт министры Марат Бариев белән бергә, олимпия чемпионнары—Алинә Кабаева, Елена Кисилева, Ирина Роднина, Николай Гуляев, Ильгар Мамедов, Россиянең теннис Федерациясенең баш тренеры Шамил Тарпищев, Дәүләт Думасының вице-спикеры Олег Морозов та килгән иде. Бер мизгелдә барысы берьюлы: "Без җиндек!!!"—дип, бөтен дөньяга белдерделәр.

ТР Премьер-министры Рөстәм Миннеханов FISU вәкилләренә рәхмәтен җиткереп, аларны 2013 елда үтәчәк җәйге Универсиадага чакырды: "Универсиада студентлар тарихында иң яхшысы булачак",—диде ул.

Казанда хәзер яңа спорт тормышы башланып китәчәк. Яңа спорт корылмалары барлыкка киләчәк. Яңа үзәк стадион, Су спорты үзәге, яңа Футбол стадионы, яңа кунакханәләр—биш ел эчендә болар барысы да булыр дип ышанабыз.

***

«Казан» халыкара аэропортында Брюссельдан җиңү яулап кайткан Татарстан делегациясен каршы алырга килгән Минтимер Шәймиевнең беренче сүзе «Ура!» булды. «Кадерле дуслар, бүгеннән без, татарстанлылар, 2013 елгы Универсиада хуҗалары һәм мин сезне шушының белән котлыйм. Бу—зур вакыйга һәм тарихыбызда мона охшаш хәлләрнең булганы юк иде әле. Казан үзенең икенче меңъеллыгын Бөтендөнья студентлар уеннарын үткәрүдән башлый һәм бу бик шәп»,—дип билгеләп үтте Президент сәламләү сүзендә. «Безгә җиңү җиңел бирелмәде, әмма республика җитәкчелеге һәм бөтен командабыз, студентларыбыз ярдәмендә без шушы җиңүгә ирештек. Без Казанның 1000 еллык тарихында тәүге мәртәбә бөтен дөньяны кунак итәчәкбез. Бу—җаваплылык, безгә җитди эшләргә туры киләчәк, һәм без мона әзер»,—дип белдерде Илсур Метшин. Рәсми өлештән соң Татарстан делегациясен каршы алган яшьләр өчен—концерт, ә журналистлар өчен уртак җиңүнең баш каһарманнары белән матбугат конференциясе оештырылды.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ XVI КОРЫЛТАЕ

23 майда "Казан" милли мәдәният үзәгендә Татарстан язучыларының XVI корылтае булып узды. Олы җыенны кереш сүз белән Татарстанның халык язучысы, күренекле драматург Туфан Миңнуллин ачты:

- Чираттагы корылтаебызга заманның үтә киеренке вакытында җыйналдык,—диде ул.—Россиянең милли яшәешебезгә янә сырты белән борылган чагы. Милли мәгариф һәм матбугатыбызга чираттагы куркыныч яный. Безне тагын җитди сынаулар көтә... Без—югалтулар булса да сынмаган халык. Безнең язмыш гел көрәштән генә тора. Без бер мәсьәләдә бердәм: һәммә татар язучысы гамендә—татар язмышы. Шуннан да изгерәк максатыбыз юк һәм булмас та! Әйдәгез, шушы рухта берләшик, бердәм көрәшкә сәләтле икәнлегебезне күрсәтик!

Аннары делегатлар һәм кунаклар ике корылтай арасында арабыздан киткән 24 каләмдәшне бер минут тынлык белән искә алды.

Корылтайның эшче президиумында—Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев, Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова, Россия Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары Геннадий Иванов, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Илфак Ибраһимов, Татарстанның халык язучылары—Дәүләт Советы депутаты Туфан Миңнуллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рабит Батулла, Татарстанның халык шагыйрьләре Шәүкәт Галиев, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Дәүләт Советы депутаты Роберт Миңнуллин, шагыйрь, Дәүләт Советы депутаты Разил Вәлиев, "Рухият" фондының башкаручы директоры Флера Шәйхетдинова һ.б.

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең ике корылтай арасындагы эшчәнлеге

турында хисап доклады белән идарә рәисе Илфак Ибраһимов чыкты. Ул үз чыгышында соңгы 3 елда үткәрелгән күпкырлы оештыру чаралары хакында бәян итте, шушы чордагы әдәби хәрәкәткә кыскача анализ ясады, төрле жанрлардагы аерым уңышлы әсәрләрне бәяләп узды, әдәби тәрҗемә эшен җайга салу, милләтара әдәби багланышларны ныгыту, язучыларның иҗади һәм көнкүреш шартларын яхшырту, китап сәүдәсен җанландыру буенча көнүзәк мәсьәләләргә басым ясады, шулай ук каләм әһелләре алдында торган күп кенә мәсьәләләрне чишүдә республика җитәкчелегенең һәрдаим булышлык күрсәтүен билгеләп үтте.

—Узып киткән 3 ел,—дип ассызыклады ул,—республика һәм бөтен халкыбыз тормышында үтә әһәмиятле вакыйгаларга бай булды: башкалабыз Казанга һәм Алабуга каласына нигез салынуга 1000 ел тулуны билгеләп үтү, Татарстанда Әдәбият һәм сәнгать елы, Хәйрия елы кысаларында Г. Тукай, М. Гафури, Акмулла, М. Җәлил, Г. Ибраһимов, К. Тинчурин һ. б. бик күп шәхесләребезнең юбилейларына мөнәсәбәтле дистәләрчә-йөзләрчә әдәби-мәдәни чараларның бөтен Евразия киңлекләрендә үткәрелүе халыкны берләштерүгә, аның милли үзаңын үстерүгә әйтеп бетергесез тәэсирле йогынты ясады.

Ревизия комиссиясе хисабын аның рәисе Фарсель Зыятдинов ясады.

Корылтайда фикер алышуларда беренче булып чыгыш ясап, Татарстанның халык шагыйре, "Казан утлары" журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин болай диде:

—Әдәбиятның җәмгыятьтәге дәрәҗәсе түбәнәйде. Шул нисбәттән аның тәрбияви роле дә кимеде. Язучы үзе социаль яклауга мохтаҗ категориягә әйләнде. Дөнья масштабында караганда, мондый хәл һәр җирдә дә алай түгелдер, әмма Россия һәм элекке СССРның күпчелек дәүләтләрендә ул шулай. Язучының матди хәле, классиканың укылмавы, тиражлар кимү... Иң авыры—киләчәккә ышанычның кимүе.

Язучылык хезмәте турыдан-туры халыкның тарихы, гореф-гадәтләре, теле, моңы, гомумән, рухи дөньясы белән, матди байлыктан бигрәк, ата-бабалар мирас итеп калдырган рухи байлык белән бәйле. Безнең миссия—әнә шул байлыкны мөмкин кадәр арттыру, үстерү, үз халкыңны бүтән халыклар арасында ким итмәү...

Пленар утырышта, шулай ук, халкыбызның рухи яшәешендәге актуаль мәсьәләләр хакында Талгат Галиуллин (Казан), Фоат Садриев чыгыш ясады.

Алда әйтелгәнчә, корылтай эшендә Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев катнашты һәм чыгыш ясады, язучыларның сорауларына җавап бирде. Илбаш үз чыгышында иң әүвәл көнүзәк мәсьәләләргә, шул исәптән әдипләрне нәкъ менә бүген борчыган проблемаларга басым ясады. Аерым алганда, милли-төбәк компоненты, татар-төрек лицейлары тирәсендәге ыгы-зыгы турында үз фикерләрен әйтте, мәктәпләрдә укытыла торган татар әдәбияты дәреслекләренең заман таләпләренә җавап бирмәвен ассызыклады:

—Безнең республика—сәясәт өлкәсендә булсын, икътисад өлкәсендә булсын—нык алга киткән төбәк,—диде ул,—һәр тармакта тотрыклы үсеш күзәтелә. Мәктәпләр, китапханәләр, спорт корылмалары төзибез. Моңа ничек сөенмисең ди?!

Президент Минтимер Шәймиев сүзләренчә, мондый уңай үзгәрешләр, күпме генә теләсәк тә, мәдәният өлкәсенә дә кагыла, дип әйтеп булмый шул әле. Бу килеп туган проблемаларны кемдер хәл итәргә теләмәгәннән түгел, юк. "Без аларны хәл итүнең юлларын күп очракта таба алмыйбыз әле",—дип ачыктан-ачык белдерде ул. Әйтик, рәссамнар, музыкантлар, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры, эстрада җырчылары һ.б. хәзерге заман базар таләпләренә җиңелрәк, тизрәк җайлашып алган булса, әдипләр белән хәл катлаулырак тора. "Еш кына шундый сүзләр ишетәсең: акча бирсәгез, һәммәсе дә яхшы булачак, янәсе. Юк, алай гына түгел ул,—диде Минтимер Шәймиев.—Совет заманында китаплар күп басылды, аларны укучы да күп иде. Тик телне югалта бардык. Элегрәк җәмәгать урыннарында үз телебездә сөйләшергә оялган булсалар, бүген моннан зарланырлык түгел инде. Тик безгә тынычланырга иртә әле. Татар телен үстерү максатларына шактый күләмдә акча бүленә. Ләкин хикмәт монда гына түгел, күрәсең. Телне ничек саклап калырга, дигән сорауга мин дә төгәл генә җавап бирә алмыйм. Бер нәрсәне инанып әйтәм: татар телен иң әүвәл һәр татар гаиләсе сакларга тиеш. Баланы кечкенәдән өйрәтмибез икән, татар телен саклагыз, дип, Президент көн саен фәрман чыгарып утырса да, файдасы булмас".

Президент чыгышында шулай ук тәрҗемәчеләр әзерләү, китап бастыру һәм сату, мәктәпләрне оптимальләштерү мәсьәләләре дә күтәрелде.

Президент Минтимер Шәймиев язучы Мөсәгыйт Хәбибуллинга татар әдәбиятын үстерүдәге зур казанышлары өчен "Татарстан Республикасының халык язучысы", язучы Борис Вайнерга "Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе" билгеләрен тапшырды.

Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева язучы Зиннур Хөснияргә—ТР Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге бүләген, язучы Әхәт Гаффарга—Ф. Хөсни исемендәге бүләкне, шагыйрь Шамил Маннаповка—Һ. Такташ исемендәге бүләкне, галим Әнвәр Хәйригә—Ж. Вәлиди исемендәге бүләкне тапшырды. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова корылтай утырышында

катнашучыларны сәламләде һәм язучылар Фәүзия Бәйрәмова, Салават Юзеев, Вакыйф Нуриев, шагыйрь Рәфикъ Юнысов, драматург Данил Салиховка ТР Дәүләт Советының Рәхмәт хатын тапшырды. Корылтайда шулай ук бер төркем каләм әһеленә ТР Мәдәният министрлыгы, Мәгариф һәм фән министрлыгы, Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының, Бөтендөнья татар конгрессының Рәхмәт хатлары тапшырылды.

"Казан утлары"ның баш мөхәррире Равил Фәйзуллин журналда ике ел дәвамында "Яңа дәвер кешесе" дигән конкурста җиңгән язучыларга дипломнар һәм акчалата бүләкләр тапшырды. Җиңүчеләр арасында Рифә Рахман, Рәмзия Габделхакова, Радик Фәизов, Марат Әмирхан h. б. бар иде.

Әдәби жанрлар буенча Зиннур Мансуров (шигърият), Зиннур Хөснияр (проза), Рафис Корбан (балалар әдәбияты), Айдар Хәлим (публицистика), Мансур Вәлиев (әдәби тәнкыйть), Әлфәт Закирҗанов (драматургия), Лилия Газизова (рус телле әдәбият) махсус докладлар белән чыкты.

Докладлар буенча фикер алышуда язучылар Рабит Батулла, Нәбирә Гыйматдинова, шагыйрьләр Ирек Сабиров (Чиләбе), Ркаил Зәйдулла, Нәҗибә Сафина, Лена Шагыйрьҗан, Газинур Морат, драматург Рәдиф Сәгъди катнашты. Алар үз чыгышларында иҗтимагый тормышта әдәбиятның, һәрбер каләм әһеленең, иҗат оешмасының ролен күтәрү, китап бастыру һәм аны тарату, авторларга гонорар түләү, күренекле әсәрләрне дөньяга тагын да киңрәк таныту, язучылык хезмәтен закон тәртибендә яклау h. б. мөһим мәсьәләләр буенча уй-теләкләрен белдерделәр.

Фикер алышу барышында әйтелгән эшлекле тәкъдимнәр нигезендә корылтай резолюция кабул итте.

Корылтай утырышларын шагыйрьләр Роберт Миңнуллин, Равил Фәйзуллин, Разил Вәлиев алып барды.

Олы җыенда шулай ук Язучылар берлегенең Уставы яңа редакциядә кабул ителде.

Корылтайда альтернатив нигездә зур күпчелек тавыш белән Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе итеп кабат Илфак Ибраһимов сайланды.

Корылтай делегатлары Язучылар берлеге идарәсенең яңа составын сайлады. Яшерен тавыш бирү юлы белән яңа идарәгә түбәндәге язучылар үтте: Туфан Миңнуллин, Разил Вәлиев, Равил Фәйзуллин, Роберт Миңнуллин, Гәрәй Рәхим, Зиннур Мансуров, Вакыйф Нуриев, Данил Салихов, Вахит Имамов, Лилия Газизова, Равил Рахмани, Искәндәр Гыйләҗев, Николай Алешков, Нәбирә Гыйматдинова, Рафис Корбан, Мөдәррис Вәлиев, Рамис Аймәт, Илсөяр Иксанова, Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Камил Кәримов, Ләбиб Лерон, Рөстәм Зәкуанов, Зиннур Хөснияр.

Язучылар корылтаенда шулай ук ревизия комиссиясе сайланды. *(Татарстан язучыларының XVI корылтае турында материаллар журналыбызның алдагы саннарының берсендә бирeләчәк.)*

## ЯЗУЧЫЛАР ПРЕЗИДЕНТ ХОЗУРЫНДА

Татарстан язучыларының XVI корылтае алдыннан Президент М. Шәймиев Кремльдәге резиденциясендә бер төркем каләм әһелләре белән очрашты. Очрашуда Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе И. Ибраһимов, Т. Миңнуллин, Р. Фәйзуллин, М. Хәбибуллин, Р. Вәлиев, Р. Миңнуллин, Р. Алешков, Б. Вайнер, Г. Морат, И. Иксанова, Л. Газизова, С. Юзеев, Р. Сәлах катнашты. Анда әдәбиятыбызга һәм, гомумән, рухиятебезгә кагылышлы көнүзәк мәсьәләләр турында сүз барды.

—Без иң авыр вакытларда Язучылар берлеген саклап кала алдык,—диде Президент.—Бу безнең ихтыяр көчебезнең ныклыгын күрсәтеп тора. Бүген берлекне ныгыту, аның эшчәнлеген камилләштерү өчен нәрсә эшләргә кирәк—шул турыда уйланырга тиешбез. Ә эшләгән эшләребез бар. Бүген Язучылар берлеге яшь иҗатчылар белән уңышлы эшли, күренекле әдипләрнең юбилейларын үткәреп килә. Әмма, миңа калса, бу гына аз, әдәби җәүһәрләребез киң катлам укучыларга барып ирешсен өчен безгә аеруча зур тырышлык куярга кирәк. Әдәби әсәрләрне укучыга җиткерү җәһәтеннән газета-журналлар, радио-телевидениенең дә өлеше зур. Бүгенге шартларда без дөрес юлдан барабыз, дип уйлыйм. Алга таба эшчәнлекне тагын да камилләштерергә кирәк.

Очрашуда Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева, Президентның эчке сәяси мәсьәләләр буенча идарә башлыгы А. Терентьев, "Татмедиа" ачык акционерлар җәмгыятенең директорлар советы рәисе М. Моратов катнашты.

## БЕРЕНЧЕ УТЫРЫШ

Татарстан язучыларының XVI съездында сайланган яңа идарәнең беренче утырышы булды. Аны Татарстан Язучылар берлегенең янадан сайлап куелган рәисе Илфак Ибраһимов алып барды. Утырышта катнашучылар Татарстан язучыларының XVI съездының оешкан төстә, эшлекле узуын билгеләп үттеләр, анда күтәрелгән мөһим мәсьәләләрнең, файдалы тәкъдимкиңәшләрнең даими игътибар үзәгендә булырга тиешлеген искәрттеләр.

Утырышта оештыру мәсьәләләре каралды. Яңа идарәнең җиде кешедән торган президиумы сайланды (Илфак Ибраһимов, Туфан Миңнуллин, Равил Фәйзуллин, Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин, Вакыйф Нуриев, Искәндәр Гыйләҗев). Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасарлары вазыйфаларына янадан Вакыйф Нуриев,

Лилия Имаева, берлекнен Чаллы бүлеге җаваплы сәркатибе итеп Вахит Имамов, Әлмәт бүлегенә Данил Салихов расланды. Татарстан Язучылар берлегенә Кабул итү коллегиясе рәисе итеп яңадан Равил Фәйзуллин, әдәби консультант Луиза Янсуар, иҗат остаханәләренең җитәкчеләре итеп Камил Кәримов (проза), Зиннур Мансуров (шигърият), Ркаил Зәйдулла (драматургия), Равил Рахмани (әдәби тәнкыйть), Рафис Корбан (балалар әдәбияты), Газинур Морат (публицистика), Лилия Газизова (рус әдәбияты һәм тәрҗемә) тәгаенләнде.

Утырышта прозаик Рөстәм Сабиров, шагыйрь Геннадий Капранов *(үлгәннән соң)* Г. Державин исемендәге әдәби премиягә тәкъдим ителде.

## МИРАСЫБЫЗНЫ БАРЛАП

Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты ТР Министрлар Кабинеты белән берлектә Казанда татар тарихы үсешенә һәм тел фәненә зур өлеш керткән күренекле фикер иясе, дин эшлеклесе, мәгърифәтче галим-энциклопедист Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 190 ел тулуга багышлап «Шиһабетдин Мәрҗани: мирасы һәм хәзерге заман» дигән Халыкара фәнни конференция уздырды. Конференциядә катнашучылар тарафыннан бертавыштан кабул ителгән резолюция текстында болай диелә:

1. Ш. Мәрҗанинең иҗади мирасын өйрәнү буенча махсус фәнни-тикшеренү төркемен булдыру. Төркемнең максаты—татар галименең хезмәтләрен бастырып чыгаруга әзерлек эшләре белән шөгыльләнү.

2. Ш. Мәрҗани исәлегенә ел саен Евразия киңлегендә ислам дине мәсьәләләренә багышланган укулар оештыру.

3. Ш. Мәрҗани яшәгән йортта музей ясау (Казан шәһәрендә).

4. ТР Министрлар Кабинетының 1998 елның 30 сентябрендәге «1998—2001 елларда Татарстан Республикасында мәдәният үсеше республика программасын раслау турында»гы 586 нчы карарын гамәлгә ашыру (19 нчы пункты—Ш. Мәрҗанигә һәйкәл проектын әзерләү һәм төзү турында).

5. ТР Мәдәният министрлыгына тарихи ядкарьләрне торгызу планына кертергә тәкъдим итәргә:

а) ТРның Арча районы Ташкичү авылындагы тарихи мәчетне төзекләндерү;

б) ТРның Әтнә районы Ябынчы авылында Ш. Мәрҗани белем бәйле тарихи корылмаларны;

в) ТРның Әтнә районы Комыргуҗа урта мәктәбендә Ш. Мәрҗани мәктәп музеен финанслау мөмкинлеге табу.

## ТӨРЕК КАРДӘШЛӘР БЕЛӘН ОЧРАШУ

Быел Россиядә Төркия елы билгеләп үтелә. Ул апрель аенда Мәскәүдә Төркия мәдәнияте фестивале белән башланып китте. Ә 22 майда "Пирамида" мәдәни-күңел ачу үзәгендә "TURK DUNYASI" дәүләт музыка төркеменең концерты белән Татарстанда Төркия көннәре старт алды.

"TURK DUNYASI" төркеме—борынгы чорларда иҗат ителгән милли музыканы ноталаштыру, аудио, видео-тәлинкәләргә яздыру, концертларда башкару аша саклау, популярлаштыру максатыннан моннан 8 ел элек Төркия Мәдәният һәм туризм министрлыгы каршында оешкан коллектив. Музыкантлар көйләр башкарып кына калмый, юкка чыгып торган бик борынгы музыка уен коралларын торгызу белән дә шөгыльләнә. Коллектив репертуарында төрек музыкасыннан тыш, бөтен төрки халыкларның музыка әсәрләре, шул исәптән татар җырлары да бар.

Концертны Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева да тамаша кылды. Ул Төркиянең Казандагы генераль консулы Әхмәт Эргинга мәдәни мирасны саклаудагы зур тырышлыгы өчен махсус диплом тапшырды.

Татарстанда Төркия көннәре кысаларында Казанда күп кенә чаралар үткәрү каралган. Июнь аенда аларның байтагы үтте дә инде. Көзгә кергәч, 6-16 октябрьдә Казан кино сөючеләре игътибарына төрек кинофильмнары тәкъдим ителәчәк. Ә 9 октябрьдә төрек пианисты Гөлсин Онай башкаруында классик музыка тыңларга мөмкин булачак.

## МУЗЕЙЛАР ХАЛЫКАРА ОЕШМАЛАРГА "ЧЫГА"

9 июньдә "Казан" милли-мәдәният үзәгендә ТР Мәдәният министрлыгы белән Халыкара музейлар советы арасында килешүгә кул куелды.

Республика музейларының йогынтылы халыкара оешмалар белән хезмәттәшлеген күздә тотучы әлеге документка ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева һәм Халыкара шәһәрләр музейлары комитеты президенты Галина Ведерникова кул куйды.

"Халыкара шәһәрләр музейлары комитеты—ЮНЕСКО каршындагы иң абруйлы консультация оешмаларының берсе. Утырышның Казанда үткәрелүе республика музейларының абруен тану турында сөйли һәм безгә дөньякүләм тәҗрибәдән файдалану мөмкинлеге бирә",—дип ассызыклады Зилә Вәлиева, журналистлар сорауларына җавап биреп.

Бүген Татарстан музейлары өчен дөньякүләм тәҗрибәгә таянып эш итү—бик мөһим мәсьәлә. Моны республика музейларында булган башкалабыз кунаклары да таный. "Утырышта катнашучылар күп кенә музейларыбызның дөньякүләм әһәмияткә ия булуын искәртә. Шуңа күрә безгә аларның инфраструктурасын үстерү буенча зур эш башкарырга туры киләчәк",—диде З. Вәлиева.

Аның фикеренчә, хәзер музейларыбыз өчен эшнең асылын үзгәртү һәм заман-

ча технологиялардән файдалану мөһим. "Безнең музейлар күз алдында борынгы әйберләрне саклау урыннарыннан мәдәниагарту учреждениеләренә әйләнә. Ә бу яңа эш тәҗрибәсенең пайда булуын, фәнни тикшеренүләрнең дәвам иттерелүен, интерактив ысуллардан файдаланыла башлавын күрсәтә",—дип искәртте мәдәният министры.

### ПУШКИН ҺӘРЧАК ХӘТЕРДӘ

Һәр елның 6 июнендә поэзия сөючеләр бөек рус шагыйре А. С. Пушкинны искә алалар. Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева татарстанлыларны Шигырь бәйрәме белән тәбрикләде. «Пушкин поэзиясе үз ватанына, халкына мәхәббәт белән сугарылган. Ул татар әдәбияты үсешенә дә йогынты ясаган. Бөек шагыйребез Г. Тукай халкыбызга Пушкин шигъриятенең хозурлыгын ачып бирде. Тикмәгә генә ул иҗат иткән чорны поэзиянең алтын гасыры дип атамыйлар. Безгә А. С Пушкин белән бәйле урыннар кадерле. Казанга ул үзенең тарихи романын язар алдыннан килгән. Мәскәү урамында ул К. Фукс белән очрашкан йорт бар»,—диде.

Башкалабызда шагыйрь һәйкәле янында узган Шигырь бәйрәмендә В. Нуриев, Л. Газизова, Л. Шагыйрьҗан, Б. Вайнер, А. Әпсәләмова, А. Каримовалар чыгыш ясадылар. Владимир Васильев, Ольга Кузмичева башкарган җырлар кичәне тагын да ямьләде. Артист Любовь Лукина А. С. Пушкин шигырьләрен кабат хәтердә яңартты.

### КИТАП ЯРАТУЧЫЛАР БӘЙРӘМЕ

ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева Бөтенроссия китапханәләр көне уңаеннан җөмһүриятебез халкына котлау юллады. "Бу бәйрәм—китап яратучы һәркемнеке,—диелгән анда.—Шул ук вакытта ул югары үсештәге җәмгыять төзү буенча дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда, бәһасез мәдәни һәм фәнни мирасны саклау һәм арттыруда иң мөһим тармакларның берсе булган китапханәләргә игътибарны җәлеп итү мөмкинлеген дә бирә.

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең Дәүләт Советына Юлламасында республика китапханәләр системасын заманча мәгълүмати технологияләр кулланып яңарту максат итеп куелды. Әлеге эш монарчы да алып барылды, әмма бүген китапханәләрне заманчалаштыруны тизләтү аеруча мөһим. Китап йортлары базасында әдәби музейлар, хокук һәм мәгариф үзәкләре, виртуаль уку заллары булдырыла. ТР Милли китапханәсендә хәзерге заман язучылары иҗатын популярлаштыруга юнәлтелгән "Зур уку" Россия -Америка проекты гамәлгә ашырыла.

Хөрмәтле китапханә хезмәткәрләре! Сез инде белемле һәм укымышлы берничә буын үстергән китапханәчеләрнең фидакяр хезмәтен дәвам итәсез. Бүген сезнең алда яңа зур максатлар тора. Аларны тормышка ашыру көн саен үзең дә укыганда һәм һөнәри яктан камилләшкәндә генә мөмкин. Игелекле хезмәтегез өчен ихлас рәхмәтемне кабул итегез. Сәламәт булыгыз, мул тормышта яшәгез, яңа иҗади уңышларга ирешегез",—диелә юлламада.

### ТАТАР БИЮЕ ҖИҢДЕ!

1-11 май көннәрендә Мәскәү шәһәренең Крокус үзәгендә Бөтендөнья олимпиадасы узган. Әлеге чарада 21 илдән барлыгы 10 мең кеше катнашкан. Олимпиада кысаларында халык биюләре бәйгесе дә үткән. Финалга чыгучылар арасында Татарстан кызы да бар. Мөслимдә яшәүче Айназ Ялалова Владивосток һәм Белоруссиядән килгән биючеләрдән аз гына калышып өченче урынга лаек булган.

***

Матбугатны, мәдәният һәм сәнгатьне үстерүдәге казанышлары өчен Балык Бистәсе районының "Авыл офыклары" газетасы редакциясе дәүләт учреждениесе баш мөхәррире **Фатыйхов Минневазыйх Хаҗип улына** "Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре" дигән мактаулы исем бирелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* *"Мәңгелек Кабан, мәңгелек Казан..."*


*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Әмир Камалиев**.

# Яңа китаплар




**Хәзерге татар әдәбияты.**—Казан: Мәгариф, 2008.—455 бит. Тиражы—1000 данә.

“Мәгариф” нәшрияты соңгы елларда “Балачак әдипләре” дип исемләнгән дүрт китап чыгарып, йөз егермеләп иҗатчы турында укучыларыбызга бай мәгълүмат биргән иде. Бу китапны шул сериянең дәвамы дип тә әйтеп була (дөрес, кайбер язучылар кабатлана). Бу хакта нәшрият директоры Мөдәррис Вәлиев үзенең кереш сүзендә болай яза: “Бу китапта без әлегә дәреслекләрдә үзләренә лаеклы урынны алып бетермәгән, әмма бүгенге әдәби тормышыбызда зур урын тоткан язучыларга игътибарны юнәлтергә ниятләдек.” Китапта 22 язучы турында шактый тәфсилле мәгълүмат бирелгән. “Гасырлар чиге татар әдәбияты” дигән баш астында галимнәребезнең проза, поэзия, драматургия турында язмалары, шулай ук, Равил Фәйзуллинның “Казан утлары” журналы турында аерым мәкаләсе урнаштырылган.




**Рәшит Гатауллин.** Сагышлы моңнар: шигырьләр (Төз. Рәдиф һәм Рәфит Гатауллиннар; кереш сүз авт.: Роберт Миңнуллин).—Казан: Татар. кит. нәшр., 2008.—223 бит. Тиражы—2000 данә.

“Сагышлы моңнар”—Башкортстанда яшәп иҗат иткән (1938—2008) татар шагыйре Рәшит Гатауллинның туган телдә чыккан беренче китабы. Узган гасырның 60нчы елларында шигърияткә килгән шагыйрьнең өч бүлектән (“Язмышым алларында”, “Онытылган дулкыннар”, “Кайтам әле”) торган бу китабына төрле елларда иҗат ителгән сайланма шигырьләре тупланган. “Мин тагын бер шагыйрь” дип исемләнгән кереш сүзне Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин язган. Китапның мөхәррире—Харрас Әюпов.



Әмир Камалиев

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)